ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ХУҖА БӘДИГЫЙ –
# ТЕЛ ГАЛИМЕ

Казан
2021

**УДК 811.512**
**ББК Ш 163.23**
**Х98**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)»
Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында
нәшер ителә

**Текстларны әзерләүче һәм төзүчеләр**
Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,
Мөхәммәтҗанова Динә Марсил кызы

Х98 **Хуҗа Бәдигый – тел галиме** / текстларны әзерләүче һәм төзүчеләр Э. Х. Кадирова, Д. М. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 252 б.
ISBN 978-5-93091-388-0

Җыентыкта күренекле тел галиме, фольклорчы, педагог Х. Бәдигыйнең татар теле белеменең төрле аспектларын яктырткан мәкаләләре туплап бирелде.

Китап татар теле белгечләренә, югары уку йорты студентлары һәм педагогларына, укытучыларга, Х. Бәдигыйнең фәнни-педагогик мирасы белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

УДК 811.512
ББК Ш 163.23

**ISBN 978-5-93091-388-0**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2021

# КҮПКЫРЛЫ ТАЛАНТ ИЯСЕ
*(КЕРЕШ)*

Галим һәм педагог Хуҗа Бәдигый (Бәдигов, Габделбәдигъ, Бәдигъ) татар тел белемен, фольклор фәнен, милли мәгарифебезне үстерүгә яңача карашлы, тирән фикерле теоретик хезмәтләре белән дә, унлаган дәреслекләр, методик кулланмалар, программалар авторы буларак та, халык иҗаты җәүһәрләрен авылдан авылга йөреп бөртекләп-берәмтекләп туплаучы, аларны гыйльми нигезгә салынган җыентыклар рәвешендә бастырып чыгаручы сыйфатында да, һәм, ниһаять, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, Каюм Насыйри исемендәге татар педтехникумы, Шәрык (Казан) педагогия институты кебек абруйлы уку йортларында утыз ел дәвамында татар теле һәм фольклоры укыткан мөгаллим, доцент, профессор вазифаларында да ифрат зур өлеш кертеп калдырды. Шәхси язмышында каты авыру, нахак репрессия газапларына дучар булса да, аның хезмәт эшчәнлеге безнең өчен чын иҗтиһад һәм фидакярлек үрнәге булып кала.

> «Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,
> Эшкә дәгъват итте безне кемдер изге нам белән», –

дип язды Тукай үзенең «Аң» шигырендә. Халыкка хезмәткә чакырган әнә шул изге авазны бөтен йөрәге белән кабул иткән ялкынлы яшь милләтпәрвәрләрнең берсе «Мөхәммәдия» шәкерте Хуҗа Бәдигый булды. Әле 1889 елда ук җәдит ысулына күчкән бу уку йорты 1905–1906 елларда алдынгы татар яшьләренең ислах-реформалар өчен көрәш үзәгенә әверелде. 1907 елның көзендә Казанда «Әлислах» газетасы чыга башлагач, Хуҗа Бәдигый фактик мөхәррире Фатих Әмирхан булган бу басманың актив хәбәрчесенә әверелә, «Мөгаллим» имзасы белән аңа мәдрәсәләр тормышын, шәкертләр хәрәкәтен яктырткан мәкаләләр яза. Соңрак шушы редакциядә ул беренче мәртәбә Габдулла Тукай белән очраша.

Гәрчә бер анкетага җавабында Х. Бәдигый үзенең фәнни эшчәнлеге башланган вакыт итеп 1912 елны күрсәтсә дә, ул инде

1907–1908 елларда ук сәләтле яшь галим һәм педагог буларак танылып өлгерә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе педагогик советының аны шушы мәшһүр уку йортында эшкә калдыруы да шул хакта сөйли. Әле берәр ел элек – 1906 елның көзендә – Казанга татар телен һәм фольклорын өйрәнү максаты белән венгр тюркологы Юлий Мессарош килгәч, аңа ярдәмче итеп Х. Бәдигыйне билгелиләр. Менә шушы фактны, һич арттырусыз, яшь галимнең фәнни эшчәнлегендә башлангыч адым дип санарга кирәк.

Халык иҗаты әсәрләрен җыюны, аларны жанрларга төркемләү эшен Х. Бәдигый Мессарош киткәч тә дәвам итә. 1912–1914 елларда галим «Мәкальләр», «Табышмаклар, такмаклар, такмазалар», «Бәетләр», «Җырлар» җыентыкларын бастырып өлгерә. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында бу эш бүленеп тора, басылмый калган хезмәтләре соңрак, янгын вакытында юкка чыгалар.

Х. Бәдигыйнең фольклористик хезмәтләрен Г. Ибраһимов югары бәяли, аны бу өлкәдә Каюм Насыйри эшчәнлеген лаеклы дәвам иттерүче дип атый, үзенең халык иҗатына караган мәкаләләренә, Х. Бәдигыйгә таянып, мөһим өстәмәләр кертә. Әйтик, 1910 елда басылган «Әдәбият мәсьәләләре» мәкаләсендә ул фольклор әсәрләрен мәгънә һәм эчтәлек ягыннан биш төргә бүлеп карый. Ә «Әдәбият дәресләре» китабында (1916) такмаклар һәм такмазалар хисабына аларның санын җидегә җиткерә. Г. Ибраһимов Х. Бәдигыйнең Гыйльми үзәк каршындагы фольклор комиссиясендә халык иҗатын барлау-эшкәртү буенча актив эшләвен искә ала. Монда, әлбәттә, 1926 елда Бәдигый әзерләп бастырган «Халык әдәбияты. Мәкальләр. Табышмаклар» җыентыгын махсус атап үтү зарур. Әгәр әүвәлге китапларында бу жанр әсәрләре әлифба тәртибендә бирелсәләр, соңгысында алар беренче мәртәбә тематик төркемнәрдә урнаштырылалар.

Х. Бәдигый ун ел чамасы Казан педагогия институтында татар фольклоры укыта, аның өчен җентекле программа төзи. Бер үк вакытта ул бу фәнне мәктәпләргә дә мөмкин кадәр киңрәк кертү мәсьәләсен күтәрә. Мәсәлән, 1926 елда Казанда җыелган Беренче тел-әдәбият конференциясендә «Фольклор һәм аннан мәктәпләрдә файдалану юллары» дигән темага доклад белән чыга.

Гәрчә Бәдигыйнең халык иҗатына караган хезмәтләре вакыт ягыннан элегрәк мәйданга куелсалар да, аның эшчәнлегенең иң төп өлеше татар телен өйрәнүгә һәм укытуга карый. Тел белемебезнең ул кагылмаган, ул үз сүзен әйтмәгән берәр тармагы бар микән? Шәрык (Казан)

педагогия институты идарәсенә 1930 елның 12 февралендә үзен эшкә алуны сорап язган гаризасында ул болай ди: «Считаю себя более-менее подготовленным в области общего языкознания, по сравнительной грамматике турецких (т. е. тюркских. – *К. М.*) диалектов, по научной грамматике татарского языка и по методике родного языка. Однако для меня более близкие предметы: научная грамматика и методика татарского языка» (Г. Ибрагимов исемендәге ТӘһСИ мирасханәсе. Х. Бәдигый фонды: № 19, тасв. 1, сак. бер. 3). Шуңа күрә дә галим, табигый булганча, татар теленең грамматик системасын тикшерүгә зур игътибар бирә һәм аны дәреслекләр рәвешендә матбугатта чыгара. Бер үк вакытта укытучылар өчен күпсанлы методик ярдәмлекләр, кулланмалар да яза. Аның күпьеллык һәм иң якын автордашы – тел галиме М. Корбангалиев. Монда беренче чиратта 1918 елда дөнья күргән «Ана теле сарыфы» һәм бер елдан соң басылган «Ана теле нәхүе» исемле морфология, синтаксис дәреслекләрен атап үтү зарур. Алар шул чор өчен иң дәрәҗәле, иң күп файдаланыла торган хезмәтләр санала. Шушы юнәлештәге эшчәнлек берничә кисәкне эченә алган «Гамәли тел сабаклары»нда уңышлы дәвам иттерелә. 1929 елда өченче кисәгенең дүртенче басмасы дөнья күрү дәреслекнең халык арасында абруй казануы, аңа ихтыяҗның зур икәнлеге турында сөйли. 1926 елда Х. Бәдигыйнең фәнни эшчәнлегендә сыйфат үзгәреше тудырган мөһим вакыйга була: Академик үзәк, белемен күтәрү өчен, галимне Ленинград Шәрык институтына укырга җибәрә, ике елдан аны тәмамлагач, шунда ук аспирантура үтә, академик А. Н. Самойловичта тюркология буенча тулы курс тыңлый, «Төрки телләрнең чагыштырма морфологиясе» дигән темага кандидатлык диссертациясе яза. Галимнең 30 нчы елларда язылган дәреслекләре һәм фәнни хезмәтләре («Татар теле грамматикасы дәресләре», «Грамматика. 1 кисәк. Морфология», «Татар әдәби теленең барышы» һ. б.) тирәнлек, системалылык ягыннан сизелерлек югары торалар. Шуны да әйтергә кирәк: Хуҗа Бәдигый хезмәтләре бүген дә үзләренең һәм теоретик, һәм гамәли әһәмиятләрен саклап киләләр. Галимнең күп кенә методик кулланмалары башка милләт вәкилләренә, рус телле кешеләргә татар телен өйрәтүгә багышланганнар. Әлбәттә, аларның актуальлеге Татарстандагы бүгенге тел вазгыятендә бермә-бер артты. Гомумән, Хуҗа Бәдигыйнең үзе исән вакытта дөнья күргән китап-дәреслекләре фәнни тикшеренүләрдә, мәктәп һәм вузларда уку-укыту процессында шактый еш файдаланылалар. Әмма аларның яңа басмалары

чыгарылганы юк. Аның тормыш юлын, фәнни-педагогик эшчәнлеген тулырак яктырткан махсус хезмәтләр дә күренми

Хуҗа Бәдигыйнең бай фәнни-методик мирасы Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (фонд 19 Т). Галимнең шактый китаплары, дәреслекләре, мәкаләләре үзе исән чагында дөнья күрә. Шулай ук 2008 елда Институт аның «Шәкли нигездә татар грамматикасы (Г. Алпаров китабының төзәтелгән 2 нче басмасы чыгу уңае белән)», «15 ел эчендә татар әдәби теле», «Татар әдәби теленең барышы» хезмәтләрен эченә алган «Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог» дигән фәнни мәкаләләр җыентыгын нәшер итте.

Институт фондында галимнең җәмәгатьчелеккә барып ирешмәгән хезмәтләре дә саклана. Алар арасында татар теле, татар фольклорының төрле мәсьәләләренә караган татар, рус, хәтта немец телендәге мәкаләләр, доклад, чыгышлар текстлары бар. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни-гамәли хезмәтләре белән татар фәнендә тирән эз калдырган Хуҗа Бәдигыйнең фәнни мирасын барлап, әлеге җыентыкта бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган аерым хезмәтләрен беренче мәртәбә туплап, укучыга тәкъдим итә. Китапта Х. Бәдигый турында М. З. Зәкиевнең «Татар тел гыйлеме үсешендә Хуҗа Бәдигый», Д. М. Мөхәммәтҗанова һәм Э. Х. Кадироваларның галимнең тормышы һәм фәнни-педагогик эшчәнлеге турында «Ученый-филолог и педагог Худжа Бадигый» мәкаләсе китерелә. Җыентыкның икенче өлешендә Х. Бәдигыйнең фәнни мирасыннан тел белеменә караган кайбер хезмәтләр урын ала. Алар арасында татар әдәби теле тарихы, татарларда имля, терминология, лексикология, грамматика мәсьәләләренә караган мәкаләләр бар. Укучыга «Вопросы алфавита и орфографии (по поводу доклада т. Алпарова)» (рус һәм татар телендәге вариантларда), «Татарларда гарәп әлифбасы» (Б. Яфаров белән берлектә язылган), «Татар теленең шәкли грамматикасы нигезләре», «Склонение в турецких диалектах», «Основы синтаксиса татарского языка (опыт изучения синтаксиса татарского языка с формальной точки зрения)», «1935 елгы тел экспедициясе материаллары йомгаклары буенча хәзерге татар әдәби һәм сөйләм теленең лексик-семантик яктан үсеш тенденциясе (башлангыч йомгаклар)», «Термины по фонетике» хезмәтләре тәкъдим ителә. Х. Бәдигыйнең җыентыкта урын алган «Turkische

Wörter im Deutschen (Төрек телендә немец сүзләре)» дигән немец телендәге мәкаләсе аның киңкырлы фәнни эшчәнлеген күрсәтә. Гарәп графикасында, яңалифтә, кириллицадагы кульъязма һәм машинкада җыелган бу текстлар рус графикасына нигезләнгән гамәлдәге әлифбага күчереп бирелде. Хезмәт басмага филология фәннәре кандидаты, доцент Энҗе Хәнәфи кызы Кадирова һәм Динә Марсил кызы Мөхәммәтҗановалар тарафыннан әзерләнде.

Хуҗа Бәдигый өч революцияне, гражданнар сугышын күргән, патша заманында, совет власте һәм шәхес культы чорында яшәгән галим. Аның идеологик һәм гыйльми карашларында кайбер каршылыклар, төрлелекләр очравы гаҗәп түгел. Бәдигый турында язучы авторлар мондый фактларга кирәкле урыннарда шәрех-аңлатмалар бирәләр. Галим мирасыннан алынган текстлар бүгенге көн орфографик кагыйдәләренә яраклаштырылып бирелде, башка үзгәрешләр кертелмәде.

*К. М. Миңнуллин,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы*

## ТАТАР ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ ҮСЕШЕНДӘ ХУҖА БӘДИГЫЙ

Мәгълүм булганча, тел гыйлеме фәне латинчадагы *lingua* (тел) сүзеннән ясалган халыкара **лингвистика** термины белән дә атап йөртелә. Мин ни өчен бу ике терминның синонимлыгыннан башладым, чөнки Хуҗа Бәдигый XIX гасырның беренче яртысында формалашкан Казан төрки лингвистик мәктәбенең күренекле вәкилләреннән санала. Менә шушы лингвистик мәктәпнең төп үзенчәлекләрен истә тоткан хәлдә генә, галимнең тел гыйлеме өлкәсендәге хезмәтләренең әһәмиятен дөрес аңлатырга мөмкин.

Казан төрки лингвистик мәктәбенә М. А. Казем-Бек, И. Хәлфин, И. Н. Березин, Х. М. Френ, Ф. И. Эрдман, Мөхәммәтгали Мәхмүдов, М. Иванов кебек фән эшлеклеләре дөнья тюркологиясе хезмәтләренә таянып нигез салганнар. Бу галимнәр эшчәнлегенең төп үзенчәлеге шунда: алар тел мәсьәләләрен башка гуманитар фәннәр белән тыгыз бәйләп тикшергәннәр. Алардагы бу ысул XIX гасыр ахырында формалашкан, дөньякүләм танылган, башында Казан

университеты профессоры И. А. Бодуэн де Куртенэ торган Казан лингвистика мәктәбенә дә күчкән. Казан төрки лингвистика мәктәбен дәвам итүче татар галимнәре дә лингвистика фәнен әдәбият белеме, фольклор, тарих, этнография, археология белән тыгыз бәйләп үстереп баралар. Моңа мисал итеп XIX гасыр ахырында яшәгән Каюм Насыйри, XX гасыр башында эшләгән галимнәрдән Г. Ибраһимов, Җамал Вәлиди[1] иҗатларын китерергә мөмкин. Хуҗа Бәдигый үз эшчәнлеген шундый киң планда башлап җибәрә: мәдрәсә шәкерте чагында ук филологиянең тел һәм фольклорга караган мәсьәләләре белән кызыксына башлый.

Галим үзенең «Исемдә калганнар» дигән мәкаләсендә, Г. Тукай белән очрашуларын искә төшереп, шундый юллар яза: «1907 елда Будапешт шәһәренең Көнчыгыш университеты гыйльми эшчесе венгр ориенталисты Дюла (яки Юлий) Мессарош, татар һәм чувашларның фольклор материалларын җыю һәм өйрәнү теләге белән, Казанга килде. Мин ул вакытта Казандагы мәдрәсәи Мөхәммәдиянең соңгы курсында укучы бер шәкерт идем әле. Иптәшләрем арасында яхшырак укучы һәм шул вакытта ук татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынучы бер шәкерт булуым сыйфаты белән булса кирәк, татар телен өйрәтү һәм фольклор материалларын җыю юлында булышу өчен, әлеге гыйльми эшчегә мин тәкъдим ителдем» (Исемдә калганнар // Тукай турында замандашлары. Казан, 1960. Б. 118). Х. Бәдигый Д. Мессарошны татарчага бик тиз өйрәтә, алар икәүләп Арча районы авылларыннан фольклор материаллары җыялар. Бу эшне соңыннан да дәвам итү өчен, Бәдигый көнбатыш методикасын үзләштереп кала.

Габдулла Тукай, Бәдигыйне беренче күргәч тә:

– Ә, халык иҗатын җыючы кеше синмени әле ул? – дип сорау бирә. Бәдигый сүзләренә караганда, Г. Тукайның бу чорда халык иҗаты турында лекция укырга әзерләнеп йөргән чагы була.

Менә шулай итеп, Хуҗа Бәдигыйнең тел һәм фольклор мәсьәләләренә кереп китүе танылган шәхесләр белән тыгыз бәйләнгән. 1910–1914 елларда ул, татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп, эшкәртеп чыгаручы буларак, галимнәр арасына килеп керә, соңрак татар халкының танылган фольклорчысы һәм лингвисты булып җитешә.

---

[1] *Вәлиди Җамал* (Җамалетдин) Җәләлетдин улы (1887–1932) – тел-әдәбият галиме, педагог, репрессияләр чоры корбаны.

1914 елларда ул татар телен һәм әдәбиятын балаларга укыту мәсьәләләре белән кызыксына башлый. Шул елда ук соңыннан татар тарихчысы булып танылган мөгаллим Гайнетдин Әхмәровның[1] «Төрки әлифба» китабына рецензия яза. Әлеге рецензия 1915 елның 20–27 июнь көннәрендә Уфа вилаяте земствосында мөселман мәктәпләренә дәреслекләр сайлау өчен ясалган киңәшмәдә яңгыраш ала. Аның бу хезмәте 1916 елда Уфада «Шәрык» нәшриятында чыккан махсус җыентыкта дөнья күрә – «Уфа вилаяте земствосында 1915 елда июньнең 20–27 сендә мөселман мәктәпләренә дәреслекләр сайлау өчен ясалган киңәш мәҗлесенең карарлары вә анда укылган докладлар» (Уфа: Шәрык, 1916. Б. 98–111).

1917–1918 елларда Хуҗа Бәдигый, тел-әдәбият укытучысы буларак, татар теленең грамматик системасын тикшерү һәм аның буенча дәреслекләр язу эшенә керешә. Танылган тел галиме һәм педагог Мөхетдин Корбангалиев белән уртак хезмәтләр чыгара, аларга Г. Баттал исемле бер укытучы да катнаша. Өчәүләп 1918 елда Казанда «Ана теле сарыфы» (сарыф – морфология) дәреслеген бастыралар. Революциядән соң татар телен укытуга игътибар артканлыктан, 1919 елда дәреслекнең икенче басмасын нәшер итәргә туры килә. Әлеге авторларның «Ана теле нәхүе» (нәхү – синтаксис) китабы да шул ук елларда дөнья күрә һәм шул чордагы иң абруйлы дәреслекләр урынын ала.

1934 елда, шулай ук М. Корбангалиев белән автордаш булып, Х. Бәдигый башлангыч сыйныфлар өчен «Әлифба» дигән китап чыгара. 1937 елда аның икенче басмасы дөнья күрә.

Октябрь революциясенең рустан башка халыкларга да тулы мөмкинлекләр бирү турындагы вәгъдәләренә татар галимнәре дә чын күңелдән ышандылар, чөнки большевиклар 1920 елда татар халкына дәүләтчелекне кире кайтарып бирделәр. Бу дәүләт, интернационализм идеяләре белән яшәсә дә, татар телен һәм халкын үстерү, саклап калу буенча төрле чаралар күрә башлады.

Татарстан Мәгариф министрлыгы (Наркомпросы) каршында 1921 елда ук оештырылган Академик үзәк (Академцентр) шундый чараларның иң олыларыннан иде. Г. С. Гобәйдуллин[2],

[1] *Әхмәров* Гайнетдин Нәҗметдин улы (1864–1911) – тарихчы, археограф, җәмәгать эшлеклесе.

[2] *Гобәйдуллин Газиз* (Габделгазиз) Салих улы (тәхәллүсе Г. Газиз) (1887–1937) – тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, профессор, репрессияләр чоры корбаны.

М. Х. Корбангалиев, Г. Х. Алпаров[1], Гали Рәхим[2], Җамал Вәлидиләр белән бергәләп, Хуҗа Бәдигый дә академүзәктә актив рәвештә эшләп килә, татарны саклау һәм үстерү проблемалары буенча күп кенә киңәшмәләрдә һәм конференцияләрдә катнаша.

1926 елның 15–22 июнь көннәрендә академүзәк тарафыннан «Беренче тел-әдәбият конференциясе» оештырыла. Алты көн буена дәвам иткән бу конференциядә тел, әдәбият, фольклор буенча бик күп докладлар тыңлап тикшерелә. Хуҗа Бәдигый анда татар теле буенча «Морфология элементлары, сүз төркемнәре турында» исемле темага доклад сөйли. Ул чорда морфология фәне нинди берәмлекләр белән эш итәргә тиеш, сүзләрне нинди төркемнәргә бүләргә дигән сорауларга әле якынча гына җавап бирелгән була. Аның «Беренче тел-әдәбият конференциясе материаллары» җыентыгында басылып чыккан тезисларына караганда, Хуҗа Бәдигый рус теле фәненең төп юнәлешләре һәм татар тел белеме тарихын җентекле өйрәнгән галим икәнлеген күрсәтә.

Революциядән соң рус телен һәм милли телләрне мәктәпләрдә укытуның киң җәелүе сәбәпле, РСФСР Наркомпросы (Мәгариф министрлыгы) каршында, төрле фәннәрне укытуны фәнни тәртипкә салу өчен, махсус бер дәүләти оешма – Дәүләт Гыйльми советы төзелә. Бу Советта мәктәпләрдә телләрне укыту һәм алар буенча дәреслекләр төзү проблемалары да еш тикшерелә. Анда рус галимнәре тел дәреслекләрендә беренче планга телнең семантикасын түгел, ә формасын куярга тәкъдим итәләр: семантикадан (мәгънәдән) чыгып, форманы (шәкли якны) түгел, ә телнең форма ягын (шәкли нигезен) җентекләп өйрәнеп, һәр форманың (шәкелнең) эчтәлеген, мәгънәсен (семантикасын) ачу юлы белән баруны беренче планга куялар. Шуңа күрә рус теле дәреслекләре форманы (шәкли күрсәткечләрне) нигезгә алып языла башлыйлар.

Гыйбад Алпаров та, Хуҗа Бәдигый дә, шул чорларда СССР Фәннәр академиясенең Ленинградтагы Востоковедение (шәрыкны өйрәнү) институтында белем алган һәм хезмәт иткән галимнәр бу-

---

[1] *Алпаров* Гыйбадулла Хәбибулла улы (1888–1936) – тел галиме, профессор, 1926 елдан Казан педагогия институтында эшли башлый, татар теленнән дәреслекләр, «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) исемле фәнни хезмәт авторы.

[2] *Гали Рәхим* (Габдерәхимов Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы) (1892–1943) – язучы, әдәбият галиме, репрессияләр чоры корбаны.

ларак, формаль грамматика проблемаларына игътибар итеп, татар дәреслекләренә дә шул юнәлешне кертергә тырышалар. Х. Бәдигый, М. Корбангалиев белән бергәләп, 1925 елда «Шәкли нигездә гамәли тел сабаклары» китабын нәшер итә, аның төзәтелгән дүрт басмасы дөнья күрә. 1925 елда Г. Алпаров та «Шәкли нигездә татар грамматикасы (Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә)» дигән китабын чыгара. Аның икенче басмасы 1926 елда дөнья күрә.

Хуҗа Бәдигый, шәкли юнәлешне яхшы аңлаган галим буларак, Г. Алпаров китабының икенче басмасына бик җентекле рецензия яза һәм 1928 елда «Мәгариф» журналының 1 нче, 2 нче, 3 нче саннарында аны бастыра. Рецензиядә Г. Алпаров хезмәтенә карата кискен генә каршылыклар белдерелсә дә, хезмәт нигездә уңай бәяләнә. Хуҗа Бәдигыйнең тәнкыйте бигрәк тә китапның керешендә бирелгән «Тел һәм сөйләшү», «Тел гыйлемнәре», «Телебезнең тышкы факторлары» (Ялганмалык, тәртип, кабатлау, сингармонизм, басым, аһәң, тыныш) темаларына карый. Г. Алпаров китабының җентекләп язылган «Телебезнең фонетикасы», «Телебезнең сарыфы», «Телебезнең нәхүе» бүлекләренә Хуҗа Бәдигый тарафыннан уңай бәя бирелә. Ул үзенең шул чордагы гомуми тел гыйлеме проблемаларыннан хәбәрдар булуын бик ачык күрсәтә.

Мәгълүм булганча, Татарстан Наркомпросы каршындагы Академүзәкнең карары буенча, татар теленең тулы грамматикасын чыгару кирәклеге танылა, аны төзү өчен, Г. Ибраһимов җитәкчелегендә галимнәр төркеме оештырыла. Тулы дәреслекнең исемен «Гамәли тел сабаклары» дип билгелиләр. Аның 1 нче китабы 1922, 1924 елларда, 2 нче китабы 1922, 1924, 1925 елларда, 3 нче китабы 1923, 1924, 1925 елларда басыла. Бу тулы дәреслекнең сарыф, нәхү өлешен язуда Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Галә Ходаяров[1], Фатих Сәйфи-Казанлылар белән бергә Хуҗа Бәдигый дә катнаша.

Хуҗа Бәдигый, татар теленең һәм халкының үсеш проблемалары белән тирәннән кызыксынып барган галим буларак, татар әдәби теленең камилләшү мәсьәләләрен дә үз игътибарыннан төшереп калдырмый. 1930 елда «Безнең юл» журналының 2 нче һәм 3 нче саннарында «Татар әдәби теленең барышы» дигән хезмәт чыгара.

---

[1] *Ходаяров* (Кудояров) Галә (Галәэтдин) Гайнетдин улы (1891–1966) – дәүләт эшлеклесе, 1928–1931 елларда Шәрык (Казан) пединституты ректоры, ТАССР Халык мәгариф комиссары.

Хуҗа Бәдигый, бер яктан, Казан төрки лингвистика мәктәбе идеяләре тәэсирендә формалаша, икенче яктан, үз чорының идеологиясен, үз заманының тел гыйлемен, аерым алганда, шул чорда хөкем сөргән Н. Я. Марр тәгълиматын да тирәнтен аңлап үзләштерергә тырышкан галим була, ягъни замана баласы буларак шәкелләшә.

«Татар әдәби теленең барышы» хезмәтенең максатын автор болай билгели: «Мин бу мәкаләмдә тулай татар әдәби теленең барышы, бер өлеш хәзерге борылышы турында анализ ясарга һәм кайбер нормадан чыгу моментларын күрсәтеп китәргә уйлыйм. Ләкин бу зур һәм җаваплы мәсьәләгә керешкәнгә кадәр, анализыбызйомгагыбызның тулы һәм төпле булып чыгуы өчен, алдан телнең гомерен, социаль урынын һәм аның методологиясен билгеләп үтәргә тиеш табам». Менә шушы бурычларны тәртипле рәвештә башкару өчен, Хуҗа Бәдигый үз мәкаләсен ун бүлекчәгә аерып яза. Керешендә пролетар революциясенең казанышлары турында сөйли. Тормышның буржуазия кулыннан пролетариат кулына күчүе иҗтимагый тормышта бик зур үзгәреш тудырды, Татарстан дәүләте төзелде», – ди ул. «Хәзер татар теле, үзенең элекке үгилегеннән, кысылуыннан, хокуксызлыгыннан котылып, тулы хокуклы дәүләт теле булып әверелде», – дип белдерә.

**I бүлекчәдә** телнең үсеш процессының ике яклы булуы турында сүз алып барыла:

1) артикуляцион-акустик ягы; 2) тамгалык-символик ягы. Бу теоретик мәсьәләләрне аңларга һәм укучыларга аңлатырга тырышуы Хуҗа Бәдигыйнең теоретик яктан да җитлеккән галим кәнлеген күрсәтә. **II бүлекчә,** тамгалар теориясеннән (знаковая теория) чыгып, телнең нинди тамганы тәшкил итүе мәсьәләсен аңлатуга багышланган. Шул чорда өстенлек алган яфетизм (Н. Я. Марр) өйрәтмәләренә ышанып, Хуҗа Бәдигый «Тел ул – идеологик символ», – дип яза. Шунда ук «телнең бөтен тормышы үзенең тамгалык функциясендә ачыла, тел – иң саф һәм иң нечкә социаль аралашу тамгасы, болардан башка тел тагы битараф тамга да була ала», – дигән фикер дә әйтә.

Марксизмның төп проблемаларыннан берсе – базисның өскормага (надстройкага) мөнәсәбәте проблемасы дип билгеләгәч, Хуҗа Бәдигый телне өскормага каратып куя, монда да ул маррчылар карашына иярә.

Телнең бөтен составы – фонемасы, морфемасы, сүзе, синтагмасы, җөмләсе һәм аның бөтен нәрсәләре – һәммәсе дә идеологик тамга дип, ул телне сыйнфый күренеш итеп күрсәтә. Хәзерге теориядә исә тел сыйнфый күренеш була алмый дип аңлатыла.

«Татар әдәби теленең барышы» мәкаләсенең **III бүлекчәсе** әдәби телнең формалашу юлларын аңлатуга багышланган. Бу мәсьәләне Хуҗа Бәдигый шулай ук яфетизмга нигезләп аңлатырга тырыша. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки 20–40 нчы елларда совет лингвистикасында Марр культы хөкем сөрә иде. Н. Я. Марр өйрәтмәсенең дөрес булуы мөмкин дә түгел, чөнки ул башта күктән алып ниндидер теория уйлап чыгара, аннан соң аны исбатларлык материал тупларга керешә, ә фән киресенчә үсә. Бу ялган өйрәтмәне танымаган, аны аңлатуда һәм үстерүдә катнашмаган тел галимнәре үз эшләреннән куылалар иде. Хуҗа Бәдигый дә менә шундый шартларда иҗат итте, һәм аның Марр өйрәтмәләренә нигезләнүе бер табигый хәл. Ләкин бу Хуҗа Бәдигыйнең ул чордагы хезмәтләрен исәпкә алмаска кирәк икән дигән сүз түгел, чөнки галимнең бик дөрес һәм рациональ фикерләре дә тулып ята. Татар әдәби теленең формалашу юлын ул дөрес билгели, ничек формалашуын дөрес ача.

**IV бүлекчәдә** Хуҗа Бәдигый, төрки һәм татар әдәби теленең сыйнфый күренеш буларак формалашуын аңлатып ялгышканнан соң, әдәби телнең үсеш чорларын күрсәтүгә керешә. Тарихи яктан төрки-татар әдәби теленең чорларга бүленешен Х. Бәдигый танылган тюрколог А. Н. Самойлович хезмәтләреннән файдаланып аңлата, төрки әдәби теленең түбәндәге чорларын аера.

1. Караханлылар теле, ягъни уйгур әдәби теле чоры. Бу телнең үрнәкләре «Кутадгы белек» һәм «Һиббәтул хакаик» әсәрләрендә бирелгән ди ул.

2. Кыпчак-угыз әдәби теле чоры, аныңча, бу тел үрнәкләрен «Кыйссаи Юсыф», «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә», «Нәһҗел Фәрадис», «Җөмҗөмә Солтан» әсәрләрендә табып була.

3. Чыгытай әдәби теле Аксак Тимер империясендә яшәгән язучыларның теле була, дип аңлата ул.

Иҗтимагый үсеш этапларына бәйле рәвештә Хуҗа Бәдигый әдәби телне өч чорга бүлеп күрсәтә: 1) феодализм әдәби теле, 2) буржуаз милләтчелек чоры әдәби теле, 3) Октябрь революциясеннән соңгы әдәби тел.

**V бүлекчәдә** Хуҗа Бәдигый әдәби телнең түгел, ә гомумән, сөйләм теленең кул хәрәкәтләре (ишарәләр) белән аралашуны җиңеп барлыкка килүен аңлата. Монда да яфетизм нигез итеп алына.

**VI бүлекчә** өченче чор – совет чоры әдәби теленең искелектән борылышы, яңага күчүе турында сөйләүгә багышланган. Революциягә кадәр бары чимал базасы гына булган милли өлкәләр, революциядән соң һәрьяклы үсүгә ирештеләр: промышленность та, колхозлар, совхозлар да, сәүдә эшләре дә чын-чыннан үсеш алдылар дигән фикергә нигезләнеп, Хуҗа Бәдигый «бу үсеш телнең үсешенә дә китерде» дигән фикер үткәрә.

**VII бүлекчәдә** Х. Бәдигый татар әдәби теле үсешендә иске мирастан файдалану һәм телне баету өчен яңа сүзләр ясау проблемаларына махсус туктала. Ул «Әдәби телнең төп өлеше иске мирасны дәвам итә, шуның белән бергә ул яңа сүзләр хисабына да байый» дигән нәтиҗәгә килә Х. Бәдигый һәм яңа сүзләр ясауның төп юлларын санап аңлатып бирә.

1. Кушымчалар ярдәмендә яңа сүз ясау: *-чы/-че – колхозчы, -чы- лык – урманчылык, -ма/-мә – өстәмә, -ым – салым, -ш – уңыш, -гыч/-геч – аергыч, белгеч, -ыч/-еч – ялыныч, үтенеч, -ык – боерык, -ак – утрак, -гак – тайгак, йомгак, -ча – сызыкча, бүлекчә, -мтә – элемтә* һ. б.

2. Сүзләр теркәү юлы белән яңа сүз ясау: *Мәскәү-Казан, социал-демократ, хатын-кыз, бала-чага, кеше-фәлән, озын-озын, кеше-меше* һ. б.

3. Сүзләрне буйсынулы юл белән бәйләп, яңа сүз ясау: *үзе куган (самогон), авыл советы, өчаяк, эшләп чыгаручы, канәфер төс* һ. б.

4. Сүзләрне кыскарту юлы белән яңа сүз ясау: *эшхәр (эшчеләр хәрәкәте), ТУМ (Татарстан универсал магазины)* һ. б.

5. Телнең үз җирлегендә яңа сүз ясап булмаса, рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән сүзләр алу юлы белән телдәге сүзләрне күбәйтү: *социализм, революционер, оратор, декан, биология, этнография, грамматика, пролетариат* һ. б.

«Татар әдәби теленең барышы» хезмәтенең **VIII бүлекчәсендә** Хуҗа Бәдигый әдәби телне баетуда иске мирастан файдалану проблемаларын тикшерә.

**IX бүлекчәдә** телне үз җирлегенә таянып үстерү мәсьәләләре яңадан, җентекләбрәк тикшерелә.

**X бүлекчәдә,** шул чор карашынча, телнең сыйнфыйлыгыннан чыгып, телне үстерүне җитәкләп баручылар – сыйныфның гыйльми җитәкчеләре булырга тиеш дигән мәсьәлә куела. Әйдәп баручы язучылар һәм тел галимнәре бу эштә гыйльми җитәкче булырга тиеш, ди Хуҗа Бәдигый.

«Татар әдәби теленең барышы» мәкаләсенең йомгагында социализм төзү чорында татар халкының һәрьяклап үсеше яктыртыла. Әдәби тел сыйнфый һәм совет чорындагы әдәби телнең хуҗасы пролетариат дигән фикер үткәрелә.

1932 елда Октябрь революциясенең җиңүенә 15 ел тулуга багышлап, Хуҗа Бәдигый «Яңалиф» журналының 9–10 нчы санында «XV ел эчендә татар әдәби теле» исемле мәкалә чыгара. Моның теоретик нигезен автор ике ел элек үзе нәшер иткән «Татар әдәби теленең барышы» мәкаләсендәге кебек үк марксизмга, яфетизмга (Марр өйрәтмәләренә) яраклаштырып биргән. XIX гасырда капиталистик мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүе татар әдәби теленең үсешен яңарак юлдан алып китте, ди автор. Моңа төп сәбәп итеп Х. Бәдигый татар пролетариаты сыйныфының барлыкка килүен күрсәтә. «Димәк, татар пролетариаты, XIX йөзнең соңнарында, һич булмаса, XX йөзнең башларында ук аерым сыйныф булып, үзенең телен крәстиян һәм буржуа теленә каршы куйган булырга тиеш», – дип нәтиҗә ясый ул. Х. Бәдигый крәстиян теле дигәннән – авыллардагы диалекталь сөйләмне, буржуа теле дигәннән иске әдәби телне күз алдында тота булса кирәк. Пролетариат телен ул завод-фабрикаларда төрле диалект вәкилләренең бергә тупланып аралашуыннан туган, әдәбиләшеп бара торган гомуми сөйләм белән, ягъни шәһәр койнесы белән тиңләп күрсәтә дигән фикер туа. Менә шушы өч төрле телебезнең кайсы әдәби норма булып урнашкан: иске әдәби телме, диалекталь сөйләмме, әллә койнемы? Хуҗа Бәдигый шул сорауларга җавап бирергә тырыша. Билгеле инде, һәр телдәге кебек үк, татар телендә дә – соңгысы. Нәкъ менә шул уртак нормага әйләнеп бара торган койнены Х. Бәдигый пролетариат теле дип атый.

Бу уртак әдәби телне, ягъни, аныңча, пролетариат телен тудыручылар – язучылар – 1905 елгы революциядән соң күренделәр, «Урал» газетасы аша яңа әдәби тел халыкка җиткерелә торды. Х. Бәдигыйнең «Урал» газетасы теленә ясаган кыска гына анализы да игътибарга лаек.

Татар әдәби теленең 15 ел эчендә үсешен Х. Бәдигый пролетар революциясенә, Маркс, Ленин, Сталин өйрәтмәләренә бәйләп аңлатырга тырыша, Татарстан дәүләтчелеге төзелүнең тел үсешендәге ролен дә ачык күрсәтә.

Ул чорда интернациональләштерү генә беренче планга чыгарыла, милләтне саклау милләтчелек исеме белән бергә буржуаз идеология дип бәяләнә иде. Х. Бәдигый дә бу идеологиягә сүздә булса да ияреpгә тырыша, ләкин чынлыкта татар әдәби теленең тууын һәм үсүен милләтне саклау дип аңлый.

Татар әдәби теленең 15 елда үсүен мисалларда күрсәтү өчен, Х. Бәдигый М. Гафури, Һ. Такташ, Ф. Бурнаш, Д. Юлтый, Н. Исәнбәт әсәрләреннән үрнәкләр китерә.

15 ел эчендә татар әдәби теленең сүзлек запасы артуга Х. Бәдигый аерым әһәмият бирә һәм яңа сүзләр тудыруның төп ысулларын санап үтә. Бу ысулларны ул «Татар әдәби теленең барышы» мәкаләсендә дә күрсәткән иде. Монда кайбер яңа ысуллар исәпкә алына: 1) русчадан алганда, рус кушымчаларын төшереп калдыру *(социологический – социологик, технический – техник, экономический – экономик, объективный – объектив, формальный – формаль* һ. б.); 2) сузык авазга беткән гарәп сүзләренең ахырына *-ви* кушымчасы ялгау *(мәгънәви, тәрбияви, гаиләви* һ. б.); 3) тартык авазга тәмамланган гарәп сүзләренә *-и/-ый* кушымчасын ялгау *(сыйнфый, гыйльми* һ. б.).

Сүзлек составын яңа сүзләр белән баетуның Х. Бәдигый дүрт юлын күрсәтә.

1. Яңа төшенчәне белдерү өчен, татарда сүз табып була икән, читтән алмаска, үз сүзеңне термин итеп кертергә.

2. Яңа төшенчә өчен үз сүзләреңнән термин ясарга тырышырга.

3. Алырга кирәк булса, сүзне иң элек башка төрки халыклар теленнән эзләргә.

4. Аларда булмаса гына, рустан яки рус теле аркылы башка телләрдән алырга.

Бу принципларның өченчесе авторны ул чорда бүкәй итеп тотылган пантюркизмда гаепләргә мөмкинлек бирсә дә, Х. Бәдигый аннан курыкмаган. Бу аның татар теле төрки телләр белән якын булганда гына үсә, сакланып кала ала дигән эчке тойгысыннан килә.

Яңа әдәби телне үстерү өчен, аның җитәкчеләре дә булырга тиеш, ди Х. Бәдигый. Андыйлар бездә бар дип, Г. Ибраһимов,

Ф. Сәйфи, М. Гафури, Шәриф Камал кебек язучыларны күрсәтә. Пролетариатның үз эченнән чыккан язучылар – тел җитәкчеләре дип, ул Ш. Госманов, К. Нәҗми, Г. Толымбай, Х. Туфан, С. Баттал, М. Максуд, А. Таһиров, М. Крымов фамилияләрен атый.

Тел генә түгел, хәтта язылган әсәрләрнең эчтәлеге дә пролетариатның үсеш юлын чагылдыра дигән фикеренә мисал итеп Х. Бәдигый Һ. Такташ шигырен китерә:

Бүгенге ул сыйнфый катлауларның
Соңгы каты көрәш заманы.
Без, искене җимереп,
Планетада
Тигез тормыш,
Матур, яңаны
Төзү уе белән янабыз.

Х. Бәдигый 15 ел эчендә татар әдәби телен төзүдә мәктәпләрнең ролен дә әйтмичә калмый, Ленинның 6 томлык әсәрләренең татарчага тәрҗемә ителүенең ролен дә исәпкә ала. Эчтәлеге ягыннан социалистик, формасы ягыннан милли булган культураның чәчәк атуы да әдәби телебезнең тууына һәм үсүенә ярдәм итте, ди автор.

«15 ел эчендә татар әдәби теле» дигән хезмәтенә йомгак рәвешендә Х. Бәдигый, үз чоры идеологиясенә туры китереп, түбәндәге фикерне әйтә: «Менә шулай, 15 ел эчендә Октябрьдә җиңеп чыккан революцион татар пролетариатының, үз идеологиясенә һәм гомумән культура үсешенә яраклашып, интернационализмга юнәлеш алып, үз әдәби теле эшләнде». Хуҗа Бәдигый турында язганда, без «ул – пролетариат диктатурасын яклаган, коммунизм идеяләренә таянып хезмәт иткән» дип кенә үтә алмыйбыз. Ул чор булган икән, тарихыбызны өйрәнгәндә, аны читкә куя алмыйбыз. Тарих объектив өйрәнелергә тиеш. Шундый шартларда да Хуҗа Бәдигый милли үсешнең төп юнәлешләрен аңлап эш иткән, үз чорының билгеле, танылган галиме саналган.

Хуҗа Бәдигый татар теле грамматикасы буенча дәреслекләр төзү эшчәнлеген өзлексез алып бара, татар мәктәпләренең башлангычлары өчен дә, тулы булмаган урта сыйныфлары өчен дә татар теле дәреслекләре төзүне үзенең бурычы дип саный.

1934 елда ул М. Корбангалиев белән бергәләп башлангычлар өчен «Әлифба» китабын чыгара, 1937 елда аның 2 нче басмасы нәшер ителә. 1936–1938 елларда ул үзе генә татар балаларына «Уку

китабы. Грамота мәктәпләре өчен» исемле бик җентекле эшләнгән китабын тәкъдим итә.

1935 елда Х. Бәдигый читтән торып укучылар өчен «Татар теле грамматикасы дәресләре» (Казан, Татгосиздат) дигән китап бастыра. Моның кереш өлешендә һәм аңлатмаларда, грамматикадан тыш, шул чордагы тел үсеше проблемалары да бирелә. Х. Бәдигыйнең бу дәреслеге үзенең яңалыгы белән шактый гына тавыш та чыгарып ала.

Нигъмәт Хәким[1] аңа «Читтән торып укучылар өчен «Татар теле грамматикасы дәресләре» исемле тәнкыйть мәкаләсе яза. Ул «Мәгариф» журналының 1935 елгы 10 нчы санында басылып чыга. Тәнкыйтькә җавап итеп, Х. Бәдигый «Мәгариф» журналының 1936 елгы 5 нче, 6 нчы, 7 нче саннарында «Кайбер тел проблемалары турында (Нигъмәт Хәкимнең "Татар теле грамматикасы дәресләре" китабы чыгуына тәнкыйть уңае белән)» дигән мәкаләсен нәшер итүгә ирешә. Х. Бәдигый һәм Н. Хәким арасында туган бу бәхәсләрне яктырту өчен аерым бер мәкалә язарга кирәк. Шуңа күрә биредә аларга тукталып тормыйбыз.

Хуҗа Бәдигыйнең төп грамматик хезмәтләре татар теле морфологиясенә карый. 1933 елда морфология дәреслекләрен ул үзе генә (М. Корбангалиевтән башка) чыгара башлый. Хезмәтнең исеме: «Грамматика. 1 кисәк. Морфология. Тулы булмаган урта мәктәп өчен дәреслек. V класс өчен». Дәреслекнең икенче басмасы – 1934 елда, өченчесе 1936 елда басыла.

Ике елдан соң, ягъни 1938 елда Х. Бәдигый, бу дәреслекне бераз үзгәртеп, җыйнакландырып, 5–6 нчы класслар өчен нәшер итә. Дәреслеккә кыска гына аңлатма бирик.

Автор 1933 елда ук чыккан морфологиясендә дәреслекнең тууын болай аңлата: «Бу дәреслек теоретик белем, төп куелыш, система һәм күләм ягыннан рус мәктәпләренең бишенче уку елы өчен А. Б. Шапиро тарафыннан төзелгән һәм РСФСР Наркомпросы тарафыннан расланган грамматика дәреслегенең беренче кисәге (морфология) буенча төзелде». Ләкин рус морфологиясеннән ни дәрәҗәдә генә файдаланмасын, автор татар теле морфологиясен яза, шуңа күрә дәреслек татар теле морфологиясенең ул чордагы үсеш дәрәҗәсен күрсәтә.

---

[1] *Хәким Нигъмәт* (Хәкимов Нигъмәтулла Гыйниятулла улы) (1889–1937) – тел галиме, әдәбиятчы. «Идегәй» дастанын язып алучы һәм фәнни әйләнешкә кертүчеләрнең берсе.

Керештә грамматика, орфография һәм пунктуация дигән фәннәргә билгеләмә бирелә. Ул чорда фонетика да морфология эчендә өйрәнелгән. Шуңа күрә бу дәреслектә дә башта фонетика бүлеге урын ала. Морфологияне аңларга ярдәм итәрлек дәрәҗәдә генә булса да, «Җөмлә» дигән тема ачылып, автор синтаксисның төп категорияләрен күрсәтә. Шуннан соң гына морфология яктыртыла.

Х. Бәдигый татар телендә тугыз сүз төркемен саный: исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, ярдәмлек сүз, ымлык, тагылма.

Ярдәмлек сүз эчендә автор хәзерге теркәгечләрне һәм бәйлекләрне тасвирлый. Ярдәмлек сүзнең өченче төре итеп билгеләвечләр исеме астында сүз башында килә торган кисәкчәләрне һәм төрле урында әйтелә ала торган модаль сүзләрне саный: *бик, иң, әллә, һич, бит, ич, ахры, бугай, шәт, нәкъ* һ. б.

Тагылмалар (кисәкчәләр) дип аталган сүз төркемнәренә шундый мисаллар китерә: *гына-генә, кына-кенә, ук-үк, да-дә, та-тә, ла-лә, мы-ме, чы-че, мыни-мени, дыр-дер, тыр-тер.*

Автор билгеләвечләрне русча – усилительные слова, тагылмаларны (кисәкчәләрне) частицы дип тәрҗемә итә.

Күренә ки, Х. Бәдигыйнең билгеләвечләрен һәм тагылмаларын (кисәкчәләрен) бергә җыеп аларга, мәгънәләреннән чыгып, яңа классификация ясарга кирәк, һәм хәзерге грамматикаларда шулай эшләнгән дә.

Дәреслекнең беренче бүлеге – теоретик материалдан, икенче бүлеге күнегүләр тупланмасыннан тора. Ахырда китапка кергән татарча-русча грамматик терминнар сүзлекчәсе бирелгән.

Без бу мәкаләдә Хуҗа Бәдигыйнең татар тел гыйлеме өлкәсендәге эшчәнлеген кыскача гына сөйләп чыктык. Күрдек: татар тел гыйлеме фәнен үстерүдә Хуҗа Бәдигыйнең хезмәте бик күп икән. Шуңа күрә ул татар тел гыйлеме тарихында, гомумән татар филологиясе тарихында (чөнки ул – әле танылган фольклор галиме дә) үзенең лаеклы урынын алырга, онытылмаска тиеш.

Үз халкын сакларга, үстерергә теләгән башка татар галимнәре язмышын Хуҗа Бәдигыйгә дә кичерергә туры килә. Сталин культы тәгәрмәченә эләгеп, төрмәләрдә тапталганнан соң, аңа озак яшәргә насыйп булмый, 1940 елда ул якты дөнья белән хушлаша.

*М. З. Зәкиев,*
*академик*

# УЧЕНЫЙ-ФИЛОЛОГ И ПЕДАГОГ ХУДЖА БАДИГЫЙ[1]

Вклад ученого, педагога, автора многочисленных научных и методических статей и учебных пособий Худжы Бадигыя в силу разных причин недостаточно всесторонне и глубоко изучен. Более основательно лингвистическая деятельность ученого освещается в сборнике материалов конференции, посвященной 100-летию со дня его рождения [18]. В данной работе впервые дается краткая историческая оценка деятельности Х. Бадигыя как педагога и одного из основателей татарской филологии XX века.

Х. Бадигый (Худжа Габделбадыйгович Бадигов) родился в 1887 г. в селе Верхний Берсут Мамадышского уезда Казанской губернии. После сельской школы в 1899 г. был направлен в медресе «Мухаммадия». В 1907 г. по рекомендации своих учителей Х. Бадигый сопровождает приехавшего в Казань для изучения татарского и чувашского фольклора венгерского ориенталиста Ю. Мессароша. Работая с ним в тесном контакте при сборе фольклорного материала и перенимая его научный опыт, Х. Бадигый втягивается в научную деятельность.

Тяжелое материальное положение заставляет Х. Бадигыя много трудиться: он дает уроки татарского языка и литературы и истории в различных учебных заведениях. В 1918–1926 гг. преподает татарский язык и литературу в Казанском педагогическом техникуме, в женской семинарии. Осенью 1926 г. Х. Бадигый поступает в аспирантуру Ленинградского восточного института. В начале 1930-х годов он, пройдя подготовку у профессора Института востоковедения А. Н. Самойловича – крупнейшего ученого-тюрколога, возвращается на кафедру татарского языка Казанского педагогического института, где, наряду с педагогической деятельностью, энергично берется за разработку важнейших проблем татарской филологии.

Х. Бадигый является ученым, внесшим большой вклад в татарскую фольклористику, «создателем новой вехи в татарской фольклористике» [3, с. 7]. Часть собранного фольклорного материала он публикует в 1912–1914 гг. в четырех сборниках под общим названием «Народная литература», куда вошли пословицы, загадки, поговорки, прибаутки, баиты, песни. Исследователь был совершенно

---

[1] *Кадирова Д. М., Кадирова Э. Х.* Ученый-филолог и педагог Худжа Бадигый // Гуманитарные науки и образование. 2016. № 2. С. 109–113.

убежден в том, что «народная литература – сокровищница языка» [7, с. 4].

Х. Бадигый также проводил исследования в области языкознания. Яркий представитель плеяды татарских языковедов начала XX века, он сыграл важнейшую роль в разработке методологии современного татарского языкознания и в его становлении как подлинно научной дисциплины. Ученый проявил себя не только как сильный теоретик, но и как деятельный практик, умелый организатор, претворяющий в жизнь результаты научных открытий.

Особое место в научной деятельности Х. Бадигыя занимает изучение проблем орфографии, татарского алфавита, которые нашли отражение в работах Г. Ибрагимова, Г. Алпарова, Г. Нугайбека и других языковедов, полемизировавших друг с другом. В статье Х. Бадигыя «Вопросы алфавита и орфографии (по докладу Г. Алпарова)» [14] наиболее полно изложены авторские и общественные взгляды на проблему изменения татарского алфавита. Статья занимает 7 листов, заполненных с обеих сторон, сама рукопись на татарском языке с использованием арабской графики, правкой и добавлениями автора на русском языке. В статье «Арабский алфавит у татар» [13], написанной в соавторстве с Б. Яфаровым, речь идет об истории татарского письма. В ней досконально описываются этапы развития письма, начиная с рунического алфавита и кончая кириллицей.

Вопросам развития татарского литературного языка посвящены такие работы ученого, как «Татар әдәби теленең барышы» («Состояние татарского литературного языка») (1930) [11], «15 ел эчендә татар әдәби теле» («Татарский литературный язык в течение 15 лет») (1932) [10]. Следует отметить, что в основных чертах Х. Бадигый правильно определил пути и этапы его формирования. Во вступительной части учебника «Грамматика татарского языка», в параграфах «Татарский литературный язык и его эпохи», «Языкознание и его главы» рассматриваются проблемы развития татарского литературного языка, деление его на периоды и характерные особенности, соответствующие этим периодам. Филологические изыскания исследователя следует рассматривать как предпосылки для становления научной теории истории татарского литературного языка.

Проблемы терминологии и орфографии также были объектом внимания Х. Бадигыя. Он считал, что основным источником

развития новой терминологии являются внутренние ресурсы языка. В рукописном документе «Термины по фонетике» им представлены термины по фонетике татарского языка, составлен русско-татарский словарь терминов.

В работах Х. Бадигыя уделяется большое внимание проблеме заимствований из русского языка. Словарь татарской терминологии, по мнению ученого, должен пополняться из трех источников – современного татарского литературного и разговорного языка, интернациональных терминов, современных русских терминов. Необходимо использовать в первую очередь словарный запас татарского языка, а в случае отсутствия удачного варианта на нем обращаться к словам русского языка или к интернациональным словам, при этом, считает ученый, желательно учитывать словообразовательные процессы в татарском языке.

В работе «Тенденции лексико-семантического развития современного литературного и разговорного языков рабочих татар и крестьян по материалам экспедиции 1935 г.» [12] Х. Бадигый отчитывается о результатах экспедиции по изучению состояния татарского языка в различных районах республики. В этот период активные процессы в татарском литературном языке становятся объектом пристального внимания ученого, с этой целью он изучает язык периодической печати на материале таких изданий, как «Вакыт» («Время»), «Йолдыз» («Звезда») и «Урал» («Урал»).

Среди работ Х. Г. Бадигыя выделяется труд о тюркских заимствованиях в немецком языке. В статье «Turkische Wörterim Deutschen» [19] автором сделан анализ отдельных тюркских слов, например: *baschlik* (шапка), *turban* (тюрбан), *pilaw* (плов), *schal* (шаль), *saffian* (сафьян) и др., встречающихся в немецком языке.

Как и многие выдающиеся языковеды, оставившие глубокий след в истории лингвистики, Х. Бадигый отличался разносторонностью и широтой научных интересов. Его лингвистическая деятельность включала в себя изучение теоретической и практической грамматики, актуальных проблем графики и орфографии, терминологии, истории литературного языка и языкознания, методики преподавания родного языка, а также общих вопросов развития тюркских языков и др.

В 1920-х гг. начинается интенсивная работа по перестройке научной и школьной грамматик на формальной основе. После того

как вышла в свет монография «Шәкли нигездә татар грамматикасы» («Формальная грамматика татарского языка») (1927) Г. Х. Алпарова [1], на страницах журнала «Мәгариф» были опубликованы рецензии Х. Бадигыя, Ф. Туйки, Й. Губайдуллина и др. Так, в своей объемной статье [8], опубликованной в трех номерах журнала и являющейся результатом подробного и глубокого научного исследования, Худжа Бадигый дает высокую оценку труда ученого. Он пишет, что в книге Г. Алпарова ясно изображены до тех пор бывшие в разрозненном виде внешние факты, заявляет о необходимости их исследования. В архиве хранится документ под названием «Татар теленең шәкли грамматикасы нигезләре» («Основы формальной грамматики татарского языка») [15], в котором представлены выводы, изложенные Х. Бадигыем на совещании по вопросу «Татарской грамматики» [1], созванном педагогическим обществом 5 октября 1928 года.

Как известно, Худжа Бадигый жил и работал в период, ознаменованный значительными преобразованиями в татарской письменности. Являясь большим специалистом в области преподавания родного языка, он не мог оставаться в стороне от этой деятельности. Ученый активно участвовал в издании методических пособий по татарскому языку, в течение долгих лет совместно с М.Х. Курбангалиевым разрабатывал учебники и учебные пособия по татарскому языку [16, с. 45–49], принимал активное участие в создании таких учебников, как «Ана теле дәресләре («Уроки родного языка)» (1919) [4], «Татар теле дәреслеге. Рус мәктәпләре өчен» («Учебник татарского языка. Для русских школ») (1925) [9], «Татар теле грамматикасы дәреслеге» («Учебник грамматики татарского языка») (1931) [5], «Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен» («Книга для чтения. Для школ грамоты») (1938) [6] и др.

Научная и педагогическая деятельность Х. Бадигыя была прервана арестом. Умер он 17 ноября 1940 года. Реабилитирован посмертно.

Богатое собрание рукописей Х. Бадигыя хранится в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова АН РТ [2] и в отделе редких книг научной библиотеки имени Н. И. Лобачевского Казанского федерального университета. Тематика рукописей разносторонняя: лексикология, терминология, графика и орфография, общее языкознание, критика, стилистика татарского языка, история татарского литературного языка и языкознания.

Однако следует отметить, что это наследие изучено в татарском языкознании фрагментарно. До настоящего времени существует настоятельная потребность в обобщающих трудах в данной области.

СПИСОК ИСПОЛЬЗОВАННЫХ ИСТОЧНИКОВ

1. Алпаров Г. Х. Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан, 1926. 196 б.

2. Әхмәтҗанов М. И. Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казань, 2005. 224 б.

3. Әхмәтова-Урманче Ф. В. Татар эпосы. Бәетләр. Казан: Раннур, 2001. 510 б.

4. Бәдигый Х. Ана теле дәресләре / Х. Бәдигый, М. Корбангалиев. – Казан, 1919. 32 с.

5. Бәдигый Х. Татар теле грамматикасы дәреслеге. Казан: Татиздат, 1931. 37 б.

6. Бәдигый Х. Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. Казан, 1938. 119 б.

7. Бәдигый Х. Халык әдәбияты. Мәкальләр, табышмаклар. 1 төп. 1 бүлек. Казань: Образование, 1912. 76 б.

8. Бәдигый Х. Шәкли нигездә татар грамматикасы // Мәгариф. 1928. № 1. Б. 75–84; Мәгариф. 1928. № 3. Б. 60–65; Мәгариф. 1928. № 4. Б. 63–68.

9. Бәдигый Х. Татар теле дәреслеге. Рус мәкт. өчен / Х. Бадигый, М. Корбангалиев. Казань: Издат. комб. татарск. прессы, 1925. 162 б.

10. Бәдигый Х. XV ел эчендә татар әдәби теле // Яналиф. 1932. № 9–10. Б. 84–94.

11. Бәдигый Х. Татар әдәби теленең барышы // Безнең юл. 1930. № 2. Б. 34–40; 1930. № 3–4. С. 38–41.

12. Бәдигый Х. Тенденции роста современного татарского литературного и разговорного языка с лексико-семантической стороны по итогам материалов языковой экспедиции 1935 года // Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н. И. Лобачевского КФУ. № 32 Т.

13. Бәдигый Х. Арабский алфавит у татар (Татарларда гарәп әлифбасы). Рукопись // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19. Оп. 2. Ед. хр. 45.

14. Бәдигый Х. Әлифба һәм орфография мәсьәләләре (ибдәш Алпаров доклады уңае белән) // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19. Оп. 2. Ед. хр. 39.

15. Бәдигый Х. Татар теленең шәкли грамматикасы нигезләре // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19. Оп. 2. Ед. хр. 52.

16. Кадирова Э. Х. Хуҗа Бәдигый – татар теленнән дәреслекләр авторы // Вопросы языкознания и методики преподавания татарского языка в русской школе: сб. ст. Казань: ТДГПУ. 2008. С. 39–50.

17. Муртазина Л. Р. Татар педагогик фикерен өйрәнүнең теоретик һәм методологик нигезләре («Татар педагогик фикере антологиясе»н төзү тәҗрибәсе нигезендә) // TATARICA. 2014. № 1 (2). С. 209–222.

18. Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог: фәнни мәкаләләр җыентыгы. Казан. 2008. 192 б.

19. BadigyKh. Turkische Wörter im Deutschen // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19. Оп. 2. Ед. хр. 47.

*Д. М. Кадирова, Э. Х. Кадирова*

# ХУҖА БӘДИГЫЙНЕҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

## ВОПРОСЫ АЛФАВИТА И ОРФОГРАФИИ (по поводу доклада т. Алпарова)[1]

С преобразованием культуры народов всего Советского Союза на пути социалистической основы и перед тюркскими народами встал вопрос уничтожения остатков феодализма и капиталистической структуры и начался период созидания культурной революции на социалистических началах. Одним из значительных фактов этой культурной революции, несомненно, нужно считать переход от старого арабского алфавита к новому латинскому.

Таким образом, можно констатировать, что все тюркские народы в настоящее время перешли на этот новый алфавит. Факт этот совершился, но вместе с этим фактом перед нами встала целая группа задач нового алфавита, в особенности вопрос орфографии и приспособления латинского алфавита к различным тюркским диалектам, исходя из их специфических особенностей, и вопрос унификации. В настоящее время эти вопросы являются самыми существенными и интересными. Поэтому тов. Алпаров для своего научного доклада избрал именно самую существенную и злободневную, а, кроме того, и ответственную тему.

Тов. Алпаров, как видно из доклада, потратил немало энергии для детальной проработки. Вопрос освещен и разобран всесторонне. Он изучил не только один диалект, а все тюркские диалекты. Он старается разрешить вопрос, исходя из особенностей каждого диалекта. Мне кажется, что он с успехом сумел разрешить многие вопросы; но вместе с этим нужно сказать, что т. Алпаров составил свой доклад в довольно сильном возбуждении, а также заметно чрезмерное увлечение некоторыми вопросами. Такой глубоко продуманный научный доклад, составленный с чистым намерением исправить ошибочные воззрения, если бы был написан более хладнокровно и с некоторой волей терпения, несомненно, с большей эффектностью отразился бы на занятых в этой области людей и явился

[1] *Бадыйгов Х.* Вопросы алфавита и орфографии (по поводу доклада т. Алпарова). 1929 г. 4 марта. Машинопись. ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19, оп. 2, ед. хр. 40.

бы основанием для более правильного разрешения этого вопроса. Я мог бы указать на некоторое особенное его увлечение следующими вопросами. Естественно, я здесь остановлюсь лишь на принципиальных моментах, ибо не могу вдаваться в подробности по той причине, что мне не удалось сидеть над докладом т. Алпарова необходимое для этого время, ибо доклад мне был вручен очень поздно.

1) тов. Алпаров в самом начале своего доклада дает очень много места рассуждениям о звуках, фонеме, буквах, профиле в различиях между ними, а также практическому письму и научной фонетической транскрипции. По моему мнению, эти термины довольно ясны занимающимся вопросами алфавита и орфографии. Никто из занимающихся алфавитом и орфографией не рассматривает звуки человеческой речи, как отдельные физические явления, а всегда от слова «звук» понимает такую же фонему, дающую понятие в человеческом мозгу и являющуюся как бы орудием взаимопонимания в коллективе одного языка, но не употребляет термин «фонема». Собственно говоря, этот термин «фонема» введен в языковедческую литературу франц. лингвистом Фердинандом де Соссюром, а затем через Бодуэн де Куртенэ перешел в среду русских лингвистов. А также термин «орфография» понимают не как научную фонетическую транскрипцию, а как практическое письмо, являющееся орудием взаимного понимания литературного языкового коллектива. Даже кто-либо из наших, напр. хотя бы Хасан Гали, если выступает в печати, защищает всецело фонетический принцип, то и он всегда обсуждает о практическом письме. Поэтому мнение тов. Алпарова: «У нас на местах это не различается, поэтому допускают в алфавитах разные ошибки»,– я считаю проявлением большой смелости.

2) вопрос унификации алфавита, орфографии, а терминов это желание всех трудящихся не только тюркских диалектов, но всех языков мира. Унификация алфавитов и орфографии, конечно, желательно, ибо, поскольку приблизятся между собою алфавиты и орфографии, постолько облегчится взаимоотношение людей и обмен культурными достижениями между народами. Тем самым они приблизятся к интернационалу. Но каким путем возможно прийти к этому – вот весь вопрос в этом. Этого, пожалуй, мы не сумеем достичь сверхсоставленным планом или путем насилия. Бывали времена, когда русское царское правительство стремилось объединить всех народов России одной религией и одним языком, но подобная

мечта не удалась. После революции не только различные народы, но даже и родственные народы, как украинцы и белоруссы, создали себе отдельные литературные языки. Раньше, например, башкиры находились под влиянием татарского литературного языка и после революции, когда появились стремления создания своего литературного языка, многим это показалось даже смешным; им казалось, что разве можно создать литературный язык народа, насчитывающего менее одного миллиона, но вопрос разрешился и башкиры имеют теперь свой отдельный литературный язык. Язык этот с каждым днем развивается.

Как нам известно, тюркские народы имели свои урхунские и уйгурские письмена, но изменившиеся жизненные условия заставили их подпасть под влияние арабской культуры и воспринять их алфавит. Теперь же тюрки, оставляя арабский алфавит в области предания, переходят на новый латинский. Но отнюдь не мерами принуждения, а естественным диалектическим путем, ибо этого требует сегодняшняя структура и культурный рост тюркских народов. Только арабисты не могли вовремя заменить это диалектическое явление. Вот эти факты показывают, что язык во всем своем составе есть создание человеческого коллектива, отображение не только его мышления, но и его общественного строя и хозяйства –отображение в технике и строе речи, равно и в ее семантике. Язык постепенно изменяется и развивается. Это развитие ведет к будущему объединению всех языков, но это объединение последует естественным путем, связываясь с общественным построением языковых коллективов всего мира.

Относительно будущего языка всего мира академик Марр пишет: «Ясное дело, что будущий всемирный язык будет языком новой системы, особой, доселе не существовавшей, как будущее хозяйство с его техникой, будущая внеклассовая общественность и будущая внеклассовая культура. Таким языком естественно не может быть ни один из самых распространенных живых языков мира, неизбежно буржуазно-культурный и буржуазно-классовый, как ни один из мертвых языков не смог стать международным в бывшем новом мире, дооктябрьском, да и в том бывшем мире ни один из них и не намечался вовсе как массово-международный».

Поэтому нам и в вопросе унификации нужно считаться вообще с этой особенностью языка и с общественным строением языкового

коллектива, и избрать не искусственный, а естественный диалектический подход.

3) В отношении взятого тов. Алпаровым принципа унификации алфавита и в особенности орфографии обнаруживается некоторая сбивчивость и неясность. В унификации диалектический подход не проводится последовательно до конца. Путем применения искусственных правил в сближении тов. Алпаров старается заключить их в рамки. Он этим самым как будто бы хочет обеспечить взаимоотношение массы и возможность обмена культурными достижениями.

Но какими искусственными правилами, хотелось бы узнать, какой процент массы возможно обеспечить сближением?

Безусловно, я не выступаю против вопроса унификации, но унификация должна быть разрешена не путем искусственных правил и заключения диалектов в определенные рамки, а именно диалектическим подходом.

Я вполне присоединяюсь к его мнению, что вместо гласных фонем в тюркских диалектах нужно брать общие графемы, ибо в тюркских диалектах нет гласных, которые могли бы образовать в отдельности фонемы. Но и здесь из графем, взятых вместо гласных фонем, я склонен утверждать, что выбранные татаро-башкирами графемы будут более правильными, так как они ими принято и во внимание международное значение этих графем.

В отношении согласных фонем в унификации я присоединяюсь к мнению Ага-Заде, который говорит о том, что каждая графема в отдельных диалектах должна употребляться за определенную фонему.

Поэтому принятие казаками графемы «S» вместо фонемы «Ş», которая употребляется, как и у тюркских народов, также и в международном масштабе и принятие туркменами графем «z» и «s» вместо диффузных фонем «ذ» и «ث», которые у других тюркских народов и в международном масштабе употребляется вместо других фонем, я считаю неудачным.

Также представление тов. Алпарова об оставлении только по одной графемы, графем «г – к», вместо фонем «ғ – г» и «қ – к», будет не совсем правильно, так как, во первых, эти фонемы в тюркских языках уже имеются и они встречаются не только в некоторых словах, но и во многих, и, кроме того, каждый из них в международном масштабе признан как отдельная фонема. Их нужно считать достижением тюркских языков и ни одно достижение древних не должно

оставаться не учтенным и не использованным в новом языковом строительстве.

Поэтому отстранением из алфавита этих графем будет достигнуто не приближение к интернационалу, а, наоборот, отдаление.

4) Мнения и доводы тов. Алпарова относительно орфографии напоминают полемику среди русских лингвистов относительно «Орфографических реформ русского языка», происходившей до революции. Всем известно, что вопрос орфографии в русской печати поднимал неоднократно. По этому поводу среди русских лингвистов и педагогов происходили довольно оживленные обсуждения. Когда масса, педагоги и близкие к массам профессора требовали реформы орфографии русского языка, то некоторые ученые, не желавшие расстаться с ним, за из своих кабинетов: «Ох, такая реформа не возможна – это значит поражение литературного языка, – это против науки и методики. Вы не можете разобрать, что такое практическое письмо». Что же требовалось от реформы? Во-первых, отстранения из орфографии круживших голову молодого поколения и не имеющих никакого значения для живого русского языка букв «Ѣ» и «Ь», а также и некоторых мертвых этимологических окончаний и т. д.

В свое время сторонниками я противниками этих реформ была выпущена целая куча литературы. Заинтересованные вероятно знакомы с этой литературой, например, можно указать следующие:

1. Проф. А. И. Томсон. К теории правописания и методологии его преподавания. Одесса, 1914 г.

2. Проф. А. И. Томсон Реформа в ущерб грамотности и правописания. Одесса, 1904 г.

3. Житомирский – Молох XX века (правописание). Москва, 1915 г.

4. Ушаков – Русск. Правописание. Москва, 1915 г.

5. Сакулин – Реформа орфографии русск. языка. Москва, 1915 г.

6. И. Н. Костин – Правописание – экспериментальная психология. Москва, 1912 г. и т. д.

Как видите, среди противников реформы имена таких известных профессоров, как Томсон и др. ученые. Несомненно, они своими авторитетами временно оттягивали реформу, но в конечном итоге кто же победил – реформаторы или консерваторы? Известно, вопрос разрешился с рабоче-крестьянской революцией. Совершалась реформа.

Основной вопрос не в принципе фонетики или морфологии, а также не в умении отличать разницу между этими двумя принципами. Занимающиеся в этой области, конечно, ясно отличают их друг от друга. Тут, по-моему, нечего «ломиться в открытую дверь», которая для наших работников на местах давно уже открыта. Вопрос – на какой основе создать орфографию, обосновав ли на живом языке без ущерба литературному языку и не оставив места анархии в письме, или же на мертвом языке. Который из них ближе к массе – живой или мертвый язык? Тогда который из них взять за основание практического письма, являющегося символом живого литературного языка? Без сомнения литературный язык, его живую фонетику и живую морфологию, а не мертвый язык и его мертвую этимологию.

Почему на русском литературном языке пишутся слова вроде «возносить, взбивать» через «воз и вз», а «восходить, вскипеть» через «вос, вс», тоже самое слова вроде «сохнуть, сухой», засыхать, сушить» пишутся через «сох, сух, сых и суш», несмотря на одинаковый корень этих слов? Потому, что орфография русского языка обоснована на живом языке и на живой морфологии.

Тов. Алпаров говорит: «У грамотного человека при письме и чтении играет роль общее начертание слов и морфем, которые закрепляются у него в зрительной памяти, путем ассоциации смежности с их значениями. Грамотный человек пишет и читает не по буквам и не по слогам, а по целым словам и фразам. Поэтому в этот период для быстроты чтения и письма очень полезно, чтобы всегда и везде иметь дело только с одинаковыми начертаниями этих значимых элементов языка. Малые количества этих начертаний окажутся легкими для зрительной памяти».

Эти мысли тов. Алпарова, приведенные выше, конечно правильны, т.к. в каждом языке насчитывается несколько тысяч отдельных слов, но при всем желании мы не можем сократить их, чтобы они при письме оказались бы также легкими для зрительной памяти. Несмотря на это, все же мы всегда приобретаем навык правильно писать, читать и понимать. А что касается морфемы, то их в нашем татарском языке, по определению проф. Катанова, всего насчитывается 180. Когда мы получили известный навык правильно писать, читать и понимать несколько тысяч отдельных слов, то спрашивается, ради чего нам нужно сокращать при письме морфемы, которых имеется в языке всего лишь несколько сот? Поэтому, я думаю, если

в башкирском литературном языке приставка глагола прошедшего времени произносится в 16 формах, то и в практическом письме нужно писать в 16 формах.

Наконец, в зависимости от того, насколько мы сумеем составить практическое письмо на основе живого литературного языка, настолько среди отдельных диалектов скорее привьется всеобщее обучение и чем скорее оно распространится, тем самым облегчится взаимоотношение между нами и обмен культурными достижениями.

Говоря вообще о докладе, нужно сказать, что доклад охватывает весьма существенные и ценные материалы, поэтому для более подробного и широкого обсуждения на местах, конечно, желательно было бы появление его в печати.

## ӘЛИФБА ҺӘМ ОРФОГРАФИЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ
### (иптәш Алпаров доклады уңае белән)[1]

Социаль советлар җөмһүриятләре союзында яшәүче башка халыкларның социализм мәдәниятенә күчүләре тәэсире белән безнең дә төрки халыклар дөньясында да иске феодализм һәм капитализм калдыкларын җимерү, яңа социаль мәдәни революция ясау сорый башлады. Бу мәдәни революциянең иң мөһим фактларыннан итеп, хәзерге вакытта билгеле төрки халыкларның иске гарәп әлифбасыннан латин хәрефләре нигезендәге яңа төрек әлифбасына күчүләрен исәпләргә кирәк. Шулай, төрек халыклары яңа әлифбага күчте. Бу инде бездә, факт хәзер. Ләкин шушы факт белән бергә яңадан әлифба, орфография һәм аларны бөтен төрек халыкларының үз шивә хосусиятләренә карап яраштыру, берләштерү кебек мәсьәләләрдән санарга кирәк, шуңа күрә иптәш Алпаров үзенең гыйльми докладына иң җанлы (существующий) һәм дикъкатьне үзенә җәлеп итә торган (злободневный), шуның белән бергә, иң мәшгулиятле теманы сайлый белгән. Иптәш Алпаров үзенең докладына күп энергия куйган, мәсьәләне берьяклы гына түгел, әтрафлы тикшергән, аерым бер шивәне генә түгел, бөтен төрек шивәләрен өйрәнгән, мәсьәләне

---

[1] *Бәдыйги Х.* Әлифба һәм орфография мәсьәләләре (иптәш Алпаров докладына уңае белән). 1928 ел. Кульъязма гарәп шрифтында. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 19 нчы фонд, 2 нче тасв., 39 нчы бер. Алдагы мәкаләнең башлангыч варианты буларак тәкъдим ителә

бөтен шивәләрнең аерым хосусиятләренә карап хәл итәргә тырышкан һәм байтак мәсьәләләрдә, минем аңлавымча, дөрес хәл итәргә муаффәкъть булган. Шуның белән бергә, иптәш Алпаровның докладны артык гасаби хәлдә язуын һәм кайбер мәсьәләләрдә увлекаться итеп китүен дә әйтеп китәргә кирәк. Саф яхшы ният белән, ялгышларны төзәтешү уе белән язылган мондый тирән гыйльми докладны сабырлык һәм салкын кан белән язса, бу мәсьәлә өстендә эшләүчеләргә яхшырак шәүләләнер, мәсьәләләре тагын да дөресрәк хәл ителүләренә сәбәп булыр иде. Шундый артык увлекаться итеп, мөхакәмә иткән мәсьәләләрдән мин түбәндәгеләрне күрсәтер идем. Табигый, мин монда принципиаль мәсьәләләр турында гына тукталам, аларның тәфсиләтенә керешә алмыйм, чөнки танышу өчен иптәш Алпаровның докладлы бик соң бирелде. Шуның өчен аңлау өстендә мин озак утыра алмадым.

1. Иптәш Алпаров үзенең докладының башында аваз, фонема, хәреф, графема һәм алар арасындагы аермаларга, шулай ук гамәли язу белән фәнни фонетик транскрипциягә (научная фонетическая транскрипция) бик күп урын бирә. Минемчә, бу терминнар әлифба һәм орфография белән шөгыльләнүчеләргә бик ачык һәм бик мәгълүм. Әлифба һәм орфография турында сөйли яки яза торган һичкем сөйләм авазларын (звуки человеческой речи) дип кенә карамый, бәлки «аваз» дигән сүздән һәрвакытта кешенең миенә аң бирә торган һәм бер тел коллективының үзара аңлашу коралы булган шул ук фонеманы аңлый, чөнки в языке не звук, а фонема, тик кайчандыр француз лингвисты Фердинанд де Соссюр тарафыннан тел белеме әдәбиятына кертелгән, шуннан Бодуэн де Куртенэ тарафыннан урыс галимнәре арасына күчкән фонема дигән термин гына кулланылмый, шулай ук орфография дигән атамадан гыйльми фонетик транскрипцияне түгел, бәлки бер әдәби тел коллективының үзара аңлашу коралы булган шул ук гамәли язуны аңлыйлар, хәтта бездәге Хәсән Гали кебек кем дә булса берәү орфографиядә йөз процент фонетик принцип дәгъва кылып, матбугатка чыга икән, ул да һаман шул ук гамәли язу турында фикер йөртә. Шуңа күрә иптәш Алпаровның «а у нас на местах это не различается, поэтому допускают в алфавитах разные ошибки» дигән фикере урында эшләүчеләр өстенә җибәрелгән зур батырлык – җөрьәт дип исәплим мин.

2. Бөтен төрек шивәләренең әлифбаларын, орфографияләрен һәм башкаларын берләштерү – унификация мәсьәләсе. Бу, билгеле,

бөтен хезмәт әһелләренең зур теләге, түгел бер төрек шивәләренең генә, бөтен дөнья телләренең, аларның әлифбасының һәм орфографиясенең берләшүләре дә мәтлуб, әлбәттә, чөнки никадәр телләр, әлифбалар һәм орфографияләр үзара якыная төшсәләр, берләшсәләр, шулкадәр билгеле, алар арасында аңлашу, бер-береннән мәдәният һәм иҗтимагыять табышларын алышышу җиңеләячәк. Шулкадәр ул халыклар социализмга якынаячаклар, ләкин моңа нинди юл белән ирешергә мөмкин. Менә бөтен мәсьәлә шунда. Моңа без, әлбәттә, көчләү яки елан хәзерләп бирү белән генә ирешә алмабыздыр. Бар иде вакытлар, царизм правительствосы көчләү юлы белән бөтен Русия халыкларын дин һәм тел ягыннан берләштерергә теләде, ләкин теләк (һич тә) барып чыкмады. Революция булу белән, хәтта украин һәм белорус кебек великорус теленә якын һәм кардәш шивәләр дә аерылып, үзләренә аерым әдәби тел тудырдылар. Элек башкортлар татар әдәби теле тәэсирендә яшиләр иде, революциядән соң башкортларның үз телләрендә әдәби тел тудыру фикере башлангач, кайбер иптәшләр көлделәр, миллионнан да ким халык үзләренә аерым әдәби тел тудыра аламы соң диделәр, ләкин мәсьәлә хәл ителде: башкортларның хәзер үзләренә аерым әдәби телләре булды, ул хәзер көннән-көн киңәеп ята. Төрек халыкларының үзләре тарафыннан иҗат ителгән орхон һәм уйгур язулары бар иде. Бервакыт аларның тормыш шартлары үзгәреп, алар гарәп мәдәнияте тәэсиренә төшәргә, гарәп хәрефләрен кабул итәргә мәҗбүр булдылар. Хәзер шул ук төрекләр күз алдында гарәп хәрефләрен ташлап, латин хәрефләренә яңа әлифбага күчәләр, ләкин һичбер көчләү юлы белән түгел, бәлки табигый, диалектик юл белән, чөнки төрек халыкларының хәзерге иҗтимагый төзелешләре, мәдәни үсешләре шуны тели, тик гарәпчеләр генә бу диалектик хәдисәне алдан күрә алмадылар. «Вот эти факты показывают, что язык во всем своем составе есть создание человеческого коллектива, отображение не только его мышления, но и его общественного строя и хозяйства – отображение в технике и строе речи, ровно и в ее семантике».

Тел үзгәрә һәм һаман киңәя бара, аның бу киңәюе киләчәктә бөтен телләрнең берләшүләренә таба алып бара. Моның өчен телнең үзенең бөтен составы белән кеше коллективы иҗады, аның уйлавының гына түгел, бәлки аның һәм хуҗалык төзелешенең шәүләләнүе икәнен игътибарга алырга кирәк.

Иптәш Алпаров әлифбаларны берләштерүдә диалектлар арасындагы авазларның мәгънәләре ягыннан үзара туры килүчелек законын принцип итеп ала, шуның белән гүя диалектлар арасында үзара аңлашуны әдәби-гыйльми хезмәтләр белән коры диалект асасын бертигез файдалануны тәэмин итмәкче була, ләкин бу принцип үзе тегәрҗеп рәвештә ахырына кадәр алып бара алмый, чөнки бездә бер авазның икенче авазга күчүе диалектлар арасында бик төрле, мәсәлән, татар диалектындагы *ч* авазы башкорт диалектындагы *с* га, казакъ диалектында *ш* га күчә.

Шулай ук татар диалектындагы *с* авазы башкорт диалектында *h* гә, төрекмән диалектында *ĉ* гә күчә һәм башкалар. Шулай итеп, әгәр без унификациядә диалектлар арасындагы аваз мәгънә ягыннан туры килү законын принцип итеп алсак, ул вакытта әлифбалар арасында тулы буталыш булачак һәм латин хәрефләренең халыкара мәгънәләре бөтенләй югалачак.

Ләкин бу берләшү табигый юл белән, бөтен дөнья тел коллективларының иҗтимагый төзелешләре белән бергә бәйләнеп барачак. Киләчәк берләшкән бөтен дөнья теле турында без академик Н. Я. Маррдан түбәндәгеләрне укыйбыз:

«Ясное дело, что будущий единый всемирный язык, будучи языком новой системы, особой, доселе не существовавшей, как будущее хозяйство с его техникой, будущая внеклассовая культура. Таким языком, естественно, не может быть ни один из самых распространенных живых языков мира, неизбежно буржуазно-культурный, буржуазно-классовый, как ни один из мертвых языков не смог стать международным в бывшем новом мире, дооктябрьском до и в том бывшем мире ни один из них и не намечался вовсе как массово-международный».

Шуңа күрә безгә бу унификация мәсьәләсендә дә, гомумән, телнең бөтен хосусияте белән, хосусан бер тел коллективының иҗтимагый төзелеше белән исәпләшергә, сыйнфый юл белән түгел, бәлки табигый юл һәм диалектик юл белән эш итәргә кирәк булыр.

3. Иптәш Алпаров әлифба һәм бигрәк тә орфографияләрне берләштерү өчен алган принципларында бераз адашучылык һәм билгесезлек күрсәтә (обнаруживает).

Унификациядә диалектик юл ахырына кадәр дәвамлы алып барылмый. Шивәләрне үзара сыйнфый кагыйдәләр буенча якынлаштыру юлы белән аларны рамка эченә алырга тели. Ул шуның

белән гүя массаның үзара аңлашуларын, мәдәни табышларны үзара уртаклаша алуларын тәэмин итмәкче була. Ләкин мондый сыйнфый кагыйдәләр юлы белән массаның ничә % якынлашуларын тәэмин итү мөмкин булыр икән?

Мин үзем, әлбәттә, унификациягә каршы түгел, ләкин унификация сыйнфый кагыйдәләр юлы белән аерым шивәләрне рамка эченә алу буенча түгел, бәлки диалектик юл белән булырга тиеш. Шуның өчен иптәш Алпаровның бөтен төрек шивәләрендәге сузык фонемалар өчен уртак графемалар алырга кирәк дигән фикеренә тулы кушылам, чөнки төрек шивәләрендә бер-берсенә башка фонемалар тәшкил итәрлек сузык авазлар юк, ләкин монда даими сузык фонемалар өчен алынган графемалардан татар һәм башкортлар тарафыннан сайланганнарны дөресрәк дип уйлыйм, чөнки алар бу графемаларның халык арасындагысын да игътибарга алганнар.

Тартык фонемаларны унификация турында мин иптәш Агазадәнең һәрбер графеманың һәр шивәдә мәгълүм бер фонемага тиеш дигән фикеренә кушылам. Шуның өчен казакларның башка төрекләрдә һәм халыкара мәгълүм булган *Ş* урынына *S* графемасын алуларын, шулай ук төрекмәннәрнең диффузный ذ һәм ث фонемалары өчен башка төрекләрдә һәм халыкара икенче фонема урынында йөри торган z һәм s графемаларын алуларын уңышсыз саныйм.

3. Шулай ук иптәш Алпаровның *ғ – г, қ – к* фонемалары өчен берәр генә *г – к* графемаларын калдырырга тәкъдиме дөрес булмастыр, чөнки, бердән, бу фонемалар безнең төрек телләрендә берничә генә сүздә түгел, бәлки күп сүзләрдә очрый һәм болар һәркайсы халыкара да берәр аерым фонема булып танылганнар, боларны төрек телләренең байлыгыннан достижение дип исәпләргә кирәк. «Ни одно достижение древних не должно остаться не учтенным и не использованным в новом языковом строительстве». Шуның өчен без бу графемаларны әлифбабыздан чыгарып ташлау белән интернационализмга якынлашабыз түгел, бәлки ераклашабыз гына.

Иптәш Алпаровның орфография турында китергән фикер һәм дәлилләре революциягә кадәр «урыс теле орфографиясе реформасы» турында урыс галимнәре арасында булып үткән низагларны искә төшерә. Һәркайсыбыз беләбез: орфография мәсьәләсе урыс матбугатында да бер генә мәртәбә түгел, берничә мәртәбәләр кузгалып үтте. Бу турыда урыс галимнәре, педагоглары арасында кызу-кызу бәхәсләр булып алды. Кайчан масса, педагоглар һәм

массага якын тора торган профессорлар урыс теле орфографиясе реформасын сорый башлагач, субъект идеологиядән аерыла алмаган яки аерылырга теләмәгән кайбер галимнәр үзләренең кабинетларында утырып: «Ә бу реформа мөмкин түгел. Бу әдәби телне бозу була, бу – фәнгә, методикага каршы, сез гамәли язуны аера алмыйсыз», – дип кычкыра башладылар. Реформада нәрсәләр сорала иде соң? Яшь буынның башларын катыра торган һәм урыс җанлы теле өчен һичбер әһәмияте булмаган *Ѣ* һәм *Ь* хәрефләрен, шулай ук кайбер үлек этимологик бетешләрне урыс орфографиясеннән чыгарып ташлау һәм башкалар сорала иде. Шушы мәсьәләләр турында вакытында яклаучылар һәм каршы торучылар тарафыннан реформа турында әллә никадәр әдәбият туып өлгерде. Кызыксынучылар, бәлки, укыганнардыр. Мәсәлән,

1. Проф. А. И. Томсон. К теории правописания и методологии его преподавания. Одесса, 1914 г.

2. Проф. А. И. Томсон Реформа в ущерб грамотности и правописания. Одесса, 1904 г.

3. Житомирский – Молох XX века (правописание). Москва, 1915 г.

4. Ушаков – Русск. Правописание. Москва, 1915 г.

5. Сакулин – Реформа орфографии русск. языка. Москва, 1915 г.

6. И. Н. Костин – Правописание – экспериментальная психология. Москва, 1912 г. и т. д.

Күрәсез, реформага каршы торучылар арасында профессор Томсон кебек мәшһүр профессорлар һәм күренекле бөек галимнәр дә бар. Билгеле, үзләренең авторитетлары белән вакытлы реформаны буып тордылар. Ләкин ахырда кем җиңде соң: реформаторлармы, консерваторлармы? Мәгълүм.

«Почему на русском литературном языке пишутся слова, вроде “возносить, взбивать” через воз и вз, а “восходить вскипеть” через вос и вс, тоже самое, слова вроде “сохнуть, сухой, засыхать, сушить” пишутся через “сох, сух, сых и суш”, несмотря на одинаковый корень этих слов. Потому что орфография русского языка обоснована на живом языке и на живой морфологии.

Товарищ Алпаров говорит: “У грамотного человека при письме и чтении играет роль общее начертание слов и морфем, которые закрепляются у него в зрительной памяти, путем ассоциации смежности с их значениями. Грамотный человек пишет и читает их по

буквам и не по слогам, а по целым словам и фразам. Поэтому в этот период для быстрого чтения и письма очень полезно, чтобы всегда и везде иметь дело только с одинаковыми начертаниями этих значимых элементов языка. Малые количества этих начертаний окажутся легкими для зрительной помяти". Эти мысли товарища Алпарова конечно правильны, кроме последнего предложения.

Так как в каждом языке насчитывается несколько тысяч отдельных слов, но на все желания мы не можем сократить их, чтобы они при письме оказались так легкими для зрительной памяти. Несмотря на это, все же мы всегда приобретаем навык правильно писать, читать и понимать. А что касается морфемы, то они в нашем татарском языке по определению профессора Катанова всего насчитываются – 180. Когда мы получили известный навык правильно писать, читать и понимать несколько тысяч отдельных слов, то ради чего нам нужно сокращать при письме морфемы, которые имеются в языке только несколько сот? Поэтому я думаю, если в башкирском литературном языке приставка глагола прошедшего времени произносится в 16 формах, то и в практическом письме нужно писать в 16 формах».

Ниһаять, орфографиядә мондый соңгы кагыйдәләр буенча никадәр унификация ясый, никадәр төрек шивәләрен бер-беренә якынлаштыра, аларның үзара якынларын җиңеләйтә алабыз икән, киресенчә, әгәр без һәр шивәнең гамәли язуын никадәр аларның җанлы әдәби телләре нигезендә төзесәк, алар арасында шулкадәр тизрәк гомуми уку (всеобщее обучение), шулкадәр тизрәк таралачак. Алар арасында гомуми уку никадәр тизрәк таралса, аларның үзара аралашулары, бер-берсенең мәдәни табышлары белән файдаланулары шулкадәр тизрәк җиңеләячәкдер.

(Тәрҗемәсе: Наконец, в зависимости от того, на сколько мы сумеем составить практическое письмо на основе живого литературного языка, настолько среди отдельных диалектов привьется всеобщее обучение тем самым облегчится взаимопонимание между ними и обмен культурными достижениями.

Говоря вообще о докладе, нужно сказать, что доклад охватывает весьма существенные и ценные материалы, поэтому для более подробного широкого обсуждения на местах, конечно, желательно было бы появление его в печати.)

## ТАТАРЛАРДА ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ[1]

Гарәпләр VIII йөзләрдә үк инде бөтен Урта Азиядә һәм Көнчыгыш Европада яши торган төрек халыклары белән сәүдә мөнәсәбәтләре башлаганнар иде. Сәүдә капиталы белән бергә гарәпнең дини әлифбасы да билгеле төрек халыклары арасында акрынлап тарала башлый. Гарәп әлифбасы төрек халыклары арасында баштарак уйгур әлифбасы белән янәшә кулланылды. Шулай да XII йөзләрдә төрек халыкларының күбесендә урнашып өлгерде. Фәкать Аксак Тимер һәм Алтын Урда дәүләтләрендә уйгур язуы XIV йөзләргә кадәр гарәп әлифбасы белән тартышып бара алды. Алтын Урда дәүләте таралып, аның өлешендә варис булып калган Казан ханлыгында инде бөтенләй гарәп әлифбасы гына калган иде. Төрекләр гарәп әлифбасының бөтен хәрефләрен алып, шуларга ڭ، گ، ژ، چ، پ، ۋ хәрефләрен арттырдылар. Авазлары булмаса да, ع، ظ، ط، ض، ص، د، ذ، ح хәрефләре дә төрек язуларында кулланылды. Гарәпнең *әлиф, wау, йа* дан гыйбарәт булган өч сузык хәрефләре төрек телләрендәге бөтен сузык авазлар урынына йөртелде.

Дини хорафатлар белән бик нык бәйләнгән, 29 хәрефтән торган бу әлифба сузык авазлар өчен фәкать өч кенә хәреф, тартык аваз хәрефләреннән дә сигезе бөтенләй татар теленә кирәксез булуына карамый, тик изге булганлыкларыннан гына иске татар әлифбасы инде дә бик озак еллар сакланып килде. Шулай да гарәп әлифбасын татар теленә җайлау, төзәтү, хәрефләр арттыру XIX йөзләрдән үк башланган иде. Бу төзәтүләр татар телендә авазлары булып да, гарәп әлифбасында булмаган хәрефләрне шул ук әлифба хәрефләренә нокта яки галәмәтләр арттырудан гыйбарәт булды. Мәсәлән, *п, ч, ж, г, ң, в* хәрефләре беренче ясалган хәрефләр иде. XIX йөзнең соңгы чирегендә Каюм Насыйри баба татар грамматикасы өстендәге кыйммәтле гыйльми тикшеренүе нәтиҗәсендә татар телендә ун сузык аваз барлыгын, татар сүзләрен дөрес язар өчен, ун сузык авазга ун хәреф ясарга кирәклеген тәкъдим итте. Шул ук гарәп хәрефләренә галәмәтләр арттырып, үрнәкләр күрсәтте. Ләкин аның татар язуына кертергә теләгән бу яңалыгы үзе исән чагында кабул

---

[1] *Бәдигый Х., Яфаров Б.* Татарларда гарәп әлифбасы. 1931 ел. Кулъязма гарәп шрифтында. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 19 нчы фонд, 2 нче тасв., 45 нче бер.



Х. Бәдигыйнең «Татарларда гарәп әлифбасы» мәкаләсеннән фрагмент

ителмәде. Шәркый-рус гәзитәсенең редакторы Шахтахтинский тарафыннан тәкъдим ителгән гарәп хәрефләрен төзәтү проектлары да вакытында төрек-татар дөньясын шаулатып үттеләр.

1905 ел революциясендән соң татарларда мәдәни күтәрелеш кызып китте. Берсе артыннан берсе гәзитә-журналлар чыгалар. Хәреф, имля мәсьәләләре матбугат битләрендә тикшерелә башладылар. Татар язуында *е, ә, ү* хәрефләре арттырылды. 1917 ел Февраль революциясендән соң тагын *е, ы, ө, ү* хәрефләре татар язуына керә башладылар.

Менә шушы үзгәрешләр сызыгында бер-берсенә бик нык бәйләнешле хәреф һәм имля төзәтү мәсьәләсе күп еллардан бирле дәвам итеп, бик күп караш һәм агымнар тудырдылар. Бу агымнарны барысын җыйнап, кыскача түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин:

## ХӘРЕФ ТӨЗӘТҮДӘГЕ АГЫМНАР

1. Бер хәреф дә арттырмый, борынгы хәреф әлифбасын яклау ягындагылар (татарның дөньяви һәм рухани феодалларның карашы). Гарәп хәрефләренең төп сызыкларын калдырып, шәкел ягыннан аларны европалаштыру, асты-өсте тигез шәкелләргә ошату (полиграф промышленниклардан Харитонов, миллионер алтынчы Рәмиевләр тәкъдиме).

2. Гарәп хәрефләренең дүрт шәкелдән тик ялгыз язылa торган шәкелләрен генә калдырып язу. Мәсәлән, *Татарстан хөкүмәте* (Әхмәдҗан Мостафа, Г. Нугайбәк, Шаһтахтинский һәм башкалар тәкъдиме).

3. Басма һәм язу өчен гарәп хәрефләренең дүрт шәкеленнән бары баш хәрефләрне генә алып, сүзнең һәммә урыннарында шул хәрефләрне йөртү. Бу хәрефләр Октябрьдән соң койрыкларын кискәләп эшләнгән гарәп хәрефләре булып, аларны гарәпчеләр латин әлифбасына каршы куйдылар (Г. Алпаров, М. Рахманкулов, Г. Шәрәф тәкъдимнәре).

## ИМЛЯ ТӨЗӘТҮДӘГЕ АГЫМНАР

1. Иске имлячылар – язуны төзәтүгә бөтенләй каршы булып, өч сузык аваз хәрефләре (уау, әлиф, йа) нигезендә гарәп имлясы белән татар сүзләрен язу ягындагы мәдәният үсүен күрә алмый торган иске феодализм калдыклары, руханилар агымы. Мәсәлән, *кирәк* сүзе *крк*, *Бәләбәй* не *Блбй* шәкелендә язу кебек.

2. Уртачылар – югарыда күрсәтелгән өч сузык аваз хәрефләре өстенә тагын ه (һәи рәсмия), ۇ (кыска و) хәрефләрен алып, 5 сузык аваз хәрефләре нигезендә язу яклы, тагын бер сузык аваз хәрефе өстәп, алтычылар дип тә йөртелде. Бу агым тарафындагылар әлифбага хәреф арттырмау ягындагы татар либераль буржуа фикерен бик саклык белән алып бардылар һәм татар байларының, промышленникларының теләген үткәрүчеләр.

3. Яңачылар, яки унчылар. Болар татар телендәге 10 сузык авазга 10 хәреф алып, фонетика нигезендә язарга омтылучылар. Каюм Насыйри мәктәбенә ияручеләр һәм аның шәкертләре дип әйтергә мөмкин.

Татар дөньясында хәреф төзәтү, имля мәсьәләсе өстендә сүз көрәштерүләр күбәйгән саен, аңлашылмаулар арта гына барды. Татар имлясын төзәтүчеләр бу турыда ясалган конференция, съезд, киңәшмәләр җеп йомгагы белән уйнаган мәче хәленә төштеләр. Бу чаралар татар язуында, матбугат һәм әдәбиятында анархия тудырудан башка нәтиҗә бирмәделәр, чөнки бу реформаларның нигезе черек иде. Аларның нигезендә һаман шул татар телендәге авазларны шәүләләндерә алмый торган өтер, язу, басмачылык һәм башка мәдәни таләпләргә җавап бирә алмый торган яраксыз тормышсыз гарәп әлифбасы тора иде. Гарәп хәрефләре белән язу һәм уку уңнан сулга карап төзеләләр, һәр хәреф дүртәр шәкелле – баш, урта, ахыр һәм ялгыз хәрефләр (ب ـب ـبـ بـ) булып йөриләр иде. Аннан соң аның хәрефләре өстенә 40 тан артык нокта һәм төрле галәмәтләр куелып язылалар иде. Бу кимчелекләр басмачылык эшләрен (хәреф кисү, кою, җыю эшләрен) бик катлауландыралар. Шуның өчен татар китаплары урыс хәрефләре белән басылган китапларга караганда күпкә кыйммәт төшәләр иде. Шулай ук укытучыларны да һәрбер хәрефнең балаларга дүртәр шәкелне аерым-аерым таныштыру, бик күп нокта һәм билгеләрне балаларның зиһеннәрендә калдыруның читенлеген педагогия өлкәсендәге бик күп тәҗрибәләр күрсәтәләр иде. Шулар өстәвенә хәрефләрне язу машиналарын җайлау, эш йөртү, бухгалтерия, статистика, телеграф эшләрендә куллану, музыка галәмәтләре, стенография ишарәләре төзү өчен яраксыз, тормышсыз икәнен гарәп әлифбасының тарихы ук ачык күрсәтеп тора иде.

Татар дөньясында хәреф төзәтү, имля мәсьәләләренең бик әкрен баруы нәтиҗәләре булмауның башка сәбәпләре дә, әлбәттә, бар иде. Бер яктан, татар феодаллары һәм руханилар, үзләренең

өстенлекләрен сакларга тырышып, бу реформаларга бөтенләй каршы көрәшеп килделәр. Икенчедән, гарәп хәрефләре ислам дине белән бик нык бәйләнеп, аның бер кисәге булуы, татар буржуазиясенә эчке Руссия һәм Көнчыгыш хезмәт ияләрен эксплуатировать итү, үзенең гегемонының саклау коралы булган дингә, дин хәрефләренә саклык белән эш итү файдалы иде. Аннан соң Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләренә полиграф промышленносте татар буржуасы кулында булып, аларның зур гына керешләре көнчыгышка дин китаплары бастырып сатудан килә иде, шуның өчен бу полиграфны тозлар өчен гарәп элифбасына зур үзгәрешләр кертү, әлбәттә, файдалы түгел иде.

## ЯҢАЛИФ ҺӘМ АНЫҢ ӨЧЕН КӨРӘШ

Татар дөньясында гарәп хәрефләрен бөтенләй ташларга, латин элифбасын алырга тәкъдим итеп, 1910 елларда шагыйрь Сәгыйд Рәмиев чыкты. Ул үзенең шушы фикерен Әстерханда чыга торган «Идел» гәзитәсе аркылы таратырга уйлап, мәкаләләр язды, элифба төзеп тәкъдим итте, ләкин ул үзен яклаучыларны таба алмады, хәтта ул вакытларда аны «Диваналар өенә җибәрергә кирәк, акылдан шашкан булырга кирәк», – дип сүктеләр генә. Ул вакытта аңа җирлек тә юк иде әле. Бер фикер булып кына басылып калды. 1910 елда Сәгыйд Рәмиев проекты тарафыннан төзелгән элифба. Аның проекты буенча

Тартык авазлар 24,
Сузык авазлар 11.
Бары – 35.

Сузык авazлар Тартык авазлар

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| a | ئا | f | ف | b | بـ |
| e | ئچ | k | ك | p | پ |
| îe | ۋ | g | گ | t | ت |
| ea | ئه | ṅ | ڭ | ĝ | ح |
| oe | (3) ئۇچ | l | لـ | ĉ | چ |
| eo | چبق | m | م | ĥ | ج |
| a | ئو | n | ن | d | د |
| i | ئی | u | و | z | ز |
| ia | لاكين | h | ھ | r | ر |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| ev | ئولهم | j | ى | ĵ | ژ |
| î | بارميم | ĵ | ٕ | s | س |
| | | | | ŝ | ش |
| | | | | ĝ | ع |

Бу проектында ул «Кушма хәрефләрне бөтенләй кушарга кирәк, чөнки бер-беренә кушып алардан бер хәреф ясарга мөмкин», – ди.

Бу проектның кабул ителүе һәм ителмәве икенче мәсьәлә, ләкин бу проектта, шөбһәсез, бер система бар, ул татар телендә булып та, латин әлифбасында булмаган авазларның билгеләре өчен ярдәмчелеккә 8 лек билгесен куллана. Сузык авазларда кушма хәрефләрне ала, шуның өчен бу проект гыйльми яктан үзенең системасын тулы рәвештә саклаган була.

Гарәп хәрефләрен ташлап, латин әлифбасына күчү идеясен чын мәгънәсе белән Октябрь тудырды, чөнки социализм төзүче төрек-татар пролетариатына гарәп әлифбасының культура революциясен ясарга яраксыз, тормышсыз икәне ачык күренде. Шуңа күрә латин әлифбасына күчү идеясе төрек-татар хезмәт ияләренең теләге булып, Октябрь революциясеннән соң ук килеп чыкты. Бу идеяне тормышка кертү иң элек азәрбайҗан хезмәт ияләре тарафыннан башланды. 1922 елда латин әлифбасы нигезендә яңа төрек әлифбасы төзелеп, рәсми рәвештә гамәлгә куелды. Шуның өчен дә азәрбайҗан хезмәт ияләре башка төрек татар, гомумән, көнчыгыш хезмәт ияләре каршында пионерлык вазыйфасын үтәгәннәр саналалар. Азәрбайҗан җөмһүрияте, Төньяк Кавказ өлкәләреннән башка җөмһүрият һәм өлкәләрдә латинлашкан әлифбага күчү турында конкрет чаралар күрү бигрәк тә Беренче Тюркология съездыннан соң гына башлана.

Бу съездны чакыруның кирәклелеге беренче мәртәбә Көнчыгышны өйрәнүдә бөтенсоюзның гыйльми җәмгыяте тарафыннан күтәрелде. Беренче съезд Мәскәү яңалиф комитеты, Азәрбайҗан җөмһүрияте һәм бөтен Советлар Союзы хөкүмәтенең матди һәм мәгънәви ярдәме белән 1926 елның февралендә Бакуда җыелды. Тулы хәзерлек белән чакырылган съезд төрек-татар хезмәт ияләренә кирәкле гыйльми һәм мәдәни мәсьәләләр арасында иң әһәмиятлесе итеп әлифба мәсьәләсен куйды. Съезд бу мәсьәлә турында бертавыштан түбәндәге революцияне кабул итте:

1. Яңа төрек (латин) әлифбасының гарәп әлифбасына һәм төзәтелгән гарәп әлифбасына караганда артыклыгын һәм техника

ягыннан өстенлек, шулай ук гарәп әлифбасына нисбәтән мәдәни һәм тәрәккый якларыннан бик зур әһәмияте булуын әйтеп китеп, корылтай аны кертүне һәр аерым төрек-татар җөмһүрияте өлкәләрендә аны тормышка үткәрүнең ысулларын һәр җөмһүриятнең, һәрбер халыкның үз эше дип исәпли.

Моның белән бергә корылтай Азәрбайҗан һәм Советлар Союзының аерым җөмһүрият һәм өлкәләрендә (Якутия, Кыргызстан, Ингушстан, Карачай, Чиркәс, Кабардин, Балкар өлкәләрендә, Осетия һәм Чечняда) яңа әлифбаның кертелүен, Башкортстанда, Үзбәкстанда, Төрекмәнстанда һәм Адыгей-Чиркәс өлкәсендә латин нигезендәге яңа әлифбаны кертү юлындагы хәрәкәтне алдынгы эш дип карый. Югарыда күрсәтелгән җөмһүрият һәм өлкәләр тарафыннан яңа төрек әлифбасының кертелүе юлында эшләнгән эшләрне кайнар тәбрик белән каршы алып, корылтай бөтен төрек-татар һәм башка халыкларга үзләрендә дә бу реформаның үткәреләчәген күз алдында тотып, Азәрбайҗан һәм башка җөмһүрият, өлкәләренең тәҗрибәләрен тәкъдим итә.

### ЯҢАЛИФ ТАТАРСТАНДА

Татарстанда латин нигезендәге яңалифкә күчү бик зур каршылыкларга очрады. Яңалиф бик зур көрәшне җиңеп чыкканнан соң гына тормышка керде. Татарстандагы иске әлиф, Яңалиф көрәше, ул гади хәреф төзәтү яки орфография төзү кебек техник бер хәрәкәт кенә булмыйча, тамырланган иске идеология белән пролетариат идеологиясе арасындагы сыйнфый көрәштән гыйбарәт иде. Яңалиф хәрәкәтенең Татарстанда, бигрәк тә Казан шәһәрендә кискен сыйнфый көрәш алуының тарихи сәбәпләре дә, әлбәттә, бар иде: Октябрь революциясенә чаклы татарлар башка төрек-татар халыкларына караганда капитализм хуҗалыгына ныклап аяк басып калган халыклардан саналалар. Татарстандагы капитализм яки сәүдә үзәге дә Казан шәһәре булган, билгеле. Шуңа күрә Казан татар буржазиясенең, татар буржуа укымышлыларының һәм руханиларының иң компакт массасы яшәгән бер шәһәр булып килде. Революциягә чаклы Көнчыгыш як илләре белән сәүдә итеп зур капиталга ия булган Казан-татар буржуасы 17–18 нче елларда эчке Руссия һәм көнчыгыш төрки-татар хезмәт ияләре өстеннән гегемон булып калу идеясен үзенең көн тәртибенә куйды. Ул, бу теләк һәм максатын үткәрү өчен, милли идарә, милли һәм хәрби шуралар, дини идарәләр

төзеде. Дин хезмәтләренә жалованиеләр куйды, көчле гаскәри бүлекләр оештырды. Татар буржуасы тарафыннан оештырылган бу көчнең Октябрь революциясенә, Советлар властена каршы куелган моментлары да Казан татар буржуасының турыдан туры актив катнашуы белән күбесе Казан шәһәрендә булып үттеләр. Казан татар буржуасы элеккеге көчен тәмам кайтарып җитә алмаса да, яхшы ук киң күләмдә эш алып баручы бер көч булып баш күтәрде. Менә шушы эштән соң җанланган татар буржуасы үзенең идеологиясен таратырга кушты. Татарстанда көчле бер агым булып тарала башлады. Китәргә форсат эзләгән чорына туры килеп, хәреф мәсьәләсе кузгалды. Хәрәкәтне татар буржуасы турыдан-туры үзе башламады. Гомумән, пролетариат диктатурасы чорында турыдан-туры эш итәргә буржуа курка. Шуның өчен бу эшне үз идеологиясенә ияргән укымышлылар, милләтчелек баткаклыгыннан чыга алмаган аумакай уң коммунистлар кулы белән эшләргә кереште. Бу таяныч көчләрнең латинга каршы көрәш мәйданында актив катнашулары татар буржуасы планының серләрен бирәләр.

Югарыда китерелгән моментлар Татарстанда латинга күчү башка төрек-татар җөмһүриятләренә караганда аерым характерда, бик нык идеология һәм сыйнфый көрәштән соң гына булуын беркадәр ачып бирсәләр кирәк.

Татарстандагы яңалиф хәрәкәтен азмы-күпме ачып бирү өчен, аны ике чорга бүлеп йөртергә тиеш таптык:

1. Латин идеясе тикшерелә башланудан Беренче тюркология съездына – 1926 елның февраленә чаклы;

2. Шул съездан тәмам гамәлгә куелып беткәнгә, 1931 ел башларына кадәр.

Яңалифкә күчү идеясе башка аерым кешеләр тарафыннан төрки конференция, съездлардагы тәкъдимнәр төсендә яссылана. Мәсәлән, 1919 елда гыйнварда Казанда чакырылган имля конференциясендә Мостафа Сөбги: «Татарлар өчен бердәнбер юл – гарәп хәрефләрен төзәтү түгел – алыштыру, латин әлифбасы кабул итәргә кирәк», – дип тәкъдим итә. 1920 елда Казанда татар-башкорт журналистлары конференциясендә шундый ук тәкъдим ясалып, кызу бәхәсләр теләк төсендә булып кына кала килсәләр дә, бер яктан, гарәп хәрефен ташлап, латин әлифбасына күчү фикере, икенчедән гарәп хәрефләрен нинди юллар белән булса да саклап калу фикере башланган иде инде; чөнки бу вакытлар Азәрбайҗан һәм Төньяк Кавказ өлкәләрендә яңа

төрек әлифбасы (латин системасындагы әлифба) сүздән эшкә күчә башлаган вакытлар иде. 1) латинга каршы яклар – гарәпчеләр башта иске буржуа методы булып йөргән татар халык мәдәниятенең башка төрек-татарлардан алдалыгына, аның Көнчыгыштагы гегемонлыгына, Казан шәһәренең борынгы авторитетына таяндылар. Алар бөтен төрек-татар халыкларының бара торган маягы итеп борынгы черек ислам мәдәниятен, пантюркизм идеясен куйдылар.

Латинчылык идеясенә каршы шуларны куеп, Совет органнары аркылы гына бу идеяне басып калырга теләделәр. Бу фактны түбәндәге тарихи документ бик яхшы ачып бирә. Бу документ 1923 ел, Азәрбайҗан советлары җөмһүрияте тарафыннан Татарстан мәгариф комиссиясе латинга күчү турындагы фикерен соравына каршы Татарстан Гыйльми үзәгенең җибәргән җавап язуыннан гыйбарәт: «Гыйльми мәркәз Татарстанда кабул ителгән имля һәм хәрефне тәкәммел иттерү белән мәшгуль. Кабул ителгән төп нигезләрне үзгәртергә ихтыяҗ юк һәм моны хәзергә мөмкин дә тапмый». Татар мәгарифе принцип ягыннан имля һәм хәреф мәсьәләсе дәверен үтте. Тагын түбәнрәк «...хәреф мәсьәләсе – бөтен ислам галәменә уртак бер мәсьәлә. Телләре ягыннан бер-берсенә якын торган төрек-татар дөньясы исә, хәреф мәсьәләсен дә уртак бер юлдан баруның гыйльми, әдәби, сәяси, иҗтимагый һәм икътисадый яклардан хосусый бер әһәмияте бар..». Моннан соң «эчке Русия татарлары, Кыргызстан, Төркестан һәм Себер илләренең салган эздән барачакларына безнең ышаныч бар».

Мәкаләнең ахырында: «...без бу номерга («Мәгариф», № 2) гарәп хәрефләренең әсасын саклау ягында, латинчылык әсасына каршы булган Г. Алпаров иптәш мәкаләсен басабыз, ди («Мәгариф», 1923, № 2). Гыйльми үзәк рәисе Г. Максудов)[1].

Татарстанда пролетариат диктатурасын тормышка үткәрә торган культура революциясе ясарга җитәкчелек итәргә тиеш булган җөмһүриятнең Гыйльми үзәге башы латинга күчүне масса каршында менә шулай куя.

Гыйльми үзәкнең органы булган «Мәгариф» журналының шул ук номерында Г. Шәрәфнең «Латин хәрефләрен алыргамы, гарәп хәрефләрен ислах итәргәме?» дигән бик озын мәкаләсе басыла. Ул гарәп хәрефләренең бөтен яктан латин хәрефләреннән артыклыгын

[1] Мәгариф. 1923. 2 нче сан. Б. 1.

күрсәтергә көчәнә. Латинчылык идеясенең дә вакытлы гына бер хәрәкәт булуын, тиз бетәчәген ышандырырга тырыша. Совет җәмәгатьчелегенә томан җибәрә. Мәкаләсенең нәтиҗә бүлегендә: «Телләре, мәдәниятләре уртак булган башка төрек халыклары белән мәдәни уртаклашуларны бозмау якларыннан гарәп хәрефләрен алга таба без башка халыкларның да телләренә кертергә ярарлык булуы һәм аларга да керүен тәэмин итә», – ди ул.

1924 елда латинчылык идеясе Мәскәүдә көчәя башлый. Аерым яңалиф комитеты төзелә. Комитет яңа татар әлифбасы проекты төзи. «Эшче» гәзите аркылы бу идея татар эшчеләре арасына тарала башлый.

1924 ел 18 июль – «Эшче» гәзитенең 126 (429) номерында шушы әлифба проекты басылып чыккан иде.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| t | ت ط | j | ج | a | ئا |
| th | ث | k | ک | b | ب |
| u | ئو بوران | l | ل | c | چ |
| û | ئۇچ (3) ئو | m | م | ç | ش |
| u | وتاو | n | ن | d | د |
| x | ح | ŋ | ڭ | dh | ذ |
| y | ي | o | ئ قالدى | e | ەربە — ە |
| z | ز | ö | ئو ئولدى | f | ف |
| ƶ | ژ | p | پ | g | گ |
| j | ى ياسى | q | ق | ĝ | ع |
| e | ێ بلدئ | r | ر | h | ه |
| | | s | ص س | i | ئي |

Мәскәүгә җыелган татар-башкорт мәгариф эшчеләре съездында латин әлифбасы турында да доклад куелгач, гарәпчеләр каршы торалар, нәтиҗәдә принцип ягыннан латин әлифбасына каршы түгел, гамәлгә уздырырга гына каршыбыз» мәмнүмендәрәк бер карар кабул иттерергә муаффәкъ булалар. Шул еллардан башлап, Казанда «Латин дуслар» ирекле оешмасы төзелеп, латинчылык фикерен таратырга керешәләр. Комсомол һәм яшьләр тарафыннан гына оештырылуына карамый, латинчы совет укымышлылары бу оешмада актив катнашып, бергә эшләп килделәр. Гарәп, латин көрәшләре

матбугат битләренә чыкты. Латинчылар гәзитә битләрендә дә бу фикерне тарата башладылар. Шул вакытларда ук эшчеләр арасында, комсомол яшьләр арасында «Латин дуслар» ирекле оешмасы, яңалиф түгәрәкләре, докладлар, дискуссияләр оештырып, бик зур эшләр алып барды, Яңалиф проекты татар хезмәт ияләре арасында таралды.

1924 елда Казанда урыс матбугатында Ш. Измайлов һәм Г. Госмановлар латинны яклап, мәкаләләр белән чыгалар. Гарәпчеләр моңа каршы авторитетлардан мәкаләләр яздырдылар:

1. «Красная Татария»дә ТатарстанҮзәк Башкарма Комитеты председателе Рәүф Сабиров үзенең мәкаләсендә: «Юк белән маташасыз, булмаган эш ул, безнең аннан (латинга күчүдән) башка да кирәк урыннарыбыз бик күп, крестьянга ул (яңалиф) кирәкме?» – дигән төслерәк итеп яңалифчеләргә киңәш бирде.

2. Г. Измайлов гарәп хәрефләрен яклап, бик озын мәкалә белән чыкты (бу мәкаләдә Г. Шәрәф бармагы бар иде)[1].

Аннан соң латин әлифбасының Тюркология съездында куелачагы җаваплы эшчеләргә билгеле була торып, моны яшерергә тырышып, бернинди дә съезд хәзерлеген күрми, саботаж ясадылар. Г. Рәхим «Татарстан делегациясе Тюркология съездына китде» дигән мәкаләсендә «Кайберәүләр съездда үзәк мәсьәлә булып латин-гарәп мәсьәләсе торыр, дип уйлыйлар. Бу дөрес түгел. Съезд һәр нәрсәдән элек гыйльми съезд, шуңа күрә ул үзәк мәсьәлә итеп латин-гарәп мәсьәләсен алмаячак»[2], – дип язды.

Күрәсез, Г. Рәхим әлифба мәсьәләсен гыйльми мәсьәләләр эченә дә кертми. Аныңча съезд ниндидер гыйльми мәсьәләләр генә карарга чакырылган. Совет җәмәгатьчелеге хезмәт ияләренә менә шулай юнәлеш бирделәр. Шул көенчә делегациянең составында күбесе гарәбиләр иде. Алар гүя бөтен төрек-татар җөмһүриятләре өстән дә, астан да койрыклары киселгән гарәп хәрефләрен итәчәкләр. Без латинчылык фикерен җиңеп кайтабыз, – дип съездга киттеләр. Чыннан да, Азәрбайҗан һәм башка җөмһүрият руханилары, гарәпчеләре Татарстан делегациясен латин бәласеннән коткаручы бер көч килә, – дип көткәннәр дә аларны. Ләкин съездга катнашкан җөмһүриятләр бөтен яктан җитешкән хәзерлек, оешкан фикер белән килгәнгә, хәреф мәсьәләсендә Татарстан делегациясе фикеренә кушылмады гына түгел, аларга бик каты отпор бирде. Делегация

[1] *Сәйфи-Казанлы Ф.* Татарлар арасында яңалиф таралмый. Б. 28, 30–33.
[2] Кызыл Татарстан. 1926. 20 март. № 2.

эчендәге Г. Рәхимләр тюркология съезды аркылы башка җөмһүриятләргә дә латин-гарәп көрәшен кертеп җибәрмәкчеләр иде, ләкин барып чыкмады. Алар үзләре бик нык җиңелеп кайттылар. Съезд күпчелек белән латинга күчәргә карар чыгарды.

Гарәпчеләр, монда эш чыкмагач, үзләренә баса торган туфрак эзли башладылар. Баштагы көрәш юлларын көчәйтү өстенә, дин хорафатлары баткаклыгыннан чыгып бетмәгән крестьян массасы арасына коткы салырга, аларның дини хисләрен уятып, аякка бастырыр өчен, озын-озын мәкаләләр, китаплар язып тарата башладылар. Г. Рәхим тарафыннан төзелгән «Беренче тюркология корылтае һәм аның тикшергән мәсьәләләре» дигән җыентык кызып киткән көрәшне план белән алып бару өчен кулланма төсендә чыгарылды. Бу җыентык яңа әлифбага каршы фронт өчен сәяси платформа булып хезмәт итә башлады. Кызып кискен үсеш алган көрәш үзенең барышын шул җыентыкта күрсәтелгән юллар, утыртылган маякларга карата билгеләнде, битлекләр ачылды, көрәш бөтенләй сәяси төс алып китте. Менә шул китапта менә нинди яңа принциплар куела иде[1]: «...без бик яхшы беләбез: гарәп хәрефе ислам белән бәйләнгән булса, латин хәрефе дин белән, 8 челек белән багланган».

«...бер яктан, менә безнең сафта муллалар күренсә, латинчылар сафында тәреле поплар, архирейлар, Ильминский шәкертләре күренәчәкләр» (73 б.). «Гарәпчеләрдә латин әлифбасы хәрефләре белән инҗил белән хәзерге карагруһ монархист урыс профессорлары, миссионер, цензура калдыклары белән баглаячаклар ...» (74 б.).

«...Димәк, гарәпкә каршы аны җимерү фронтында ике лагерьның (латинчылар белән төзүчеләр) бергә эшләве факт. Әмма иҗади эшкә гарәпне җимергәч нинди әлифба бирүдә бераз аерылалар. Ильминский комиссиясе урыс әлифбасы, диде. Татар телендә урыс әлифбасы белән күп китаплар таратты. Ләкин бу мәҗбүри түгел иде. Урыс әлифбасы берәр сәбәп белән гамәлгә керә алмаса, латинны гамәлгә куялар иде. Чөнки төп максат исламлы гарәп әлифбасының юлын кисү иде. Ерак Себернең төньягындагы кайбер кечкенә төрки кабиләләрнең урыс миссионерлары ярдәме белән латин әлифбасын алулары мәгълүмдер...». «...ләкин мәсьәлә Русия белән генә бетми. Ислам белән христиан арасындагы көрәш күп заманнан бирле бөтен Җир йөзе буенча диярлек җәелгән иде...».

[1] *Рәхим Г.* Беренче тюркологик корылтай һәм аның тикшергән мәсьәләләре... Б. 72–74.

«...Димәк, бу әлифба талашы, гарәп-латин фронты төрле вакытта, төрле җирдә, төрле рәвештә була килгәндер. Христиан миссионерлары кулы белән, сәяси куәт аркасында бик күп кечкенә кавемнәргә, урынына, заманына карап, урыс әлифбасы да, латин әлифбасы да бик күп төзелеп бирелде. Бик күп санда шул яңа әлифбада – урыста да, латинда да бик күп басылып буш таралды, Мәскәүдә укылды. Шулай итеп, керәшеннәр яки ойротлар кебек кайбер халыклар «яңа әлифбалы» булдылар. Монда урыс әлифбасы да, латин әлифбасы да йөреде. Шуңар күрә, мәсьәләнең бу ягын караганда, ул Ашмариннар, Ильминскийлар урыс яклы иде дип кенә котылырга юктыр, чөнки мәсьәлә бер исемдә, бер фамилиядә генә түгел, бәлки тарих буенча килеп, бөтен дөньяга таралган киң иске фронттадыр...»[1].

Тюркология съездына чаклы һәм съездда гарәпчеләр «без латинга принцип буенча каршы түгел, тик гамәлгә куярга гына каршы, гарәп хәрефләренә 100% реформа бирелергә тиеш» дигән һәм башка шундый лозунглар буенча көрәш алып барсалар, югарыда китерелгән өземтәләр төп максатларын һич яшерми «ислам берлеге», «милләт берлеге»нә мөрәҗәгать итеп, «латин әлифбасы аркылы татарларны чукындыралар, урыслаштырырга телиләр» дип, караңгы крестьян массасының дини хисләренә таянып эш итәргә чакырдылар.

Югарыда китерелгән мисаллардагы фикерләр белән, панисламист Муса Бигиевнең мәчеттә латинга каршы сөйләве арасында шулай ук бер зур җыелышта пантюркистларның җитәкчеләреннән Мирсәет Солтангалиевнең: «Латинны алу – руслашуга, татарның йотылуына, югалуына хәзерлек өчен корылган бер сәясәттер; шуңа күрә аңа каршы торырга кирәк, урыс хәрефен кертмәкчеләр иде, ул барып чыкмады, хәзер латин аркылы шул максатка бармакчы булалар», – дигән фикерләр арасында нинди аерма бар? Әлбәттә, бернинди дә аерма юк»[2]. Г. Ибраһимовның да «принципчылар һәм реализация, техникачылар» дип гарәпчеләрне икегә бүлеп, дифференцацияләр ясап маташуының бернинди дә нигезе юк иде. Менә бу лагерь, үзләренең максатларына ирешер өчен, хәрәкәт итә торган көрәш көчләре итеп буржуа агуыннан әле котылып җитмәгән крестьяннарга таянырга уйладылар. Г. Рәхим үз китабының 82 нче

[1] *Рәхим Г.* Беренче тюркологик корылтай һәм аның тикшергән мәсьәләләре. Б. 84–85.

[2] Шунда ук. Б. 66.

битендә моны ачык күрсәтә: «...Бөтен төрек дөньясының һәммә крестьянары, һичшиксез, безнең белән баралар, безгә кушылалар...

Шулай итеп без ... бөтен төрек-татар халкының 99,9% ы белән бер позициядә, бер сафта барабыз!» – ди ул. Менә кайдан гарәпчеләр көрәш көчен алырга исәпләгәннәр иде.

Татарстанда, хосусан Казанда бу вакытларда (тюркология съездыннан соң) бу мәсьәлә бик кызып китте. Г. Ибраһимов һәм башка гарәпчеләрнең юлбашчылары матбугат битләрендә, төрле җирләрдә латинга каршы бер-бер артлы чыгышлар алып бардылар.

Яңалифкә һәр җирдә киртә салу көннән-көн артты. Урыннардан яңалиф әдәбияты сораган яңалифчеләргә Г. Рәхим китабын җибәрделәр, ә яңалифчеләрнең мәкаләләрен газета-журналларда бастырмаулар, уку йортларына, төрле учреждениеләргә доклад белән барган яңалифчеләргә «сез Татарстан хөкүмәтенең декретын бозучылар» дип куып чыгарулар, уку йортларындагы яңалифчеләргә «сез яңалиф артыннан йөреп, дөрес укымыйсыз» дип түбән баллар бирүләр, инша язганда, теманы яңалифтән алган студентларны провалить итүләр, хәтта яңалифчеләрне эшен калдыру белән куркыту кебек күренешләр санап бетергесез күп иделәр. Дөрес, мондый хыянәтләр, саботажлар вак кына кебек күренсәләр дә, башта активы бик аз санда гына булган яңалифчеләр өчен зур комачау булып төштеләр[1].

Югарыда саналып киткән кыенлыкларга карамый, яңалиф идеясе Татарстан авылларына, Идел буе татар хезмәт ияләре арасына бик тиз таралды. 1926 елның 8 апрелендә Казанда төзелгән ирекле «Яңалиф» җәмгыяте Коммунистлар партиясенең турыдан-туры җитәкчелеге астында латинчылык идеясен массага таратучы, Татарстанны яңалифләштерүдә эшнең башыннан ахырына чаклы алып баручы бер оешма булды. Ул иң элек үз тирәсенә яңалиф активы оештырды. Бер яктан, гарәпчеләр белән туктаусыз көрәш, дискуссия эшләрен алып барса, икенче яктан, яңалифне гамәлгә кую чараларын күрде. Иң элек үз тирәсенә яңалиф активы оештырды. Латин әлифбасы өстендәге тәҗибәләрне исәпкә алып барып, яңа татар әлифбасының нигезләрен билгеләде, яңа татар әлифбасын төзеде. Татарстан авылларында, завод-фабрикаларда яңалиф ячейкалары оештырып, юлбашчылык эшләрен алып барды. «Яңалиф» газеты һәм «Яңалиф» журналы чыгарып, бөтен татар хезмәт ияләре

[1] *Әлми Г.* Революцияме, реформамы? Мәкаләләр җыентыгы. Сафа Борһан мәкаләсе. Б. 56.

арасында таратты. «Яңалиф» журналы культура революциясе фронтында гаять уңышлы рәвештә эшләп килә. «Яңалиф» җәмгыяте яңалифләштерү планнары төзеде. Бу эштә мәгариф учреждениеләре ярдәм итте. Вакытлы курслар оештырды. Татарстандагы вакытлы матбугатта «Кызыл Татарстан», «Кызыл Армия», «Крестьян газеты», «Кызыл яшьләр» газеталарында, «Авыл яшьләре», «Мәгариф», «Безнең юл» журналлары аркылы яңалифләштерү эшләрен оештырды, яңалиф орфография нигезләрен билгеләү кагыйдәләрен эшләү, боларны рәсмиләштерү турында турыдан-туры катнашты. Кыска гына вакыт эчендә «Яңалиф» җәмгыяте бөтен оешма һәм учреждениеләрдә, уку йортларында яңалиф идеясен кертеп җибәрү, яңалифне гамәлгә кертү буенча өстенә төшкән бурычларны үтәде.

«Яңалиф» дәүләт әлифбасы булгач, «Яңалиф» җәмгыяте, төрек-татар яңалиф әлифбасының 3 нче пленумы карарына таянып, 1929 елның 25 февралендә «Укый-яза белмәүчелекне бетерү җәмгыяте» белән көчләрен берләштереп, наданлык белән көрәш – культура революциясе фронтында эшләп китте.

Татарстанда яңа татар әлифбасының киң хәрәкәт массасының күпчелеге арасына тиз арада таралып өлгерерүенә, әлбәттә, Коммунистлар партиясенең җитәкчелеген, яңа татар әлифбасының массага тиз арада ничек таралуын Татарстан ВКП(б) өлкә комитеты карарларыннан түбәндәге өземтәләр ачык күрсәтәләр:

1. Обкомның моннан элекке карарларында латинизация мәсьәләсенә принцип ягыннан һичбер каршылык булмаганын искә алып, латинчылык хәрәкәтенә кайбер органнарның каршылык ясаулары кебек фактларны ялгыш хәрәкәт дип табарга.

2. Наркомпрос һәм башка тиешле органнарның латинчыларның түгәрәк һәм башка инициатива группаларына ярдәм итүләрен көчәйтергә, шулай ук I баскыч мәктәпләр, техникумнарда һәм башкаларда латин әлифбасын өйрәтү чараларын күрергә һәм татар эшче-крестьяннары арасында латин әлифбасын эшкә ашыруның төп мәгънәләрен һәм юлларын популярлаштыру хәрәкәтләрен көчәйтергә кирәк дип таба (Татарстан өлкә ВКП(б) комитетының 1926 ел октябрь карарыннан).

Инде 1927 ел беренче майда чыгарган карарында өлкә комитеты «Яңалиф» җәмгыяте эшләренә һәм латинчылык кузгалышына мондый бәя бирә: «Кыска гына вакыт эчендә «Яңалиф» җәмгыятенең шактый күп эш эшләгәнлеген, 2000 дән артык членлы күп кенә

санда ячейкалы оешма хәленә килгәнлеген әйтеп үтә. Бу хәл татар хәрефен латинлаштыру фикеренең тормышка яраклы икәнлеген һәм татар хезмәт ияләренең киң катлавында бу фикернең тамыр җәюен күрсәтә», – ди. Шул ук вакытта: «Шуңар карап партия үзәк комитеты бөтен кантком һәм райкомнарга, Совнарком һәм Татарстан үзәк башкармасы фракцияләренә, матбугат органнарына һәм мәгариф комиссариатында хезмәт итүче партиялеләренә “Яңалиф” җәмгыятенә үзләренең игътибар һәм ярдәмнәрен көчәйтергә тәкъдим итә», – дип әйтелә[1].

Партия карарларына һәм яңалифләштерү эшләре идеясенең массалаша башлавына карамыйча, гарәпчеләрнең лидерларынан «Кызыл Татарстан»ның 1927 ел 26 март номерында ачык хатлары басылып чыкты.

Алар үзләренең ачык хатларында:

Латинчы булып йөрүне хәзергә кирәк санамыйбыз, чөнки:

1. Без Октябрьдән соңгы мәдәни үсешебезнең килешеннән өметсезлеккә, ышанмаучылыкка төшүдән ерак торабыз.

2. Социализм төзелеше өчен хәзерге көндә совет тиеннәреннән игътисад ясаганда, һәрбер тиенне тиешле урынына кую өчен зур көч куйган бер чорда, киң күпчелек өчен кирәксез латинчылык кузгалышына акча түгүгә дә кушылмыйбыз», – диләр. Гарәпчеләр «чукындыралар, урыслаштыралар» кебек артта калган крестьян массасының дини хисләрен кузгата торган лозунглары белән дә эш чыкмагач, үзләренең өзекләрен совет теленә күчереп, латинчылык – пессимистлык, Октябрь биргән җимешләренә ышанмаучылык; латинчылык – ул бушка акча түгү, растрата, димәкче булдылар. Бу чыгыш партия, совет сәясәтләренә оешып торырга чакыруда гыйбарәт иде»[2].

Моннан соң өлкә комитеты, хөкүмәт, мәгариф учреждениеләренә, вакытлы матбугат идарәләренә яңалифкә матди һәм мәгънәви ярдәм итәргә һәм каршылыкларны бетерергә кирәк дип тәкъдим иткәч, яңалиф чын-чынлап практикага керә башлагач, гарәпчеләр чыдаша алмый, оешкан хәлдә яңалиф көрәшен партия эчендә кертеп җибәрергә теләп, өлкә комитеты пленумына 82 кеше имзасы белән «гариза» бирделәр.

---

[1] *Сәйфи-Казанлы Ф.* Татарлар арасында яңалиф тарихы. Б. 64, 69.

[2] *Әлми Г.* Революциям, реформамы? Мәкаләләр җыентыгы. Сафа Борһан мәкаләсе. Б. 57.

«Җиде» тарафыннан бирелгән сигналдан соң массаның киң күпчелеге булып, 82 кеше тарафыннан кул куелган гариза мәйданга килеп чыкты. Монысы инде гүя ачыктан-ачык партиягә ультиматум куеп чыккан масса демонстрациясе иде. 82 гаризасы һәм шул рәвештә совет җәмәгатьчелегенең моңа карашы һәм чарасын ачыграк бирү өчен «Яңалиф» җәмгыяте советының 1927 ел 8 июнь җыелышында бер авыздан кабул иткән резолюциясе тарихи документы булганга тулысы белән күчерәбез:

«Яңалиф» җәмгыятенең советы үзенең 8 июньдә булган киң җыелышында, Татарстан өлкә партия комитеты җаваплы секретаре иптәш Хатаевичның пропагандачылар киңәшмәсендә «хәзерге әхваль һәм партия оешмасының хәзерге бурычлары» турындагы реченең «82 гаризасы» дигән бүлеген укыганнан соң, бер авыздан түбәндәге резолюцияне чыгарды:

I. Татарстан өлкә партия комитеты бюросының латин хәрефләре турында 1927 ел 3 майда чыгарган карары, «Яңалиф» җәмгыятенең ВКП(б) фракциясе докладын тыңлаганнан соң чыгарылган иде.

Бу карарында өлкә партия комитеты Татарстанда яңалиф кузгалышына түбәндәгечә бәя бирә: «Кыска гына вакыт эчендә “Яңалиф” җәмгыятенең шактый күп эш эшләнгәнлектән, 2000 нән артык членлы, күп кенә санда ячейкалы оешма хәленә килгәнлеген әйтеп үтә. Бу хәл татар хәрефен латинлаштыру фикеренең тормышка яраклы икәнлеген һәм татар хезмәт ияләренең киң катлавында бу фикернең тамыр җәюен күрсәтә», – диелә.

Шул ук карарда:

«Шуңар карап партия өлкә комитеты бөтен кантком һәм райкомнарга Совнарком һәм Татарстан үзәк башкармасы фракцияләренә матбугат органнарында һәм мәгариф комиссариатында хезмәт итүче партиялеләргә “Яңалиф” җәмгыятенә үзләренең игътибар һәм ярдәмнәрен көчәйтергә тәкъдим итә» дип әйтелә.

Партия комитетының бу карары беренчеләре безнең ирекле нигездә төзелгән һәм көннән-көн үсә барган «Яңалиф» кузгалышына туры хаклы бәя бирүдән гыйбарәт;

икенчеләре ирекле җәмгыятьләрдән берсе булган «Яңалиф» җәмгыятенә Советлар илендәге гомум тәртип буенча җитәкчелек кылудан гыйбарәт;

өченчеләре, эшче-крестьяннарның рәсми органнарын, партия оешмаларын, киң күпчелеге ирекле рәвештә җәмәгать өчен культура

тармагында сызганып хезмәт иткән бер оешмага («Яңалиф» җәмгыятенә) булышлык күрсәтергә өндәүдән гыйбарәт.

Шуңар күрә дә өлкә партия комитетының бу карарын без, партияле һәм партиясез яңалифчеләр, барыбыз да котлап каршы алабыз.

II. «82 гаризасы» дип дан алган бер төркем буржуа интеллигенциясенең петициясе культура эшләрендә – черегән искелекне, идеология ягыннан – татар җәмгыятендә әле дә калган консерваторлыкны, сәяси яктан – НЭП чорында татар буржуасының ирәеп киткәнлеген һәм совет властена каршы көчләрнең татар буржуасы арасында яшәгәнлеген күрсәтә торган, шулай да формасы һәм содержаниесе белән зәгыйфь бер документтан гыйбарәттер.

Алар гаризаларында: «Гарәп хәрефе куллана торган төрек халыкларына латин хәрефләренең бер ягы белән дә артык булмаганлыгы берничә ел барган бәхәсләшүләрдән ачык күренде», – диләр.

Ләкин элек гарәп хәрефе кулланган барлык төрек халыкларында (Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Кавказ илләре, Башкортстан һәм башкаларда) хәзерге көндә латин хәрефләре турында бәхәсләр бөтенләйгә киселеп, латин хәрефләрен чын-чынлап тормышка кую эше киң күләмдә җирләшеп бара. Менә бу хәл, әлеге бер такым «татар интеллигенциясендә» дип йөрүчеләрнең төрек халыклары тормышы, аларның культура үсүләре белән бөтенләйгә таныш булмаганлыкларын, яхуд белә торып, күз дә йоммыйча ялганларга керешкәнлекләрен, оятсыз рәвештә партия оешмаларын алдарга маташканлыкларын күрсәтә.

Алар гаризаларында: «Обкомның бу карарында татар эшче крестьяннары күпчелегенә һәм тырышчан интеллигенциягә көтелмәгән бер нәрсә булды», – диләр.

Обкомның бу карары көтелмәгән бер нәрсә түгел иде. Бәлки ул обкомның моннан бер ел электән бирле чыгарган карарларының дәвамы гына. Шуның белән бергә, көннән-көн татар эшче-крестьяннары күпчелеге эчендә тамырланып барган бу кузгалышны беркетеп үтүдән генә гыйбарәт. Аеруча татарның хезмәткәр зыялылары өчен. Чөнки «Яңалиф» җәмгыятендә хәзерге көндә 2000 нән артык татар укымышлыларының рәсми әгъза булулары һәм татар укытучыларының күпчелеге латин хәрефләре яклы булуы, шулай ук 10 меңләгән татар комсомолының «Яңалиф» кузгалышын тирәнәйтергә» дип чыгарган карарлары, шулар өстенә рабфак вузларда укучы татар эшче-крестьян яшьләренең зур күпчелеге (Казанда,

Мәскәүдә, Свердловскида, Ташкентта һәм башкаларда) яңалифче булулары моңарга ачык шаһид. Менә бу хәл исә «Яңалиф»кә каршы гариза язганнарның эшче-крестьян күпчелегеннән генә түгел, татарның укымышлылар күпчелегеннән дә тәмам арылып, артта торып калганнарын, хәзерге тормыштан бөтенләйгә ераклашканнарын, тәмам искереп-мүкләнеп калганнарын күрсәтә.

«Яңалиф» хәрәкәтенә каршы язылган гаризага кул куючы 82 кеше арасында дистәләгән чех-словак фетнәсе, Колчак контрреволюциясе вакытында шул фетнәчеләр һәм Колчаклар белән бергә советка, татар, башкорт кызыл гаскәрләренә каршы корал күтәреп сугышкан кешеләрнең булуы бу гаризаның яхшы уй белән түгел, яман ният белән язылганын ачык күрсәтеп тора.

Алар гаризаларында: «Октябрь революциясе барлык милләтләргә бөтенләйгә аерылып чыгуга чаклы үзләренчә көн күрергә мөмкин дип игълан кылгач, мондый саф мәдәни мәсьәләләрне күтәрү һәм чишүдә ул милләтләрнең үзләренә мөмкинлек бирелергә, андый мәсьәләләрне администрация чаралары белән чишмәскә тиеш иде», – диләр.

Бу исә Октябрь революциясенең зур бүләкләреннән берсе булган җирле, сулы һәм күпчелеге шул җирле халыктан булган административле республикаларга каршы булу һәм мулла-мунтагай, кулак, мирзаларны эш башына утырткан «милли-мәдәни мөхтәрият» яклы булу дигән сүз. Чөнки республика төзелү аркасында җирле администрацияләр (авыл Советы, волость, кантон, район, үзәк башкарма, комиссариатлар һәм башка администрация дип аталган учреждениеләр) күпчелеге җирле халыктан сайланып куелганнар. Башка бик күп зур эшләр белән бер уңайдан алар саф мәдәни эшләрне дә алып баралар. Гариза язучылар исә Совет органнарының культура эшләренә катнашуларына протест бәян итеп азапланалар. Шулай ук 82 гаризасының төбендә Совет власте принципларына каршылык һәм Советка каршы яман уй уйлап йөрүчеләрнең куллары барлыгы ап-ачык күренеп тора.

III. Бер төркем иске фикерле татар буржуа интеллигентларының болай ирәеп китеп, зыялылар исеменнән дигән булып, бөтен татар хезмәткәр укымышлылары йөзенә кара ягардай гаризалар язып чыгулары, һәм шуңар күрә дә бу гаризага кайбер җиңелчә уйлаган советчы татар зыялыларының да ялгыш кул куеп җибәргән булулары гаҗәп түгел. Шулай да чын күңелдән советчы булган

укымышлылар бу гаризага куйган имзаларын кире алу юлы белән үзләренең җиңелчә уйлау аркасында ясаган хаталарын төзәтерләр дип уйлыйбыз.

Шулай ук моңа чаклы латинмы, гарәпме мәсьәләсендә әйлешәйле икеләнеп йөргән иптәшләрнең менә шундый 82 гаризасы кебек чыгышлардан гыйбрәт алып, гарәп хәрефе платформасына көннән-көн консерватор (карагруһ) бәндәләр елышканлыгын исәпкә алып, бу ике якка аерылган фронтта күпчелек ягына – «яңалиф»-челәргә кушылачакларына һәм яңа әлифбаның җиңелрәк рәвештә тормышка ашуына кулларыннан килгән кадәр булышлык итәрләр дип ышанырбыз. Соңгы көннәрдә шул хәл сизелә дә инде.

Шуның белән бергә, 82 гаризасына кул куючыларның татар эшчән укымышлылары исеменнән сүз сөйләргә бер генә чиметем дә хаклары юк икәнлекләрен әйтеп китәбез.

IV. «Яңалиф» җәмгыятенең урыннардагы ячейкаларын, аерым членнарын һәм күңеле яңалифкә тарткан һәрбер гражданны «Яңалиф» кузгалышын киңәйтү, тамырландыру юлында тагы да сызганыбрак эшләргә өндибез.

«Яңалиф»кә каршы як, киң җәмгыять уе алдында җиңелгәч, соңгы чараларга кереште. Матбугатта сугышып, җыелышларда бәхәсләшеп булдыра алмагач, төрле петицияләр язарга, яшерен имзалар җыйнарга, аерым кешеләрне берәмләп үгетләргә керештеләр. Бу – бер як. Икенче яктан, революция башыннан бирле кара эш эшләп килгән бәндәләр, төрле сылтаулар тапкан булып, революциячән яшь буынның һәм Совет власте белән Коммунистлар партиясенең культура төзү эшенә аяк чалырга тырышалар.

«82 гаризасы» дип йөртелгән документ төбендә әнә шундый кешеләр тарафыннан оештырылган бер нәрсә. Бу кара документка кул куючылар арасында татарлар өчен хәреф имля мәсьәләсен кайгырту түгел, үзе җүнләп татарча яза һәм сөйли белмәгән, туганнан соң ук татарга җирәнеп карап килгән һәм татарның культура эшләрендә бер тиенлек тә йомышы булмаган бәндәләрнең булуы моңа шаһит.

Менә шуларның барысын искә алып, «Яңалиф» җәмгыятенең Үзәк Советы барлык «Яңалиф» ячейкаларын моннан соң аеруча тырышып эшләргә, «Яңалиф» кузгалышын, аеруча эшчеләр, крестьяннар арасында ныграк тамырландырырга өнди.

Урыннардагы «Яңалиф» ячейкаларына моңа чаклы хәреф гарәп яклы булып та, хәзер әнә шундый «82 гаризасы» кебек хәлләрдән

гыйбрәт алып, латинлашу ягына авыша башлаган кешеләргә аеруча күңел биреп, аларга үзләренең уйларын «Яңалиф» ягына борып җибәрергә киң мөмкинлек ачарга, аларга шул юлда булышлык күрсәтергә өндибез. Шушы уңай белән «Яңалиф» җәмгыятенә әгъза булып язылучыларга чын-чыннан «Яңалиф»не яклаучы, аны көчәйтергә тырышучы яңа көчләр дип карарга тиешлекне белдерәбез.

82 гаризасы гарәпчеләрнең сәяси йөзләрен ачып бирде. Бу чыгыш аларның ачык рәвештә соңгы чыгышлары булды. Шуннан гарәпчеләр идән астына киттеләр. Тагы дөресрәк әйткәндә, астыртын эшкә керештеләр. «Яңалиф»не практик тормышка үткәргәндә, боларның саботажлары бик озакка барды. Бу турыда бик күп фактлар булып үтте. Мәсәлән, бик күп җаваплы эшчеләрнең яңалифчә укый-яза белүдә «койрыкта килүләре», яңалифчә язылган кәгазьләргә гарәп хәрефләре белән резолюция салулары бу эштәге бюрократлык, эшкә формаль караулары бик күп булды. Ләкин 7 язучының протесты, 82 гаризасы һәм астыртын булган комачаулары, «Яңалиф» идеясен тарату, яңа татар әлифбасын тормышка кертү эшләрен арттырдылар гына. Бу вакыйгалардан соң Татарстан хезмәт ияләре масса төсендә яңалифне өйрәнә башладылар. Гарәпчеләрнең, телләре бер булган төрек-татар хезмәт ияләре тормыш һәм мәдәнияттә бер-берсеннән ераклашырлар, латин әлифбасы боларны таратыр, дигән фикерләре дә юкка чыкты. 1928 елның июнендә Бакуда Бөтенсоюз күләмендә Яңалиф Үзәк комитеты пленумы булып, Төрек-татар әлифбалары берләштерелделәр. Димәк, бөтен төрек-татар хезмәт ияләренең бер төрле генә әлифбасы булып калды. Бу эш яңа татар әлифбасының тормышлы әлифба икәнен тагын бер мәртәбә күрсәтте.

Берләштерелгән яңа әлифба

| | | | |
|---|---|---|---|
| m | م | a | ئا |
| n | ن | b | ب |
| ŋ | ڭ | c (электә ç иде) | چ |
| o (электә o иде) | ( وُ (سوُلوُ | ç (электә c иде) | ج |
| ө (электә o иде) | (وُ (ئوُچن | d | د |
| p | پ | e | (алды) ﻟ |
| r | ر | ь (электә e иде) | |
| s | س | ә | ه |

| | | | |
|---|---|---|---|
| t | ت | f | ف |
| u | | ƣ | ع (электә g иде) |
| y (электә v иде) | ئو (ئو لەم) | g | گ |
| x | ح | h | ھ |
| ьj (электә y иде) | ئي | i | |
| z | ز | j | ى |
| ƶ | ژ | q | ق (элек тә k иде) |
| ş (электә ш иде) | ش | к | ك |
| v (электә w иде) | و | l | ل |

Татарстан Үзәк башкармасының 1928 елның июнь, ноябрь һәм 1929 елның февраль карарлары белән яңа татар әлифбасы рәсми дәүләт әлифбасы булып расланды. 1928 елда ике айлык яңалиф компаниясе үткәрелде.Фәкать шушы кампаниядә генә Татарстанда 57 мең кеше яңалифчә укырга-язарга өйрәтелде. Партия членнары һәм комсомоллар 100% яңалифләштеләр. 1928/29 уку елларында 200 000 нән артык кеше яңалифчә укырга-язарга өйрәнде. Культура революциясе фронты көчәеп китте. Комсомол культпоходлары оештырылды. Моңарчы никадәр көч һәм акча сарыф итеп, язу машинасы күрә алмаган татар хезмәт ияләре тик җирле материал һәм җирле техник көчләр белән генә язу машиналары эшли торган мастерской тудырдылар. Бу мастерской өр-яңа язу машиналары эшләп чыгару белән генә калмыйча, үзенә кирәкле хәрефләрне штамповка станоклары хәзерләү юлларын да табып, эш җайлады.

Моңа чаклы бер генә данә дә линотип яхуд монотип күрмәгән татарлар, аз еллар эчендә ничә дистәләгән типографларга ия булдылар. 125 еллардан бирле зур мәдәни урын тоткан университетлы Казанда набор машинасы булмавын, әле дә урыс телендә бер генә линотип булуын хәтергә алсак, яңалифләшү безнең нинди зур тарихи культура революциясе факторы булганын тагы да ачыграк аңларбыз[1].

1931 ел башыннан игътибардан Татарстан өлкә комитеты карары һәм Татарстан хөкүмәтенең декреты белән яңалифләшүне 100% гамәлгә кую турында кискен борылыш ясалды. Татарстан инде бөтен эш тармакларында яңалифкә күчте. Ачыграк әйткәндә,

[1] «Татарстанда социализм төзелешенең ун еллыгы» мәҗмугасы. Б. 78.

Коммунистлар партиясенең туры һәм дөрес җитәкчелеге аркасында татар хезмәт массасы алдына Октябрь революциясе тарафыннан куелган зур бурыч эшкә ашырылды. Феодолизм, капитализм идеологиясенә буялган гарәп хәрефләре архивка ташланып, культура революциясе коралы яңа татар әлифбасы Татарстанда 100% тормышка куелды.

Яңалифләшү эшләренең сыйфат якларын яхшырту, җитешсезлекләрне бетерү, яңалиф техникасын тагын да үстерү һәм яхшырту бурычларын тулысы белән үтәүгә хәзер Татарстанда бик зур мөмкинлек һәм бик киң җирлек бар.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТАРАЛУ ҺӘМ АППАРАТЛАРНЫ ҖИРЛӘШТЕРҮ ДӘРӘҖӘСЕ

Татарстан өлкә комитеты, Өлкә комсомол комитеты, Татарстан үзәк башкарма комитеты директивалары нигезендә националь кадрлар хәзерләү сызыгында аппаратларны җирләштерү, Татарстан Бөтенсовет системасында тарату темасын тагын да көчәйтү, татар телен өйрәнү эшләрен оештыру, азчылык милләтләргә үз ана телләрендә эшләрне алып бару өчен мөмкинлекләр тудыру һәм башкалар Татарстан җөмһүрияте һәм шушы эшне тормышка үткәрү оешмалары каршында хәзерге көндә бик әһәмиятле бурычлар саналалар. Аппаратларны җирләштерү, татар телен гамәлгә кую эшләрендә милли сәясәтне практик тормышка кертүдә иң туры һәм дөрес юллар икәнен хәзерге хуҗалык һәм мәдәни төзелештә ирешелгән уңышлар тагын бер мәртәбә дөресләде. Совет аппаратларын масссага якынайту, җөмһүриятне районлаштыру чаралары аппаратларны җирләштерүгә зур уңайлыклар тудырды.

Татарстан җөмһүрияте туганга чаклы үзәкләрдә генә түгел, волостьларда да татар эшчеләре бик аз иде. Мәсәлән, Татарстанда 234 волбашкармаларда, татарлары күп булган волостьлар була торып, барысы 5–6 рус секретаре, 20–25 канцелярия хезмәтчесе, 20–25% ВИК һәм авыл Советы членнары гына булган. Үзәкләрдә фәкать 4% чамасы татар хезмәтчесе исәпләнгән.

1921 елның 25 июлендә Татарстан СИК һәм ГИКлар тарафыннан татар телен гамәлгә кую эше буенча декрет чыгарыла. Үзәк РТя комиссиясе төзелә.

Ләкин 1921–1922 елгы ачлыклар бу эшкә зур комачаулык ясыйлар. Фәкать 1923 елдан башлап, бу эшкә беркадәр шартлар туа, бер

төс алып гамәлгә куела башлый. Мәсәлән, 1921 елны үзәк учреждениеләрдә татар хезмәтчеләре 7,8% булса, 1923 елның беренче маена бу сан 9,7 гә, 1924 елның беренче апреленә 14,0% ка җитә. Ләкин татар хезмәтчеләренең саны шулай үсүгә карамастан, үзәк учреждениеләрдә эш йөртү урыс телендә бара иде. Аларның күбесендә татар телендә эш алып бару тәэмин ителмәгән иде[1].

Ул елларда татар телен эшкә ашыру урыннарда яхшы барды. 1924 елны инде 350 татар авыл Советларының 75% ы эш йөртүне татар телендә алып бара, ә күпчелеге татар булган рус башкармаларының 55 ендә эш йөртүнең күп өлешен татар теленә күчерделәр.

Бу вакытта район күләмендә әһәмиятле булган учреждениеләр арасында бары тик суд, тикшерү учреждениеләре генә сизелерлек уңышларга ирешәләр. Аларның 25% ы эш өйрәтүне һәм судларда сөйләүне татар теленә күчерделәр. Медицина, агрономия һәм ветеринария пунктларында эш начаррак барды, чөнки монда татарлардан квалификацияле кадрлар җитешми иде.

Татар телен эшкә ашыру өчен, биш еллык план төзелер алдыннан, эшләр шул хәлдә тора иде. 1925 елның гыйнвар аенда Үзәк башкарма комитет президиумы бишьеллык планны раслады. Бу 5 еллык план буенча яңа бурычлар, яңа темплар билгеләнде. Шул вакыттан башлап, татар эшчеләрен сыйнфый яктан сайлауга җитди игътибар ителә башлады. Моңар чаклы Үзәк комитет бу якка кирәгенчә игътибар итмәгән. Моның аркасында дәүләт аппаратының кайсыбер тармакларына социаль яктан чит булган элементлар кереп алганнар иде. Үзәк башкарма комитетының 1927 елның март аенда чакырылган хәрби сессиясендә татар телен эшкә ашыру эше тикшерелеп чынлап та эш итү һәм бу эшне бер системага күчерүнең кирәклеген әйтте. Нәтиҗәдә һәр ике телне белгәннәрнең исемлеген төзү тәртибе, кадрлар хәзерләүнең сыйфат якларын үзгәртү кебек чаралар кабул ителде.

1930 елда Татарстанны районлаштыру мөнәсәбәте белән зур күпчелек татарлар булган 28 районны татар районы итеп билгеләп куйды. Бу районнарда уртача хисап белән 84% татарлар тора (татарлары 89–80% булган районнар да бар). Менә шушы районнарда эш башкару һәм язуы багланышларны татар телендә тормышка куелды (1930 елның 9 октябрендә ТатЦик Президиумы карары буенча).

---

[1] «Татарстанда социализм төзүнең ун еллыгы» мәҗмугасы. Б. 177.

Чувашлар торган ике районда (Аксубай һәм Октябрь районнарында) үз эчләрендә эш башкару, эш йөртү эшләре чуваш телендә куелды. Югарыда күрсәтелгән 28 районнан 11 районны, әлбәттә, җирле татарларның процентларын шунда эшләүче татар хезмәтчеләренең процентына чагыштырып карасак, түбәндәге хәлне күрәбез (Үзәк РТя комиссиясе белешмәләре буенча):

| № | Район исемнәре | Гомуми халык исәбеннән татарларның % ы | Гомуми хезмәтчеләр исәбеннән татарларның % ы |
|---|---|---|---|
| 1 | Кама Тамагы | 61,3 | 56 |
| 2 | Дөбъяз | 72,3 | 58 |
| 3 | Дрожжаное | 67,7 | 35,1 |
| 4 | Арча | 77 | 60 |
| 5 | Минзәлә | 56,1 | 32,4 |
| 6 | Тымытык | 90,7 | 88 |
| 7 | Тынтәр | 84 | 88 |
| 8 | Сарман | 89,2 | 78,3 |
| 9 | Мөслим | 77,2 | 75,5 |
| 10 | Норлат | 71 | 58,1 |
| 11 | Кукмара | 77 | 74,5 |

Бу районнарда (Минзәлә, Кукмара һәм Дрожжановский районнардан башка) хезмәтчеләр проценты татарларның тулай санына җавап бирүен күрәбез.

Шул ук тәртип белән азчылык милләтләрнең процентына, шул районнарда эшләүче азчылык милләт хезмәтчеләренең процентын чагыштырып караганда түбәндәге рәвештә күренә:

| № | Район исемнәре | Гомуми халык санына караганда азчылыкның % ы | Гомуми хезмәтчеләр санына караганда азчылыкның % ы |
|---|---|---|---|
| 1 | Кама Тамагы | 6 | 4,7 |
| 2 | Дөбъяз | – | 0,9 |
| 3 | Минзәлә | 1,3 | 2,8 |
| 4 | Тымытык | – | 1,8 |
| 5 | Тынтәр | 14,5 | 8,0 |
| 6 | Тәкәнеш | 7,6 | 1,3 |
| 7 | Мөслим | 4 | 4,7 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Норлат | – | 3,2 |
| 9 | Кукмара | 17 | 4,0 |
| 10 | Дрожжаное | 35 | 56,7 |

Кайбер районнарда националь кадрларны учреждение һәм оешмаларга тарту җитәрлек булып куелмаса да, югарыдагы саннар Татарстан районнарында бөтен Совет системасы оешмаларын җирләштерү эшенең зур уңышларга ирешелгәнен бик ачык күрсәтәләр.

Хәзер инде үзәк учреждениеләрдәге җирләштерү эшләренең дәрәҗәсен күрсәтеп үтик:

Үзәк һәм район учреждениеләрендәге 1926 елдан 1930 елга чаклы хезмәтчеләрнең прцентлары түбәндәгечә булган[1]:

| Учреждениеләр | 1926 ел | 1927 ел | 1928 ел | 1929 |
|---|---|---|---|---|
| Үзәк учреждениеләрдә | 17,7% | 17% | 19,7% | 24,6% |
| Кантон, район һәм волость учреждениеләре | 29,0% | 34,5% | 39,7% | 39% |

1931 елда Үзәк учреждениеләрне үзләштерү дәрәҗәсе

| Учреждение исемнәре | Хезмәтчеләрнең тулай саны | Шуннан татарлар | Шуннан татар җавап эшчеләре | Тулай саннан татарлар, % |
|---|---|---|---|---|
| Наркоматларда | 858 | 295 | 137 | 34,3% |
| Үзәк акча учреждениеләре | 529 | 111 | 37 | 21% |
| Казан шәһәр учреждениеләре | 309 | 97 | 16 | 32,2% |
| Трестларда | 482 | 92 | 9 | 19% |
| Сәүдә һәм кооператив учреждениеләре | 1783 | 585 | 72 | 32,8% |
| Банкларда | 440 | 105 | 11 | 25% |
| Җәмәгать оешмаларында | 7 | 4 | 2 | 57% |
| Уку йорты һәм учреждениеләре | 1003 | 159 | 38 | 16% |
| Багланыш һәм юл эшләре учреждениеләре | 579 | 83 | 44 | 14,8% |
| Барлыгы | 5990 | 1541 | 366 | 26% |

[1] «Татарстанда социализм төзүнең ун еллыгы» мәҗмугасы. Б. 177.

Үзәк учреждениеләрне җирләштерү эшләре буенча эш тармакларында бер төсле түгел. Мәсәлән, Госплан (11,8%), ТСПХ (21%), ВОЗ һәм дәүләт университеты кебек оешма, уку йортларында җирләштерү эшләре арттa баралар. Шуңар карамастан уңышлар бик зур дип әйтми мөмкин түгел. 1929 елның беренче гыйнварында 22 үзәк учреждениегә күтәрелгән 10 татар эшчесе бар иде. Бу сан 1930 елның беренче апрелендә 90 га җиткән, ә инде 1931 елда 9 эш тармагындагы үзәк учреждениеләрдә барлыгы 1541 татар хезмәтчесе, шулардан 366 җаваплы эшче, Наркоматларда 34,3% татар хезмәтчеләре булуын күрсәтәләр[1].

Националь кадрлар хәзерләү эшен тәэмин итүне күтәрү сызыгында турыдан-туры Өлкә комитеты юлбашчылыгы белән югары уку йортлары, техникумнарда укыту эшләрен җирләштерү эшләре башланды.

1931 елның 31 маенда Өлкә комитеты карары һәм инструкциясе нигезендә югары уку йортлары, техникумнар 1931/32 уку елында укыту эшләрен җирле укучылар теленә күчерә башларга тиешләр. Бөтен мөмкинлекләрдән чыгып, бу уку йортлары үзләренә кирәкле фән эшчеләрен тарту, укучыларның сан һәм сыйфат якларын күтәрү, татар телендә бөтен фәннәр буенча терминология төзү, дәреслекләр хәзерләү кебек бик зур эшләр алып баралар.

Совет аппаратларын җирләштерү сызыгында РТя курслары аркылы 7 ел эчендә 2000 гә якын татар эшчеләре хәзерләнде. Болар эчендә: 200 ләп машинада язучылар, 15 ләп стенографистлар.

1931 елда 3 еллык РТя курслары Совет төзелеше техникумына әйләндерелде. Бу техникум социализм төзү темасына җавап бирерлек бик зур бурычлар куеп эшләп бара.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ МАТБУГАТ ДӨНЬЯСЫНДА ТАРАЛУЫ

Татарстан җөмһүриятенең матбугат дөньясында да татар теленең таралуы бик зур уңышларга ирешә. Соңгы бер ел эчендә бөтен төп предприятиеләрдә һәм районнарда басма гәзитләр чыгарыла башлады.

Хәзерге вакытта завод-фабрикалардагы басма газитләрдән һәм район гәзитләреннән башка татар телендә 8 гәзит, 10 журнал чыгарыла. 1931 елда 6 гәзит һәм 10 журналның басма табак саннарын

[1] Үзәк РТя комиссиясе белешмәләре буенча.

арттырырга төзелде. Аларның басма табак саннары 1930 елга 1442, 50 табактан, 31 нче елда 1703, 73 табакка җитәчәк – 18% үсү була[1].

Берничә мисал алып күрсәтергә мөмкин:

1. Сельхозснабжение партия һәм хөкүмәт карарларын игътибарсыз калдыра, татар телен гамәлгә кую, үз сызыкларындагы учреждениеләрне җирләштерү турында администрация шундый «положение» тәкъдим итә: хезмәтчеләр булмаганга, Алабуга һәм Кукмарада аппаратларны җирләштерүне үткәрә алмыйбыз. Бу эш бары 1932 нче елда гына мөмкин булыр», диләр.

2. Кайбер районнарда профсоюз оешмаларын җирләштерү мәсьәләсен колдоговорларга керткәннәрдә, аппаратка татарларны 40, 50 процент кертергә дип куйганнар мөмкинлекләр белән исәпләшергә этәрә.

3. № 14 аптиккә бер хатын керә дә татарча бер даруның хакын сорый, аның ни сораганын кем дә төшенми. Кассада эшләүче Галиева аның белән татарча сөйләшә башлый, ул хатынның сорауларына җавап бирә. Шул вакытта аптека мөдире: «Дару хакын чит кешеләргә әйтергә ни хакың бар?» – дип, Галиевага җикеренә башлый. Галиева аның: «Ул бит урысча сөйләшә белми» диюенә каршы мөдир: «Синең эшең түгел», – ди.

4. Түбән Чаллы тегү мәктәбендә урыслар белән бергә 3 татар хатын-кызлары да өйрәнәләр. Мәктәп мастеры Борисова элекке сәүдәгәр татар хатын-кызларын курстан чыгарырга тырышып йөри, аларга заданиеләр бирми, аларның эшләрен тикшерми. Татарча белүче Андреева татар тегүчеләренә ярдәм итә башлагач, Борисова аны травить итә башлый. Чүпрәк кисәкләре арасына уймак яки җеп уралып качып күренмәсә дә, «Татар хатынары урлаган булса кирәк, тентергә кирәк үзләрен», – ди. Аларны кеше алдында тентиләр, ләкин берни дә чыкмый. Бу күренеш һәр көн диярлек булып тора.

5. Иске Тамашкин мәктәбендә (Чистай районы) – Иске Тамашкин һәм Рождественское авылларындагы балалар укыйлар. Бу авылларда җирле халыкның 80% ы чувашлар. Урыс балалары чуваш балалары белән бергә утырмыйлар, чуваш балалары белән дуслашмыйлар, аларга югарыдан карыйлар, чуваш балаларына «чуваш», «чашка» сүзләрен әйтәләр Урысларның чувашлар белән күмәк бәрелешләре вакытлары да була. Мәсәлән, чуваш балаларына «растрепа», «неряха», «как чув. баба» һ. б. диләр.

[1] «Татарстан җөмһүриятенең 11 еллыгына» мәҗмугасы. Б. 24.

«Пролетариат диктатурасы шартларында 13 ел үсү, Совет Татарстанының культурасына төбеннән үзгәртү керде. Шулай булса да культура төзелешендә ирешелгән уңышлар җитәрлек дип һич тә санарга тиеш түгелләр. Бөтен фронт буйлап социализм һөҗүме, бөтен кискенлеге белән партия һәм эшче сыйныфы алдына әйләнә дә сыйнфый көрәш кискенләшкән вакытта бөтен хезмәт массасын яңа катлаулы һәм җаваплы эшләргә иң кызу темп белән хәзерләү бурычын куя. (ВКП(б) Татарстан өлкә комитетының ноябрь пленумы карарларыннан)

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ШӘКЛИ ГРАММАТИКАСЫ НИГЕЗЛӘРЕ[1]

1. Хәзерге көндә татар теленең шәкли грамматикасы бер дәрәҗә эшләнгән, бу турыда җитәрлек кадәр фикер алышулар булган дип исәпләргә мөмкин. Шуның белән бергә, шәкли грамматиканың кайбер күп нигезләре турында бер-берсенә каршы булган карашлар юк түгел әле. Бу каршы карашлар төзеләчәк дәреслекләрдә архия тууга, тел өстендә эшләүчеләрнең көчләрен юкка әрәм итүгә, укучылар алдында телнең әһәмияте кимүгә сәбәп булуы мөмкин. Менә бу уңайсызлыктан котылу өчен, татар теленең шәкли грамматикасы белән кызыксынучыларның бер урынга җыелып, бергәләшеп фикер алышулары, аңлашулары, шул юл белән бер фикергә килүләре тиеш иде.

2. Шәкли грамматика. Элеккеге грамматикаларыбызның төзелеше безгә мәгълүм. Аларда тел фактлары шәкли категорияләргә (төркемләргә) аерылып, шул категорияләргә карап, системага салынмый, бәлки тел категорияләре белән мантыйк фактлары бергә буталып йөртеләләр иде. Мәсәлән, сарыфка сүз төркемнәреннән фигыльне аңлатырга теләсәк, «эш яки хәлне аңлаткан сүзләр фигыль дип атала» дип тәгъриф итә идек тә, мәгънәләре ягыннан шушы тәгърифебезгә туры килгән сүзләрне фигыль дип атый идек. Аларның шәкли якларына бөтенләй әһәмият бирелми, яки әһәмият бирелсә дә шәкелне мәгънәгә ияртелеп йөртелә иде. Тел фактларын шәкелнең катнашы булмаган мантыйк фактлары белән бергә буталып төзелгән

[1] *Бәдигый Х.* Татар теленең шәкли грамматикасы нигезләре. Кульязма гарәп шрифтында. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 19 нчы фонд, 2 нче тасв., 52 нче бер.

грамматикаларны, гадәттә, «мантыйкый грамматика» дип атыйлар. Шәкли грамматика исә мантыйкый грамматикага каршы куела. Монда тел фактларын тикшерүдә үзәк итеп шәкли алына, шуңа күрә «шәкли грамматика» дип атала. Шәкли грамматикада шәкел белән белдерелмәгән мантыйкый фактларга урын бирелми.

Тел шәкелләренең ике ягы бар: 1) авазлар ягы, 2) шул авазлар белән белдерелгән мәгънә ягы. Шәкли грамматикаларда мәгънәгә бәйләнгән авазлар тезмәләре белән белдерелгән мәгънәләр тикшерелә. Шуңа күрә шәкли грамматикаларны төзүдә ике төрле юл (подход) булырга мөмкин: 1) мәгънәләрдән шул мәгънәләрне белдергән шәкелләрнең авазлар ягына күчү юлы, яки 2) шәкелләрнең авазлар ягыннан аларның мәгънәләренә күчү юлы. Икенчесе беренчесенә караганда ачык тел шәкелләрен өйрәнүдә читкә тайпылудан саклану өчен бердәнбер юл булганлыктан, грамматика төзүдә тел галимнәре арасында шушы соңгы юл кабул ителгән.

3. Грамматика шәкеле. Сүзләр белән белдерелгән төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтнең авазлар аркылы тәгъбир ителүе «грамматик шәкел» дип атала. Төшенчәләр арасындагы бу мөнәсәбәтләр аерым сүзләрдә һәм сүзтезмәләрдә булырга мөмкин. Шуңа карап, грамматика шәкли икегә бүленә: 1) сүз шәкеле һәм 2) сүзтезмәсе шәкеле.

4. Сүз шәкеле. Телебезнең бик күп сүзләре безнең аңыбызда кисәкләргә аерылалар. Алыйк бер сүз, мәсәлән, *эшче*. Менә бу сүз безгә үзеннән-үзе ике кисәктән кушылган кебек булып тора: *эш* һәм *че*. Без моның ике кисәктән кушылганын аны үзебез сизмәстән үзенә охшаган сүзләргә чагыштырып беләбез, мәсәлән, *эшнең, эшме, эшсез, эшчән, эшлә*... Менә шушы сүзләр белән чагыштырудан безнең аңыбызда аларның һәммәсе өчен дә уртак булган бер кисәк аерыла: *эш*.

Шул ук вакытта без *эшче* сүзен тагы икенче төрле сүзләр белән чагыштырудан аңыбызда аларның һәммәсе өчен дә уртак булган бер кисәк аерыла: *эш.*

Шул ук вакытта без «эшче» сүзен тагы икенче төрле сүзләр белән чагыштырабыз. Мәсәлән, *игенче, сөтче, күмерче, тимерче*... бу сүзләрне бер-берсе белән чагыштырудан безнең аңыбызда аларның һәммәсе өчен дә уртак булган тагын бер кисәк аерыла: *эш* һәм *че*. Чагыштыру арасында безнең башыбызга килгән бу сүзләр авазлары ягыннан гына түгел, мәгънәләре ягыннан да *эшче* сүзенә охшыйлар. Димәк, *эшче* сүзе һәр икәвенең аерым-аерым мәгънәләре



Х. Бәдигыйнең «Татар теленең шәкли грамматикасы нигезләре» мәкаләсеннән фрагмент

булган ике кисәккә аерыла икән: беренче кисәкнең аерым торганда мәгънәсе бар, әмма икенчесенең аерым торганда бер дә мәгънәсе юк кебек, ләкин икенче бер сүзгә кушылганда, аның да мәгънәсе була икән, шулай ук икенче кисәгебез беренче кисәккә басым һәм сингармонизм ягыннан да буйсына икән.

Шулай итеп, сүзнең телдә аерым сөйләнми, аерым торганда берәр мәгънә аңлатмый һәм үзе кушылган төп кисәккә басым һәм сингармонизм ягыннан буйсына торган кисәк формаль кисәк дип һәрвакытта алдан әйтелә, үз алдына торганда да мәгънәсе булып телдә аерым сөйләнә торган кисәк материаль кисәк дип атала. *Эшче* дигән сүздә *эш* – материаль морфема яки төп матди кисәк, *че* – формаль морфема яки кушымча. Димәк, бер сүздә шәкли булу өчен, телдә табылырга кирәк: *эшче, эшнең, эшме, эшсез, эшлә.... Игенче, укчы, күмерче, тимерче*.

Исемнең горизонталь (басма) рәтендә шул ук материаль морфема төп бүтән шәкли кисәкләр ( формаль морфема яки кушымчалар белән, вертикаль (ятма) рәтендә шул ук шәкли кисәк (формаль морфема) белән күренергә тиеш.

Менә шундый ике төрле чагыштыру аркасында гына сүзнең кисәкләргә (морфемаларга) бүленүе һәм ул сүздә шәкел барлыгы билгеле була. Әгәр нинди булса да бер сүзгә телдә мондый чагыштырып карарлык ике рәт сүзләр табылмый икән, димәк, ул сүздә шәкел (форма) булырга мөмкин түгел. Шуңа күрә *өчен, белән, күрә, таба, саен* кебек сүзләр – шәкелсез (формасыз) сүзләр.

Димәк, безнең телебездә сүзләр шәкелле (формалы) яки шәкелсез (формасыз) булалар икән. Шуның белән бергә, кайбер сүзләр кисәкләргә (морфемаларга) аерылмый. Шулай булсалар да аларда шәкел (форма) бар дип баралар. Мәсәлән, *урман* һәм *укы* сүзләрен тикшереп карасак, боларда шәкел кисәкләр юк кебек, чөнки бу сүзләрне инде яңадан кисәкләргә бүлү мөмкин түгел. Шулай була торып, болар югарыдагы *өчен, саен* сүзләре кебек бөтенләй шәкелсез сүзләрдән түгел, чөнки боларда шәкел (форма) барлыгын безнең күңелләребез сизенә. *Урман* сүзендә баш килеш һәм берлек шәкеле кисәкләре, *укы* сүзендә фигыль төрлеге (боерыклык), берлек һәм нисбәт шәкел кисәкләре бар. Боларның мондый шәкел кисәкләре барлыгын күзебез күреме күрүен, ләкин бу сүзләрне икенче сүзләр белән чагыштырып караганнан соң, боларда шәкел барлыгын күңелебез бик ачык сизә.

Димәк, кайсыбер сүзләрдә шәкли кисәкнең юклыгы үзе шәкел (форма) игътибар итеlә, икенче төрле әйткәндә, андый сүзләрнең шәкли кисәге (формаль морфемасы) шул була.

Шулай итеп, сүзнең аваз һәм мәгънә буенча төп һәм шәкли кисәкләргә аерылу хосусияте «шәкел» дип атала. Шуның өстенә аваз буенча шәкли кисәк нуль дә булырга мөмкин. Димәк, 1) сүздә һәр шәкел шул сүзне әйтүченең аңында аның матди (материаль) һәм шәкли кисәкләргә аерыла алуы белән туа; 2) бу кисәкләрдән һәр икәвенең үзенә аерым мәгънәсе була; 3) шулай итеп, шәкеле булган һәр сүздә грамматика ноктасыннан караганда бер генә мәгънә түгел, бәлки иң кимендә ике була. Бер үк сүздә берничә шәкли кисәк һәм шуңа карап берничә шәкел булырга мөмкин. Мәсәлән, *сөйләштергәлә* сүзе иң элек бер төп (материаль морфема) белән бер шәкли кисәккә аерыла: *сөйләш+тер*. Аннан соң *сөйләш* сүзе тагы бер төп бер шәкли кисәккә аерыла: *сөйлә+ш*. Шулай итеп, *сөйләштергәлә* дигән сүздә өч шәкел һәм өч шәкли кисәк була.

Иң ахырдан төп (материаль морфема) булып аерылып калган *сөйлә* сүзен яңадан кисәкләргә аерырга мөмкин түгел. Менә мондый сүзнең һәрвакытта алдан әйтелә һәм яңадан кисәкләргә бүленми торган кисәге «тамыр» дип атала. Димәк, һәр тамыр төп була ала, әмма һәр төп тамыр булмаска мөмкин.

Бер үк шәкли кисәкнең берничә шәкли мәгънәсе булырга мөмкин. Мәсәлән, *укыган* сүзендәге *ган* дигән шәкли кисәкнең 4 мәгънәсе бар: берлек, гаиблек, заманлык һәм төркемлек.

Бертөрле үк авазлы булган шәкли кисәкнең бер-берсенә бөтенләй башка булган берничә шәкли (формаль) мәгънәсе булырга мөмкин. Мәсәлән, *кызчык, адәмчек һәм валчык, бөтерчек* дигән сүзләрнең әүwәлге икесендә *чык* дигән шәкли кисәк (формаль морфема) кечерәйтүне, соңгы икесендәге бертөрле матди (материаль) мәгънәдән икенче төрле матди (материаль) мәгънәне, ягъни фигыльдән исем ясалуны белдерәләр.

3) Төрле авазлы булган шәкли кисәкләр (формаль морфемалар) бер үк шәкли мәгънәне белдерергә мөмкин. Мәсәлән, *укый, яза* дигән сүзләрдә *-ый -а* шәкли кисәкләре һәр икәве хәзерге заман мәгънәсе бирәләр.

4) Бер үк шәкли кисәкнең сүзенә күрә аваз төсе үзгәрүгә карап, шәкли мәгънәсе үзгәрмәскә мөмкин. Мәсәлән, *яздыр, ачтыр* дигән

сүзләрдәге *-дыр*, *-тыр* шәкли кисәкләре һәр икәве дәрәҗәлек (баблык) мәгънәсен бирәләр.

Югарыда сөйләнгәннәр аерым сүзләрнең шәкелләре турында булды. Тагы боларга өстәмә итеп, безнең телебездә түбәндәге ярдәмче шәкелләрне күрсәтергә мөмкин.

1. Ике сүзнең янәшә килүе. Мәсәлән, *хатын* һәм *кыз* дигән сүзләрнең үз алларына аерым торганда һәр икәүнең үзләренә караган мәгънәләре бар инде. Шул ике сүзне янәшә китереп, *хатын-кыз* дигән бу сүзләрнең аерым мәгънәләре күз алдына китерелми, бәлки боларның һәр икәвеннән туган уртак бер мәгънә – урыс телендәге *женщина* мәгънәсен аңлыйбыз. Димәк, ике сүзне бергә янәшә китерү белән ике матди мәгънәле сүзләрдән бер матди мәгънәле сүз ясадык. Шуңа күрә янәшәлек ярдәмче шәкел була.

2. Ике сүзнең бергә кушылуы. Мәсәлән, *Кабан күле* дигән сүзне икегә аерырга мөмкин: *Кабан+күл*. Бу ике сүзнең аерым торганда һәр икәвенең аерым матди мәгънәләре бар. Билгеле, грамматика кануны буенча аларны бергә кушкач, инде, аларның аерым мәгънәләре урынына икенче бер матди мәгънә – бер әйбернең исеме аңлатыла.

3. Бер сүзнең кабатлануы. Мәсәлән, *карый-карый кайтдым, озын-озын бүрәнәләр* дигәндәге *карый һәм озын* сүзләрен кабатлау белән аларның мәгънәләренә аерым куәс биргән булабыз.

4. Басым. Мәсәлән, *Карама кара урманда үсә. Карама беләккә, кара йөрәккә* дигән һәр ике җөмләдәге *кара, карама* сүзләре бер-береннән басым белән аерылалар. Шуңа күрә басым ярдәмче шәкел була.

Сүз шәкеле турында сүз барганлыктан, монда телебезнең сингармонизм табигате өстендә дә бераз тукталырга туры килә. Телебездә бер сүздәге авазларның я калын гына, я нечкә генә әйтелү табигате бар. Хәтта *тор-төр, оч-өч, уч-үч, бул-бүл* кебек байтак аваздаш сүзләрнең мәгънәләре бер-берсеннән бары калынлык яки нечкәлекләре белән генә аерылалар. Шуңа күрә сингармонизм табигате шәкел була торгандыр дигән фикер килергә мөмкин. Ләкин мондый аваздаш сүзләрдә калыннарның бертөрле, нечкәләрнең икенче төрле мәгънә аңлатулары телебездә сингармонизм табигате булганлыгыннан килми, чөнки монда бер калын сүз элек бер мәгънәдә булып та, шул ук сүз, бөтенләй нечкәреп китеп, икенче мәгънәгә күчә, ди. Ләкин боларның калыннары башта ук бер мәгънәгә, нечкәләре икенче төрле мәгънәгә куелганнар. Киресенчә, *аз-әз, ач-әч, ачкыч-әчкеч,*

*ачлык-әчлек* кебек сүзләрдә башта калын булып та соңыннан нечкәгә әйләнүләре, калыннарның элекке матди мәгънәләренә йогынты ясамавын күрәбез. Шуңа күрә телебездәге сингармонизм табигате сүз шәкеле ягыннан караганда шәкел булмаска кирәк.

5. Сүзләрнең шәкли төркемнәре (категорияләре). Югарыда без сүз шәкеленең авазлар ягы белән аның мәгънәсе арасындагы тулы муафәкать юклыгын, бер үк шәкли кисәкнең берничә төрле шәкли мәгънәсе барлыгын һәм киресенчә бер үк шәкли мәгънәне берничә төрле шәкли кисәкләр белдергәнен күреп уздык. Телебезнең менә бу хосусияте шәкли кисәкләрне төркемләргә бүлүдә безне бераз уңайсыз хәлгә төшерә. Шуңа күрә безгә монда шәкли кисәкләрнең нинди әсасларга каралып төркемнәргә бүленүләре турында бераз тукталырга кирәк.

Алыйк, мәсәлән, берничә сүз: *укыдым, укыдың, укыды*. Менә бу сүзләрнең ахырларындагы *м, ң,* нуль шәкел кисәкләре нисбәтлек мәгънәсен аңлаталар. Шул ук мәгънәне бераз гына үзгәреш (күплек) белән *укыдык, укыдыгыз, укыдылар* дигән сүзләрнең ахырларындагы *ķ, гыз, лар* шәкли кисәкләреннән дә аңлыйбыз. Тагы югарыдагы сүзләр белән *укыймын, укыйсың, укый, укыйбыз, укыйсыз, укыйлар* сүзләре белән чагыштырып, бу соңгыларының ахырларындагы *мын, сың, (ул), быз, сыз, лар* шәкли кисәкләренең дә нисбәтлек мәгънәсен белдергәннәрен күрәбез. Димәк, без монда авазлары ягыннан бер-берсенә бөтенләй башка булган берничә төрле шәкли кисәкне мәгънәләре ягыннан карап, нисбәт шәкли кисәкләре исме белән бер төркемгә керткән булабыз. Инде шул ук *укыдым, укыдың, укыды сүзләрен бер якдан укыйбыз, укыйсыз, укыйлар* сүзләре белән, икенче яктан, *укыймын, укыйсың, укый, укырмын, укырсың, укыр, укысам, укысаң, укыса* сүзләре белән чагыштырып, аларның ахырларындагы *м, ң* ул шәкли кисәкләренең нисбәтлек мәгънәләренә бөтенләй башка булган тагы икенче төрле мәгънәләре – берлек мәгънәләре булганын күрәбез. Аларның бу соңгы мәгънәләренә караганда, *укыдым, укыдың, укыды* сүзләре белән *укыдык, укыдыгыз, укыдылар* сүзләре арасында инде шәкел ягыннан бик зур аерма бар. Әмма икенче яктан болар белән *укыймын, укыйсың, укый*... сүзләре арасында шәкел ягыннан һич аерма юк. Алай булгач, *укыдым, укыдың, укыды* бу соңгы мәгънәләре белән нисбәтлек мәгънәсе ягыннан бөтенләй бер үк төркемдә булган *укыдык, укыдыгыз, укыдылар* сүзләреннән аерылып, боларга бөтенләй башка шәкелдә булган икенче сүзләр белән

*(укыймын, укыйсың, укый...)* бер төркемдә берләштеләр. Димәк, бу мисалларда да авазлары ягыннан бер-берсенә бөтенләй башка булган шәкли кисәкләрне, шәкли мәгънәләренә карап, берлек шәкли кисәкләре исемендә бер төркемгә керткән булабыз.

Тагын алыйк берничә сүз: *урманга, арбага, укырга, авырганга, укыган*. Менә бу сүзләрнең шәкли кисәкләре *-га* була. Аваз ягыннан һәммәсенең дә бертөрле, ләкин бу шәкли кисәкнең үзенә карап, бик күптөрле шәкли мәгънәсе бар. Мәсәлән, *Гали урманга китде* (юнәлешне аңлата), *Арбага утырдым* (урын), *Укырга килдем* (максат), *Авырганга килә алмадым* (сәбәп) һәм башкалар. Менә бу мисалларда *ға* ның берничә шәкли мәгънәсе булды. Шулай булса да без аны юнәлеш тәмамлыгының шәкли кисәге исемендә бер төркемгә (дөресрәге төркемчәгә) кертәбез. Димәк, шәкли мәгънәләре берничә булып, авазлары бертөрле булган шәкли кисәкләрне дә бер төркемнән саныйлар икән.

Килеш шәкеле кисәкләрен тикшереп карасак, гомумән, без аларның авазлары ягыннан да, мәгънәләре ягыннан бик күптөрле булганларын күрәбез. Шулай булсалар да, без аларны бер шәкли төркемнән саныйбыз, чөнки без аларның икенче бер сүзгә ияреп килүләрен игътибарга алабыз. Димәк, авазлары ягыннан да, мәгънәләре ягыннан да төрле булган шәкли кисәкләрне дә бер төркемгә кертәбез икән.

Шулай итеп, мәгънәләре ягыннан берләшкән һәм үзләренең аерым авазлар характеристикасы булган шәкли тезмәсе сүзләрнең шәкли төркеме дип атала.

Менә шушы югарыдагы хасларга таянып, шәкли кисәкләрне түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин.

1. Нисбәт кушымчалары. Болар ялгыз боерык, үткән заман һәм шарт фигыльләргә ялганалар.

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Языйм* | *яздым* | *язсам* | *-м* |
| *Яз* | *яздың* | *язсаң* | *-ң* |
| *Язсын* | *язды* | *язса* | *-н* |
| *Языйк* | *яздык* | *язсак* | *-ќ-к* |
| *Языгыз* | *яздыгыз* | *язсагыз* | *ғ-г* |
| *Язсыннар* | *яздылар* | *язсалар* | *лар-ләр* |

2. Хәбәрлек кушымчалары. Берләрдә шул ук нисбәт кушымчалары булып, хәзерге заман фигыльләренә җөмләдә хәбәр булып килгән сыйфат фигыльләр генә һәм исемнәргә ялганалар.

| | | |
|---|---|---|
| *Кешемен* | *укыганмын* | *-мын* |
| *Кешесең* | *укыгансың* | *- сың* |
| *Кеше* | *укыган* | *-* |
| *Кешебез* | *укыганбыз* | *-быз* |
| *Кешесез* | *укыгансыз* | *-сыз* |
| *Кешеләр* | *укыганлар* | *-алар* |

3. Тартым кушымчалары. Тартым килеше белән төрләнгән сүзнең нисбәтенә муафикъ, аны ияртүче сүзгә кушыла торган кушымча.

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Минем (миннең)* | *атым* | *алмам* | *-м* |
| *Синең (синнең)* | *атың* | *алмаң* | *-ң* |
| *Аның(булың)* | *аты* | *алмасы* | *-се/-и* |
| *Безнең* | *атыбыз* | *алмабыз* | *-быз* |
| *Сезнең* | *атыгыз* | *алмагыз* | *-гыз/гез* |
| *Аларның* | *аты* | *алмасы* | *–* |

4. Килеш кушымчалары. Безнең грамматикаларыбызда килеш мәсьәләсе өзелеп җиткәне юк әле. Кайбер телчеләребез телебездә килеш юклыгын дәгъва итәләр, бар дигәннәре кайберләре баш килеш белән алты, кайберләре сигез, кайберләре тугыз килеш саныйлар. Килеш барлыгы хәзер хәл ителгән дип исәпләргә ярый. Фәкать хәзер телебездә ничә һәм кайсы кушымчаларны килеш кушымчаларыннан исәпләү мәсьәләсе тора. Минем аңлавымча, килеш кушымчаларыннан исәпләргә тиеш була: берничәләре килеш кушымчасы сингармонизм һәм басым ягыннан үзе ялганган сүзгә буйсынып, ул ялгану белән сүз тышкы яктан караганда үзенең бөтенлеген җуймаска тиеш, икенчеләй, ул кушымча җөмлә эчендә сүзләргә икенче сүзнең (ияртүченең) теләве буенча сөйләүченең үз иркеннән башка ялганып, бер сүзнең икенчесенә мөнәсәбәтен күрсәтергә, шуның өчен җөмләдә тәмамлык булып, аергыч яки хәл булып килә алмаска тиеш. Өченчеләй, ул ялганган сүз җөмлә тышында аерым сөйләнә торган мөстәкыйль сүз исәпләнмәскә тиеш. Менә шушы шартларга туры килә торган кушымчалар безнең телебездә биш булып, шарты уларак баш сүзне (сүзнең килеш белән үзгәргән хәлен) үзен бер килештән исәпләсәк, безнең телләребездә барлыгы алты килеш була.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Баш килеш | *урман* | *өстәл* | *–* |
| Тартым килеше | *урманның* | *өстәлнең* | *-нең* |
| Төшем килеше | *урманны* | *өстәлне* | *-не* |
| Юнәлеш килеше | *урманга* | *өстәлгә* | *-га/-гә -ка/-кә* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Чыгыш килеше | *урмандан* | *өстәлдән* | *-дан/-дән -тан/-тән* |
| Вакыт-урын килеше | *урманда* | *өстәлдә* | *-да/-дә -та/-тә* |

5. Сан кушымчалары. Исемнәрдә һәм гаиб өчен булган фигыльләрдә күплек шәкеле: *урманлар, укыдылар, укыганлар (-лар/-ләр).*

6. Фигыль төркеменең кушымчалары. Монда һәр фигыль төркеменең үзенә караган кушымчалары керә.

7. Заман кушымчалары. Шул ук фигыль төркеменең кушымчалары да булалар.

8. Фигыльләрдә юклык кушымчалары. Калын фигыльләрдә -*ма,* нечкәләрендә -*мә.*

9. Фигыль дәрәҗәсе кушымчалары 1) төп фигыль дәрәҗәсе (нуль); 2) кайтым дәрәҗәсе (*н*); 3) йөкләтү дәрәҗәсе *(-т, -дар/-дәр, -дыр/-тыр, -кар/-кәр, -кыр/-кер, -ар/-р, -кыз/-гыз);* 4) төшем дәрәҗәсе *(н, л)*; 5) уртаклык дәрәҗәсе *(ш);* 6) кабатлау яки сирәкләү *(-гала/-гәлә, -кала/-кәлә, -ыштыр).*

10. Исем дәрәҗәсе. Иркәләү һәм кечерәйтү кушымчалары.

11. Сыйфатлык дәрәҗәсе. Чагыштыру һәм аз итү кушымчалары.

Сүз тезмәсе шәкеле. Сөйләү һәм берәр аң бирү ягыннан берләшкән ике яки икедән артык сүзләрне «сүз тезмәсе» дип атыйбыз. Берничә сүзнең бергә кушылып берәр аң аңлатырлык булып сүз тезмәсе ясалуы өчен, аның эченә кергән сүзләрнең үзләренә караган аерым шәкелләре булулары гына җитми, бәлки сүз тезмәсе үзе дә билгеле төс, билгеле тышкы һәм эчке төзелеш алырга кирәк. Менә шушы сүз тезмәләренең үзләренә караган төзелешләре сүз тезмәсе шәкеле дип атала. Сүз тезмәсе шәкеле нәхәви сүз шәкелләренең мәгълүм бер комбинациясе белән туа, моннан сүзләр нәхәви бәйләнешләренең төп типлары килеп чыга.

Нәхәви бәйләнешләрнең төп типлары. Нәхүнең төп мөндәриҗәсе булган җөмлә һәм аның кисәкләрен билгеләү өчен, алдан телнең төзелешендә сүзләр нинди юллар белән бәйләнүләренә, нинди нәхәви бәйләнешләр барлыгын, аларның типларын билгеләп китәргә кирәк була, җөмлә эченә кергән сүзләр үзара ияручелек, ярашучылык, яки янәшәлек юллары белән бәйләнергә ияручелек санда һәм фисиятдә, килештә яки ярдәмлек сүзләр ярдәме белән булырга, янәшәлектә үз нәүбәтендә исем яки фигыль белән янәшәлек булырга мөмкин. Менә элек боларның кайсылары безнең телебездә табылып-табылмавын, табылганнарының ничә типка аерыла алуларын өзәргә кирәк. Шуннан соң җөмлә һәм аның кисәкләрен билгеләргә мөмкин була.

## ШӘКЛИ НИГЕЗДӘ ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ (Г. Алпаров китабының төзәтелгән 2 нче басмасы чыгу уңае белән)[1]

Телне тикшерү, күзәтү һәм өйрәнүдә форма-шәкелне нигез итү агымы башта Европа, аннан соң урыс тел галимнәре арасында күптән үк башланып, бу мәсьәлә инде бөтендөнья сугышына кадәр үк иҗаби яктан чишелү дәрәҗәсенә ирешкән иде. Урыс теленең грамматикасын шәкли нигездә төзү өстендә урыс тел галимнәре арасында үз вакытында яхшы ук җитди бәхәсләр булып, бу турыда җитәрлек кадәр киң әдәбият туып өлгергән иде. Ләкин Октябрь революциясенә чаклы телне шәкли нигездә күзәтү методлары эшләнеп, саф шәкли нигездә грамматика дәреслекләре төзелеп, бу агым мәктәпләрдә гражданлык алып өлгерә алмады. Мәктәпләрдә грамматиканы һаман шул мантыйкый нигездә, яки ярым мантыйкый, ярым шәкли нигездә төзелгән дәреслекләр буенча укыту дәвам итте.

Октябрь революциясе тормышта икътисади-иҗтимагый зур үзгәреш ясаган кебек, гыйльми, фәнни мәсьәләләрдә дә дөрес карашларның мәйданга чыгуына, фән ияләре арасында тикшерелеп, алар тарафыннан чишелеп тә, иске традицияләр астында күмелеп яктан бик күп иҗатларның тормышка кереп китүләренә сәбәп булды. Мәктәпләрдә иске, яраксыз методлар ташланып, алар урынына яңа иҗади методлар урнашу белән, телне күзәтүдә дә саф фәнни метод – формаль метод кабул ителде. Шәкли нигездә грамматика дәреслекләре, кулланмалар төзелде. Шулай итеп, хәзерге вакытта урыс мәктәп дөньясында формаль грамматика тормышка керде, урынлашты.

Формаль грамматика агымы безгә Октябрь революциясеннән соң гына күчте. Аңа кадәр төзелгән грамматикаларыбыз я бөтенләй мантыйкый нигездә, яки ярым мантыйкый, ярым шәкли нигездә язылганнар иде. Революциядән соң мәктәпләр мөндәриҗә һәм максат ягыннан үзгәреп, эш нигезенә корылу белән, Татарстан Гыйльми үзәге янындагы педагогия комиссиясе тарафыннан I һәм II баскыч мәктәпләр өчен эш нигезенә каратылып яңа программалар төзелгәндә, ана теле программы да формаль грамматикага тәтбикъ ителеп төзелде, аларның аңлатмаларында формаль грамматиканың фәнгә

[1] *Бәдигый Х.* Шәкли нигездә татар грамматикасы (Г. Алпаров китабының төзәтелгән 2 нче басмасы чыгу уңае белән) // Мәгариф. 1928. № 1. Б. 75–84; Мәгариф. 1928. № 3. Б. 60–65; Мәгариф. 1928. № 4. Б. 63–68.

һәм максатка якын булучылыгы, эш мәктәпләрендә телне күзәтүдә формаль методны куллану кирәклеге әйтелде. Шуннан соң формаль грамматика агымы матбугатта да күренә башлады. Бу турыда гыйльми журналларыбызда аерым мәкаләләр, формаль грамматиканы төрек телләренә тәтбикъ итү мөмкин булу һәм булмау турында яхшы ук җитди бәхәсләр дә булып алды. Шулай да күпчелек формаль грамматика ягына авышты. Тел өстендә эшләүчеләребез арасында телебезнең формаль грамматикасы турында эзләнү туды. 1924 елда М. Корбангалиев һәм Р. Газизовлар тарафыннан урыслар өчен төзелеп басылган «Опыт краткой практической грамматики татарского языка» исемле грамматикаларында шәкли нигез итү тәҗрибәсе бар иде. 1925 елның язында Гыйльми Үзәкнең чакыруы буенча профессор А. Н. Самойлович тарафыннан «Төрек телләре формаль грамматикасының әсаслары» турында Казан университетында берничә тапкыр лекцияләр сөйләнде. Шулай итеп, формаль грамматика турында туфрак хәзерләнде, кирәксенүчеләр артты. Ләкин бездә әле югарыда сөйләнгән програмнар, аерым мәкаләләр, лекцияләр тел өстендә эшләүчеләребезнең эзләнүләре, Корбангалиев һәм Газизовларның һәм шул ук профессор А. Н. Самойловичның анатолия төрек теленә каратылып төзелгән «Грамматика османско-турецкого языка» исемле әсәреннән башка, татар теленең үзенә тәтбикъ итеп төзелгән һәм грамматикасының бөтен маузугларын үзендә гәүдәләндергән тулы формаль грамматикабыз юк иде. Аның юклыгы белән тел бабында киң бушлык сизелә иде. Г. Алпаров иптәшнең 1925 елда басылып чыккан «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дигән әсәре тел бабындагы менә шушы бушлыкны тутырды, ул турыдагы зур кимчелекне бетерде. Ул басылып чыгу белән формаль грамматиканы татар теленә тәтбикъ итү мөмкин булу һәм булмау мәсьәләсе үзеннән-үзе чишелде. Моңа кадәр аерым мәкаләләр, лекцияләр, эзләнүләрдән күп узмаган, таркау һәм томанлы хәлдә торган телебезнең тышкы фактларын ачып, шул тышкы фактларга карап татар теленең кануннарын системага салып, формаль метод буенча телне күзәтү юлларын күз алдында гәүдәләндерде. Бу яктан караганда ул грамматикаларыбыз тарихында үзенә аерым урын алырга тиеш.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы»ның безнең өчен икенче яңалыкларыннан – аның телебездә булган барлык кушымчаларны тикшереп, барлап, аларны бер системага салып, алар белән формаль

грамматикаларда файдалану юлларын ачып бирүен санарга кирәк. Кушымчалар безнең бер татар телендә генә түгел, бәлки барлык ялганмалы телләрдә дә иң әһәмиятле урын алган морфологик элементларның берсе, шуның белән бергә, алар моңа кадәр бик аз тикшерелгән, бик аз эшләнгән һәм билгеле бер системага салынмаган иде. 1919 елның 1–12 гыйнварында Казанда гыйльми һәйәт тарафыннан чакырылган хат һәм имля конференциясендә профессор Катанов кушымчалар турында озын гына доклад укып, татар телендә барлыгы 128 кушымча булуын, аларның һәммәсе дә парлы килүен, билгеле системнары барлыгын сөйләгән иде. Ләкин аның ул доклады конференциянең башка материаллары белән бергә матбугатка чыга алмый калды. Ул докладтан хәзерге көндә дә бик нык файдаланырга булыр иде.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы» материалга бай, моңа кадәр башка белгечләребез тарафыннан аз тикшерелгән, аз өйрәнелгән телебезнең аерым маузуглары турында да Алпаров иптәшнең озак утырганы, яхшы ук тирән тикшергәне, билгеле системга салырга тырышканы күренеп тора. Шуның белән бергә, Алпаровның үзе язганча, «телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә» булганча, билгеле аның кимчелекләре, буталчык урыннары, хәтта ялгышлары да булырга мөмкин. Шуның өчен «Шәкли нигездә татар грамматикасы» чыгу уңае белән телебезнең нормаль грамматикасын тикшерү һәм өйрәнү юлында тел өстендә эшләп килгән белгечләребезнең, мәктәпләрдә тел укытучыларыбызның фикер алышулары, бу юлдагы белем һәм тәҗрибәләрен уртаклашулары бик тиешле иде. 1927 елның 15–22 июльләрендә Казанда бөтенсоюз күләмендә беренче мәртәбә чакырылган тел-әдәбият укытучылары конференциясе дә, шушындый ук теләкне әйтеп, грамматикада телнең шәкли ягын нигез итүнең фәнни булуын, тел фактларын күзәтү ягыннан да шәкли нигезнең уңай һәм системлы чыгуын игътибарга алып, мәктәпләрдә телне күзәтүдә моңа кадәр килгән мантыйкый нигезне ташлап, шәкли нигезгә күчүне тиешле тапкан иде. Ләкин мәсьәлә артык яңа булганмы, кирәк телебезнең нормаль грамматикасын тикшерү юлында булсын, кирәк Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» турында булсын, матбугатта әле үзара фикер алышулар, бу юлдагы тәҗрибәләрне уртаклашулар күренми. Шуның белән бергә, вакыт үтә, мәктәпләр кулланмалар, дәреслекләр әзерләүне көтә. Шушы сөйләнгән фикерләрне искә алып, мин, теле-

безнең формаль грамматикасы өстендә эзләнүемнең нәтиҗәсендә туган үз карашларым белән «Шәкли нигездә татар грамматикасы» карашларын бергә чагыштырып, ике караш арасында булган аермаларны, аңлашу уе белән, бу урында күрсәтеп китәргә уйладым.

Фонетика. «Шәкли нигездә татар грамматикасы» башта «Тел һәм сөйләшү, тел гыйлемнәре, грамматика бүлекләре, грамматика нигезләре һәм телебезнең тышкы фактлары» кебек, берничә гомуми маузуглар турында кыскача гына тукталганнан соң, башка гыйльми грамматикаларда кабул ителгән систем буенча өчкә бүленеп төзелгән: 1) Фонетика; 2) Морфология; 3) Синтаксис.

Беренче басмасында башта морфологияне, аннан соң синтаксисны, иң ахырда фонетиканы сөйли, икенче басмасында исә, бу тәртипне үзгәртеп, югарыдагы тәртип буенча фонетикадан башлап китә. Грамматика бүлекләреннән кайсысын алдан сөйләү эше метод мәсьәләсе булганлыктан, бу грамматика мәктәпләр өчен махсус кулланма яки дәреслек итеп төзелмәгәнлектән, бу урында аның тәртибе турында тукталырга туры килми.

Бер безнең татар телендә генә түгел, башка мәдәни телләрдә дә аваз хадисәләре телдә ачыграк һәм аныграк булганга, грамматиканың фонетика бүлеге иң яхшы эшләнгән; аерым сүзләрнең шәкелләре сүз тезмәсенең шәкелләренә бәйләнешле булганга, морфология бүлеге азрак; синтаксис бүлеге исә бөтенләй аз эшләнгән була. Алпаров грамматикасында да без шундый ук хәлне күрәбез. Шуның белән бергә, фонетика дигәч тә, монда татар теленең эксперименталь фонетикасы тикшерелми, бәлки, гомумән тел галимнәре тарафыннан тикшерелеп-өйрәнелеп карарлашкан-урнашкан аваз хадисәләре кануннарын татар теленең авазларына тәтбикъ итеп кенә күрсәтелә, шуңа күрә безгә фонетикадан бигрәк грамматиканың морфология белән синтаксис бүлекләре әһәмиятлерәк.

Телебезнең тышкы фактлары. Формаль грамматика – шәкли нигездә татар грамматикасы булгач, билгеле, тикшерүне иң шушы «телебезнең тышкы фактлары»ннан башларга, аларны барлап, формаль грамматикада аларның кайсыларын бизмән итү мәсьәләсен, икенче төрле әйткәндә, грамматиканың форма-шәкел ягын билгеләп үтәргә кирәк, чөнки формаль грамматика – телнең тышкы хадисәләрен системга салу, форма-шәкел турында сан алу гыйльме, ул телдә ныгып алып урынлашкан тышкы фактлар белән эш күрергә, шуларны тикшереп араларындагы мөнәсәбәтләрен табып кануннар чыгарырга,

шул кануннарны билгеле бер системга салып бирергә тиеш. Шулай булгач, телнең хадисәләренә классификация ясаганда, аларны төркем һәм төркемчәләргә аерып билгеле системга салганда, бу телнең шушы тышкы фактларын үзебезгә бизмән итәбез, корал итәбез. Шуның белән бергә, формаль грамматикада телебезнең бөтен тышкы фактлары түгел, бәлки аларның кайсылары грамматика хадисәләрен бу яки теге яктан системга салуда шәкел булу-булмау ягыннан карап кына тикшерергә тиеш булабыз. Юк исә, телнең тышкы фактлары бик күп: сөйләшкәндә тел белән әйтелеп колакка ишетелгән авазлар, сүзләр, җөмләләр һәм башкаларның һәммәсе дә телнең тышкы фактлары булалар. Формаль грамматикада төрле карашларның тууы да күбрәк телнең менә шушы тышкы фактларыннан кайсыларын бизмән итеп билгеләү, форма-шәкел итеп алуның төрлечә булуыннан килеп чыгарга мөмкин. Алпаров иптәш телебезнең тышкы фактлары итеп түбәндәге 6 төрле фактны саный: 1) ялганмалык; 2) тәртип; 3) кабатлау; 4) сингармонизм; 5) басым; 6) аһәң-тон.

Ялганмалы тип – агглютинирующий тип – телләрдә аң һәм мәгънәнең шәкли төсләрен (оттенокларын) тәгъбир итү өчен төп сүзгә билгеле бер тәртиптә, аннан бөтенләй аерым һәм үзалдына тора торган махсус морфология элементлары – кушымчалар ялганалар. Бу кушымчалар төп сүздән һәм шулай ук бер-берсеннән ачык аерылып торалар. Мәгънәнең һәрбер аерым шәкли төсләре өчен һәрвакытта бер үк төрдән булган кушымчалар кулланыла. Телнең менә шушы хосусияте тел гыйлемендә «агглютинация» дип атала. Урал, Алтай телләрендәге менә шушы ялганмалык хосусияте грамматика хадисәләрен бу яки теге яктан төркемләп системга салган чагында, бизмән-шәкел булып хезмәт итә аламы? Минемчә, «ялганмалык табигате» дөньядагы бөтен телләргә классификация ясап төркемнәргә аеруда бизмән булып хезмәт итсә дә, инде шул бизмән – хосусият белән ялганмалы телләрне башка телләрдән аерып бер төркем ясаганнан соң аның хезмәте шуның белән бетәргә, грамматика хадисәләрендә исә шул ялганмалык табигатеннән туган кушымчалар шәкел булып хезмәт итәргә тиеш. Грамматика хадисәләрендә шәкел итеп «ялганмалык»ның үзен атау белән, аннан туган «кушымчалар»ны атау арасында зур аерма бар: мәгънәнең шәкли төсләрен тәгъбир итү өчен, төп сүзгә билгеле тәртиптә кушымчалар ялгана торган телләрне аерым бер төркем ясап, аларны «ялганмалы телләр» дип атасак та, шул ук ялганмалы телләрнең эченә кереп граммати-

ка хадисәләрен тикшерә башлаганнан соң, кайбер сүзләргә шул ук кушымчаларның ялганмавын күрәбез, менә шуңа карап, сүзләрне кушымчалана һәм кушымчаланмый торган ике төркемгә, икенче төрле әйткәндә, үзгәрә һәм үзгәрми торган сүзләргә бүләргә мөмкин. Шулай булгач, грамматикада шәкел итеп «ялганмалык»ның үзен түгел, бәлки аннан туган «кушымчалар»ны алырга кирәк була.

Телебезнең тышкы фактларыннан икенчесе итеп Алпаров иптәш «тәртип»не саный. 12 нче биттә: «Кайвакыт безнең телебездә сүзләрнең мәгънәгә бәйләнгән тышкы төре кушымча белән дә, ярдәмлекләр белән дә беленмәскә мөмкин, бу вакыт аны бер сүз тезмәсендәге тәртибенә, җөмләдә торткан урынына карап танырга тиеш булабыз. Шуңа күрә безнең җөмләләребездә сүзләрнең нинди тәртиптә тезелеп әйтелүләре дә бик әһәмиятле урын тота, чөнки җөмләдә сүзнең тәртибен үзгәртү белән, күп вакыт әйтергә теләнгән мәгънә дә үзгәреп китүчән була. Мәсәлән: *Аю адәм ашаган* яки *Адәм аю ашаган* дигән җөмләләрнең беренчесендә без, сүзнең тәртибенә карап, ашаучы аю, ашалган нәрсә адәм икәнне, икенчесендә моның киресе булганны аңлыйбыз...» ди. Шул ук тәртип турында 125 нче биттә: «Безнең телебездә җөмлә төзелешенең иң әһәмиятле ягы – сүзләрнең тәртибе. Бездә бер җөмлә эчендәге сүзләр, төрле кушымча һәм ярдәмлекләр белән төрләнүләренә һәм төрләнмәүләренә карамастан, аерым бер канун, урынлашып каткан ныклы бер тәртип белән тезеләләр... Сүз тәртибе ягыннан урыс теле белән төрек теле арасында аерма зур. Урыс телендә ныгып урынлашкан, катып калган бер тәртип юк диярлек...», – ди.

Сүз тезмәсендә тәртип – җөмлә кисәкләренең табигый урынnарында килүләре безнең телебездә, билгеле, зур урын тота. Хәтта кисәкләрнең үз урыннарыннан авышулары җөмләнең нормаль фикеренә әзме-күпме йогынты ясый, ләкин җөмлә төзелешендәге бу хосусият бер төрек телләре өчен генә хас түгел, бәлки һәрбер телдә, шулар эченнән урыс телендә дә, нормаль фикерне нормаль тәгъбир иткәндә, җөмлә кисәкләренең җөмләдә үзләренә караган тиешле урыннары була. Аларны шушы табигый урыннарыннан авыштыру, гадәттә, җөмләнең нормаль фикеренә аерым төс бирү өчен ясала, ләкин аңа карап җөмләнең баштагы төп фикере үзгәрми һәм грамматика хадисәләренең билгеле системына зарар килми. Ачыграк аңлашылсын өчен, бер җөмлә алып, андагы кисәкләрнең урыннарын алмаштырып карыйк:

*Укытучы балаларны Бөек Октябрь бәйрәме белән котлады.*
*Балаларны Бөек Октябрь бәйрәме белән укытучы котлады.*
*Укытучы Бөек Октябрь бәйрәме белән балаларны котлады.*

Менә бу өч җөмләнең өчесендә дә төп фикер бер (укытучының балаларны Бөек Октябрь бәйрәме белән котлавы), ләкин өчесе өч төрле сөальгә җавап булып әйтелүләренә карап, өчесендә өч төрле максат күзәтелгән, төп фикергә аерым төс биргән. Беренче җөмләдә нормаль фикер нормаль тәгъбир ителде, икенчесендә балаларны Бөек Октябрь бәйрәме белән котлау билгеле, ләкин кем котлаганы билгесез иде. Ияне (укытучы) хәбәр янына күчерү белән шул билгесезлекне җибәрү күздә тотылды, төп фикер искечә калды. Өченчесендә исә, укытучының Бөек Октябрь бәйрәме белән котлавы билгеле, ләкин аның кемнәрне котлаганы билгесез иде. Тәмамлыкны (балаларны) табигый урыныннан хәбәр янына күчерү белән, шул билгесезлек бетерелде. Моны кыскарак җөмләләрдә тагы ачыграк аңларга мөмкин: *Мәче баздагы майны ашаган, Баздагы майны мәче ашаган.*

Димәк, сүз тезмәсендә тәртип – җөмлә кисәкләренең табигый урыннарында килүләре – безнең телебездә зур урын тотса да, ләкин Алпаров әйткәнчә, алар үз урыннарында «ныгып урынлашкан, катып калган бер тәртип» белән түгел, бәлки җөмләнең нормаль фикеренә аерым төс бирү өчен кайчагында ул тәртип бозылырга, аларның урыннарын вакыты белән юри алмаштырырга кирәк була. Шулай булгач, «тәртип»не грамматика хадисәләрен билгеле системга салуда тышкы факт, бизмән итеп алуга караганда аны «өслүб»кә калдыру дөресрәк булыр иде.

Телебезнең тышкы фактларыннан өченчесе итеп «кабатлау» китерелә. 12 нче биттә «сүзләрнең тышкы төре бездә, кушымчалардан һәм тәртиптән башка, бер сүзне бөтен көенчә, йә аның бер кисәген тәкрар итү – кабатлау белән дә ясалырга мөмкин. Мәсәлән, сыйфат һәм рәвеш сүзләре күп вакыт шулай тәкрар белән ясалалар. *Укый-укый, килә-килә, тора-тора, күп-күп, озын-озын... кебек* ди.

Бер үк сүзне бер яки берничә мәртәбә кабатлау безнең телебездә бер рәвеш һәм сыйфат исемнәрендә генә түгел, алардан башка сүзләрдә дә, мәгънә яки фикергә аерым төс бирү өчен кабатлануны очратырга мөмкин: *сыз(ы)ла, сыз(ы)ла, сыз(ы)ла күңлем, сыз(ы)ла бертуктамыйча*; *су анасыннан котылгачтан, тынычлангач әни, әй орышты, әй орышты, әй орышты соң мине; мәйданга чыксам, ни күз*

*белән күрим: әй халык, халык, халык!..* һәм башкалар. Димәк, безнең телебездә кабатлау бар, кабатлау – тышкы факт, ләкин ул грамматикада шәкел урынын тота аламы? Телнең тышкы фактларыннан берәрсен грамматикада шәкел итеп алдың исә, грамматика хадисәләрен бу яки теге яктан карап системга салуда, төрле кануннар чыгаруда, аның шәкел булуын күрсәтергә кирәк иде. Кабатлауның кайсы яктан шәкел хезмәтен үтәве күрсәтелми, чөнки ул грамматикадан бигрәк өслүбтә, өслүбне тасвири ясауда тышкы факт була. Шуның өчен аны да «тәртип» кебек үк «өслүб»кә калдырырга кирәк иде.

«Сингармонизм» сүзләрне калын һәм нечкәгә бүлүдә, «басым» кушымчаларны ярдәмлек кушымчалардан аеруда, «аһәң» җөмләләрне төркемнәргә аеруда грамматикадан тышкы факт булып хезмәт иткән- лекләреннән, болар турында тукталырга туры килми.

Алпаров иптәш грамматикада шәкел булулары ягыннан әһәмиятләре аз булган тәртип, кабатлау, басым, сингармонизм кебек тышкы фактларны санап, алар турында яхшы ук озак тукталса да, җөмлә төзелешендә бердәнбер тышкы факт-шәкел булган «ярашу»ны ни өчендер бөтенләй төшереп калдырган. Шуны төшереп калдыру аркасында, ул грамматиканың нәхү бүлегендә тәгърифләрдә буталырга, яки бөтенләй ялгышырга мәҗбүр була.

«Ярашу» дип мин монда җөмлә эченә кергән сүзләрнең нинди юл белән булса да үзара теркәлүләрен атыйм. Мәсәлән, *Балалар күрше авылдан җәяү кайттылар* дигән җөмләне тикшереп карасак, мондагы сүзләрнең иң элек пар-пар булып үзара ярашуларынтеркәлүләрен күрәбез: *балалар кайттылар, җәяү кайттылар, авылдан кайттылар, күрше авылдан*. Бу пар сүзләр тагы үзара теркәләләр: *балалар кайттылар, балалар авылдан кайттылар, балалар күрше авылдан кайттылар, балалар күрше авылдан җәяү кайттылар.* Шушы рәвешчә, сүзләр үзара бөтенләй теркәлеп, бербөтен ясалганнан соң гына «җөмлә» була, шуның өчен формаль грамматикада «җөмлә» дип бер-берсе белән үзара ярашып, бербөтен ясалган сүзләр тезмәсен атыйбыз.

«Ярашу» безнең телебездә ике төрле юл белән була: 1) иярүчелек; 2) янәшәлек. «Иярүчелек» дип бер сүзнең икенче бер сүзне үзенә ияртүен, үзенә буйсындыруын атыйбыз. Урыс грамматикаларында аны «управление» дип йөртәләр. Иярүчелек нисбәттә булырга мөмкин: *мин язам* (һәр икәве сөйләүче өчен). Монда *мин* сүзе үзеннән соң килгән «язам» сүзен нисбәттә үзенә ияртკән; санда

булырга мөмкин: *мин язам* (һәр икәве берлек), *без язабыз* (һәр икәве күплек); килештә (кайбер сүзләр үзләренә ияргән сүзләрнең билгеле бер килештә генә килүләрен соравы) булырга мөмкин: *шәһәргә бардым* (*бардым* фигыле үзенә ияргән сүзнең юнәлү килешендә булуын сорый).

«Янәшәлек» дип җөмлә эчендә сүзнең нисбәттә, санда һәм килештә икенче бер сүзгә иярмичә, тик үзеннән соңгы сүз белән янәшә генә килүен атыйбыз. Урыс грамматикаларында аны «примыкание» дип йөртәләр. Җөмлә эчендә сүзләр исем белән яки фигыль белән янәшә килергә мөмкин: *Балалар күрше авылдан җәяү кайттылар* дигән җөмләдә *күрш*» сүзе исем белән *(авылдан), җәяү* сүзе фигыль белән *(кайттылар)* янәшә килгән. *Балалар күрше авылдан җәяү кайттылар* дигән җөмләнең эченә кергән сүзләрне үзара ярашулары ягыннан күзәтсәк, аларның түбәндәгечә ярашуларын күрер идек: *балалар кайттылар – балалар* гаиб һәм күплек булуын теләгән. Димәк, болар арасында ярашу нисбәттә һәм санда иярүчелек юлы белән булган. *Авылдан кайттылар – кайттылар* фигыль, ул үзенә ияргән *авылдан* сүзенең кучү килешендә булуын теләгән. Димәк, болар арасында ярашу килештә иярүчелек юлы белән булган. *Җәяү кайттылар – җәяү* сүзе нисбәттә, санда һәм килештә икенче бер сүзгә ияреп үзгәрмәгән, ул бу җөмләдә үзеннән соң килгән *кайттылар* сүзе белән янәшә килүне сорый, шуңа күрә боларның араларына икенче бер сүз кысыла алмый. Димәк, болар арасында ярашу янәшәлек белән булган. *Күрше авылдан – күрше* сүзе нисбәттә, санда һәм килештә икенче бер сүзгә ияреп үзгәрмәгән, ул бу җөмләдә үзеннән соң килгән *авылдан* сүзе белән янәшә килүне сорый, шуңа күрә боларның араларына бу җөмләдәге икенче бер сүз кысыла алмый. Димәк, болар арасында ярашу янәшәлек белән булган.

Менә шушы «ярашу»ның төрләре инде җөмлә кисәкләрен төркемнәргә аеруда тышкы факт – шәкел булып хезмәт итә. Моннан без нәхүдә шушындый нәтиҗәләр чыгара алабыз:

1) Хәбәр – җөмлә эчендә хәбәрлек кушымчасы белән бетеп, нисбәттә һәм санда икенче бер сүзгә (иягә) ияреп-ярашып килгән сүз (югарыдагы җөмләдә – *кайттылар*).

2) Ия – җөмлә эчендә баш килештә булып, нисбәттә һәм санда икенче бер сүзне (хәбәрне) үзенә иярткән сүз *(балалар).*

3) Аергыч – җөмлә эчендә исем белән янәшә килеп (ярашып), нисбәт, сан һәм килеш белән үзгәрмәгән сүз *(күрше).*

4) Тәмамлык – җөмлә эчендә фигыльдән алда килеп, аңа килеш кушымчасы яки иярчен сүзләр ярдәме белән ияргән сүз *(авылдан).*

5) Хәл – җөмлә эчендә фигыль белән янәшә килеп, нисбәт, сан һәм килеш белән үзгәрмәгән сүз *(җәяү).*

Димәк, җөмлә эчендә сан, нисбәт һәм килеш белән үзгәрмәгән сүзләр йә исемнәр яки фигыльләр белән янәшә киләләр. Исем белән янәшә килгәннәрен «аергыч» дип, фигыль белән янәшә килгәннәрен «хәл» дип атыйбыз.

Югарыда сөйләнгән фикерләрне җыеп нәтиҗә чыгарганда, телебезнең тышкы фактларыннан формаль грамматикада бизмән-шәкел итеп тагы «ярашу»ны өстәргә туры килә.

Кушымчалар. «Шәкли нигездә татар грамматикасы»нда Алпаров иптәш фонетика бүлегеннән соң морфологиягә күчеп, морфология, аерым сүз, сүз кисәкләре турында бераз туктала да, кушымчалар һәм аларның төркемнәрен соңгарак калдырып, турыдан-туры сүзләрне төркем һәм төркемчәләргә бүләргә керешә. Формаль грамматиканың морфология бүлегендә аерым сүзләр төп мөндәриҗә булсалар, морфология хадисәләрен күзәтүдә аларны бу яки теге яктан карап системга салуда төп бизмән-шәкел булып телебезнең тышкы фактларыннан кушымчалар хезмәт итәләр. Кушымчаларны җентекләп өйрәнү, аларга дөрес карый белү, гомумән, морфология кануннарын дөрес табуга, хосусан сүзләрне төркем һәм төркемчәләргә бүлүдә туры юлга керүгә сәбәп була, шуңа күрә сүзләрне төркем һәм төркемчәләргә бүлүгә керешүдән элек кушымчалар, аларның төркемнәре һәм һәр төркемнең морфологиядәге функцияләре белән таныштырып үткән булса, бер яктан морфология хадисәләрен нинди принциплар буенча системга салуы ачыграк күренгән, икенче яктан, тикшерүчеләргә морфология кануннарын җиңелрәк аңларга юл ачкан булыр иде. Шуларны искә алып, мин китапның тәртибенә карамастан сүз төркемнәреннән элек кушымчаларга тукталам.

Профессор А. Н. Самойлович үзенең төрек теле грамматикасында морфология элементларыннан берсе итеп кушымчалар – приставкины болай тәгъриф итә: «Телдә аерым сөйләнми, аерым торганда берәр мәгънә аңлатмый һәм үзе кушылган төп кисәккә сингармонизм һәм басым ягыннан буйсына торган морфология элементы». Бу тәгърифкә караганда, кушымча булу өчен телдә аерым сөйләнмәскә, үзе кушылган сүзгә сингармонизм һәм басым ягыннан буйсынырга, кушымча ялганганнан соң да сүз тышкы яктан һаман

бөтен сизелергә тиеш. Димәк, *бик, өчен, белән* кебек элементлар телдә аерым сөйләнеп, басым һәм сингармонизм ягыннан буйсынмаган, *ук-үк, гына-генә, кына-кенә* кебек элементлар басым ягыннан буйсынмаганга кушымчадан саналмыйлар. Соңгыларын ул «ярдәмлек – кушымчалар» («послелог – приставки») дип атый. Теләсә ничек атасын, ләкин ул аларны кушымчалардан аерым элемент итеп саный. Алпаров исә кушымчаларны үзенчәрәк аңлый, үзенчәрәк төшенә, шуңар күрә аның кушымчаларны тәгъриф итүе дә профессор Самойлович һәм башка тел галимнәренең тәгърифләренә караганда башкачарак килеп чыга. 11 нче биттә ул кушымчаны тәгъриф итеп: «Кушымча (аффикс) – һәрвакыт тамырның азагына кушылып, ияртеп әйтелә торган, үзбашына аерым торганда мәгънәсе булмаган кисәк. *Чы, ла, лә, лык, лек, дән, дан, дар, са...* кебекләр» ди. Үзенең тәгърифе буенча ул кушымчаларны тоткан урыннарына, хезмәтләренә карата өчкә бүлә.

1) Сүз ясаучы кушымчалар. Төрле ясалма сүзләр, төрле фигыль, исем, сыйфат дәрәҗәләре ясаучы кушымчалар шушы төркемгә керәләр.

2) Сүз төрләндерүче кушымчалар. Фигыльләрдә заман, япсару, исемнәрдә сан, япсару, килеш төрлекләре шушы төркемгә керәләр.

3) Өстәмә кушымчалар. Болар теләсә нинди сүзләргә иң азаккы чиратта килеп кушыла торган, сүзнең басымын да үзләренә үткәрми торган кисәкләр. Болар әйтелгән сүзнең мәгънәсенә бер чик кую, очлау өчен кайсылары җөмлә эчендә сүзнең бәйләнешен белдерү өчен кулланылалар. *Ук-үк, гына-генә, рак-рәк, ла-лә, да-дә, сана, мы, мени, мен, без, сең, сез...* кебек кушымчалар шушы төркемгә керәләр. Димәк, Алпаров кушымча сүзен киңрәк аңлап, шуңар карап киңрәк тәгъриф итә һәм үзләре кушылган сүзләргә басым ягыннан буйсынмый торган элементларны да кушымчалардан санап, аларны «өстәмә кушымчалар» исемендә өченче бүлеккә кертә. Боларның кайсысы дөресрәк, кайсысы фәнгә якынрак? Профессор Самойлович аңлаганча, үзләре кушылган сүзләргә сингармонизм һәм басым ягыннан буйсынган элементларны гына кушымчадан санап, басым ягыннан буйсынмаганнарын икенче исем астында йөртергәме, әллә Алпаров тәгъриф иткәнчә, сингармонизм ягыннан буйсынган элементларның һәммәсен кушымчадан санаргамы? Моңа җавап бирү өчен билгеле безгә беренче һәм икенче бүлеккә кергән кушымчалар белән өченчегә кергән өстәмә кушымчалар-

ны чагыштырып карарга, һәр икесенең үзлекләрен, морфологиядә бер-берсенә башка нинди функцияләре булуларын тикшереп карарга кирәк. Әгәр һәр икесенең үзлекләре һәм морфологиядәге функцияләре бер икән – һәммәсен бергә, бер исем астында, аерым икән, ул вакытта аларның икесен ике исем астында өйрәнергә тиеш булабыз. Ләкин өстән генә тикшереп караганда да, болар арасында зур гына аермалар барлыгын күрергә мөмкин.

1) Өченче бүлектәгеләр беренче һәм икенче бүлектәге кушымчалардан иң элек үзләре ияргән сүзләргә басым ягыннан буйсынмаулары белән аерылалар. Димәк, телебезнең тышкы фактлары ягыннан болар бер-берсенә башкалар.

2) Өченче бүлектәгеләр теләсә нинди сүзгә һәм иң азаккы чиратта гына кушылалар. Бу яктан алар тегеләрнең арасына керә алмыйлар *(авылдан ук – авыл уктан)*.

3) Беренче һәм икенче бүлектәге кушымчалар бер сүздән икенче яңа сүз ясау өчен, яки җөмлә эчендә сүзләрнең бер-берсенә бәйләнешен күрсәтү өчен кушылалар. Өченче бүлектәгеләр исә аерым сүзнең мәгънәсен генә түгел, бәлки җөмләдәге фикерне тәмамлау өчен киләләр. Димәк, Алпаровның өстәмә кушымчалар дигәне баштагы ике бүлек кушымчалардан тышкы фактлары ягыннан да, морфологиядәге функцияләре ягыннан да бер-берсеннән бик нык аерылалар. Шулай булгач, аларны кушымчалар рәтеннән чыгарып, үзләренә аерым морфология элементы итеп, үзләренә аерым исем астында өйрәнергә кирәк була. Өстәмә кушымчаларны үзләренә аерым бер исем астында аерып алганнан соң, калган саф кушымчаларны да грамматикадагы функцияләренә карап, икегә бүләргә туры килә. Болар арасында бер сүздән икенче төрле яңа сүз ясый торган кушымчалар бар һәм үзләре кушылган сүзнең мәгънәсенә шәкли төс биреп үзгәртә яки сүз тезмәсендә сүзләрнең үзара бәйләнешләрен – ярашуларын күрсәтә торган кушымчалар бар. Мәсәлән, *тимер* дигән сүздән бер мәгълүм металлны аңлыйбыз, әгәр аңа *че* кушымчасын ялгап *тимерче* дисәк, аннан инде бөтенләй икенче мәгънәне – тимер белән кәсеп итүче кешене аңлыйбыз; *тимерлә* дисәң, аннан тагы *тимер* һәм *тимерче* дигән сүзләрдән бүтән мәгънәне – эшне аңлыйбыз. Димәк, *че* һәм *лә* кушымчалары бер сүзгә кушылып, аннан бөтенләй башка мәгънәне аңлата торган – сүз ясый торган кушымчалар булдылар. *Эшче, эшчән, эшлә, кышлык, кышкы, кыргыч* сүзләрендәге *че, чән, лә, лык, гыч* кебекләр дә сүз ясый

торган кушымчалардан булалар. Әгәр *бала* дигән сүзгә *кай* кушып *балакай*, *ның* кушымчасын кушып *баланың* дисәң, соңгыларыннан *бала* дигән сүзнең төп мәгънәсе югалмый. *Кай* кушылганда аның мәгънәсенә шәкли төс биреп, мәгънәсе бераз үзгәргәнен, «*нең*» кушылганда икенче бер сүзнең балага мөнәсәбәтен аңлыйбыз. Шулай булгач, болар сүзне үзгәртә торган кушымчалардан булалар. Алпаров иптәш тә кушымчаларны сүз ясаучылар, сүз төрләндерүчеләр исемнәрендә икегә бүлсә дә, ләкин ул аларның морфологиядә функцияләренә карап бүлмәгәне, бер бүлектәгеләрен икенчеләренә кертеп чуалтканы сизелә. Аларны төркемнәргә бүлгәндә, морфологиядәге функцияләренә карап бүләргә, сүз ясый торган бүлегенә чынлап та бер сүздән икенче яңа сүз ясый торганнарын гына кертеп, калганнарын һәммәсен дә сүзне үзгәртә торган кушымчалардан санау кирәк иде. Сүз ясый торган кушымчалар бер сүзгә ялганып яңа сүз ясаулары белән аларның морфологиядәге функцияләре бетә, әмма сүз үзгәртә торган кушымчаларның бер сүзгә ялганып, аларның мәгънәсен үзгәртү, бу яки теге якка юнәлдерү белән генә функцияләре бетми, аларның тагы сүзләрне төркемгә бүлүдә, җөмлә кисәкләрен билгеләүдә шәкел булу функцияләре дә кала әле.

Сүз ясый торган кушымчаларның морфологиядәге функцияләре – аларның берәрсе бу сүзгә ялгану белән аннан бөтенләй башка мәгънә аңлана торган, хәтта кайберләреннән электә мәгълүм бер төркемнән булган сүзне икенче төркемгә күчереп, соңгы төркем кануннарына буйсына торган яңа сүз ясау була. Мәсәлән, *тимер* сүзе исем иде, исем кануннарына буйсына иде; *ач* фигыль иде, фигыль канунарына буйсына иде; *тимерлә* дисәң, исемнән фигыль ясалды, фигыль кануннарына буйсынды, *ачкыч* дисәң, фигыльдән исем ясалды, инде фигыль кануннарына буйсынды.

Сүз үзгәртә торган кушымчаларның функцияләре исә аларның билгеле бер төре, билгеле бер төркем сүзләргә генә ялганып, сүзнең төп мәгънәсенә аерым төс (оттенок) яки юнәлеш бирү һәм сүзләрне төркемләүдә шәкел хезмәтен үтәү була. Кушымчаларның морфологиядәге шушы функцияләренә карап, сүз ясый торганнарын «ясагыч кушымчалар», сүз үзгәртә торганнарын «төрлек кушымчалар» дип атарга мөмкин. Төрлекләрне тагын үз нәүбәтләрендә икегә бүлеп өйрәнергә туры килә. Боларның арасында сүз тезмәсе эчендә килгәндә үзенең пар сүзе теләве буенча турыдан-туры килеп ялгана торганнары һәм пар сүзенең теләве буенча түгел, бәлки

сүзнең төп мәгънәсенә аерым төс (оттенок) бирү өчен, сөйләүченең үз ирке белән ялгана торганнары бар. Мәсәлән, *мин кайттым, син кайттың, ул кайтты, авылга кайттым, авылны күрдем* дигән сүз тезмәләрендә *м, ң, ы* төрлекләре *мин, син, ул* сүзләренең теләве буенча, *га, ны* төрлекләре *кайттым* һәм *күрдем* сүзләренең теләүләре буенча сөйләүченең үз иркеннән башка ялгандылар. Шул ук мисалларда *мин кайттым, син кайтырсың, ул кайтачак, авылкайга кайтам, авылчыкны күрә* дисәң, болардагы *ар, р, ачак, кай, чык* төрлекләре икенче бер сүзнең теләве буенча түгел, бәлки сөйләүченең үз ирке белән ялганалар. Беренчеләрен «нәхәви төрлекләр», икенчеләрен «сарфи төрлекләр» дип атарга мөмкин. Нәхәви төрлекләр сүз тезмәсендә сүзләрнең бер-беренә бәйләнешен, үзара ярашуын күрсәтеп, боларга «күплек, нисбәт (япсару), килеш» төрлекләре керәләр; сарфи төрлекләр сүзләрне ялгыз сарфи яктан гына үзгәртеп, боларга «дәрәҗәлек, юклык, заман» төрлекләре керәләр.

Димәк, кушымчаларны морфологиядәге функцияләренә карап төркем һәм төркемчәләргә бүлгәч, түбәндәге схема килеп чыгарга тиеш:

| Төрлекләр | | | | | | Ясагычлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Нәхәви төрлекләр | | | Сарфи төрлекләр | | | |
| Килеш | Нисбәт (япсару) | Күплек | Заман | Юклык | Дәрәҗәлек | |

Сүз төркемнәре. Грамматиканың морфология бүлегендә сүз, сүзнең төзелеше һәм аның формаль элементлары белән танышканнан соң, шул формаль элементларга карап, сүзләрне төркем һәм төркемчәләргә бүлү мәсьәләсе килә. Сүз төркемнәре морфологиянең төп мөндәриҗәсеннән саналганлыктан, сүзләрне төркемләү мәсьәләсе иң әһәмиятле урын тота. Шуңа күрә монда метод – балаларга өйрәтү ягыннан гына түгел, бәлки иң элек төркемләүнең гыйльмифәнни булу ягыннан карарга, аның өчен алдан әсаслар билгеләп, шул әсаслар буенча уртак кануннар чыгарып төркемләргә туры килә.

Алпаров иптәш, сүзләрне төркемләүгә керешүдән элек, күбесе гомуми төркемләүнең үзенә генә кайтып кала торган 4 төрле шарт күрсәтә дә, иң элек сүзләрне эчке яктан карап үзенчә 9 төркемгә бүлә, аннан соң тышкы яктан карап өчкә – 1) фонетика ягыннан; 2) тамыр кисәкләрнең төзелеше ягыннан; 3) морфология ягыннан бүлә.

Сүзләрне эчке яктан карап төркемләү, билгеле, формаль грамматика эше түгел. Ул аны үзе дә сүз төркемләүнең шәкли ягы белән мәгънә ягын чагыштырып карау өчен генә бүлеп китә. Иске грамматикаларыбызда сүзләрне эчке якларыннан карап төрлесендә төрлечә бүленә иде. Кайсыларының бүлүе дөрес булгандыр, Алпаровныкымы, башкаларныкымы, монда ул мәсьәләгә тукталырга туры килми. Шулай ук, тышкы яктан карап бүлгәндә дә фонетика һәм тамыр кисәкләренең төзелешләре якларыннан карап бүленүләре дә безнең өчен әһәмияте аз. Монда безнең өчен әһәмиятлесе морфология ягыннан карап төркемләү, чөнки морфологиядә төп максат – төп җирлек итеп, сүз төркемнәреннән шушы соңгысы алына. Менә шушы морфология ягыннан карап бүлгәндә, инде төркемләү катгый һәм фәнни булып чыгуы өчен, минем аңлавымча, Алпаров иптәш күрсәткән 4 шарттан башка тагы түбәндәге ике төп мәгънәне хәл итеп китәргә тиеш була.

1) Сүзләрне төркемләүдә кайсы сүзләрне нигез итеп алабыз: төп сүзләрне генәме, әллә ясалма сүзләрне дәме?

2) Сүзләрне төркемләүдә нормаль элементлардан шәкел итеп кайсы кушымчаларны алабыз: төркемнәрне генәме, әллә ясагычларны дамы?

Башта без сүзләрне ничек ясалулары ягыннан карап тикшердек. Төп (тамыр) сүзләр булганын, ясагычлар (мин монда саф ясагычларны гына алам) ялганып ясалма сүзләр булганын күрдек. Инде сүзләрне морфология ягыннан карап төркемләгәндә безнең алдыбызда «сүз» тора. «Сүз» эченә төп сүзләр дә, ясалма сүзләр дә керә. Менә хәзер без аларны төп һәм ясалма булуларына карамастан, тулаем алып сүзләрнең морфологиядә нинди төрлекләр ялганып төрләнүләрен, шушы төрлекләр ялгангандагы табигать һәм хосусиятләрен тикшерергә тиеш булабыз. Тулаем сүзләрне алып, аларга нинди төрлекләр ялгана алуын, мәгълүм төрлекләр генә ялгана торган сүзләрне бер төркем итеп аерып, бу төрлекләр бу төркем сүзләргә нинди уртак төс (оттенок) яки юнәлеш биргәнен, боларның нинди уртак кануннары булып, башка төркем сүзләрдән нинди аермалары барлыгын билгелибез. Аннан соң бик күп сүзләрнең хәзерге вакытта төп яки ясалма икәнен аерырга да мөмкин түгел, аларны бары тарихи чагыштыру аркасында гына хәл итәргә була. Бу яктан караганда да төркемнәрдә тулаем сүзләрне алырга кирәклек аңлашыла.

Алпаров иптәш, сүзләрне морфология ягыннан карап төркемнәргә бүлгәндә, бу ике принципны игътибарга алмый, бер урында төп (тамыр) сүзләргә генә, икенче бер урында төп һәм ясалма сүзләргә дә карап була. Төркемләүдә дә шәкел итеп бер урында нәхәви төрлекләрне генә, икенче бер урында сарфи төрлекләрне, хәтта өченче бер урында ясагычларны да ала. Шуңа күрә тәгърифләрдә күп урында үз-үзенә каршы килә, сүз төркемнәре «әфрадын җамигъ», «әгъбарын манигъ» була алмый. 62 нче биттә «морфология ягыннан карап, сүзләрне төркемнәргә аера. Башка яктан карап төркемләүләргә караганда, иң катлаулы һәм безнең өчен иң әһәмиятлесе бу яктан карап сүзләрне төркемнәргә аеру өчен, аларның ялгыз авазларына яки фәкать тамыр кисәкләренә генә карау җитми, аларның тамыр кисәкләре белән бергә кушымча кисәкләренә дә, ягъни аларның ничек ясалу, ничек төрләнүләренә дә игътибар итәргә, сүзләрнең шушы яктан булган аерымлыкларын күзәтеп эш итәргә кирәк була...» ди. Шушы әсастан чыгып, тамыр сүзләрне иң элек икегә бүлә: 1) төрләнүче сүзләр; 2) төрләнмәүче сүзләр. Турыдан-туры тамыр хәлендә җанлы телдә төрләндерүче кушымчалар (төрлекләр) белән әйтелә алган сүзләрне «төрләнүче сүзләр», туры мәгънәләрендә алынганда тамыр хәлендә төрлекләр белән әйтелмәгән сүзләрне «төрләнмәүче сүзләр» дип атый. Безнең телебездә төрләнә һәм төрләнми торган сүзләр бар, бу яктан карап, икегә бүләргә туры килә, ләкин төп (тамыр) сүзләр генә түгел, бәлки ясалма сүзләр дә шулай ук икегә бүленәләр, шулай булгач, нигә төп сүзләрне генә бүләргә, тулаем сүзләрне алып бүләргә тиеш була. Менә моның эч серенә төшенеп булмый, бәлки ул төп хәлендә кайсыбер сүзләрнең төрләнми торган булып *(уф – уфылда),* ясалма булганның соңында төрләнә торган яки киресенчә булуыннан (акча – акчалата) кача торгандыр, ләкин моннан безгә качарга хаҗәт юк: төп хәлендә төрләнә икән, без аны шул төп хәлендә төрләнә торган сүзләр төркеменә, аннан икенче төрләнми торган сүз ясалган икән, аны инде шул ясалма хәлендә төрләнми торган сүзләр төркеменә кертергә тиеш булабыз.

Аннан соң нинди төрлекләр белән әйтелә алуларына карап, төрләнүче сүзләрне тагы ике төркемгә бүлә: 1) фигыльләр; 2) исемнәр. Үзләренең азагына турыдан-туры дәрәҗәлек (баб) һәм юклык *(ма-мә)* кушымчалары алган сүзләрне фигыльләрдән, үзләренең азагына туры мәгънәләрендә тамыр хәленчә килеш төрлекләрне алган

сүзләрне исемнәрдән саный. Монда да нинди төрлекләр алуларына карап бүлгәч, бу ике төркем арасындагы аерманы да һәр икәвеннән төрлекләр белән күрсәтергә кирәк иде, дәрәҗәлек һәм юклык кушымчалары төрлекләрдән саналмый иде. Сүзләрне төркемнәргә бүлүдән төп максат – бер төркем эченә кергән сүзләрнең нинди төрлекләр белән төрләнә алу хосусиятләре белән таныштыру булырга һәм һәр төркемне тәгъриф иткәндә аның үзенә хасрак булган бөтен хосусиятләрен тәгъриф эченә алырга тиеш, шуңа күрә фигыль белән исемне тәгъриф иткәндә дә, аларның нинди төрлекләр белән төрләнә алу хосусиятләрен эченә алырлык итеп тәгъриф итү дөресрәк булыр иде.

Фигыльләрне төркемчәләргә бүлүдә дә Алпаров иптәш фикеренә кушылырга мөмкин булмаган урыннар юк түгел. Ул фигыльләрне, заман һәм хәбәрлек (нисбәт) төрлекләре белән төрләнешләрендә булган аерымлыкларына карап, өчкә бүлә: 1) хәбәр фигыльләр; 2) хәл фигыльләре; 3) исем фигыльләр. Аннан соң бу төркемчәләрне үз нәүбәтләрендә тагы түбәндәгечә төркемчәләргә бүлә:

Хәбәр фигыльләре: 1) боерык фигыле; 2) үткән фигыль; 3) шарт фигыле; 4) хәзерге фигыль.

Хәл фигыльләре: 1) рәвеш фигыльләр (үткән, хәзерге); 2) вакыт фигыльләре (элекке вакыт, эш вакыты, соңгы вакыт); исем фигыльләр: 1) үткән; 2) киләчәк; 3) җавап.

Фигыльләрне төркемчәләргә бүлүдә заман һәм хәбәрлек төрлекләре белән төрләнешләрендә булган аерымлыкларын алгач, бу төркемчәләрнең һәммәсе дә шул төрлекләр белән төрләнергә, тик болар белән төрләнештә аерма гына булырга кирәк иде, ләкин боларның беренчеләре генә бу ике төрлек белән төрләнеп, калганнары хәбәрлек төркемнәре белән төрләнмиләр. Аннан соң төркемчәләргә бүлүдә бу ике төрлекне генә нигез итү аркасында, үз тәгърифебезгә үзебез каршы килеп, кайбер фигыль булырга тиешле сүзләрне фигыль төркемчәләре арасына кертми калдырабыз. Мәсәлән, *эшләр, эшләмәк, эшләүче, эшлисе* кебек сүзләр югарыдагы тәгърифебезгә караганда шәкли яктан фигыль төркемчәләре эченә керергә тиешләр, чөнки болар башка фигыльләр кебек дәрәҗәлек һәм юклык белән төрләнәләр: *эшләү, эшләтү, эшләшү..., эшләмәү, эшләтмәү..., эшләүче, эшләтүче..., эшләмәүче, эшләтмәүче...* Шуның белән бергә, «отышлы, барышлы» кебек мәгънә ягыннан да, шә-

кел ягыннан да фигыль булмаган сүзләр фигыль төркемчәләре арасына кергәннәр. Шулай ук *сагынганда, укыганда* кебек сүзләрне дә исем фигыльләрнең килеш белән төрләнеше итеп кенә карарга кирәк иде. Фигыльләрне төркемчәләргә бүлү гомумән таркау чыккан. Бер-береннән заман белән генә аерыла торган фигыльләр төрле исем астында аерым төркемчәләрдән саналган. Мәсәлән, хәбәр фигыльләреннән үткән һәм хәзерге фигыльләрне бер генә исем астында йөртергә мөмкин. Шулай ук хәл фигыльләрен рәвеш һәм вакыт фигыльләре исемендә ике төркемчәгә аерып йөртергә хаҗәт юк, чөнки рәвеш фигыльләренең шәкел ягыннан вакыт фигыльләреннән аермасы юк, болар бер-береннән бары заман белән генә аерылалар. *Укыгач, укып, укыганчы* фигыльләрен алып, җөмлә эчендә тикшереп карыйк: «*бала укыгач утырды*». Утырудан элек уку эшен эшләгән, аннан соң утырган – үткән заман; *бала укып утырды*. Утыру эше вакытында уку эшен дә эшләгән – хәзерге заман; *бала укыганчы утырды*. Утыруга кадәр уку эшен эшләгәне юк әле – киләчәк заман була. Шәкел ягыннан карасак, иң элек болар һәммәсе дә күплек белән төрләнмиләр, аннан соң җөмлә эчендә иярчен кисәк булып кына (хәл) йөриләр, димәк, шәкел ягыннан караганда да болар уртак кануннарга буйсыналар, шулай булгач, аерма фәкать заманда гына булып кала. «*Укый*» төрен искәрмә рәвешендә генә хәл фигыленнән санарга кирәк, чөнки төбендә ул саф фигыльдән була.

Исем фигыльләргә килсәк, болар арасына *укучы, эшләүче* төрен дә кертеп, барысын бергә «сыйфат фигыль» дип атау яхшырак булыр иде. *Укучы* сүзенең *укыган, укыячак* сүзләреннән шәкел ягыннан һич аермасы юк. Болар һәммәсе дә бертөсле фигыль төрлекләреннән дәрәҗәлек, юклык, заман һәм күплек белән төрләнәләр. Шулар өстенә боларда сыйфат хосусиятләре дә бар, тик болар бер-береннән заман белән генә аерылалар: *укыган кеше* – үткән заман, *укучы кеше* – хәзерге заман, *укыячак кеше* – киләчәк заман.

«*Уку, укымак*» төрләрен дә фигыльләр рәтенә кертеп, боларны «исем фигыль» дип атау дөрес булыр, чөнки болар дәрәҗәлек, юклык һәм күплектә төрләнүләре белән бергә исем кануннарына буйсыналар. Мәсәлән, *уку китабы, ашау әйбере* дип әйтергә мөмкин. Әмма *укыган китабы* (баланың укыган китабы белән саташтырмаска кирәк) һәм *укыячак китабы* дип әйтергә мөмкин түгел.

Фигыльләргә шәкли яктан карап анализ ясаганнан соң, аларны төркемчәләргә бүлгәч, түбәндәге схема килеп чыгарга тиеш:

| Сүзләрнең төркем һәм төркемчәләре | | | | Сарфи төрлекләр | | | Нәхәви төрлекләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Дәрәҗәлек | Юклык | Заман | Күплек | Япсару | Тартым | Килеш |
| Төрләнми торган сүзләр | Фигыльләр | Саф фигыль | Боерык фигыль | + | + | – | + | + | – | – |
| | | | Хәбәр фигыль | + | + | + | + | + | – | – |
| | | | Шарт фигыль | + | + | – | + | + | + | – |
| | | Хәл фигыль | | + | + | + | – | – | – | – |
| | | Сыйфат фигыль | | + | + | + | + | – | + | + |
| | | Исем фигыль | | + | + | – | + | – | + | + |
| | Исемнәр | Зат исеме | | – | – | – | + | – | + | + |
| | | Сыйфат исеме | | – | – | – | + | – | + | + |
| | | Сан исеме | | – | – | – | + | – | + | + |
| | | Алмашлык | | – | – | – | + | + | + | + |
| Рәвешләр | | | | – | – | – | – | – | – | – |
| Ярдәмлекләр | | | | – | – | – | – | – | – | – |
| Ымлыклар | | | | – | – | – | – | – | – | – |

**Исем төркемчәләре.** Исемнәрне төркемчәләргә бүлүдә дә шәкел итеп кайсыларында ясагычлар, кайсыларында төрлекләр алына. Шушы юл белән исем төркемчәләре түбәндәгечә 5 килеп чыга: 1) зат исеме; 2) сыйфат исеме; 3) сан исеме; 4) вакыт-урын исеме; 5) алмашлык.

Зат исемнәрендә *даш, сез, чен* кушымчалары, сыйфат исемнәрендә башларында килә торган «кып, йәм» кебек иҗекләр, сан исемнәрендә «*нче*», алмашлыкларда бу хосусиятләрнең юклыгы шәкел итеп алына.

Кушымчаларның морфологиядәге функцияләрен сөйләгәндә, сүз ясый торган кушымчаларның функцияләре чынлап та сүз ясау гына булганын, сүзләрне төркем һәм төркемчәләргә аеруда алар белән катгый канун чыгару мөмкин түгеллеген сөйләгән идем. Хәзер бу фикерләрнең дөреслеген югарыдагы сүз төркемчәләрендә ачыграк күрергә була. Зат исемнәренең билгесе итеп китерелгән *даш, сез, че* кушымчалары чынлап та зат исемнәрен башка төркемчәләрдән аера торган билге була алаларны, болар чынлап та ялгыз зат исемнәренә генә ялганаларны, аларга гына ялгансалар да, аларның һәммәсенә

телебезнең табигате буенча ялганырга мөмкинме? Юк, чөнки *че, даш* кушымчалары ялгыз зат исемнәренә генә түгел, фигыльләргә дә ялганалар: *укучы, эшләүче, күзәт – күзәтүче, телән – теләнче, там – тамчы, утыр – утырдаш*... исемнәргә ялганганда да телебезнең табигате буенча һәрбер исемгә түгел, мәгълүм бер төркем (*че* – иялек, һөнәр һәм сәнәгать; *даш* – уртаклыкны кабил булган һәм башкалар) сүзләргә генә ялгана. Мәсәлән, *кеше – кешечe, кешедәш; борын – борынчы, борындаш*, дип әйтүне телебезнең табигате сыйдырмый. *Сыз* кушымчасы фигыльләр белән алмашлыкларга да ялгана ала: *укусыз, укытучысыз, минсез, синсез, ансыз, аларсыз, шунсыз*... Шулай ук «вакыт-урын» исемнәренә шәкел итеп алынган, *кы-гы, ге-ке* кушымчалары да ялгыз вакыт һәм урынны аңлата торган сүзләргә генә ялганалар дип әйтеп булмый. Алар фигыльләргә, иялек һәм урын килешендә булган башка сүзләргә дә ялганалар: *той – тойгы, төрт – төртке, себер – себерке, чап – чапкы, тип – типке, киер – киерге, авылның – авылныкы (авылныңкы), авылда – авылдагы*. Шуның өстенә бу кушымчалар вакыт һәм урын аңлата торган сүзләрнең дә һәммәсенә ялганмыйлар, *арт – арткы, ал – алгы* дип әйтергә мөмкин. *Уң – уңгы, сул – сулгы* дип әйтелми. Шулай булгач, болар исемнәрне төркемчәләргә бүлүдә шәкел була алмыйлар, шуның белән бергә, вакыт һәм урын аңлата торган сүзләрне зат исемнәреннән аерым, «вакыт-урын исемнәре» астында үзләрен аерым сүз төркемчәсе ясарга да таяныч калмый. Шуңа күрә безгә исемнәрне төркемчәләргә бүлүдә шәкелне ясагычлардан түгел, бәлки төрлекләрдән, нәхәви төрлекләрдән булмаса, сарфи төрлекләрдән эзләргә кала. Дөресен әйтергә кирәк, безнең телебездә исемнәрне шәкли яктан гына карап бүлү эше яхшы ук читен һәм икеле мәсьәләләрдән. Чөнки болар җөмлә эчендә килгәндә дә, аерым торганда да бер-береннән шәкли яктан катгый кануннар белән аерылып җитмиләр, боларның һәммәсе дип әйтерлек күплек, тартым, килеш һәм хәбәрлек төрлекләре белән төрләнәләр. Шуңа күрә алар җөмләдә баш кисәкләр дә, иярчен кисәкләр дә була алалар. Шулай да боларны шәкли яктан төркемчәләргә бүләргә бөтенләй юл юк түгел: исемнәрнең алмашлыклардан башкалары һәммәсе дә дәрәҗәлек төрлекләре белән төрләнүне кабилләр. Һәр төркемчәнең үзенә хас дәрәҗәлек төрлекләре бар. Менә шушы дәрәҗәлек төрлекләрен шәкел игътибар итеп, исемнәрне түбәндәгечә 4 төркемчәгә бүләргә мөмкин.

1) Зат исемнәре – иркәләү *(кай-кәй)* һәм кечерәйтү *(чык-чек)* төрлекләре белән төрләнүне кабил булган исемнәр.

2) Сыйфат исемнәре – артыклык *(кып, ямь, бик, иң, дөм...),* чагыштыру *(рак-рәк)* һәм азсыту *(гылт-гелт, кылт-келт, лҗем, келтем, су, сел...)* төрлекләре белән төрләнүне кабил булган исемнәр.

3) Сан исемнәре – тәртип *(нче),* бүлем *(ар-әр, шар-шәр)* һәм чама *(лап-ләп)* төрлекләре ялганып төрләнә торган исемнәр.

4) Алмашлыклар – дәрәҗәлек төрлекләре белән төрләнми торган исемнәр.

Менә бездә исемнәрне шушы дәрәҗәлек төрлекләре белән генә төркемчәләргә аерырга, башкача юл юк. Ләкин монда һәр төркемчәнең үзенә махсус дәрәҗәлек төрлекләре белән төрләнә алуын, төрләнүне кабил булуын, шуны телебезнең табигате сыйдыруын игътибар итәргә кирәк. Кайбер исемнәр үзләре зат яки сыйфат исемнәреннән була торып, үзләренең дәрәҗәлек төрлекләре белән җанлы телдә бик санаулы зат исемнәре генә төрләнеп йөртелә. Ләкин, гадәттә, алар бу төрлекләр белән төрләнүне кабил: *кеше, җир* сүзләрен *кешекәй, җиркәй, кешечек, җирчек* дип берәү сөйли яки яза икән, бу ялгыш исәпләнми, чөнки моны телнең табигате сыйдыра. Шулай ук мәгънәләренә карап яки җөмләдә аергыч булып килүләренә карап, моңа кадәр сыйфат исемнәреннән саналып йөртелгән бик күп сүзләр, сыйфат дәрәҗәлек төрлекләре белән төрләнүне кабил булмасалар да, шәкли яктан сыйфат исемнәренә кертелмәскә тиеш. Мәсәлән, *авылдаш, тимерче* сүзләре *авылдаш, авылдашрак, иң тимерче, тимерчерәк* дип әйтүне телнең табигате күтәрми. Шуңа күрә мондый сүзләрне зат исемнәреннән исәпләргә кирәк була. Аннан соң җанлы телдә, бигрәк тә җырларда аналогия буенча төркемчәнең дәрәҗәлек төрлекләре белән икенче бер төркемчә сүзләрнең төрләнүләрен дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, *чибәркәй, солыкай, карт аюкай.*

Исемнәрдә ахырында «килеш (падеж) төрлекләре» турында бераз тукталырга туры килә. Алпаров иптәш баш килеш белән барлыгы сигез төрле килеш саный, ләкин болардан соңгы икесенең (рәвеш һәм ошату кисәкләре) килеш исәпләнүләре бераз гаҗәбрәк. Чөнки «килеш нәрсә ул, кушымчаларның кайсылары килеш төрлекләре исәпләнәләр?» дигән сорауларга җөмлә эчендә исемнәрнең икенче бер сүзгә иярүе – буйсынуы – килеш, шул икенче бер сүзнең теләве буенча сөйләүченең иркеннән башка ук исемнәргә килеп кушылган кушымчалар – килеш төрлекләре санала, дип җавап бирелә. Икенче

бер сүзгә ияреп төзелгән исемнәрнең җөмлә эчендә аергыч һәм хәл булып килә алмавы, җөмлә тышында мөстәкыйль – бөтен сүз булып исәпләнмәве аларның килеш белән төрләнүләренең билгеләре була. Баш килеш шартлы рәвештә генә килеш дип атала, шуның өчен аның турында сүз булырга мөмкин түгел. Башкаларын тикшереп карасак, иялек, чыгыш, юнәлеш, төшем, вакыт-урын килешләре белән төрләнгән сүзләр чынлап та җөмлә эчендә аергыч һәм хәл булып килә алмыйлар *(кызылны кеше, кызылдан кеше* дип әйтелми). Шулай ук болар телдә мөстәкыйль сүз булып исәпләнмиләр. Әмма *урысча, аюдай* сүзләре җөмлә эчендә аергыч та, хәл дә булып килә алалар: *урысча китап, урысча сөйли, аюдай егет, күзләре уттай яна*. Соңрак болар үзләре килеш белән төрләнә алалар, шуңа күрә бу икесен килешләр арасына кертмәскә кирәк иде.

Сүз төркемнәре турындагы югарыда сөйләнгән бөтен фикерләрне бергә җыйгач, нәтиҗә рәвешендә түбәндәге схема килеп чыгарга тиеш була:

<table>
<tr><th colspan="3">Нәхәви төрлекләр</th><th colspan="4">Сарфи төрлекләр</th><th colspan="5">Фигыльләр</th></tr>
<tr><th>Исемнәр төре</th><th>Япсару</th><th>Күплек</th><th>Заман</th><th>Юклык</th><th>Дәрәҗәлек</th><th>Шәкелләр</th><th colspan="2">Мисаллар</th><th>Заманнар</th><th>Төркемчәләр</th><th>Фигыль төркемнәре</th></tr>
<tr><td>–</td><td>+</td><td>+</td><td>–</td><td>+</td><td>+</td><td></td><td>Укы</td><td>Яз</td><td></td><td>Боерык фигыль</td><td rowspan="4">Саф фигыль</td></tr>
<tr><td>–</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>д</td><td>Укыды</td><td>Язды</td><td>Үткән заман</td><td rowspan="2">Хәбәр фигыль</td></tr>
<tr><td>–</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>ыйа</td><td>Укый</td><td>Яза</td><td>Хәзерге заман</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td>Укыса</td><td>Язса</td><td></td><td>Шарт фигыль</td></tr>
<tr><td>–</td><td>–</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>+</td><td>гач</td><td>Укыгач</td><td>Язгач</td><td>Үткән заман</td><td rowspan="3"></td><td rowspan="3">Хәл фигыль</td></tr>
<tr><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>+</td><td>–</td><td>+</td><td>п</td><td>Укып (укый)</td><td>Язып (яза)</td><td>Хәзерге заман</td></tr>
<tr><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>+</td><td>–</td><td>+</td><td>нчы</td><td>Укыганчы</td><td>Язганчы</td><td>Киләчәк заман</td></tr>
</table>

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| – | – | + | + | + | + | ган | Укыган | Язган | Үткән заман | | Сыйфат фигыль |
| + | – | + | + | + | + | учы | Укучы | Язучы | Хәзерге заман | | |
| + | – | + | + | + | + | ячак ачак | Укыячак (укыр) | Язачак (язар) | Киләчәк заман | | |
| + | – | + | – | + | | у мак | Уку (укымак) | Язу (язмак) | | | Исем фигыль |

Нәху. Нәхүдә шәкел формаль элемент итеп телебезнең өч төрле тышкы факты күрсәтелә: 1) ялганмалык; 2) тәртип; 3) басым, аһәң, тыныш.

Югарыда телебезнең тышкы фактларын тикшергәндә, «ялганмалык»ның артык киң мәгънәдә булуын, грамматикада тышкы факт итеп «ялганмалык»ның үзен түгел, бәлки кушымчаларны алырга кирәклеген, шулай ук тәртипнең дә грамматика кануннарын чыгаруда артык зур урын тотмаганын, әмма нәхүдә төп шәкел булган «ярашу»ның төшеп калганын сөйләгән идем. Дөрес, моннан мин грамматикада ялганмалык һәм тәртипне бөтенләй төшереп калдырырга дигән фикерне аңлатырга теләмим. Сүзләрне төп кушымчаларга аеруда телебезнең ялганмалык табигате белән, җөмлә кисәкләренең табигый урыннарын билгеләүдә тәртип белән таныштырырга кирәк була, шуның белән бергә, морфологиядә кушымчаларның төрләре (сүз ясауда ясагычларның, сүз төрләндерүдә төрлекләрнең), нәхүдә «ярашу»ның төрләре (иярүчелек һәм янәшәлек) төп шәкел булуын алдан күз алдында гәүдәләндерергә кирәк иде, дим.

Алпаров иптәш, нәхүне тәгъриф иткәннән соң, телебезнең шушы өч төрле тышкы фактын нигез итеп, җөмләнең төзелешенә күчә. Җөмләнең үзен шәкли яктан карап билгели. Аннан соң җөмләне баш һәм иярчен кисәкләргә бүлә. Баш кисәкләргә тукталырга туры килми, аларны шәкли яктан карап тәгъриф итүдә генә бераз аерма булырга мөмкин. Иярчен кисәкләрне, җөмләдәге нинди төркемнән булган сүзгә бәйләнүләренә карап, дүрт төркемгә бүлә: 1) фигыльгә бәйләнгән иярченнәр (тәмамлыклар); 2) исемгә бәйләнгән иярченнәр (аергычлар); 3) сыйфатка бәйләнгән иярченнәр (ачыклаулар); 4) ярдәмлекләргә бәйләнгән иярченнәр (тәмамлыклар). Димәк, иярчен кисәкләрне төркемнәргә аеруда җөмлә эчендәге сүзләрнең үзара ярашу-бәйләнешү төрләренә караудан бигрәк мәгънәгә әһәмият бирә, шуңа күрә нәтиҗә булып килеп чыккан төр-

кемнәр, һәр төркемнең тәгърифләре, хәтта шул тәгърифләргә карап китерелгән мисаллар үзара чуалалар.

Бу чуалулар, ялгышулар, минем аңлавымча, җөмләне кисәкләргә бүлүдә сүзләрнең үзара коры бәйләнүләрен генә нигез итеп алудан килеп чыкты. Әгәр нигез итеп чынлап та җөмләнең тышкы күренешен – ярашуның төрләрен алсак иде, җөмләнең өстенә карау белән, җөмлә кисәкләрен ничә һәм нинди төркемнәргә бүләргә мөмкинлеге, кайсының нинди төркемгә кергәнлеге күренеп торыр иде. Мәсьәлә четереклерәк булганга, берничә мисал алып тикшереп карыйк:

| | |
|---|---|
| Октябрь революциясенә кадәр эшчеләр начар яшәгәннәр.<br>Эшчеләр яшәгәннәр, начар яшәгәннәр, революциясенә кадәр, Октябрь революциясенә кадәр яшәгәннәр | Коммунада җирне трактор белән сөрәләр.<br>Сөрәләр, трактор белән сөрәләр, җирне сөрәләр, Коммунада сөрәләр |
| Аның кара күзләре ут шикелле яна.<br>Күзләре яна, ут шикелле яна, аның күзләре, аның кара күзләре | Мин сиңа ул сүзне юри әйттем.<br>Мин әйттем, сүзне әйттем, ул сүзне, сиңа әйттем, юри әйттем |
| Мин бөтен бәхетсезлекне үземнән күрәм.<br>Мин күрәм, үземнән күрәм, бәхетсезлекне күрәм, бөтен бәхетсезлекне | Безнең бүлмә бу өйдән зуррак булыр.<br>Бүлмә булыр безнең, зуррак булыр, бүлмә бу өйдән, өйдән зуррак |

| | | |
|---|---|---|
| Эшчеләр яшәгәннәр | Җирне сөрәләр | Трактор белән сөрәләр |
| Мин әйттем | Коммунада сөрәләр | Ут шикелле яна |
| Без килдек | Безнең бүлмә | Революциясенә кадәр |
| Бөтен бәхетсезлекне | Өйдән зуррак | Яшәгәннәр |
| Ул сүзне | Юри әйттем | |
| Кара күзләре | Начар яшәгәннәр | |
| | Зуррак булыр | |

Менә нинди генә һәм күпме генә мисал алмыйк, аның эчендәге сүзләрнең ярашулары тышкы күренешләре ягыннан караганда шушы биш төрдән-формадан артмаячак та, кимемәячәк тә. Боларны бер-берсе белән чагыштырып карасак, беренче, икенче һәм өченче

бүлектәгеләр ияручелек юлы белән ярашканнар, ләкин ияручелектә аерма бар: беренчеләре санда һәм нисбәттә ияручелек юлы белән, икенчеләре килештә, өченчеләре ярдәмлекләр аркылы ияручелек юлы белән ярашканнар.

Дүртенче һәм бишенче бүлектәгеләре баштагы сүзләр һичбер төрлек белән төрләнмичә, тик янәшәлек белән генә ярашканнар, бер-берсен табышканнар, ләкин бу икесенең арасында да аерма бар: 4 нче бүлектәге баш сүзләр теш белән, 5 нче бүлектәгеләре фигыль белән янәшә килгәннәр. Димәк, безнең телебездә ярашу – сүзләрнең үзара бәйләнүләре ике төрле юл белән була икән: 1) ияручелек; 2) янәшәлек. Ияручелек үзе ике төрле: 1) санда һәм нисбәттә ияручелек; 2) килеш төрлекләре һәм ярдәмлекләр белән ияручелек. Янәшәлек үз нәүбәтендә тагы ике төрле: 1) исемнәр белән янәшә килүчелек, фигыльләр белән янәшә килүчелек.

Шәкли грамматика безнең нәхү бүлегендә җөмлә кисәкләрен билгеләүдә һәм аларны тәгъриф итүдә ярашуның шушы төрләре шәкел- формаль элемент булырга һәм алардан түбәндәге нәтиҗәләр килеп чыгарга тиеш:

1) Ия – җөмлә эчендә үзенә икенче сүзне ияртеп, аның белән санда һәм нисбәттә ярашып килгән сүз.

2) Хәбәр – җөмлә эчендә ияга ияреп, аның белән санда һәм нисбәттә ярашып килгән сүз (ия гаиб өчен һәм күплек булганда хәбәрнең берлектә, күплектә килергә яравын ярашуның тәфсиләте сөйләнгәндә әйтелә).

3) Тәмамлык – җөмлә эчендә икенче бер сүзгә (фигыльдән башка булырга да мөмкин) ияреп, яңа килеш төрлекләре яки ярдәмлекләр белән ярашып килгән сүз.

4) Аергыч – җөмлә эчендә икенче бер сүзгә иярми һәм төрләнми, фәкать исемнәр белән янәшә килгән сүз (парлап аерганда).

5) Хәл – җөмлә эчендә икенче бер сүзгә иярми һәм төрләнми, фәкать фигыльләр белән янәшә килгән сүз. Тәмамлыкларны үз нәүбәтләрендә нинди килеш төрлекләре белән төгәлләнүенә һәм ярдәмлекләргә карап: 1) иялек; 2) төшем; 3) юнәлеш; 4) чыгыш; 5) урын-вакыт; 6) ярдәмлек тәмамлыклары исемендә 6 га бүләргә туры килә.

Мәкаләм артык озынга китү сәбәпле, мин «Шәкли нигездә татар грамматикасы»ның нигез мәсьәләләре турында гына тукталдым. Гыйбад иптәш Алпаров бу грамматикасы белән моңа кадәр таркау

һәм томанлы хәлдә торган телебезнең шәкли грамматикасы турында киң юл ачты. Тик шул юлны дәвам иттерергә, эзләргә, тикшеренергә, тапкан белем һәм тәҗрибәләребезне уртаклашырга кирәк иде, дигән теләк белән сүземне бетерәм.

## СКЛОНЕНИЕ В ТУРЕЦКИХ ДИАЛЕКТАХ[1]

Хотя и принято думать, что к настоящему времени мы уже имеем грамматики всех турецких диалектов, составленные в достаточной степени подробно и поверхностно, как европейскими тюркологами, так и самими турецкими лингвистами. Но все же пока что нет сравнительной грамматики турецких диалектов, систематизировавшей в конкретной форме и изучающей в плоскости как исторической, так и генетической и вместе с тем фонетическими сравниваемой грамматические факторы всех турецких диалектов между собой. В этой области работа ограничивается лишь несколькими сравнительными грамматиками некоторых отдельных диалектов, кроме того можно встретить отрывочные мысли востоковедов, лишь формально изучивших отдельные грамматические факторы в грамматиках кой-каких диалектов. Появление же полной сравнительной грамматики турецких диалектов дало бы возможность составлению сравнительной грамматики турецкого языка с родственными и близкими к нему языками, а последнее несомненно послужило бы ключом к разрешению многих до сих пор еще спорных в науке об языке проблем.

Предлагаемый вниманию этот доклад ставит целью классификацию падежей турецких диалектов и рассмотрение функциональной частицы каждого падежа, или говоря обычным грамматическим термином морфемы, прежде всего с фонетической, а потом с исторической и генетической точек зрения и, наконец, общий обзор с происхождением некоторых отдельных функциональных частиц.

Тема несомненно весьма обширная и довольно трудная, требующая больших усилий и трудов. В какой степени достигнута поставленная мной цель доклада, конечно, определяет проводимые языковые факты.

[1] *Бадигов Х.* Склонение в турецких диалектах. Доклад на заседании аспирантов Ленинградского института восточных языков. 1928 г. Машинопись. ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19, оп. 2, ед. 30.

Языковые факты в докладе взяты большей частью из материалов самих турецких диалектов, но наряду с этим для определения вероятной гипотезы или же для доказательства правильности определившей гипотезы, местами пришлось пользоваться также и фактами родственных языков.

Что касается построения доклада, то прежде всего имеет место краткое суждение по методологии яфетической теории о происхождении склонения вообще в языках. Затем идет классификация падежей в турецких диалектах и выводится таблица, показывающая какие падежи имеются в турецких диалектах.

Далее следует таблица, показывающая по порядку функциональные частицы падежей в отдельных диалектах. Потом идет рассмотрение о фонетическом изменении каждой функциональной частицы. И, наконец, останавливаясь о функциях падежей употребляемых в настоящее время в различных турецких диалектах, определяется с каких функциональных слов произошли вследствие социальных факторов – функциональные частицы.

## О ПРОИСХОЖДЕНИИ СКЛОНЕНИЯ ВООБЩЕ В ЯЗЫКАХ

Ни один из всех существующих языков не является даром природы в готовом виде и не возник сам по себе. Каждый язык есть творчество человечества. После возникновения звуковой речи, яфетическая теория вопрос о дальнейшем ее оформлении и процесс накопления запаса слов связывает с организацией более и более сильного коллектива из разрозненных отдельных групп людей, ибо язык есть самый чистый и тонкий знак общения. Знак вообще не может существовать между двумя отдельными и несвязанными между собой индивидуумами. Между ними должна быть социальная связанность, коллективизм. Следовательно, отдельный человек не может творить язык, а он рождается потребностью общения и группирования людей на основе этих интересов. И дальнейший рост словесного запаса языка находится в полной зависимости от потребностей общения. Новая мысль, возникшая в конкретных условиях организации и каждое новое слово, необходимое для понятия чего-либо и каждый термин, конечно, не возникают для потребностей двух несвязанных между собой индивидуумов, а создаются для удовлетворения потребностей людей – членов коллектива, как необходимость для понимания друг друга в трудовом процессе. С ростом потребности общения членов

коллектива осложняется и состав слов, а с осложнением построения коллектива осложняется и построение языка вообще.

Если язык растет в процессе взаимоотношения между социально связанными людьми, точно также и формы его обуславливаются теми социальными формами общения, в которых находятся люди. Рассматривая с этой точки зрения важно не только то, что язык – как чистый знак, тут важно еще и повсеместность его социального нахождения.

Язык во взаимоотношениях и общении друг с другом в совместном трудовом процессе, в идеологическом оформлении в постоянных житейских столкновениях в политических взаимоотношениях, а также и в различных остальных всевозможных случаях жизни, сжимается и уплотняется, как клубок.

Все области социального общения идеологическими нитями наматываются в языке. Следовательно, само собой понятно, что язык является фактором, показывающим различные области социального изменения его цельности и все стадии оформления, как идеологической системы. Язык встречается в стадии, когда социальные изменения не успели еще оформиться и не достигли степени новой идеологической системы, встречается также и в процессе медленного количественного изменения.

Язык в состоянии уловить самые тонкие социальные изменения и его переходные моменты. Поэтому классификация форм языка вообще должна быть основана на классификации форм общения. А классификация форм общения, как известно, определяется производственными отношениями и социально-политической структурой общества.

Раньше в первобытных языках совершенно не имелись части речи. Даже не только отсутствовали части речи, но и не было слов в нашем теперешнем представлении. Были лишь звуковые комплексы, используемые для изображения образа, представления и понятия.

Значение этих звуковых комплексов, в зависимости от социальной структуры человеческого коллектива, стабилизируется сначала целыми пучками и, наконец, единицами и представляются как отдельные слова. С расширением и накоплением слов, люди для выражения своих мыслей начинают постепенно составлять фразы из имеющегося запаса слов. Но в те времена слова еще не подразделялись на глаголы и на имена. Несколько одно и тоже слово означало и именное понятие и действие, то значение определялось в

зависимости от месторасположения слова во фразе. Действие всегда выражалось словесным комплексом, одно из которых означало источник действия (субъект), другая – цель действия (объект), и третье – образ действия (сказуемое).

С истечением времени цельные слова во фразе установились в роли символа предметов, а впоследствии в роли символов субъекта и объекта – или иначе говоря в роли активного или пассивного участия в действии из тех же звуковых комплексов образовались заместители имен – местоимения.

Вместе с тем в дальнейшем дифференциация местоимения на местоимение первого лица, а также и вообще единственного числа происходит вследствие дальнейшего развития человеческого коллектива, в котором возникает понятие об отдельном лице, о его самостоятельности и о частной собственности и вообще.

После того, как местоимения получают распространение, то из имен уже выделяются глаголы. И, наконец, из этих же имен уже выделяются глаголы. И, наконец, из этих же имен образовываются функциональные слова.

Постепенно эти функциональные слова, обратившись в функциональные частицы (формальные морфемы) и последние в свою очередь, будучи в известной системе, соединены с и материальными морфемами образовывают уже новые слова, которые с истечением времени теряют свои коренные значения. И впоследствии же в соединении с материальными морфемами употребляются в языке как придающие известный оттенок коренному их значению и применяются также в целях нового словообразования или же в качестве показателя отношения одного слова к другому.

Отношение одного слова к другому означает в жизни статистическое взаимоотношение членов общества между собою, а в языке же соответственно с этим означает взаимоотношение между собою членов предложения.

Предложение это – выражение известной мысли словами возникшей от взаимоотношения предметов между собою.

Если взаимоотношение предметов между собой находит формальное выражение во флективном типе языков прямое изменение окончаний, вошедших в предложение слов, а в агглютинативном типе соединение функциональных частиц к окончанию слов, то это уже обычно в грамматике называется склонением.

Склонение обычно выражается не только взаимоотношением слов между собою, но и согласованностью слов между собою, означающих данные предметы, как в жизни любой производственной организации между ее членами и предметами.

Формальное обозначение взаимоотношения и согласования предметов, или иначе говоря, потребность в формальном обозначении социальности слов, возникла, несомненно, в позднейшее время, в эпоху соответственного роста и дальнейшего развития общественных форм.

Следовательно склонение вообще в языке как видно выше из диалектического развития звуковых языков и из палеонтологического анализа языковых фактов турецких диалектов (об этом ниже), обязано своим происхождением с одной стороны организации в процессе труда из мелких и разрозненных человеческих групп в сильные и крупные коллективы, разделению труда между ее членами, осознанию самостоятельности, а с другой стороны, образованию семейной ячейки с выделением кровного родства.

## ФУНКЦИОНАЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ ПАДЕЖЕЙ В ТУРЕЦКИХ ДИАЛЕКТАХ

Человеческая речь вообще в своем процессе развития в основном едина.

Расчленение же языков на различные системы, оформившиеся в своем направлении в известных эпохах в основном продолжение одного и того же процесса развития, ибо языки не развиваются сами по себе.

Развитие языка тесно связано с потребностью членов организованного коллектива в трудовом процессе. Поэтому и внешняя форма языка изменяется в зависимости от социально-экономического состояния языкового коллектива.

В результате система языков, являясь лишь отдельными проявлениями в общем прогрессивном потоке языков, генетически тесно связываются между собою.

Турецкие диалекты по их теперешнему процессу развития считаются из урало-алтайской системы языков или по терминологии яфейтической теории называются Алданской системой языков.

Языки Урало-алтайской системы от аморфно-синтетического и флективного типа языков отличаются, во-первых, агглютинативными особенностями.

Если отдельные понятия аморфно-синтетического типа языков выражаются отдельными корнями, а отношения между ними определяются от месторасположения их в фразе, то во флективном типе языков это отношение между словами выражаются особыми функциональными частицами – формальными элементами. Вместе с тем эти формальные элементы бывают органически соединены с корнем или основой и сплетены между собой. Чтобы придать отдельные оттенки в материальных значениях слов или для выражения отношения между ними в агглютинативном типе языков к корню или основе соединяются те же формальные элементы.

Но это соединение к основе или корню этих формальных элементов по сравнению с флективным типом языков, как социально, так и формально весьма закономерны.

С формальной стороны они определенной системой механически одна за другой соединяются к окончанию корней или основ. Поэтому они отличаются друг от друга, а также и от основ их корней.

Например,

*qul* – рука

*qulьm* – моя рука

*qulьmda* – в моей руке

*qulьmdagь* – находящийся в моей руке

*qulьmdagьn* – находящегося в моей руке и т. д.

С социальной стороны для того, чтобы придать оттенок понятиям, в большинстве случаев соединяется один и тот же формальный элемент.

Формальные элементы, соединенные во взятом выше примере *qul* могут быть соединены точно также и к окончанию любых имен, чтобы дать известный оттенок.

Во-вторых, агглютинативные типы языков отличаются от других типов аггармонизацией – особенностью согласования между собой гласных звуков. В агглютинативном типе, звуки, вошедшие в одно и то же слово с начала до конца бывают или твердыми, или наоборот мягкими, или же твердые гласные звуки соединяются только твердыми согласными звуками, а гласные мягкие с мягкими согласными. Формальные элементы сами подчиняются закону аггармонизации корней и основ.

Как всегда твердым корням или основам соединяются твердые формальные элементы, а мягкому только мягкие.

Например, *taş* (камень), *taşlar* (камни), *taşlarda* (в камнях) и т. д. *teş* (зуб), *teşlər* (зубы), *teşlərdə* (в зубах) и т. д.

В турецких диалектах обе эти особенности хорошо сохранились до сих пор. Но вместе с тем нельзя считать, что эти две особенности являются для всей системы урало-алтайских языков общим и установившимся законом.

С изменением форм общения между отдельными языковыми коллективами изменяются также постепенно и внешние формы языков. Можно проследить изо дня в день разрушение этих двух особенностей в турецких диалектах. В диалектах узбекском и таранчинском можно считать совершенно исчезнувшей особенностью аггармонизацию. Довольно ясно заметно постепенное разрушение этих особенностей и а остальных диалектах в условиях последней социально-экономической структуры, в особенности, под влиянием чужих терминов, заимствованных от других языковых коллективов.

В третьих, агглютинативные языки от других типов отличаются также и синтаксическими построениями. Если наиболее важные слова во фликтивном типе языков обычно стоят в начале предложения, то в агглютинативном типе языков эти наиболее важные слова вообще остаются в конце предложения, а самое важное слово стоит как правило в самом конце предложения.

А также с точки зрения связи слов в предложении нельзя сказать, что нет в них различия.

В турецких диалектах слова в предложении соединяются прежде всего одним из двух способов.

1. Путем сочинения. В этом случае отношение одних слов в предложении с другими бывает равное. Поэтому от перестановки месторасположения этих слов в предложении не изменяется ее основная мысль.

2. Путем подчинения. Слова соединенные этим путем между собой, как в смысле значения, так и по своей форме бывают подчинены одна другой.

Это подчинение в свою очередь делится на три категории:

1. Согласование. В турецких диалектах в предложениях подлежащее со сказуемым согласуются в лице и числе.

2. Управление. В этом случае управляемое и управляющее слово в турецких диалектах связаны с функциональными частицами падежей.

3. Примыкание. Определение своим определяемым и обстоятельства со своим глаголом соединяются путем примыкания.

При определении функциональных частиц падежей в турецких диалектах необходимо принять во внимание следующие принципы, исходя из этих трех особенностей агглютинативного типа языков.

1. Функциональной частицей падежей необходимо считать только морфологические элементы, которые не употребляются отдельно и не означают полного значения, подчиняясь основе или корню по закону сингармонизма.

На основе этого принципа слова, употребляемые в функциях падежей вроде *белән, өчөн,* хотя и считаются в некоторых грамматиках падежами, но они в докладе не относятся к их числу, так как они в языке могут быть употребляемыми совершенно отдельно.

2. Функциональной частицей падежей нужно считать морфологические элементы, означающие объект действия и соединяющие в предложении слова по требованию других слов.

По принципу морфологические элементы, означающие не объект состояния или действия как *ca – torekcә*, *daj – ajudaj*, а означающие обстоятельства и соединяющиеся по воле говорящего, хотя и относятся в некоторых грамматиках тоже как падежи, но в докладе они не включены в число функциональных частиц падежей.

Взяв эти принципы за основу, в турецких диалектах мы встретим следующие функциональные частицы падежей (табл. 1).

В этой таблице ясно видно неравномерность количества падежей в турецких диалектах, вместе с тем наличие общих падежей в турецких диалектах, вместе с тем наличие общих падежей всех диалектов и одинаковое происхождение функциональных частиц падежей от функциональных слов.

Если это положение с одной стороны отвергает то, что турецкие диалекты когда-то имели праязык и что этот праязык, потом получил различные изменения или то, что эти диалекты некогда составляли одно «государство» или «нацию» и что падежи возникли потом, то с другой стороны ясно показывает постепенное возникновение падежей во всех диалектах в силу одних и тех ж социально-экономических условий.

Рассмотрим в каких социальных условиях возникли каждые падежи и функциональные слова, из которых возникли функциональные частицы.

Таблица № 1, показывающая сколько и какие падежи имеются в турецких диалектах

| диалекты | каз.-тат. | башк. | казак-кирг. | узб. | азерб. | анат. тур. | туркм. | алт. | якут. | чув. | уйг. | орхон. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Именит. п. | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Родит. п. | nəñ nə̈ñ | nəñ nə̈ñ | nəñ nəñ | nəñ nə̈ñ | nыñ niñ | nыñ niñ | nыñ niñ | nыñ niñ | – | nəñ nə̈ñ | nыñ niñ | nыñ niñ |
| Дат. п. | qa ga | qa ga | qa ga | qa ga | a ä | a ä | a ä | qă ğă | qa ğa | a – ă na – ya | qar ğar | qar ğar |
| Винит. п. | nə nə̈ | nə nə̈ | nə nə̈ | nə nə̈ | ə ə̈ | ə ə̈ | nы ni | nы ni | nы ni | na nä | nы ni | nы ni |
| Исход. п. | dan dän | dan dän | dan dän | dan dän | dan dän | dan dän | dan dän | dan dän | dan dän | tan tän | dan dän | da dä dan |
| Мест. п. | dan dän | da dä | da dä | da dä | da dä | da dä | da dä | da dä | – | ta tä | da dä | da dä |
| Инстр. п. | – | – | – | – | – | la lä | – | – | nan nän | yalan yälan | – | n n |
| Част. п. | – | – | – | – | – | – | – | – | la lä | – | – | – |
| Совмест. п. | – | – | – | – | – | – | – | – | lən lə̈n | – | – | – |
| Сравнит. п. | – | – | – | – | – | – | – | – | dağur dağur | – | – | – |
| Направит. п. | – | – | – | – | – | – | – | sar sar | – | – | – | – |

В турецких диалектах не образовалась отдельная функциональная частица для именительного падежа, поэтому первоначальное положение каждого слова условно считается именительным падежом.

Из остальных падежей, как видно из связи слов в предложении, прежде всего оформился родительный падеж.

Начнем анализ с родительного падежа.

РОДИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ

В прилагаемой таблице представлены функциональные частицы родительного падежа в 12 диалектах – казанско-татарском, башкирском, казак-киргизском, узбекском, азербайджанском, анатолийско-турецком, туркменском, алтайском, якутском, чувашском, уйгурском и орхонском, а вслед затем указаны иллюстрирующие примеры.

Приведенные варианты функциональных частиц родительного падежа, отражающие фонетические законы соответствующих диалектов, восходят к двум древнейшим типам – без начального *n* и с начальным *n*. В турецком языке и вообще в южном отделе, с включением туркменского языка и в сельджукском (еще также в чувашском), встречаем оба типа, дифференцированные внешним образом, соответственно конечному звуку основы: после гласных окончание является начальным *n*, а после согласных без начального *n*. В орхонских надписях в основах на согласные находим окончание без начального *n,* т.е. подобно языкам южного отдела, напр., *bägen* «князя». Окончание *en/nen* родительного падежа не чуждо и прочим турецким диалектам, существуя в них лишь в категории местоимений личных и указательных сравн. казанск. татар *sin-en* (тебя), *anen* (его).

Значит, в результате фонетического анализа в турецких диалектах должна быть функциональная частица родительного падежа *nәñ* или *neñ*.

Профессор Богородицкий в своей статье «Эволюции окончаний родительного падежа в турецких диалектах» после сравнительного анализа над четырьмя диалектическими материалами пытается доказать, что в основе функциональной частицы родительного падежа должна быть *ennәn* и что якобы первоначальный *n* произошел по аналогии от местоимения[1].

Второй ученый С. В. Ястремский в своем большом труде «Грамматика якутского языка», утверждая образование в якутском языке

[1] Вестник Научного общества татароведения. № 3. 1925. С. 13.

прежде всего родительного падежа, который впоследствии как бы исчез, говорит:

«В языках Урало-Алтайской ветви “*n*” является безусловно основным окончанием родительного падежа»[1].

Кроме формальных исследований двух этих ученых об основе функциональной частицы родительного падежа в турецких диалектах, других источников нет. Даже, если бы и были, то я уверен, что до сих пор все лингвисты-тюркологи, вследствие формального и сравнительного метода и подхода языковому материалу, не были бы больше того, что эти указанные выше ученые.

Правильность одной из этих форм, а также и образование в турецких диалектах вообще функциональной частицы родительного падежа, может быть уяснена не формально-сравнительным методом, а палеонтологическим анализом. Здесь приходится считаться как с оформлением родительного падежа, также его семантикой. Поэтому прежде всего приходится установить функции употребления в турецких диалектах родительного падежа в настоящей стадии, ибо в настоящей стадии во всяком случае функция будущих стадий, архаизм должен быть сохранен.

Родительный падеж в турецких диалектах образуется от соединения двух слов, первое управляемое, второе управляющее. Управляющее слово, как правило, находится в начале в соединении с функциональной частицой падеже, управляющее слово, находясь вслед за ним, в зависимости от лица управляемого слова соединяется притяжательной частицей. Например, *balanьñ kitabь = bala-nьñ + kitab-ь; minem kitabьm = min-em (neñ) + kitab-ьm; sineñ kitabьñ = sin-eñ (neñ) + kitab-ьñ.*

В простонародном языке управляющее слово может быть в начале, а управляемое в конце. Например, *tübäse tuzdь ojneñ.*

Иногда даже функциональная частица падежа совершенно может выпасть, но выпадение ее отражается на значении и тогда управляемое и управляющее вместе означают название какого-либо предмета. Например, *Ural tavь.*

Даже и притяжательная частица, находящаяся в конце управляющего слова может совершенно отпасть и образовать сложное слово. Например, *bilbav (bilbavь), kөncogьş (kөncogьşь).*

---

[1] *Ястремский С.В.* Грамматика якутского языка. 1900.

Между прочим, исчезновение родительного падежа в якутском языке можно объяснить как раз этим путем.

Во всех турецких диалектах в настоящей стадии родительный падеж означает принадлежность, через прибавление родительного падежа, именно понятие становится более узким и более определенным. Например, если сказать *atапьñ öуö – д*ом отца, то означает, что дом принадлежит отцу и что собственником дома является отец.

Если это так, то функция родительного падежа в настоящей стадии дает нам право считать и строить вероятную гипотезу об образовании его после возникновения понятия «имущества и собственности».

Запасы пищи, во всяком случае, не могли послужить исходной точкой для возникновения понятия о собственности. Иначе обстояло дело относительно орудий, хотя бы и самых простых, которые были бы для человека в одно и то же время и орудием и оружием. Таковы заостренная палка и простой или обделанный камень. Чем менее было у человека запасов пищи, тем более он должен был быть всегда наготове, чтобы добыть ее себе. Поэтому орудия и оружие он должен был носить всегда с собой. Пока ими служили только необработанная камень и палка, сохранение именно того или другого экземпляров не имело особого значения: их можно было найти повсюду. Но как только появилась самая незначительная их отделка – орудия приобрели для человека индивидуальную ценность, и он перестал отдавать и обменивать их с такой же легкостью, как раньше. Древненемецкое слово *munt* означает в одно и то же время и руку и обладание предметом. Также и в турецких диалектах в настоящее время есть случаи употребления слова *qul* в аллегорическом смысле как «имущество». Например, о щедром человеке говорят *kiŋ qullь keşe* (человек с просторной рукой), о человеке склонном воровству говорят *ozon qullь keşe* (человек с длинной рукой). Но в эти времена понятие собственности и имущества имеют чересчур широкую и абстрактную форму, ибо тогда еще нет перехода имущества, как наследства из рук в руки, из рода в род.

В истории общественных форм конкретизации понятий собственности и имущества начинаются в патриархальном родовом строе, а в особенности патриархальном родовом строе с разделением на кровное родство.

В эти отдаленные времена *bala* (дети) в имуществе играет крупную роль, он считается эквивалентом имущества, даже для дока-

зательства своего потомства и о принадлежном ребенке в родовом обществе установился так называемый обычай *кувады*.

Поэтому в те времена слово *bala* (дитя) должно быть употреблялся в значении *gailä* (семья), *bala* (дитя) и имущество.

Исходя из этой вероятной гипотезы, перед нами открывается возможность рассматривать функциональную частицу родительного падежа в турецких диалектах, как образовавшуюся от слова *nan* – дитя.

Если к тому же прибавит, что элементы фамилии вомногих языках по палеонтологическому анализу происходят от слова *дитя,* а в турецких диалектах употребление *bala* в прямом смысле элементом фамилии, а в простонародном языке употребление фамилии в родительном падеже (как например *Səjdəş Axatçanь*, то правильность нашего рассуждения становится еще более очевидной.

Выше после фонетического анализа мы видели, как функциональная частица родительного падежа осталась в формах *mən* и *men*.

На самом деле есть в говоре мамадышского кантона казанско-татарского диалекта *nanьj*, в тиляутском диалекте *nanaqqaj* и в кайбальском *nançь* – ласкательные слова в обращении к детям *j* в конце слов эта функциональная частица звательного падежа в турецких диалектах, остается *nan* – буквально дитя; в казанско-татарском диалекте *näni*- маленький и младший, *näni abьj* – младший брат; в шорском диалекте *naajas* – маленький ребенок; в танно-тубинском *näñ* – внук; в тиляутском *naçьgaj*, *najьgaj* – кукла; в чагатайском *ninäk* – зрачок; в крымском азербайджанском и анатолийско-турецком диалектах *nänä* – матушка, в карагасском *näñä* – тетка; в шорском и тубинском *näñä*, в сагайском *nägäce*, в тубинском *nägäj* – невеста, жена старшего брата; в киргизском *nagaş ata* – отец матери, и *nagaş aga* – брат матери; в чагатайском *nagacь* – родственник по матери; в алтайском и тиляутском *naja* – товарищ; в киргизском *nañiz*, в татарском *nigiz* – основание, происхождение, семейство; в танно-тубинском *non* – народ; в Кудатку-белек *näñsäñun* – какое-то почетное лицо какого-то племени или каких-то племен; в шорском *nämä* – вещь, имущество, существо; во всех турецких диалектах *ni* – вопросительное местоимение; в уйгурских надписях *nañ* – имущество, собственность. Например, کیژی نه کی ئالما, یانه توکمه قان – ты не бери чужой собственности и не проливай кровь; в Махмуд Кашгари XI века слово *näñ* переводится как الشی, т.е. – вещь. Например, بونه نه ك ئول , ای ما هزه الشی т.е. ‘что такое эта вещь’; точно также

*näñ* переводится как المال, т.е. товар и имущество. Сюда же, думаю, относится и русское слово *няня*.

С другой стороны, по фонетическому закону в пределах турецких диалектов имеем перебой, когда начальный звук *n* переходит на *j*, в башкирском диалекте *jengäj*, в казахском *ƶiŋgäşь*, в казанско-татарском *ciñgäj* – невеста, жена старшего брата; с подъемом *g* → *k, k*→*q*, в крымском и анатолийско-турецком *gäneş* – молодой, свежий, новый; в башкирском *kinjä*, в казахском *kinƶa* – последыш, последний ребенок; в шорском qomaj, в тюмянском *kiñägä* – младший брат и сестра; в куманском, табульском, киргизском и чагатайском *küŋ*, в барабинском *küñcük* – рабыня, служанка. Например, سارا ایدی مین تقی الله نینک بیر کونجکی ‘Сара говорила, что я тоже ничтожная рабыня бога’. (Рабгузи); в сагайском и уйгурском – народ. Например, ‘Испытанный человек знает дела народа’: во всех диалектах *küñel* – сердце, сердечное чувство, милость; قای کم قان – вопросительные местоимения.

Также и конечные элементы слова قوزعن (ворона) должны быть образованы от того же слова с усечением конечного в слове قارعا (ворона).

Значит, قوزعن (ворона) и قارعا (ворона) означает = дитя огня = дитя солнца. Наконец функциональной частицы ласкательности в турецких диалектах / по-видимому от того же слова *nan* (дитя).

Следовательно, основа функциональной частицы родительного падежа в турецких диалектах, как видно в результате нашего анализа, состоит из третьего элемента *nan,* относящиеся к ионским элементам. Это слово в пучковом значении означало в те времена понятие дитя, семья и имущество.

А в последствии установилось в различных турецких диалектах в значении членов семьи и имущества.

Таким образом, первоначальное построение родительного падежа мыслится так ئول + ئوی + ناك + ئاتا буквально значит ‘отец+ дитя + дом +это’.

ДАТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ

В прилагаемой таблице представлены функциональные частицы дательного падежа тоже в двенадцати диалектах.

Приведенные варианты функциональных частиц дательного падежа, отражающие фонетические законы соответствующих диалектов, восходят к двум древнейшим типам *qar*/*ğar*.

Основная функция дательного падежа – обозначает лицо или предмет, для которых совершается действие, или место, к которому направляется действие. Таким образом, рассматриваемый падеж соприкасается по своей функции с местным падежом, который показывает место на котором или время, когда совершается действие. Разницу между этими падежами можно определить таким образом, что один из них является падежом положения (мест. п.), а другой – падежом движения к чему-либо (дат. п.). Вследствие смыслового соприкосновения этих падежей происходило частое распространение по аналогии формы с одного падежа на другой. В турецких диалектах мы встречаем случаи одинакового обозначения для дательного и местного падежей, например, в якутском языке дательный падеж выражает все различные отношения места, времени, дополнения и обстоятельства образа действия и цели, сводимые, как к отношениям направления на вопрос куда?, так и к отношениям покоя на вопрос где? А в алтайском диалекте дательный падеж обозначает только лицо или предмет, для которых совершается действие, а для выражения места, к которому направляется действие, образовался особый падеж – падеж направительный.

Во время выражения глаголов, требующих дательного падежа, с точки зрения основных функций последнего, обычно на ряду с этими глаголами, если действие совершается лицом или предметом, то мы в состоянии указывать пальцем на эти предметы и лица.

Во всяком случае руки в дательном падеже играют большую роль. Этот обычай, конечно, ни с проста, он, по-видимому, является остатком древней кинетической речи. Поэтому есть основание думать и строить вероятную гипотезу, что функциональная частица дательного падежа образовалась от слова *qul* ‘рука’.

Так как звуковая речь по доказательствам яфетидологии нарастала постепенно в путях той идеологии, которая была получена в наследие от кинетической речи, как, например, в зависимости от того, что ‘звать’ заменило в звуковой речи ‘мановение рукой’, с движением к себе в знак приглашения, а указывать заменило в звуковой речи указание ‘перстом’, т.е. ‘рукой’, слово рука оказалась в основе глаголов, означающих одинаково и ‘звать’ и ‘указывать’. Отсюда рука использовалась и для обозначения, т.е. выражения знака.

Даже в русском слове ‘показывать’, ‘указывать’ основа *kaz*← *kas* разновидность *kal, kar* в языках яфеической системы пережившего

в армянском *kar* (рука) → ‘сила’: *kal* – бери (рука) и означавшего прежде всего руку.

Точно также, по палеонтологии доказано, что глаголы турецкого языка, например, *qərmaq* (тереть, разбить), *qor-maq* (строить, заряжать ружье), *or-maq* (бить, ударить), *ərğət-maq* (бросать, кидать), *kəl-maq* (делать, производить), *al-maq* (брать), *vär-mäq* (дать), *ur-maq* (жать), *urla-maq* (красть, воровать), *ülcä-mäq* (вешать, мерить), *el-mäq* (вешать, повести) и т. д. Все они происходили от слова *qul* – *äl*, т.е. от руки.

Уже было видно выше из фонетического анализа функциональной частицы дательного падежа в турецких диалектах мы остановились на следующих формах: в чувашском и вообще в южных диалектах *a* – *ä*, северных диалектах *qa* – *ğa*, в уйгурских и орхонских надписях *qar* – *ğar*.

Следовательно, нет надобности доказывать из анализа о существовании раньше двух типов функциональных частиц дательного падежа *qar* – *ğar*. С истечением времени в северных диалектах произошло усечение конечного *r* , а в чувашском и южных турков начальные и конечные звуки.

## ОСНОВЫ СИНТАКСИСА ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА
## (Опыт изучения синтаксиса татарского языка с формальной точки зрения)[1]

Течение формального изучения языка хотя и началось давно среди европейских ученых, в том числе и русских лингвистов, и составлены уже были грамматики и разработаны методы изучения по тому принципу еще до Октябрьской революции, но это течение проникло к нам лишь после Октябрьской революции. Грамматики, составленные татарскими лингвистами до Октября были, т.е. носили логический характер, или же в лучшем случае полулогический характер.

После революции, когда татарские школы со стороны цели и содержания, изменившись, стали писаться на основе трудового принципа и Педагогическими комиссиями при Академическом центре Татнаркомпроса и были составлены на основе трудового принципа

[1] *Бадигов Х.* Основы синтаксиса татарского языка (опыт изучения синтаксиса татарского языка с формальной точки зрения). Машинопись. ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 19, оп. 2, ед. 34

программы для школ 1-ой и 2-ой ступени, тогда и при составлении программ родного языка также в первый раз был применен принцип формальной грамматики. В объяснительных записках этих программ проводилась мысль о том, что только формальная грамматика научна и близка к цели при изучении языка и что потому необходимо применять формальный метод в трудовых школах при наблюдении над языком. После этого, в научных журналах в этой области появились научные статьи лингвистов, а также серьезные дискуссии о возможности применения формального принципа к грамматике татарского языка (см. статьи тов. Н. Хакимова в журналах «Безнең юл» 1922 г., № 4, 1923 г., № 6, «Магариф». 1924 г., № 3–4, и 1926 г. № 1–2. Статью доц. Г. Саади в журнале «Магариф», 1925, № 4–5. Статьи тов. Г. Алпарова в журналах «Белем», 1925, № 4 и «Магариф», 1925, № 10–11). В результате большинство проявило склонность к формальной грамматике. И среди наших языковедов выявилось стремление к изучению грамматики татарского языка с формальной точки зрения. В составленном в 1924-м году М. Курбангалиевым и Р. Газизовым для русских «Опыт краткой практической грамматики татарского языка» были попытки применения формального принципа. По желанию Акцентра Татаркомпроса весной 1925 года были устроены лекции проф. Александра Николаевича Самойловича на тему «Морфологические элементы турецкого языка» в Казанском университете. Таким образом была подготовлена почва для формальной грамматики татарского языка. Число охотников и исследователей увеличилось. Но кроме вышеупомянутых программ, отдельных статей, лекций, исследований языковедов, «Опыта краткой практической грамматики татарского языка» Курбангалиева и Азизова, «Краткой учебной грамматики современного османско-турецкого языка А. Н. Самойловича, составленной на основе анатолийско-турецкого языка в 1925 г., у нас не было полной формальной грамматики татарского языка, которая охватывала бы все вопросы грамматики в применении к татарскому языку.

Наконец, в 1925 году вышла из печати на татарском языке «Татарская грамматика по формальному принципу» тов. Алпарова. Эта грамматика систематизировала вопросы формальной грамматики языка, которые до сего времени были в разбросанном, несвязном состоянии. Второй важной стороной этой грамматики нужно считать исследование приставок и приведение их в систему.

Таким образом, сколько бы и какие бы ни было предложения мы возьмем, всегда обнаружим, что имеются ни больше ни меньше, как четыре вышеупомянутые виды грамматических связей. Если сравним со стороны связей эти парные слова в этих четырех отделах, то мы увидим, что первые слова из парных слов в первом отделе находятся в имен. падеже, а вторые слова, путем управления с ними, связаны в числе и лице. Например, когда говорим " قوياش چيقدی ", слово „ قوياش „ требует, чтобы слово " چيقدی " стояло в единственном числе третьего лица; когда говорим " مين تابدم ", слово " مين " требует, чтобы " تابدم " стояло в единственном числе первого лица.

Во втором отделе парные слова связаны между собой путем управления при помощи падежных приставок или служебных слов; например, при выражении " مهجيننڭ كوزلری " , слово " كوزلری " требует, чтобы слово " مهجی " стояло в притяжательном падеже. При выражении " آولدان قايتديلر ", слово " قايتديلر " требует исходного падежа от слова " آول ". Точно также при выражении " بلتردان بيرلی سويلر " слово " سويلر " требует, чтобы предыдущее слово " بلتر " было управляемо при помощи служебного слова " بيرلی ". При выражении " تشلر بلن كيمرلر " слово " كيمرلر " требует то же самое при помощи служебного слова " بلن ".

В парных словах же 3-го и 4-го отдела нет такого управления. Они только связаны между собой путем примыкания. Но между ними также имеется различие. Первые слова 3-го отдела примыкают к именам, 4-го же отдела – к глаголам. Из этого видно, что

Х. Бәдигыйнең «Основы синтаксиса татарского языка (Опыт изучения синтаксиса татарского языка с формальной точки зрения)» мәкаләсеннән фрагмент

Приставки являются важным морфологическим элементом не только в татарском языке, но и во всех других агглютинирующих языках. Несмотря на это, эти приставки в нашей грамматике были мало изучены. На созванной Научной коллегией в 1919 г. (1–12 января) «Конференции письма и орфографий» в г. Казани проф. Катановым был сделан очень важный доклад, в котором он указывал на существование в татарском языке 128 приставок, каждая из которых имеет две формы по принципу сингармонизма и на существование систем этих приставок. Но этот его доклад, как и другие материалы конференции, к сожалению, не появились на страницах печати. Можно было бы этот доклад использовать и в настоящее время.

Сказать, что с выходом из печати грамматики т. Алпарова все вопросы формальной грамматики татарского языка уже разрешены – нельзя, ибо возможны там недостатки, противоречия и существование незатронутых еще других грамматических вопросов. В особенности синтаксическая часть грамматики у нас еще очень слабо разработана. Поэтому полагаю, что настоящая статья, являющаяся результатом изучения вопросов формальной грамматики татарского языка, не будет напрасным трудом.

## СИНТАКСИС КАК ОТДЕЛ ГРАММАТИКИ

Каждый язык возникает, развивается, живет и все время изменяется. Хотя, по утверждению лингвистов-тюркологов, турецкие языки по сравнению с другими языками менее всего подвергаются изменению и, таким образом, являются более консервативными, но все-таки, если сравнить язык орхонских надписей VIII века с современными живыми языками, то мы обнаружим значительную разницу. Но эти источники, имеющие огромное значение при изучении истории турецких народов как единственные памятники на турецком языке, еще не вполне расшифрованы и многие места, считающиеся расшифрованными, являются спорными. Значит, строй современных живых турецких языков в своей жизни образовался, изменяясь по определеным закономерностям явлений языка. Поэтому при составлении грамматики какого-нибудь языка, необходимо считаться с его современным состоянием. В современном живом языке мы находим звуки определенной системы, дошедшие до нас от прошлого язык и принятые самим языком слова, образуемые этими звуками, формальные элементы, предохраняющие строй

языка от сильных изменений и словосочетания, которые получаются из слов при помощи упомянутых элементов. Таким образом, наука грамматики построена на трех базисах: звуки, слова и словосочетания. Соответственно этому, грамматика, естественно, делится на три отдела: 1) фонетика, 2) морфология, 3) синтаксис.

Фонетика изучает язык со стороны звуков и их систем; морфология, можно сказать, представляет собой инвентарь отдельных слов и формальных элементов, а синтаксис показывает, как пользоваться этими словами и формальными элементами при словосочетании. Таким образом, синтаксис, как отдел грамматики, раскрывает законы связывания слов в словосочетании и изучает типы зависимостей этих слов.

## ФОРМАЛЬНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ В СИНТАКСИСЕ

Так как синтаксис является наукой о связывании слов, то нам необходимо теперь определить те формальные элементы, с помощью которых происходит это связывание. Если мы возьмем всевозможные предложения, употребляемые в нашем языке и рассмотрим входящие в них слова со стороны их связи, то найдем там нижеследующие грамматические элементы, являющиеся формальными элементами синтаксиса татарского языка.

1. Приставки – такие морфологические элементы, которые в отдельности в языке не употребляются, в отдельности ничего не обозначают, подчиняются сингармонизму и ударению тех слов, к которым присоединяются. Приставки по своей грамматической функции делятся на две части: 1) морфологические приставки – это те, которые присоединяясь по желанию говорящего к словам, дают новое слово с совершенно другим смыслом, или же основному значению данного слова придают особый оттенок. К этим приставкам относятся чисто словообразующие приставки и приставки, которые изменяют слова в морфологическом отношении, как например, приставки степени, отрицания и наклонения; 2) синтаксические приставки – это те приставки, которые присоединяются к словам вне желания говорящего по требованию других слов, являющихся управляющими и показывают отношения слов друг к другу и связь между ними. В синтаксисе служат формальными элементами, конечно, эти последние – синтаксические приставки.

Личные приставки, которые соединяются к чистым глаголам:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| *м* | *языйм* | *яздым* | *ķ – к* | *языйк* | *яздык* |
| *ң* | *яз (ң)* | *яздың* | *гы-гез* | *языгыз* | *яздыгыз* |
| *ы-сын* | *язсын* | *язды* | *лар-ләр, сынлар-сенләр* | *язсынлар* | *яздылар* |

Приставки сказуемости – это чистые формы сказуемости, присоединяющиеся к именам и причастиям, являющимися сказуемым в предложении:

| | | | |
|---|---|---|---|
| *мын* | *кешемен* | *яхшымын* | *укыганмын* |
| *сың* | *кешесең* | *яхшысың* | *укыгансың* |
| *ул* | *кеше* | *яхшы* | *укыган* |
| *без* | *кешеләрбез* | *яхшыларбыз* | *укыганларбыз* |
| *сез* | *кешеләрсез* | *яхшыларсыз* | *укыганларсыз* |
| *алар* | *кешеләр* | *яхшылар* | *укыганлар* |

Сказуемые не имеют для третьего лица специальных приставок сказуемости, но вместе приставок сказуемости иногда употребляются местоимения *ул* для един. числа и *алар* для множест. числа, или частица *дыр*. Напримр, *Агыйдел бик матур ул. Мәскәү, Ленинград һәм Казан ССҖ Союзында мәшһүр шәһәрләр алар.*

Притяжательные приставки – приставки, соединяющиеся к управляющим словам, соответственно лицу управляемого слова, находящегося в притяжательном падеже:

| | | |
|---|---|---|
| *м* | *минем (минең) атым* | *алмам* |
| *ң* | *синең (синнең) атың* | *алмаң* |
| *ы-сы* | *аның (улның) аты* | *алмасы* |
| *без* | *безнең атыбыз* | *алмабыз* |
| *гыз-гез* | *сезнең атыгыз* | *алмагыз* |
| – | *аларның аты* | *алмасы* |

Приставки множественного числа – формы множ. ч. для имен и для глаголов 3-го лица:

*лар-ләр урманлар кешеләр укыдылар укыганлар*

Падежные приставки. В нашей грамматике вопрос падежа еще не вполне разрешен. Некоторые наши специалисты совершенно отрицают существование падежей в татарском языке, другие считают шесть падежей вместе с именительным, третьи – восемь и даже девять падежей.

После анализа татарского языка, нам известно, что слова делятся на две группы: изменяемые и неизменяемые. Каждое изменяемое слово – имена и глаголы – имеет по несколько форм словоизменения

данной категории. Но в своей речи в каждом определенном случае мы можем употребить слово лишь в одной из свойственных ему форм, причем выбор данной формы всецело зависит от того, с каким словом или словами это слово стоит в связи. Таким образом, в нашем языке слова в речи тесно связаны друг с другом, зависят одно от другого в выборе форм. Следовательно, наш язык относится к синтаксическим языкам. Имена по требованию других слов спрягаются при помощи определенных приставок; слова, к которым присоединялись эти приставки по законам синтаксической связи, считаясь дополнением, не могут быть определением или обстоятельством, и также эти слова не употребляются как самостоятельные слова вне предложения, поэтому такие приставки нужно считать падежными. Теперь нам надо выяснить, сколько таких приставок в нашем языке. Под падежными приставками, по моему мнению, следует понимать: во-первых, приставки, подчиняющиеся сингармонизму и ударению слова, к которым присоединяются и после присоединения которого все слово с внешней стороны продолжает оставаться в форме целого слова; во-вторых, то, что эти приставки, присоединяясь вне желания говорящего именам, по требованию других слов, показывают отношение одного слова к другому в предложении, и поэтому эти имена их, те приставки, по присоединении которых слово не может считаться самостоятельным вне предложения. Соответствующих этим условиям приставок в нашем языке пять. Если условно считать первоначальную форму слова за падеж, тогда всего получится следующие шесть падежей:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1) Именительный падеж | – | *урман* | *өстәл* |
| 2) Притяжательный падеж | *ның* | *урманның* | *өстәлнең* |
| 3) Винительный падеж | *ны* | *урманны* | *өстәлне* |
| 4) Направительный падеж | *га-гә, ка-кә* | *урманга* | *өстәлгә* |
| 5) Исходный падеж | *дан-дән, тан-тән* | *урмандан* | *өстәлдән* |
| 6) Временно-местный | *да-дә, та-тә* | *урманда* | *өстәлдә* |

2. Служебные слова, из которых некоторые (союзы), показывая связь между словами или предложениями, не оказывают влияния на постановку предыдущих слов. Например, *һәм, тагы (тагын), ләкин, я, яки, бәлки, чөнки, тик...*

Некоторые из них (предлоги), показывая связь между словами и предложениями, одновременно влияют на постановку склоняемых

слов в определенном падеже. Эти слова, смотря по тому какой падеж они требуют, разделяются на три группы.

1) Служебные слова, требующие притяжательного падежа. Эти слова изменяют только местоимения, за исключением местоимения третьего лица мн. ч. *алар;* например, *белән, өчен, кеби (кебек, күк), шикелле, төсле, тикле, аркылы, аша, арка, саен. Синең өчен тырышам. Үзем төсле күрәм. Алар аркасында кеше булды. Почта аркылы җибәрдем. Сандугач кебек сайрый.*

2) Требующие направительного падежа: *чаклы, хәтле, таба, күрә, кадәр. Төшкә чаклы эшләп бетерик. Урманга таба качды. Шуңа күрә йомшарды. Кешесенә күрә.*

Слово *чаклы*, иногда входя в ряд требующих притяжат. падежа слов, изменяет местоимения в притяжат. падеже. Слово *күрә* большею частью употребляется вместе с местоимением *шул* и со словами, к которым присоединены притяжательные приставки: *Синең чаклы бар. Тау чаклы печән кибәне. Шуңа күрә. Чиләгенә күрә капкачы.*

3) Требующие исходного падежа: *башка, бүтән, бирле, соң, соңра, элек, ары, бире. Атдан башка көн күрү авыр. Синдән бүтән кешене күрмәдем. Төшдән соң бераз эшләб алдык. Кичәдән бирле яңгыр ява. Ул бездән ары тора.*

3. Относительные слова. Они показывают связь между предложениями, входящими в состав сложного. Роль относительных слов играют большею частью разные формы указательных и вопросительных местоимений. Смотря по тому, какая будет находиться форма вопросит. местоимения в первом предложении, во втором предложении ей будет соответствовать такая же форма указательного мстоимения. Например, *кем – ул, ни – шул, нинди – шундый, ничек – шулай, кайсы – шунысы, кая – шуңа, кайда – шунда, әнә – менә. Кем эшли, шул ашый. Ни чәчсәң, шуны урырсың. Атасы нинди, баласы шундый. Кигән кийем ничек туза, яшь гомер шулай уза.*

4. Интонация – определяет тип и законченность или же законченность предложения.

## ОСНОВНЫЕ ТИПЫ ГРАММАТИЧЕСКИХ СВЯЗЕЙ

Значит, в татарском синтаксисе существуют четыре вида формальных элементов вышеупомянутых, из которых одни показывают связь между словами, другие между предложениями. При помощи этих четырех элементов мы можем узнать только связь между

предложениями или же словами речи. Но по ним еще нельзя установить предложения и его члены, являющиеся главным содержанием синтаксиса. Для этого нужно сначала определить, как связываются слова в строе языка и какие имеются грамматические связи и их типы. Слова в речи могут быть соединены путем управления, согласования или примыкания; управление может проявляться в числе, лице, падеже или при помощи служебных слов; примыкание также может быть: примыкание с глаголом или примыкание с именем и т. д. Итак, нужно выяснить, какие из этих грамматических связей находятся в татарском языке и на какие типы они резделяются, потому что сами эти типы грамматических связей считаются формальными признаками для определения самого предложения и его членов.

Какими путями в татарском языке слова связываются и какие имеются типы грамматических связей? Чтобы дать ясный ответ на эти вопросы, возьмем несколько предложений, отделим слова, входящие в каждое предложение попарно и попробуем анализировать их с точки зрения их связей:

*1) Нурлы кояш кара болытлар арасындан ялтыраб чыкды.*

| | |
|---|---|
| *кояш чыкды* | *ялтыраб чыкды* |
| *арасындан чыкды* | *болытлар арасындан* |
| *кара болытлар* | *нурлы кояш* |

*2) Балалар күрше авылдан җәяү кайтдылар.*

| | |
|---|---|
| *балалар кайтдылар* | *җәяү кайтдылар* |
| *авылдан кайтдылар* | *күрше авылдан* |

*3) Октябрь революциясенә кадәр эшчеләр авыр яшәделәр.*

| | |
|---|---|
| *эшчеләр яшәделәр* | *авыр яшәделәр* |
| *революциясенә кадәр яшәделәр* | *Октябрь революциясенә кадәр* |

*4) Тау башында салкын чишмә челтер-челтер агадыр.*

| | |
|---|---|
| *чишмә агадыр* | *челтер-челтер агадыр* |
| *башында агадыр* | *тау башында* |

*5) Мин бу матур кызыл чәчәкне бакчадан табдым.*

| | |
|---|---|
| *мин табдым* | *бакчадан табдым* |
| *чәчәкне табдым* | *кызыл чәчәкне* |
| *матур кызыл чәчәкне* | *бу матур кызыл чәчәкне* |

*6) Син миндән буйга озынрак булырсың.*

| | |
|---|---|
| *син булырсың* | *озынрак булырсың* |
| *буйга озынрак* | *миндән озынрак* |

*7) Без былтырдан бирле җирне трактор белән сөрәбез.*

| | |
|---|---|
| *без сөрәбез* | *трактор белән сөрәбез* |
| *җирне сөрәбез* | *былтырдан бирле сөрәбез* |

*8) Белем гранитларын яшь тешләрегез белән кимерегез.*

| | |
|---|---|
| *кимерегез* | *тешләрегез белән кимерегез* |
| *гранитларын кимерегез* | *яшь тешләрегез белән* |
| *белем гранитларын* | |

*9) Сез киләчәк якты көнләр өчен тырышыгыз.*

| | |
|---|---|
| *сез тырышыгыз* | *көннәр өчен тырышыгыз* |
| *якты көнләр* | *киләчәк якты көнләр* |

*10) Караңгыда мәченең күзләре ут шикелле ялтырый.*

| | |
|---|---|
| *күзләре ялтырый* | *ут шикелле ялтырый* |
| *караңгыда ялтырый* | *мәченең күзләре* |

Теперь, если мы рассмотрим эти парные слова со стороны их связей и будем их классифицировать, то найдем в татарском языке нижеследующие грамматические связи:

| | |
|---|---|
| *1) кояш чыкды* | *2) мәченең күзләре* |
| *балалар кайтдылар* | *авылдан кайтдылар* |
| *мин табдым* | *буйга озынрак* |
| *без сөрәбез* | *былтырдан бирле сөрәбез* |
| *син булырсың* | *тешләрегез белән кимерегез* |
| *сез тырышыгыз* | *ут шикелле ялтырый* |
| *3) нурлы кояш* | *4) ялтыраб чыкды* |
| *кара болытлар* | *җәяү кайтдылар* |
| *күрше авылдан* | *начар яшәделәр* |
| *салкын чишмә* | *челтер-челтер агадыр* |
| *бу матур кызыл чәчәкне* | *озынрак булырсың* |
| *яшь тешләрегез белән* | *укыгач ятдылар* |

Таким образом, сколько бы и какие бы ни было предложения мы возьмем, всегда обнаружим, что имеются ни больше ни меньше, как четыре вышеупомянутые виды грамматических связей. Если сравним со стороны связей эти парные слова в этих четырех отделах, то мы увидим, что первые слова из парных слов в первом отделе находятся в имен. падеже, а вторые слова путем управления с ними, связаны в числе и лице. Например, когда говорим *Кояш чыкды*, слово *кояш* требует, чтобы слово *чыкды* стояло в единственном числе третьего лица; когда говорим *Мин табдым*, слово *мин* требует, чтобы *табдым* стояло в единственном числе первого лица.

Во втором отделе парные слова связаны между собой путем управления при помощи падежных приставок или служебных слов; например, при выражении *мәченең күзләре*, слово *күзләре* требует,

чтобы слово *мәче* стояло в притяжательном падеже. При выражении *Авылдан кайтдылар*, слово *кайтдылар* требует исходного падежа от слова *авыл*. Точно также при выражении *былтырдан бирле сөрәбез* слово *сөрәбез* требует, чтобы предыдущее слово *былтыр* было управляемо при помощи служебного слова *бирле*. При выражении *Тешләрегез белән кимерегез* слово *кимерегез* требует то же самое при помощи служебного слова *белән*.

В парных словах же 3-го и 4-го отдела нет такого управления. Они только связаны между собой путем примыкания. Но между ними также имеется различие. Первые слова 3-го отдела примыкают к именам, 4-го отдела – к глаголам. Из этого видно, что основных типов грамматических связей в татарском языке два: 1) управление; 2) примыкание.

Управление делится на две категории: 1) управление по числу и по лицу; 2) управление при помощи падежной приставки или служебного слова. Примыкание также в свою очередь делится на две категории: 1) примыкание к именам и 2) примыкание к глаголам.

При установлении предложения и его членов и их определения эти основные типы грамматических связей являются формальными признаками.

Предложение *Укучы балалар үзләренең укытучылары белән күрше авылдан җәяү кайтдылар* графически можно представить в следующем виде:



## 15 ЕЛ ЭЧЕНДӘ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ[1]

Татар пролетар әдәби теле татар пролетариатының үз тарихы белән – аның аерым бер сыйныф булып килеп чыгу һәм үсү тарихы белән билгеләнә.

Татар җәмгыятендә XVIII йөзнең ахырларында үсү адымын атлаган татар капитализмы XIX йөзнең башларында инде яхшы ук күтәрелгән иде. «Казан татар ратушасы» журнал һәм протоколларының мәгълүматы буенча, 1800 елда бер Казанның үзендә генә 2 сабын, 3 казыл, 10 күн – барлыгы 24 завод бар иде. Болардан башка 1803 елда Вятка губернасы, Уржум өязе, Пратәнур авылы йомышлы татары Мәхмүт Мамотовның бер комач фабригы булганы, бу фабрикта эшләү өчен Бохарадан мамык китерелгәне мәгълүм.

XIX йөзнең беренче ярымы соңнарында инде Казан татарлары арасында сәүдә һәм промышленность яхшы нык алга киткәне күренә. Бу турында врач Карл Фуксның 1844 елда Казан университеты типографиясендә басылган «Казанские татары в статическом и этнографическом отношениях» исемле әсәрендә түбәндәге мәгълүмат бар:

«XIX йөзнең беренче ярымының ахырларында Казан татарлары арасында елга илле мең пот яхшы сабын эшләп чыгара торган 5 сабын заводы (кенәз мирза Заманов, Юнусов, Арсаев һәм Якупов заводлары), елга бер йөз илле казыл эшләп чыгара торган 5 казыл заводы (Юнусов, Апанаев һәм Госманов заводлары), елга егерме мең пот шәм чыгара торган ике зур завод (Юнусов һәм Арсаев заводлары) һәм болардан башка шул ук әйберләрне эшләп чыгару өчен Казанда тагы бик күп вак заводлар да бар. Болар өстенә биш туку фабригы (купецлардан Апаков, Ишимов (Гасымов), Уразов, Гаптуллин һәм Бикмөхәммәтовларның фабрикалары) булып, алар үзләрендә эшләнгән товарларын Оренбург ярминкәләрендә саталар. Болар белән тагы ике татар бистәсе арасында һәр ел 50 мең пот эшләп чыгара торган тоз заводы (Алишов заводы), читек һәм кәвеш кайый торган фабрикалар (Гаптуллин һәм Фәйзуллин фабрикалары) бар. Бу фабрикаларда татар хатын-кызлары һәм алар белән бергә рус кызлары да эшлиләр. Бу ике каю фабригыннан башка да бик күп татар читеге каю белән шөгыльләнәләр. Хәзерге вакытта бигрәк купецлар бай саналалар. Ике ярым миллион суммалы (Гаптрәшит Юнусов кебек) купецлар булганы кебек, 3 миллионнан

[1] *Бәдигый Х.* 15 ел эчендә татар әдәби теле // Яңалиф. 1932. № 9–10. – Б. 84–94.

артык суммалы купецлар да бар. Ярым миллион суммалы кешеләр дә шактый күп (Хөсәен Апанаев, Аппаков, Корбангали Арсаев, Исхак Якупов, Тимербулат Якупов, Давыд Җидегәрәев, Мостафа Ләбәчин, Миңнебай Фазылов кебекләр). Болардан башка тагы зур гына капитал ияләре дә аз түгел...» (124–131)

«Шул ук йөзнең ахырларында Казан базарларында төрле яклардан күп кенә татар мещаннары җыелып, алар авыллардан чималлар китерәләр. Казанга һәр ел Кама артыннан, Уфадан, Оренбург тирәләреннән барысы миллион ярымга якын чи тире кирә. Шулар эченнән, шулар ук кулыннан рус купецлары аркылы алты йөз мең сыер, дүрт йөз мең ат тиресе Петербургка озатыла. Казанның сабын һәм шәм заводлары өчен ел саен йөз илле мең потлар чамасы эрегән туң май, уң мең потлар чамасы балавыз, егерме мең потлар чамасы бал кирә. Болар һәммәсе дә тик татарлар тарафыннан, татар сәүдәгәрләре кулы аркылы гына кергәннәрнең хисабы...»

«...Татар авылларыннан Казандагы татар сабын һәм тире заводларына җиде йөзләп кеше эшкә ялланып киләләр...»

Карл Фуксның бу мәгълүматы буенча XIX йөзнең беренче ярымы ахырларында ук инде татарлар арасында фабрик һәм заводлар барлыгын, бу фабрик һәм заводларда татар эшчеләре ярала башлавын, бер Казанның үзендәге сабын һәм тире заводларында гына 700 ләп эшче булганын күрәбез. Ләкин бу чорда әле татарлар капитализм үсешенең икенче стадиясен генә үткәреп, бу фабрика һәм заводлар төбендә ярым мануфатура, кул белән эшләп чыгару нигезендә иделәр, шуңа күрә боларда эшли торган эшчеләр дә чыгышлары ягыннан крәстияннәр булып, алар әле авыл һәм җир белән бик нык бәйләнешле сезонлы эшчеләр иделәр.

Казан татарларында сәүдә һәм промышленность капиталы үсүенә, бер яктан, аларның көнбатыш һәм көнчыгыш арасында халыкара зур сәүдә юлы булган Волга буенда яшәүләре, икенче яктан, үзләренең Урта Азия халыклары белән тел һәм дин ягыннан якын торулары төп сәбәп булган иде. Ләкин XIX йөзнең соңгы яртысыннан алып Россиянең төрле өлкәләре тимер юл челтәре белән чолганып та Казан бераз читтәрәк калуы аркасында, бу өлкәнең сәүдә һәм промышленностьта роле бераз кими төште. Татар сәүдә һәм промышленность капиталының зур көче Башкортстан белән Себергә, Урта Азия белән Европа арасында озын бер буй булып төзелгән шәһәрләргә – Әстерхан, Уральск, Оренбург, Орск, Троицк,

Петропавловск (Кызыл Яр), Семипалат шәһәрләренә күчте. Хәзерге Башкортстанның үзәгендәге Уфа һәм аның өязләре, Себер һәм Ерак Көнчыгышның да Чита, Харбин, Владивостокка чаклы булган сәүдә үзәкләре, татар сәүдә капиталының тармалары, бүлекләре, агентлары белән капланды. Боларның иң көчле җирләре – әнә шул Урта Азия белән Европа арасындагы буйда, бигрәк тә Оренбург – Каргалы, Троицк кебек үзәкләрдә булды. Шул рәвешчә, Казан тирәсеннән читкә сибелгән татар капиталы XIX йөзнең соңгы яртыларында тагы көчәеп, XX йөзгә таба инде эре индустрия промышленностенә кызу омтылыш башланды. Урта Азиягә чиктәш җирләрдә ит һәм май хәзерләү эшләрен, эчәк заводларын (Әхмәт һәм Гани Хөсәеновләр), зур пар тегермәннәрен (Яушевлар) кулга алсалар, Урта Волга буенда татарлар арасыннан зур текстиль фабрикалары (Акчурин, Агишов, Дибирдиев, Әхмәт бай Хөсәеневләр...), Уралда зур-зур алтын прииска фирмалары (Закир һәм Шакир Рәмиевләр...) дөньяга киләләр[1]. Шулай итеп, XX йөзнең башларында инде татарлар арасында капитализм формалары яхшы яхшы ук нык үсте. Татарның буржуа сыйныфы бөтенләй формалашып, чынлап ук үзенең көчен күрсәтә башлады. Татар промышленностендагы менә бу моментны татар буржуасының индустрия промышленностена күчү һәм үзен формалашып җиткән аерым бер сыйныф итеп феодалларга каршы кую вакыты дип карарга кирәк. Шуның белән бергә, IX йөзнең ахырларында – XX йөзнең башларында Россиядә татарлар арасында эре индустрия промышленностенең көчәюе эре индустриянең промышленностьны игенчелектән кискен аеруы аркасында гомумән Россиядә, бераз соңрак татар җәмгыяте эчендә кирәк үзләренең материаль, кирәк идеологик яктан югары теләкләре белән, икенче төрле тормыш төзелеше, икенче төрле гаилә мөнәсәбәтләренең яңа формасы белән кустар һәм крестьянлеккә бөтенләй ят булган өр яңа бер сыйныф-пролетариат туды. 1905 ел революциясенә кергәндә инде яшь татар пролетариаты үз эченнән Сәфиулла Галиәкбаров, С. Якупов, С. Гафуров, Сәгыевләр кебек аерым алдынгы революционер эшчеләр Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов кебек оештыручы һәм җитәкче большевиклар чыгара алды.

Димәк, татар пролетариаты XIX йөзнең соңнарында, һич булмаса XX йөзнең башларында ук аерым бер сыйныф булып, үзенең

---

[1] *Ибраһимов Г.* Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. Б. 13–14.

телен крестьян һәм буржуа теленә каршы куйган булырга тиеш. Ләкин татар пролетар әдәби теле, татар пролетариатының үз язучылары, үз әдәбияты, гомумән үз матбугаты мәйданга килү белән генә оеша һәм ясала ала. Татар пролетариатының үз язучылары, үз әдәбияты, гомумән матбугаты исә бары 1905 ел революциясеннән соң гына күренәләр. Башта, революция елларында социал-демократ комитеты тарафыннан җилем басма белән идән астында басылган яшерен прокламацияләр таратылалар. Боларның саннары яхшы ук күп була. Бу прокламацияләрнең татар пролетариат әдәби теленең тарихын өйрәнү өчен әһәмиятләре бар, шуңа күрә без бу урында беренче прокламациядән түбәндәге өземтәне күчерәбез:

«Российский социал-демократический рабочий партия

Кушылыгыз бергә, бөтен дөньяның пролетариаты! Җәмәгать!

Революция баруыннан туктамый, халык иркенлек өчен сугышка күтәрелде. Безнең туганнарыбыз, дусларыбызның каннары ага. Корал белән күтәрелү башланды инде. Бөтен Россиядә чуен юлда эшләүче хезмәтчеләр һәм эшчеләр забастовка башладылар. Менә алтынчы көн инде һәр җирдә дип әйтерлек поездлар йөрмиләр. Россиянең тормышы төптән үк тукталды. Эшчеләр патша самодержавиясенең кан бозарлык көчләвенә забастовка белән җавап бирделәр. Правительство үзе пенсионный касса тугрысында мәслихәтләргә Пагатилов комиссиясенә чакырган эшчеләрдән сайланып килгән депутатларны арестовать итте (япты). Депутатлар үзләрен сайлаучы чуен юл эшчеләренең кушулары буенча бөтен чиновникларны һәм башларындагы Пагатиловны кудылар. Экономический һәм политический требованияләр куйдылар...»

Бу прокламацияләрнең теле гомумән кытыршы, бер дә эшләнмәгән иде, ләкин аларның һәммәсе өчен уртак булган терминнарда гарәпчелектән качу, эшчеләр массасына аңлаешлы язарга тырышу кебек әдәби телдә яңа юнәлеш эзләнү факты ачык күренеп тора иде.

Аннан соң 1907 елның гыйнварында беренче мәртәбә татар социал-демократ большевиклар органы булып Оренбургта «Урал» исемле газет чыкты. «Урал» газеты чынлап та пролетариатның революцион идеологиясен беренче мәртәбә татар телендә гәүдәләндерде, «Урал» газеты аша татар теле беренче мәртәбә пролетариат идеологиясенә хезмәт итә башлады. Ул беренче номерның баш мәкаләсендә үк үзенең пролетариатка хезмәт итәчәген түбәндәгечә игълан итте:

«Россиядә иске тәртипкә каршы булган көрәш иркенлекне теләгән һәр сыйныфның моңарчы алдагы сафларының гына эше иде. Әмма хәзер бөтен халыкның эшенә әйләнә бара, ягъни иске тәртипкә каршы көрәш тирәнләнә һәм киңәя барадыр.

Шулай ук бу көрәштә халыкның төрле сыйныфларының арасындагы каршылык көннән-көн өскә чыга бара.

Хәзер эшчеләр сыйныфының бурычы үзен сыйнфый дошманнардан алдатмыйча, бу көрәшне ахырына чаклы җиткереп үзенең олуг булган теләге – социализм өчен көрәшкә юл ачудыр.

Моның өчен пролетариат (эшчеләр сыйныфы) берләшкән һәм сыйныфына билгеле файдаларын аңлаган булырга тиешле.

Икенче яктан, бу көрәшне ахырына җиткерү, бу көрәштә пролетариатның якын иптәше буларак крестьян халкының һәм шәһәр җирләрендәге фәкыйрь халыкның үзләренең файда вә зарарларын аңнаулары артудан һәм үзара берегешеп кушылуларыннан булачактыр.

Шуңа күрә без үзебезнең гәзитәбездә пролетариатны бергә кушылырга өндәп, аның сыйныфына билгеле аның арттырырга булышу кебек крестьян халкын һәм шәһәр фәкыйрьләрен дә үзара кушылырга өндәячәкбез», – ди.

«Урал» гәзите 3 нче номерында «Мөселман иттифагы» исемле татар буржуа партиясенең сыйнфый йөзен түбәндәгечә ачып бирә:

«...Бөтен дөнья халкы динен, милләтен аермаенча төрле сыйныфларга бүленгән шикелле Россия мөселманнары да төрле сыйныфларгы бүленәләр. Мәсәлән, мөселманнарда бер яктан помещиклар һәм капиталистлар, икенче яктан крәстияннәр һәм ялланып эшли торган эшчеләр дә бар. Икътисади җәһәттән теләкләре бер булган кешеләр бер сыйныфка керәләр. Бу сыйныфлар һәр вакыт бер-берсе белән көрәшәләр.

Россиянең башка милләттән булган халыклары төрле партияләргә керергә тиешләр, чөнки, бая әйткәнчә, мөселманнар да төрле сыйныфларга бүленәләр. Моннан бөтен мөселманнарның диннәре бер булса да, икътисади интереслары бер булмаганга күрә, барысы да “Мөселман иттифагы” дигән бер партиягә керә алмавы бик ачык күренәдер. Күпме кычкырышсалар да, һаман кадетлар тирәсендә генә әйләнеп ерак китмичә бер программа төзеделәр. Ни өчен кадетлардан артык үтә алмыйлар? – Болар байлар шул, буржуалар шул. Болар үзләренең партияләрен кадетлар дип атамыйлар, “Мөселман

иттифагы” дип атыйлар, чөнки “мөселман” дисәң бөтен мөселманнар керәләр дип уйлыйлар. Бу “мөселман иттифагы» дигән партия – мөселманнардан җирсез авыл халкы өчен һәм эшчеләр өчен фәкать зарарлы бер партиядер. Моны эшчеләр һәм фәкыйрь зарарлы бер партиядер. Моны эшчеләр һәм фәкыйрь халык бик яхшы белергә тиеш. Дин кардәш булса да, мал кардәш түгел бит...”, – ди.

«Урал» гәзите татар эшче язучыларын үз тирәсенә яхшы гына җыя башлаган иде, ләкин гомере бик кыска булып, бары 30 гына номеры чыгып калды. Апрель 18 ендә сәяси юлы зарарлы табылып, патша хөкүмәте тарафыннан туктатылды.

Шул ук «Урал» гәзите тарафыннан «Урал көтепханәсе» исеме астында русчадан тәрҗемә ителеп, 5 данә икътисади-сәяси брошюралар басылып таратылдылар.

Болардан башка, татар пролетар матур әдәбиятының беренче карлыгачы булып 1908 елда Гафур Коләхмәтовның «Яшь гомер» исемле пьесасы басылды. Бу инде татар пролетар әдәби теленең матур әдәбиятта беренче күренеше иде. Монда инде пролетар теле яхшы гына әдәби эшләнә башлануын күрәбез. Үрнәк өчен түбәндәге өземтәне күчерәбез:

«Менә безнең татар байлары мәкәрҗәдә җыелган булдылар да, “Мөселман иттифагы партиясе” кыстырган булдылар. Үзләренә күрә комитет та сайлап куйдылар. Комитетка кемнәр керде? ... Һәрбер член комитет кушканча эшләсен, имеш!...»

«...юк, башка кшеләрне алдасагыз да, без эшчеләрне алдый алмассыз!..»

«Алар пычак пычакка кilә торган ике сыйныфны бергә катыштырмакчы булалар... Катыштырмый торыгыз әле...»

Менә татар пролетар әдәби теленең капитализм шартлары эчендә бөтен ясалышы, бөтен байлыгы шушылардан гыйбарәт иде. Капитализм шартлары эчендә, бер яктан, буржуазия диктатурасы яшәү аркасында гомумән пролетар әдәби теленең, икенче яктан, рус империализмының рус берлеген саклау сәясәтләре, төрле чикләү законнары аркасында, бигрәк тә вак милләт пролетар әдәби теленең үсүенә, чып-чыннан формалашуына җирлек тә, мөмкинлек тә юк иде. Татар пролетар әдәби теленең ваянә дә таза җирлек, киң мөмкинлек бары пролетариат революциясеннән соң гына башлана.

Пролетариат һәм аның җитәкчесе булган коммунистик партиянең ленинче милли сәясәте, милли культура һәм милли телгә

карашы билгеле һәм ачык. Чөнки тел уйлау һәм йөрү кебек кешенең биология хадисәсе түгел ул. Маркс билгеләве буенча әйткәндә:

«Тел шулай ук аң кебек борынгы, тел ул – практик, башка кешеләр өчен, димәк, минем үзем өчен дә яши торган реаль аң; аң кебек үк тел дә башка кешеләр белән мөнәсәбәт ихтыяҗларыннан килеп чыга».

Димәк, Маркcның кыска, шуның белән бергә, телнең бөтен үзенчәлекләрен эченә алган бу конкрет фикере буенча, тел ул – иҗтимагый хадисә, аңны реаль тәкбир итүче өскорма. Өскорма булганнан соң ул сыйнфый җәмгыятьтә башка өскормалар кебек сыйнфый, сыйнфый булганнан соң ул үзеннән-үзе партияле дә була, шуңа күрә милли культура һәм милли телләр коммунистик партиянең съездларында, конференцияләрендә һәрвакытта аерым төр мәсьәләләрдән булып килде. Бигрәк тә партиянең XVI съездында иптәш Сталин, бу милли культура, милли телләр турында аерым тукталып, бу мәсьәләне теоретик һәм практик нигезләп, түбәндәгечә ачып бирде:

«Без киләчәктәге милли культураны бер тел белән уртак (формасы ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да) бер культурага күчү ягында торабыз, шуның белән бергә, хәзерге вакытта, пролетариат диктатурасы чорында милли культураларның гөрләп чәчәк атулары ягында торабыз. Бу нәрсә гаҗәп тоелырга мөмкин. Ләкин монда гаҗәпләнерлек бер нәрсә дә юк. Барлык культураларны бер тел белән уртак культурага кушу шартларын тудыру өчен, милли культураларга үзләренең бөтен яшерен көчләрен өскә чыгарып үсәргә һәм киңәергә юл бирергә кирәк. Пролетариат бөтен дөньяда җиңгәч, социализм тормышка кергәч, формасы ягыннан милли, эчтәлеге ягыннан социалистик булган милли культураларны уртак бер тел белән уртак социализм (формасы ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да) культурасына кушу өчен, бер илдә пролетариат диктатурасы шартларында аларның гөрләп үсүләре – Ленинның милли культура мәсьәләсен куюдагы диалектикасы менә шуннан гыйбарәт».

«Милли культура һәм милләтләрнең ерактагы киләчәкләренә килгәндә, мин һәрвакыт Ленин карашында булдым һәм хәзер дә шул караштa калам. Бу караш буенча, социализмның бөтен дөнья күләмендә җиңүе чорында, социализм ныгыгач һәм тормышка кергәч, милли телләр чарасыз рәвештә бер уртак телгә кушылырга тиешләр, ләкин бу тел, билгеле, великорус теле дә, немец теле дә булмас, нинди булса да бер яңа тел булыр»...

«Милли телләрнең үлүе һәм аларның уртак бер телгә кушулары мәсьәләсе ул – бер дәүләт эчендәге социализмның бер билгеле җиңүе мәсьәләсе генә түгел, бәлки халыкара бер мәсьәлә, социализмның халыкара күләмдә җиңүе ул... Ленин, милли аерымлыклар хәтта пролетариат диктатурасы бөтен дөнья күләмендә җиңеп чыкканнан соң да бик озаккача калыр әле, дип юкка гына әйтмәде», – ди.

Димәк, коммунистик партиянең һәм Советлар Союзы хөкүмәтенең Ленинча милли сәясәте буенча, пролетариат диктатурасы һәм СССРда социализм төзелеше чорында милли культуралар һәм милли телләрнең үсүләре, өлгереп чәчәк атулары алдан ук тәэмин ителгән иде.

Пролетариат революциясеннән соң рус империализмы җимерелеп, аның урынына пролетариат диктатурасы, Советлар системы урнашу, коммунистлар партиясенең генераль юлы буенча милли сәясәтне тормышка ашыру тәҗрибәсендә Татарстан җөмһүрияте мәйданга килде. Бөтен Союз илендә җөмһүриятләр белән янәшә Татарстан җөмһүриятендә дә промышленностьның алга китүе, елдан-ел җирле пролетариат кадрының үсә баруы, бөтен Татарстан күләмендә авыл хуҗалыгын социализм нигезендә – коллектив хуҗалыклар нигезендә өр-яңадан кору һәм гомумән бөтен хезмәт массасының культура үсеше темпын җитезләтү фактлары белән, хәзер татар хезмәт массасының экономикаларында һәм бөтен тормыш төзелешләрендә гадәттән тыш үзгәреш ясалды. Шушы үзгәреш белән бергә чын чынлап экономик базис өстенә корылган идеологик өскорманың (надстройканың) органик продуктыннан гыйбарәт булган татар пролетар әдәби теленең дә үсүенә төрле һәм ныклы нигез салынды. Моның өстенә аппаратны төп халыклаштыру, шулай ук татар телен тулы хокуклы дәүләт теле итеп тану белән бергә, аны күз алдына тормышка ашыру фактлары белән инде татар пролетариат әдәби теле үсү юлындагы бөтен киртәләр алынып ташланды.

Россиядә советлар системы төзелү белән, төрле милләтләр арасында яңа хокукый мөнәсәбәтләрнең туулары, борынгы патриарх феодализм һәм гаилә төзелешенең җимерелүе белән яңа сыйнфый карашларының килеп чыгулары – гомумән телнең төзелешенә, аның яңадан-яңа сүзләр, терминнар, хәтта кайчагында әлегә кадәр ишетелмәгән бөтен яңа алымнар (приемнар) белән баюына йогынты ясаулары турында сөйләп тә торасы юк. Димәк, татар пролетариат әдәби теленең үсүенә хәзер таза җирлек бар һәм аның бу үсү җирлеге гаять киң.

Революциядән соң пролетариат властьны үз кулына алу белән бергә, яңа тормыш төзүдә гадәттән тыш зур роль уйнаучы әдәби телдә билгеле аның иркенә күчәргә, аның үз идеологиясенә яраклашып, өрянa юнәлеш алып үзгәрергә тиеш иде. Ләкин дәүләт, власть бер сыйныф кулыннан икенчесенә тартышсыз, көрәшсез, революциябез бирмәгән кебек, әдәби тел дә табигый бер сыйныфтан икенчесенә җиңел генә, шома гына күчә алмый, аның төп юнәлеше турында сыйныфлар арасында башта кызу көрәш һәм бәхәсләр була. Татар пролетар әдәби теле дә үзенең үсүе юлында, үзенә төп юнәлеш билгеләү юлында бер яктан җирдә милләтчелек күренеше, икенче яктан олы державачылык шовинизмы агымы тарафыннан, кайчагында астыртын, кайчагында ачыктан-ачык рәвештә, төрле каршылыкларга очрады.

Баштарак яңа туып килә торган пролетар әдәби телен «урам теле» дип түбән күрү, яңа үсеп килә торган яшь пролетариат язучыларның әсәрләрен бастыруга салкын карау, пролетариат диктатурасы шартлары эчендә дә әдәби телдә милләтчелек идеясен – пантюркизм идеясен яшәтергә тырышу кебек фактлар булгаладылар. Шулай ук, көчле рус әдәбияты, бай рус әдәби теле каршында татар әдәбиятын, татар әдәби телен бик түбән санап, өметсезләнеп, турыдан-туры руслаширга йөз тоту кирәклеген сөйләүчеләр, шуны теоретик нигезләргә тырышучылар да килеп чыккаладылар.

Шуның белән бергә, Октябрьдән соңгы татар әдәби телендә билгеле вакытларгача буржуа әдәби теле тенденцияләре дә яшәп килде. Буржуачылык-милләтчелек дәвереннән калган мирасда тәнкыйть күзе белән карый алмау, тиешле бәя бирә алмау аркасында, бик күп язучыларның телләрендә «көчләр алласы, без үзебез – аллалар, мәкаддәс җиһат, изге көрәш, шәһитләр каны, җәһәннәмнән эссе, зәмһәрирдән салкын, дию-пәриләрдән көчлерәк, яшь пәйгамбәр, изге хезмәт тәкъбир әйтте...» кебек буржуа әдәби телендә генә табыла ала торган мистика образларын, милләтчелек, вак милләтчелек тәкбирләрен күп очратырга була иде.

Мисал өчен түбәндәге өстәмәләрне күрсәтергә мөмкин:

*«Җәһәннәм эссе утларында*
*Чуен эреп, су булып ага,*
*Каты корыч анда бер минутта*
*Әйләнделәр юка тактага.*
*Тышта зәмһәрирдән салкын икән*
*Эчтә һавадан эссерәк,*

*Анда тәгәрәп торган машиналар*
*Дию пәриеннән көчлерәк».*
(М. Гафури. «Эшче» поэмасыннан)

*«Таң уртасы гакыл уйлап ята,*
*Җир өстендә җәннәт төзәргә,*
*Көчле кулы белән табигатьнең*
*Барлык богауларын өзәргә».*
(Һ. Такташ. «Эшлиләр» шигыреннән)

*Тәкбир әйтте шунда җир, күк бергә,*
*Тәһлил әйтте, дөнья тетрәде,*
*Изге көчкә – мәңге эш сорады,*
*Тәкъбир әйтте сәма, күкрәде.*
(Ф. Бурнаш. «Эш иртәсе» шигыреннән)

*«Бер мәләк тә какмасын зикер канатын өн белән*
*Чөнки*
*Без яшь көчләр кулыбызда кояш яна,*
*Без аллалар, тормыш бары бәхет безгә»*
(Н. Исәнбәт)

Ләкин татар пролетариаты да, башка сыйныфлар кебек үк, үзенең әдәби теле, үзенең идеология билгеләрен торган саен гәүдәләндерде. Әдәби тел инде әкренләп феодалчылык һәм милләтчелек сазлыгыннан әрчелеп, интернационализмга таба юнәлеш алып, гигант адымнар белән һаман үсә.

Пролетар әдәби теленең формалары да хәзер пролетариатның үз социаль оешмалары, шулай ук аның үзара аралашу формалары белән яраклаша бара. Пролетариат революциясеннән соң җәмгыять төзелеше тамырыннан үзгәрү белән *староста, старшина, урәтник, полицейский, справник, становой, пристав, политсәмистер, губернатор, патша, җанаби гаиләләре, әфәндем хәзрәтләре, падишаһ әгзам хәзрәтләре...* кебек бик күп сүзләр, терминнар, алымнар хәзер кулланудан чыктылар. Пролетариатның үз идеологиясе белән яраклашып, элеккеге бик күп сүзләрнең, терминнарның мәгънәләре һәм функцияләре үзгәрде. *Әфәнде, хәзрәт, мәхдүм, мулла, остабикә, хәлфә, ишан, суфи, мирза, абзый...* кебек бик күп сүзләр элек буржуа әдәби телендә хөрмәт һәм олылау өчен кадерле булып йөрсәләр, хәзер бу сүзләр хурлау һәм кимсетү урынында кулланылалар. *Эшче, ялчы, хезмәтче, хезмәткәр, хезмәт ияләре, батрак, ярлы, урта хәлле, кулак...* кебек бик күп сүзләрнең мәгънәләре арасында дифференциация ясалды.

Бу 15 ел эчендә татар әдәбиятында сүзлек запасы да әллә никадәр артты. Сүзлек запасы арту һәм баю процессы гомумән телләрнең үсү процессында табыла торган факторлар буенча, бер яктан, үзенең иске мирасыннан файдалану юлы белән, икенче яктан, икенче тел коллективларыннан халыкара сүзләр, терминнар, алымнар, хәтта яңа грамматик формалар алу юлы белән бара. Сүзлек запасы үрчетүдә иске мирастан файдалану факторы, телләре нормаль үсә торган һәр тел коллективында беренче урында тора, чөнки телдә сүзләр бервакытта да бөтенләй яңабаштан тумыйлар, бәлки яңа туган төшенчә, тойгы һәм әйберләрне аңлату өчен кирәкле булган яңа сүз ясау процессы иң элек шул беркадәр сүзлек составыннан файдаланып, аларны фонемнар ягыннан бер-береннән тышкы аеру *(күз – күр, хикәя – әкият, биек – бөек...)* юлы белән, тамырларының күренешләрен үзгәртү, төрләрен катнашма яклы кушма сүзләргә кушу һәм гомумән материал морфемнарга формаль морфемнар ялгау юлы белән ясала. Пролетариат революциясенә кадәр татар әдәби теле яңа сүз ясауда морфемнарны бергә ялгау юлы белән кәнагатьләндерерлек файдалана алмады; тик соңгы унбиш ел эчендә генә моңа чын-чынлап әһәмият бирелә башлады. Бу эштә терминология комиссияләре, дәреслекләр төзү коллективлары, матур әдәбият һәм якты матбугат фронты, шулай ук кайбер яшь язучылар һәм тәрҗемәчеләр яхшы ук активлык күрсәттеләр. Эш йомгагында шушы унбиш кенә ел эчендә дә бу юл белән яңа конкрет төзелеш шартларында туган яңа әйберләр, яңа төшенчәләр һәм тойгыларны аңлату өчен, әллә никадәр яңа сүзләр, яңа терминнар ясалып өлгерде. Бу формаль морфемнардан күбесенең элеккеге функцияләренә караганда хәзерге мәгънәләре яхшы ук киңәйде. Мәсәлән, *ма-мә* морфемнарыннан элек әйбернең ничек ясалганын белдерә торган зат исемнәре генә ясала иде *(яр – ярма, бүл – бүлмә),* хәзер теләсә нинди фигыльдән теләсә нинди зат исемнәре ясала башладылар: *чы-лык, че-лек* морфемыннан элек күбрәк кәсеп һәм һөнәрне аңлата торган зат исемнәре ясалалар иде, хәзер рус телендәге *изм*, яки ирония урынында йөри торган *шина* морфемнары функцияләрендә дә кулланыла башладылар *(милләтчелек, солтангалиевчелек).*

Сүзлек запасын үрчетүдә ике яки икедән артык сүзләрне бергә кушу юлы белән сүз ясау да яхшы ук киң урын алып бара. 15 ел эчендә бу юл белән файдаланып, гаять күп һәм бик уңышлы яңа кушма сүзләр һәм терминнар эшләнеп торалар (*көнчыгыш, көнбатыш, өскорма, чимал, өчпочмак* һ. б).

Кушма сүзләр белән беррәттән телдә аларны кыскартып яңа терминнар ясау процессы Польшада һәм Россиянең көньяк-көнбатыш якларында эшләүче идән асты революционерлары арасында 1890–1900 елларда ук яхшы гына таралган булган. 1905 ел революциясе вакытларында мондый терминнар киң масса арасында да бераз тарала башлап калган иде. Октябрь революциясеннән соң исә бу процесс телдә бөтенләй гадәт булып китте. Россиядә Советлар системы урнашу белән, бик күп оешма һәм учреждениеләр катлаулы кушма сүзләр белән исемләнделәр. Аларны практикада бу катлаулы хәлләрендә куллану, әлбәттә, авыр иде. Хәзер бу терминнарның бик күбесе *(ВКП(б), Коминтерн, комсомол, колхоз, совхоз...)* шул кыскартылган хәлләрендә билгеле бер төшенчәне аңлата торган бербөтен «термин» булып кына тасвир ителәләр, аларның кайсы сүзләрдән һәм нинди юллар белән ясалганнары турында уйланып та торылмый. Тора-бара киләчәк буын өчен аларның кушма сүз икәнлекләрен белү бары сүзлекләр, тел тарихлары аркылы гына мөмкин булачак.

Катлаулы кушма сүзләрне кыскартып яңа терминнар ясау тенденциясе Октябрь революциясеннән соң татар әдәби теленә дә күчте. Шулай да, иске әлиф вакытында бу тенденция үзенә күрә юл алып, бер эзгә төшеп җитә алмады, чөнки гарәп хәрефләренең берничә формада кулланулары, сүздә баштанаяк кушылып язылулары моңа яхшы ук комачаулый иде. Яңалифкә күчкәннән соң, бу комачаулыклар үзләреннән-үзләре югалдылар. Хәзер кыскарту юлы белән яңа терминнар ясау процессы татар әдәбиятында да социаль нормага кереп бара.

Татар массасының үз теле җирлегендә материаль морфемнарга формаль морфемнар ялгап, берничә сүзне бергә кушып, яки катлаулы кушма сүзләрне кыскартып яңа сүзләр, яңа терминнар ясалу белән беррәттән революциядән соң татар әдәби теленә икенче тел коллективларыннан халыкара тел элементлары да керә башладылар.

Халыкара терминнар дигәч тә, аларның күбесе үзләренең чыгышлары ягыннан төбендә латин яки грек сүзләренә кайтып калалар. Шулай да, башка тел коллективларыннан да халыкара оборотка (әйләнмәгә) кереп киткән сүзләр дә аз түгел. Бу терминнар үзләренең әйтелешләре ягыннан төрле тел коллективларында төрлечә була. Алар татар әдәби теленә билгеле рус әдәби телендәге әйтелешләре буенча керәләр. Моның шулай булуы бик табигый да, чөнки татар җәмгыяте каршында иң көчле һәм иң якын культура – рус

культурасы. Икенче төрле әйткәндә, татар җәмгыяте интернациональ культурага рус җәмгыяте аша якынлаша. Халыкара терминнар гына түгел, хәтта рус культурасы йогынтысы астында русның саф үз сүзләре, бигрәк тә дәүләт төзелешенә, эшбашкаручылыкка, шулай ук техникага бәйләнешле терминнарда татар әдәби телендә үзләренә яхшы ук киң урын алалар.

Яңа конкрет культура үсеше шартларында хәзергә кадәр алынган әдәби, гыйльми, фәлсәфи, экономик, техник һәм революцион халыкара терминнардан билгеле берәр дисциплина яки билгелерәк берәр мәгънәдә бәйләнешле үзләренең формалары белән кергәннәре, шуңа күрә бу яки теге яктан карар грамматик системага алырга мөмкин булганнары да бар, алар арасыннан түбәндәге формаларны күрсәтергә мөмкин:

*1. Социализм, коммунизм, ленинизм, реализм, идеализм, материализм.*

*2. Биология, социология, физиология, яфетидология, методология.*

*3. Этнография, орфография, биография, типография, стенография.*

*4. Грамматика, математика, физика, методика.*

*5. Революционер, милиционер, комиссионер, акционер.*

*6. Марксис, коммунис, социалис, империалис.*

*7. Социолог, физиолог, психолог.*

*8. Оратор, диктатор, провакатор, редактор.*

*9. Декант, аспирант, комендант, спекулянт* һ. б.

Гомумән, ялганмалы телләрдә, шулар эчендә татар телендә дә, фликцияле телләрдәге кебек сыйфат исемнәрнең үзләренә караган аерым сыйфатлык морфемнары эшләнеп җитмәгән, алар аморф хәлләрендә ныгып калганнар. Башка сүз төрләреннән сыйфат исеме ясый торган морфемнар да бик аз, булганнары да чикле сыйфат мәгънәсен генә аңлатып, билгеле сүз төрләреннән генә ясалалар. Хәзерге катлаулы хуҗалык төзелешендә туган катлаулы уй һәм тойгыларны тулы аңлату өчен, телебездәге бу сыйфатлык морфемнары гына, әлбәттә, җитмиләр иде. Бигрәк тә соңгы вакытта икенче тел коллективларыннан кергән халыкара сүзләрдән сыйфат исемнәре ясауда татар әдәби телендә бик нык кризис хөкем сөрә иде. Шуңа күрә яңа сыйфатлык формалары я телебезнең үз нигезендә ясалыргаы, яки икенче тел коллективларыннан алынырга тиеш иде. Ләкин Советлар Союзындагы искиткеч тизлек белән хуҗалык һәм

культура үсеше аркасында татарның үз теле нигезендә яңа сыйфатлык формалары эшләнеп, өлгерә алганы юк әле, халыкара терминнар белән беррәттән яңа сыйфатлык формалары да кереп, хәзерге вакытта алар үзләренә билгеле бер систем алып, рус әдәби телендәге әйтелешләре буенча татар әдәби телендә әйтелешләре буенча татар әдәби телендә урнашып баралар. Бу сыйфатларны, аларның чыгышларын һәм төрләрен тикшермичә, бары рус әдәби телендәге халыкара терминнардан ясалган кайсы сыйфатлар урынына татар әдәби телендә нинди морфемнар ялганып ясалуларына карап, түбәндәге төркемнәргә аерып карарга мөмкин.

1. Рус әдәби телендәге халыкара терминнардан *ический – ич + еск + ий* морфемнары ялганып ясала торган сыйфат исемнәре урынына татар әдәби телендә шул ук терминнарның ахырларына француз теле сыйфатлык формасы булган *ik – iquc* морфемы ялганып ясала.

*Социология – социологический – социологик.*
*Техника – технический – техник.*
*Этнография – этнографический – этнографик.*
*Экономия – экономический – экономик.*

2. Рус телендәге халыкара терминнардан *аль-ый – альный* морфемнары ялганып ясала торган сыйфат исемнәре урынына татар әдәби телендә шул ук француз теле сыйфатлык формасы булган *аль* морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре туры киләләр. Димәк, боларда да ахырларындагы рус сыйфатлык формасы ташланып, татар телендә француз сыйфатлык формасы калган була:

*Индустрия – индустриальный – индустриаль.*
*Форма – формальный – формаль.*
*Театр – театральный – театраль.*
*Музыка – музыкальный – музыкаль.*

3. Рус телендә халыкара терминнардан *ив+ н+ый – ивный* морфемнары ялганып ясала торган сыйфат исемнәре урынына татар телендә шул ук француз теле сыйфатлык формасы булган *if* морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре туры киләләр. Болардан да ахырларындагы рус сыйфатлык формасы ташлана:

*Объект – объективный – объектив.*
*Субъект – субъективный – субъектив.*

4. Рус телендә халыкара терминнардан ахырларында «*ный*» морфемнары ялганып ясала торган сыйфат исемнәреннән татар әдәби

телендә ахырындагы рус сыйфатлык формасы ташланып, шул хәлләрдә генә сыйфат урынында кулланыла:

*Конкретный – конкрет.*
*Стандартный – стандарт.*

Соңгы вакытларда татар әдәби телендә күренгәли башлаган *революцион, агитацион, традицион, артикуляцион* формаларын да шушы категориядән исәпләргә мөмкин. Ләкин мондый форманың Европа тел коллективларында сыйфат булып йөрүе юк, шуңа күрә мондый формаларны татар телендәге *конкрет эш, ефәк яулык, көмеш кашык...* кебек сыйфат исемнәре урынына йөри торган зат исемнәре белән чагыштырырга мөмкин. Шуның белән бергә, бу формалар урынына «революциячел, революциячән, революцияче» рәвешләрендә татар теленең үз сыйфатлык морфемын ялгап кулланучылар да юк түгел.

Татар әдәби теленә яңа сыйфатлык формалары белән беррәттән гарәп теленнән мирас булып калган һәм хәзерге вакытта да әдәби телдә кулланыла торган түбәндәге ике төрле сыйфатлык формаларын да өстәргә кирәк.

1. Ахырлары тартык авазга беткән гарәп сүзләренең ахырларына *ый-и* морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре:

*Сыйныф – сыйнфый, гыйлем – гыйльми, фән – фәнни, әдәп – әдәби.*

2. Ахырлары сузык авазга беткән гарәп сүзләренең ахырларына *ви* морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре:

*Дөнья –дөньяви, мәгънә – мәгънәви, гаилә – гаиләви, тәрбия – тәрбияви.*

Чит тел элементлары һәр яктан татар теленең үз грамматик төзелешенә буйсыналар. Алардан, *кристаллашу, рационлаштыру, популярләшкән, стандартлаштырылган, конкретлап, детальләр...* кебек төрле форма фигыльләр, шулай ук *характерлы, квалификацияле, тактикалы – тактикасыз, партияле – партиясез, культуралы – культурасыз, революциячел, советчыл...* кебек сыйфат исемнәре дә ясала алалар.

Әдәби телдә чит тел элементлары белән файдалануда һәм гомумән яңа конкрет культура шартлары үсеше шартларында килеп чыккан яңа төшенчәләрне аңлату өчен кирәк булган яңа терминнар тудыруда һәр тел коллективында закон урынына йөри торган «норма» була. Бу норма, гадәттә, әдәби телгә билгеле бер юнәлеш бирә,

шуңа күрә һәр сыйныф бу норманы үзенчә, үзенең сәяси программына, юлбашчы идеясенә карап билгели. Мәсәлән, буржуачылык-милләтчелек дәверендә бу норма татар әдәби телендә пантюркизм нигезендә булып, җыеп әйткәндә, аны түбәндәгечә күз алдына китерергә мөмкин иде.

1. Берәр әйбер яки төшенчәне аңлату өчен татарның үз телендә сүз бар икән, аның урынына тел коллективыннан мотлака сүз алмау.

2. Яңа әйбер яки төшенчәне аңлату өчен яңа сүз кирәк чакта, аны мөмкин кадәр татарның үз теле җирлегендә яңадан ясау.

3. Татарның үз телендә сүз табылмаганда яки үз теле җирлегендә сүз ясау мөмкин булмаганда, башка төрек халыкларыннан сүз алу (казак, үзбәк, Анатолия төрекләреннән һәм башкалардан).

4. Башка төрек халыкларыннан да сүз табылмаганда, гарәп яки фарсы телләреннән сүз алу.

Октябрь революциясеннән соң исә татар әдәби теле бөтенләй яңа юнәлеш алды, эшче-крәстиян теле нигезендә үз башына үсү юлына керде. Гарәп һәм фарсы сүзләре урынына, пролетариат культура үсеше теләве буенча, халыкара терминнарга киң урын бирелә башлады. Шушы нигезләрдән чыгып, чит тел элементлары белән файдалануда һәм әдәби фәнни тел төзүдә бөтенләй яңа «норма» билгеләнде. Бу турыда әле рәсми органнар тарафыннан киң рәвештә эшләнеп, рәсми игълан ителгән «норма» булмаса да, хәзерге татар әдәби теленең практик үсешеннән чыгып, Салах иптәш Атнагулов тарафыннан төзелгән һәм Марксизм-ленинизм кабинеты янындагы тел-әдәбият секциясе һәм Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү редакциясе тарафыннан тикшерелеп, төзәтелеп кабул ителгән төп принциплар[11] бар.

Татар пролетар әдәби теленең үсеше фонем һәм әлифба өлкәсендә дә бик нык чагылды. Элек гарәп культурасы йогынтысы астында татар теленә *х*, *һ* фонемнары кереп урнашып калган булса, хәзер гомумән пролетариат культурасы йогынтысы астында халык арасында халыкара *о* һәм *е* фонемнары артты. Руханилар катлаулы эксплуатациясе коралы булып килгән гарәп хәрефләре бөтенләй ташланып, аның урынына халыкара латин хәрефләре нигезендәге «Яңалиф әлифбасы» кабул ителде. Яңалиф кабул ителүе белән, татар әдәби теленең үсүе, тормышка кереп китүе массалашуы әллә ничә өлеш көчәйде.

[1] Бу турыда «Яңалиф»нең 1931 елгы 10 нчы санындагы мәкаләне карагыз.

Бер сыйныфның әдәби теле баюы, классик бер тел булып чын-чынлап формалашуы өчен, аңа шул сыйныфның гыйльми җитәкчеләре, аерым талантлары, бигрәк тә әдип-шагыйрьләре һәм тәрҗемәчеләре үзләренең гадәттән тыш зур көчләрен сала килгәннәр.

Үз чорлары, үз сыйныфының мохите хәзерләгән бу талантлар, бу даһилар үзләренең иконология, эвфония һәм компарациягә искиткеч осталыклары белән билгеле бер чорны, билгеле бер сыйныфның чын-чынлап экономик башларында корылган идеологик өскорманы гәүдәләндереп кенә калдырмаганнар, бәлки шул идеологик өскорманы тулы һәм бөтен килеш гәүдәләндерерлек шул сыйныфның көчле әдәби телен дә тудырганнар. Бу көчле тел байлыгы аларга үзеннән-үзе күктән төшмәгән, бәлки алар үз мохитләре этәрүе буенча үз сыйныфларының әдәби теленә хезмәт итүне үзләренә профессия итеп сайлаганнар, тормыш мәктәбендә үз телләренең бөтен законнарының бөтен нечкәлекләрен энәсеннән җебенә кадәр җентекләп өйрәнгәннәр.

Татар пролетариатынында хәзер үз әдип-шагыйрьләре, эшхәп һәм авылхәпләре, тәрҗемәчеләре, гомумән үз гыйльми җитәкчеләре өлгерә башладылар. Пролетариат революциясенә кадәр үк үзләренең көчле галимнәре белән танылган Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал һәм башкалар кебек әдип, шагыйрь һәм җәмәгать эшчеләре өстенә пролетариат революциясе үзе җитештергән, революция казанында кайнап үскән һәм үзләре инде танылып өлгергән Ш. Госманов, Кави Нәҗми, Г. Толымбай, Туфан, С. Баттал, М. Максут, Афзал Таһиров, М. Кырыймов һәм башкалар кебек әллә никадәр яшь көчләр килеп кушылдылар. Боларның саннары көннән-көн арта һәм үсә баралар. Болар татар пролетар әдәби теленең үсүенә, бөек социализм төзү чорының идеологик өскорманың тулы һәм бөтен килеш гәүдәләндерә алырлык көчле классик әдәби тел эшләнүенә, формалашуына гаять зур көч һәм хезмәт салалар.

Бөтен гомерләрен фабрик һәм заводларда, авылның киң кыр һәм урманнарында, эш һәм хезмәт белән үскән, революция казанында кайнап чыныккан бу әдип һәм шагыйрьләр, эшхәп һәм авылхәпләр эш һәм хезмәтнең, гомумән коллектив тормышын, социализм ярышы хәрәкәтләренең бөтен матурлыкларын био-психологик нечкәлекләре, үз тормышларында каннарына сеңгән бай сүзлек запаслары белән пролетар әдәби теле, буржуа әдәби телендә күрелмәгән бөтенләй яңа тәгъбирләр, бөтенләй яңа алымнар белән бизәлә.

Түбәндәге берничә юллык үрнәкләрдән дә эшчеләр тормышын, промыселлар күренешен, эш һәм хезмәт симфониясен гәүдәләндерә торган әллә никадәр яңа терминнар, яңа сурәтләр, яңа алымнар очратырга мөмкин:

*«Шимбә.*
*Сәгать икене кимерә.*
*Мазутка, корымга буялган, кайнар тир белән*
*Капланган йөзләр –*
*Горналардан биегән ялкыннар*
*Сузылып сызгырган тимерләр,*
*Киерелеп ухылдаган чүкечләр, станоклар,*
*Маховиклар, каешлар, тимер-имән бүкәннәр,*
*Такталар, пыялалар аркылы карап*
*Ял көне якшәмбегә елмаялар.*
*Бүген получка...»*

*«Атна буе эш белән талган куллар: беләкләр ял итәчәк. Йомшаган мускулларга тимер тутырылачак, тамырларга тузан белән болганып куерылган каннар урынына яңа, саф тимер каннар тутырылачак. Ми тамырларына яңа энергия утлары кертеләчәк».*

(К. Ильясов. «Получка»)

*Заводлардан килгән гудук тавышын*
*Йөрәк тыңлый, йөрәк сизенә.*
*Тарих: тыңла!*
*Тиңсез яшәү язының*
*Юл маршы шуннан ишетелә».* (Демьян Фәтхи)

*«Дәрт агылсын безнең йөрәкләрдән,*
*Батыр була дәртле кешеләр.*
*Ә батырлык нигә кирәк тагын:*
*Ярамаса төзү эшенә?!*
*Әй, күтәр, күтәр тумарны*
*Ал да свайларга бәр!*
*Арма!*
*Талма!*
*Калма!*
*Алга!*
*Темп белән илне күтәр!*

*Җырларның чыңгыравыклы дулкыннары йөрәкләрне тиберәлдерәләр. Йөрәкләрдә куанычлы җылы кан бәйләнде. Мускуллар: куллар, аяклар җыр дулкыны белән чайкалганлыкларын сизми дә калдылар.*

*Их, тагын, тагын... Тагын да дәртлерәк җыр! Күңелләр шуны тели, телләр җыр белән тибрәләләр. Җыр көче дәрт ташкыны булып күңелләрдән күңелләргә җәелә. Дөньяда бөтен нәрсә онытыла да, җыр һәм аның ритм агышына бирелгән хезмәт хәрәкәте генә кала. Сәетләрнең, Сабирларның... барсының... барсының күңеләреннән күтәренке җыр ташкыны юып алып китә. Аларның күкрәкләре яңгыравыклана. Аларның дәрт ташкыннарын җырга ялгап җибәрәләр дә, алар да җырлыйлар. Көчле җыр дулкыны йөрәкләрдән каннарга, мускулларга, кулларга, аякларга җәелде. Алар да хезмәт барышы иркенә хәрәкәтләнделәр.*

*Эш кызды, кайнарланды. Көрәкләр чыкылтап балчык калҗаларын турадылар. Балталар чаң-чоң килделәр. Балта чүпләре сызгырышып чәчерәделәр... Пычкылар иңгылдаштылар... Эш симфониясе һава барабанының зәңгәр припонкаларына сугылып ярыктагы пычкылы таулар артына төшеп ятты.*

*Җырлар тындылар, тик хезмәт кенә калды...*» (Х. Госман. «Чаң тавышы»)

Күмәк хуҗалык, күмәк тормышка өндәү белән беррәттән аваз инструментовкасы җирлегендә өр-яңа алымнар да күзгә ташланалар:

«*Ашлыкны җилгәрәмсең,*
*Җилгәр,*
*Җилгәр,*
*Тормышның*
*Чүп-чарларын*
*Җилгә*
*Җибәр!*
*Бер туган күк*
*Бергә эшлик,*
*Бергә йөрик,*
*Машиналы*
*Күмәк тормыш*
*Төзеп җибәр!*» (Сирин. «Булмый-булмый»)

«*Ана сөте белән кермәгәнне*
*Тормыш*
*үзе*
*кертә күңелгә –*
*Ана сөте белән кергәнне дә*
*Үзгәртәләр безнең гомерләр*». (Туфан)

«*Ярлы да мин, надан да мин,*
*Мә, партия мине!*
*Миңа аң кирәк,*
*Әй, синдәме Ленин?*
*Өлеш кирәк безгә, “Партия”*». (Туфан)

Бөек социализм төзү чорында татар эшчеләре арасындагы ударчылык һәм социализм ярышы хәрәкәтләрен гәүдәләндерә торган түбәндәге үрнәкләрне күрсәтеп китәргә кирәк.

*Фәридә цехы – удар цехлардан берсе. Электрик белән яктыртылган зур бер бүлмә. Бүлмә буйлап озын өстәлләргә тезелгәннәр. Өстәлләр янында блуза җиңнәрен терсәк тигентен сызганган кызлар, җегетләр... Алар барысы да – Фәридә кул астында өзеклек белән көрәшче бригада әгъзалары. Ашыгыч заказның да күп өлешен алар үтиләр. Алар – фабриканың алдынгы көрәшчеләре – үрнәк бригада. Арттарак баручы цехлар шушы удар бригаданың ярдәме астында эшлиләр... Фәридә бригадасы ул цехларны буксирга алган.*

*Яшьләр сүз көрәштерәләр!*

*– Бу турыда Ленинның X томында бик яхшы әйткән...*

*– Нәрсә дип әйткән?* (И. Гази. «Көмеш сулы Нурминкә»)

*Мә, ударник,*
*Син тот бүген ал байракны,*
*Син баш бүген сафның алдына!*
*Меңнәр теле:*
*Син әйт бүген:*
*Станогың*
*Ничә тапкыр артык алдыра?!* (Ф. Кәрим. «Беренче май»)

Соңгы сыйнфый көрәш һәм социализм төзелеше уңышларын тулысы белән гәүдәләндерә алырлык тирән алымнар, көчле сурәтләр әдәби телдә эшләнәләр:

*«Бүгенге ул сыйнфый катлауларның*
*Соңгы каты көрәш заманы,*
*Без, искене җимереп,*
*Планетада*
*Тигез тормыш,*
*Матур, яңаны*
*Төзү уе белән янабыз!*
*Һәм без планетаны сыйныфлардан*
*Тазартуга таба барабыз!*
*Без унөч ел*
*Бөек илебезне*
*Дошман сыйныфларыннан сакладык,*
*Без гигантлар төзедек,*
*Һәм без инде*
*Социализм чорына атладык!*
*Хәзер*

*Бөлгенлеккә төшкән буржуа иле*
*Теләсә генә ничек итсә дә,*
*Безгә блокадалар ясау түгел,*
*Борны белән чәнчелеп китсә дә,*
*Без җиңәрбез!*
*Бөек планетаны*
*Үзебезнең кулга алырбыз,*
*Ерак илләр күкрәгенә тик бер байрак –*
*Безнең байрак белән барырбыз!*
*Хыял – безнең өчен чит бернәрсә,*
*Һәрбер теләк, якын киләчәк!*
*Һәрбер колхоз, һәрбер гигант совхоз*
*Яшәү көче безгә бирәчәк!*
*Без еллыкның бөек гигантлары*
*Һаман үсә,*
*Һаман күккә таба үрелә,*
*Башларыннан инде сез яшәгән*
*Коммунизм кыры күренә!...* (Һ. Такташ. «Киләчәккә хатлар»)

Бер сыйныфның әдәби теле эшләнүендә, урнашуында, ул сыйныфның иркендә булган югары уку йортлары, урта һәм башлангыч мәктәпләре, шулай ук суд һәм администрация органнары да аз роль уйнамыйлар. Академияләр, университетлар, институтлар гыйльми тел һәм гыйльми терминология эшләнеп чыгуына хезмәт итәләр, әдәби телнең дәрес һәм туры юл белән үсүендә җитәкчелек итәләр, нормадан читкә тайпылу моментларында юл күрсәтәләр. Урта һәм башлангыч мәктәпләр әдәби телнең киң масса арасына таралуына, суд һәм администрация органнары әдәби телнең бөтен дәүләт күләмендә җәелүенә сәбәп булалар.

Пролетариат революциясенә кадәр татар әдәби теле бу факторлардан бөтенләй мәхрүм иде.

Патша хөкүмәте вакытында татар теле дәүләт теле булып танылмады. Суд һәм администрация органнарында татар телендә эш йөртелмәде, шуңа күрә кәнсәләрия һәм эшбашкаручылык теле бөтенләй эшләнә алмады. Күбрәк рухани кадрлар хәзерләү өчен хезмәт итә торган мәдрәсәләрдән башка урта һәм югары фән уку йортлары ачарга ирек бирмәде. Шуңа күрә гыйльми тел, гыйльми терминология эшләнергә мөмкинлек булмады. Татар теле пролетариат революциясеннән соң гына мондый киртәләрдән, чикләү законнарыннан котыла алды. Коммунистлар партиясенең генераль

юлы буенча, Ленин милли сәясәте тормышка ашырылу аркасында, хәзер татар теле дәүләт теле булып эшләнеп өлгерде. Хәзерге вакытта Татарстандагы югары уку йортларын төп халыклаштыру чарасы уңай белән югары уку йортлары янында татар теле һәм әдәбияты кафедралары төзелде, һәр уку йортларының үз белгечләренә карата гыйльми терминнар төзү өчен шул уку йортлары янында терминология комиссияләре, уку йортлары күләмендә дәреслекләр, кулланмалар һәм тәрҗемә итү өчен коллективлар оештырылды. Татар гыйльми эшчеләре арасыннан квалификацияле тәрҗемәчеләр кадры өлгерде. Хәтта хәзерге көндә Ленинның 6 томлык әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителеп басылып яталар. Димәк, ашыгыч темп белән татар телендә гыйльми тел эшләнеп килә.

Менә шулай, 15 ел эчендә Октябрьдә җиңеп чыккан революцион татар пролетариатының үз идеологиясенә һәм гомумән культура үсешенә яраклашып, интернационализмга таба юнәлеш алып, үз әдәби теле эшләнде. Бу 15 ел эчендә татар әдәби теле бик күп сүзләр, яңа терминнар, татар буржуа телендә күрелмәгән яңа сурәтләр, революцион алымнар белән баеды. Татар әдәби теле хәзер татар пролетариатын оештыру һәм СССРда социализм экономикасын төзү коралы булып хезмәт итә.

Менә шулай, иптәш Сталин әйткәнчә: «СССРда пролетариат диктатурасы һәм социализм төзелеше чоры – эчтәлеге ягыннан социалистик, формасы ягыннан милли булган культураның чәчәк ату чорыннан гыйбарәт».

## ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ БАРЫШЫ[1]

Русиядә коммунистлар партиясе җитәкчелеге астында пролетариат революциясе ясалу белән рус империализмы, җимерелеп, аның урынына Советлар власте урнашкач та, беренче нәүбәттәге эшләрдән берсе булып, партиянең Ленин юлы буйлап милли политиканы практикада тормышка ашыру мәсьәләсе башлана. Эш йомгагында берсе артыннан икенчесе милли җөмһүриятләр мәйданга киләләр. Шуның белән бергә үк, бу җөмһүриятләрдәге моңа кадәр рус империализмы тарафыннан изелеп килгән төп җирле

[1] *Бәдигый Х.* Татар әдәби теленең барышы // Безнең юл. 1930. № 2. Б. 34–40; 1930. № 3–4. Б. 38–41.

халыкның хуҗалыгын күтәрү, милли пролетариат кадрын үстерү, культура үсеше темпын җитезләү, аппаратны төп халыклаштыру, милли телләрне тулы хокуклы дәүләт теле итеп тану белән бергә, аларны практикада тормышка ашыру кебек милли җөмһүриятләргә бәйләнешле бик күп мәсьәләләр үзләреннән-үзләре туалар. Бу мәсьәләләр хәзер Советлар Союзы конституциясенә кертелеп канунлаштырылды, аларны тормышка кертеп җибәрү турында да күптән үк партия тарафыннан директивалар бирелде.

Димәк, хәзер татар теле, үзенең элекке үгилегеннән, кысылуыннан, хокуксызлыгыннан котылып, тулы хокуклы дәүләт теле булып әверелде. Кысылу, изелү, хокуксызлык турында беркемгә дә зарланырга, үпкәләргә урын калмады. Инде шуны чын-чынлап тормышка кертеп җибәрү мәсьәләсе генә бөтен күләме белән безнең алдыбызда тора. Ләкин моңа кадәр үги бала саналып кысылып, изелеп килгән, чын-чынлап эшләнеп җитмәгән бер телне тиз үк арада дәүләт күләмендә тормышка кертеп җибәрү билгеле, бик үк җиңел эш түгел, әлбәттә. Бу эш үз дәрәҗәсендә яхшы ук авыр һәм байтак ук зур хезмәт куюны сорый. Бу эш өстендә партия һәм совет конференцияләрендә, съездларында төрле теләкләр, резолюцияләр чыгару, төрле директивалар бирү белән генә эш бетми әле. Бер телнең чынлап та дәүләт теле, эшләп чыгаручылык теле, дәүләт күләмендә аралашу коралы булу дәрәҗәсенә ирешүе өчен, ул үзенең теоретик һәм практик бик нык эшләнүен – фонетикасы, орфографиясе, грамматикасы, терминологиясе, энциклопедиясе, әдәбияты, әдәбият кануны, әдәбият тарихы һәм башкалары кебек, бөтен тармаклары белән марксизм нигезендә кристаллашуын көтә. Бу колоссаль зур эш күбрәк безгә – совет укымышлыларына, бигрәк тә телчеләребезгә, әдәбиятчыларыбызга һәм тәрҗемәчеләребезгә йөкләнә. Мондый гадәттән тыш зур эшләрне, билгеле, үз нәүбәтләрендә бөтен дәүләт күләмендә алдан хәзерләнгән бер план буенча алып барырга тиеш була.

Татар әдәби теле Октябрь революциясеннән соң буржуа кулыннан пролетариат кулына күчү белән хәзерге вакытта зур борылыш алдында тора. Ул бу борылышында гигант адымнар белән һаман алга бара, үсә, киңәя. Тел үзенә мондый яңа борылыш алган периодларында үзенең натураль нормасыннан чыгып, күбесенчә ялгыш юлга кереп киткән фактлары да булгалый, шуңа күрә безгә – тел белән кызыксынучыларыбызга – телебезнең бу борылышы кая таба һәм ничек барганын күзәтеп, вакыты белән ревизия ясап, нормадан чыгу

фактларын бер-беребезгә күрсәтешергә, ялгышларыбызны шул ук моментта төзәтешергә, төртелеп, тәрәлеп, икеләнеп торылган урыннарда юл ачып җибәрешергә кирәк. Югыйсә мондый вакытларда телнең үз тормышыннан аз гына читкә тайпылуы, ялгыш юлга кереп китүе – киләчәктә әдәби телнең имгәнеп калуына сәбәп булуы мөмкин.

Мин бу мәкаләмдә тулай татар әдәби теленең барышы, бер өлеш хәзерге борылышы турында анализ ясарга һәм кайбер нормадан чыгу моментларын күрсәтеп китәргә уйлыйм, ләкин турыдан-туры бу зур һәм җаваплы мәсьәләгә керешкәнгә кадәр, анализыбыз-йомгагыбыз тулы һәм төпле булып чыгуы өчен алдан телнең гомерен, социаль урынын һәм аның методологиясен билгеләп үтәргә тиеш табам.

I

Тел процессының ике ягы бар: 1) артикуляцион-акустик ягы, 2) тамгалык-символик ягы.

Тел процессының артикуляцион-акустик ягы сөйләү органнарының ярдәме белән эшләнеп чыгарыла. Сулыш аппараты, бугаз, авыз һәм борын куышы төп сөйләү органнарыннан саналалар. Тел процессын бу яктан караганда, тел, башка гади физик әйберләр, эшләп чыгаручылык кораллары һәм кулланучылык продуктлары кебек, хәзергә үзе-үзенә генә булып тора әле. Сөйләү органнарының төрле социаль фонемнар эшләп чыгарырлык дәрәҗәгә ирешүләре өчен, индивидиумнарның хезмәт процессында үзара коллектив булып оешулары тиеш. Фонемнарның төрле тел коллективларында (мәсәлән, татарларда бертөрле фонемнар, русларда икенче төрле фонемнар эшләнгән кебек) төрлечә эшләнүләре моңа бик гади мисал була ала. Шуңа күрә телнең артикуляцион-акустик ягы безнең бу темабыз өчен артык әһәмиятле түгел, безгә монда аның бигрәк икенче ягы – тамгалык-символик ягы әһәмиятлерәк.

Тел һәрбер идеологик продукт – физик әйберләр, эшләп чыгаручылык кораллары, яки кулланучылык продуктлары кебек натураль һәм социаль тормышның (действительность) бер өлеше генә түгел, бәлки бу саналган хадисәләрдән тыш, ул тагын нинди дә булса икенче бер тормышны да чагылдыра һәм шәүләләндерә. Икенче төрле әйткәндә, һәрбер идеологик хадисәнең үзенә караган берәр мәгънәсе була. Ул үзеннән тыш тагы нинди дә булса икенче бер әйберне күз алдына китерә, икенче бер әйбер белән таныштыра – ул тамга (знак) була. Тамга булмаган урында идеология дә юк.

Физик әйбер ул башта үзе-үзенә генә тигез була әле, ул үзенең ялгыз натураль барлыгы белән генә очрашканда хәзергә бер нәрсә дә аңлатмый; анда идеология юк. Ләкин теләсә нинди физик әйбер нинди дә булса берәр нәрсәнең сурәте (образ) булып күңелдә урнаша ала. Әйтик, бер физик әйбердә натураль тынлык гәүдәләндерелә икән, бу вакытта инде бу физик әйбернең мондый символик сурәте идеология продукты була. Монда әлеге физик әйберебез тамга булып әверелә һәм бу әйбер материаль тормышның бер өлеше булу белән бергә билгеле бер рәвештә икенче бер тормышны да чагылдыра һәм шәүләләндерә. Шулай ук һәрбер эшләп чыгаручылык коралы, һәрбер кулланучылык продукты үз хәлләрендә генә үзләре үзләренә тигез. Аларның әле үзләренә караган аерым мәгънәләре генә бар. Алар берсе бертөрле, икенчесе икенче төрле эшне башкарырга ярый. Ләкин шул ук эшләп чыгаручылык кораллары яки кулланучылык продуктлары вакыты белән идеология продукты булып әверелә ала. Мәсәлән, безнең СССР гербында урак белән чүкеч хәзер билгеле бер идеология символы булып әверелгәннәр.

Димәк, натураль хадисәләр, эшләп чыгаручылык кораллары һәм кулланучылык продуктлары белән рәттән тагы бер дөнья – тамгалар дөньясы бар.

Һәрбер тамгага чын, ялган, изгелек, усаллык кебек төрле идеологик кыйммәт кушыла ала. Идеология өлкәсе һәрбер вакыт тамга өлкәсе белән тап була. Болар арасына тигезлек билгесе куярга мөмкин.

Тамга булган урында, әлбәттә, идеология дә бар. Тамгаларның үз эчләрендә – идеология түгәрәгендә тирән аермалар була: монда әдәби сурәтләр дә, дини символлар да, фәнни формулалар да, хокукый нормалар да һәм башкалар да керәләр. Идеология өлкәсенең һәрберсе тормышка үзенчә яраклаша һәм аны үзенчә чагылдыра. Һәр өлкәнең социаль тормышта үзенә караган аерым функциясе бар, ләкин тамгалык хәрәкәте бөтен идеологик хадисәләр өчен һәр хәлдә уртак билгеләнә. Һәр идеологик тамга тормышның күләгәсе һәм шәүләсе генә түгел, бәлки ул бу тормышның материаль өлеше дә була. Һәрбер тамгалык идеологик хадисә, аваз, физик массалар, төс, тән хәрәкәте һәм башкалар кебек нинди дә булса берәр материалда бирелә. Тамга – тышкы дөнья хадисәсе. Ул үзе һәм һәрбер аның белән эшләнеп чыгарылган эффектлар, реакцияләр, хәрәкәтләр һәм чолганып алынган социаль мохиттә ул үзе тудырган яңа тамгалар – һәммәсе дә тышкы тәҗрибәләрдә агалар.

Тамгалар индивидуаль аңнар арасындагы мөнәсәбәт процессында гына туалар. Ул бары индивидуаль территорияләр арасында гына яши ала, шуның белән бергә, бу территория, турыдан-туры үз мәгънәсендә әйткәндә, натураль түгел: ике үзара бәйләнешсез индивид арасында тамга була алмый, бу ике индивид, әлбәттә, үзара социаль оешкан булырга, алар арасында коллектив төзелергә тиеш. Шул вакытта гына болар арасында тамгалык мохите ясалырга мөмкин. Индивидуаль аң үзе исә – тамгалар белән тутырылган социаль, идеологик факт. Икенче төрле әйткәндә, аң, идеологик мөндәриҗә тамгалы мөндәриҗә белән тулган чакта гына, шулай булгач социаль мөнәсәбәт процессында гына чын аң булып әверелә. Кешедә аң сурәте (образ), сүздә, мәгънәле ымда (жест) һәм башкаларда гына оялый ала. Бу материаллардан тыш ул тамгалар белән яктыртылмаган ялангач физиологик акт кына булып кала. Димәк, идеологик тамга – турыдан-туры экономик базис өстенә корылган өскорма (надстройка). Индивидуаль аң исә бу өскорманың архитекторы түгел, бәлки ул идеологик тамгаларның социаль йортына урнашкан фатирчы гына.

Һәрбер тамга социаль оешкан халыкның үзара мөнәсәбәтләре процессында гына ясалган кебек, аның нормалары да әлеге социаль оешкан халыкның социаль оешмалар (организация) белән, шулай ук аларның үзара аралашу рәвешләре белән шәраитләнгән. Бу формалар үзгәрә икән – тамга да үзгәрә. Тамга белән тормышның (бытье) үзара мөнәсәбәте бары шундый юл (подход) белән генә конкрет тәгъбир алырга һәм шушы шәраиттә генә тамганың тормыш белән натураль билгеләнү процессы күз алдына килергә мөмкин, моның өчен, әлбәттә, түбәндәге методологик таләпләр белән файдалану тиеш була:

Идеологияне тамганың материаль тормышыннан, тамганы (гади физик әйберләргә әйләндереп) социаль аралашуның конкрет формасыннан (чөнки тамга – оешкан социаль аралашуның бер кисәге), шулай ук аралашуны һәм аның формасын үзләренең материаль базисыннан суырып ташларга ярамый.

## II

Менә шушы тамгалар дөньясының һәр яктан һәм өзлексез аралашу белән шәраитләнгәне, әлбәттә, тел була.

Тел – ул идеологик символ. Телнең бөтен тормышы үзенең тамгалык функциясендә ачыла. Тел – иң саф һәм иң нечкә социаль

аралашу тамгасы, болардан башка тел тагы битараф тамга була. Калган тамгалык материалларның һәммәсе дә идеологик иҗатларның аерым өлкәләренә генә багышлана. Һәр өлкә үзенең идеологик материалын гына били, үзенең хосуси (специфический) тамгаларын – символларын гына формалаштыра, башка өлкәләргә тәтбикъ ителә алмый. Монда, телдә исә тамгалык ялгыз идеологик функция белән генә туа һәм аннан аерыла алмый. Тел бөтен идеологик функциягә битараф, ул, фәнни, дини, мораль, эстетик функцияләр кебек, теләсә нинди идеологик функцияне үти ала.

Шуның белән бергә, тел тәннән башка тагын икенче нинди дә булса берәр коралның катышуыннан тыш, бары индивидуаль организмның ярдәме белән генә эшләнеп чыгарыла, шуңа күрә ул эчке тереклекнең-аңның да тамгалык материалы була ала (эчке сөйләм). Димәк, чын-чынлап тәгъбир ителгәнчә үк ул тамгалык хезмәтен башкара ала.

Марксизмның төп проблемаларыннан бере дә – базисның өскормага мөнәсәбәте проблемасы. Аерым катлаулы һәм үзенең продуктив эшләнүе өчен, алдан чиксез күп материалга мохтаҗ булган базис белән өскорманың үзара мөнәсәбәте проблемасы – тел материаллары өстендә тагы да аңлаешлырак ачылырга мөмкин. Бу яктан караганда телнең саф тамга булучылыгы гына түгел, бәлки аның һәркайда социаль табыла алуы да әһәмиятле. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, үзара аралашулары вакытында – бергәләшеп хезмәт процессында, идеологик аңлашуда, очраклы көнкүреш бәрелешүләрендә, политик үзара мөнәсәбәтләрдә һәм башкаларда – һәр урында хәрефкә хәреф, бер тиенгә бер тиен кушыла һәм тыкшына бит ул. Телдә социаль аралашуның бөтен өлкәләре тезелгән чиксез күп идеологик җепләр катылган. Шулай булгач, телнең социаль үзгәрешләренең һәр төрен – аларның яңа гына өлгереп килә торганнарын, аларның әле бөтенләй бергә кушылып җитмәгәннәрен, идеологик системнар булып әле формалашуга ирешелмәгәннәрен һәммәсен дә сизгер күрсәтүче факт булучылыгы үзеннән-үзе аңлашыла. Тел яңа һәм идеологик форма булып туарга өлгермәгән, яңа идеологик сыйфат булып әверелү дәрәҗәсенә ирешмәгән, бары сан ягыннан әкрен генә үзгәреш бара торган мохиттә да табыла. Тел социаль үзгәрешләрнең гаять нечкә һәм узгынчы моментларын да эләктереп кала ала.

Димәк, телнең бөтен составы – фонемы, морфемы, сүзе, синтагмасы, җөмләсе һәм аның бөтен нәрсәләре – һәммәсе дә – идеологик

тамга. Телнең югарыда тикшерелгән үзлекләре – аның саф тамгалыгы, һәр көнкүрешле аралашуга катнашуы, аның эчке сүз була алучылыгы, һәрбер идеологик актта табылучылыгы, ниһаять, һәр социоүзгәрешләрнең иң нечкә һәм узгынчы моментларын да эләктереп кала алучылык – ул үзенә марксистик һәм социологик метод буенча гаять тирән һәм нечкә анализ ясауны сорый.

Әдәби тел өстендә фикер йөрткәндә дә, телнең шушы хосусиятләрен, әлбәттә, истә тотарга тиеш була.

III

Мәсьәләне бераз популярлаштыру максаты белән бергә бу урында «әдәби тел» дигән терминның мәгънәсен һәм бу мәгънәсе белән аның берлек коллективы эчендә ничек килеп чыгуын, нинди юллар белән урынлашуын билгеләп үтәргә кирәк. «Әдәби» терминнан безнең көндәлек, гадәттә, нинди булса да берәр әйбернең матур әдәбиятка гына бәйләнешле булучылыгы аңлашылып кала. «Әдәби тел» дигәндә исә, бу бер терминны гадәттәгегә караганда бераз шартлы һәм байтак ук киң мәгънәдә кулланабыз. Бу яктан караганда, әдәби телне «китап теле» яки «культура теле» дип атарга мөмкин. Әдәби тел, гадәттә, халык теленә каршы куела. Болар һәр икәве бер үк халыкның, бер үк тел коллективының телләре булсалар да, ләкин һәрхәлдә алар арасына тигезлек билгесе куярга мөмкин түгел. Халык теле – чуар тел. Ул үз эчендә төрле диалектларга, диалектлар тагы үз нәүбәтләрендә сөйләшләргә (говорларга) аерыла. Җирле халык, гадәттә, үзара үзләренең җирле телләре белән, җирле диалект, җирле сөйләш телләре белән аңлашалар. Җирле тел җирле халыкның ихтыяҗларын гына үти ала. Бер әдәби тел эченә кергән шул ук җирле халык матбугат мәйданына чыгып, берәр хәбәр, мәкалә, әсәр язарга теләсә, ул инде бөтен тел коллективы өчен уртак булган әдәби тел белән генә яза. Төрле як халкыннан җыелган җыелышларда, конференцияләрдә, съездларда үзенең фикерен, речен тагы шул ук уртак әдәби тел белән генә сөйли. Ул үзе дә шул ук уртак әдәби телдә язылган гәзит-журнал яки төрле темадагы китаплардан файдалана. Балалары мәктәпләрдә шул ук бер әдәби телдә язылган дәреслекләрне укый; театрларда шул ук уртак әдәби телдә язылган пьесаларны тамаша кыла. Димәк, әдәби тел, бер яктан караганда, бер тел коллективы эченә кергән бөтен халыкның уртак теле – үз теле; икенче яктан, аерым җирле халыкка караганда бер дәрәҗә чит

тел, ят тел, чөнки әдәби телгә бер тел коллектив эченә кергән бөтен халыкның иҗат көче катнашкан, аның өстенә аңа башка тел коллективларыннан байтак ук сүзләр кереп урнашкан була, шуңа күрә әдәби тел белән халык теле арасында яхшы ук зур аерма туа.

Яфетидологиянең ачуы буенча, аваз телләре яралганнан соң, аларның чын-чынлап формалашу процессы төрле ялгыз-ялгыз кеше төркемнәренең көчлерәк җәмгыять булып оешуларына бик нык бәйләнгән. Менә шундый төрле ялгыз-ялгыз кеше төркемнәреннән берләшкән һәрбер аерым җәмгыять, үз тормышының озын процессында, башка үзе кебек берләшкән җәмгыятьләрдән аерылып билгеләнгән юнәлешенең этәрүе астында, ялгызы үсү сызыгы белән аерылып киткән үзлекләрен йөз еллар, хәтта мең еллар буенча һаман беркетә һәм ныгыта баралар. Мондый озын периодлардан – башлап кеше төркемнәренең «ыру» булып, аның артыннан «милләт» булып берләшүләрен санарга кирәк. Бу озын периодлар үзләренең культура иҗатларында, шулар эчендә телдә дә, һәркайсы үзенә аерым координатлар (координаты – характерлы тамгалар) эшләп чыгарганнар. Шулай итеп, элек аерым-аерым ыру телләре (кабилә телләре), алар артыннан аерым-аерым милләт телләре туалар. Шуның белән бергә, җәмгыятьләр бер урында гына таптанып кала алмаган кебек, җәмгыять тормышында гадәттән тыш әһәмиятле, көнкүрешле һәм колоссаль роль уйнаучы тел дә, һәм үзенең килеп чыгуында, һәм үзенең үсүендә, башка идеологик өскормалардан аерылып кала алмый. Җәмгыять үзгәрү, үсү, киңәю белән бергә тел дә үзгәрә, үсә һәм киңәя. Кайбер көтүчелек белән көн күрүче ыруларның үзара сөйләшүләре күбесенчә шул үзләренең хайваннары турында гына була, чөнки эшләп чыгаручылык көчләренең түбәнлеге аларга шундый эшләп чыгаручылык процессы, шундый тормыш бирә. Шулай итеп, тел дә, боларда турыдан-туры шушы процесс белән бәйләнеп, түбән дәрәҗәдә тора. Эшләп чыгаручылык көчләре җирлегендә җәмгыятьтә башка идеологик өскорма белән бергә тел дә үсә бара. Хәзерге вакытта халыкара хуҗалыкның үсүе уңаеннан төрле якларда һәр җәмгыятькә, һәр тел коллективына бертөрле үк кирәкле әйберләрнең, яки бер төрле кызыклы вакыйгаларның чыгып торулары белән бергә бәйләнеп, телефон, телеграм, радио, аэроплан, трактор, коминтерн, большевизм, ленинизм, совет кебек халыкара бик күп терминнарның һәр тел коллективына аермасыз һәм туктаусыз агылып торулары телнең үсүенә бик гади мисал була ала.

Җәмгыятьнең, тел коллективының сыйныфларга, төркемнәргә, профессияләргә аерылулары да телгә йогынты ясамый калмый, әлбәттә. Шәһәр халкы теле авыл халкы теленнән, эшчеләр теле кустарьлар теленнән аерылганы һәркемгә билгеле. Бер тел коллективында халык теленнән башка тагы бер уртак тел – әдәби тел килеп чыгуын да менә шушы эшләп чыгаручылык көчләренең үсүе белән бергә бәйләнеп, җәмгыятьнең үсүеннән, аның аерым бер милләт булып, аерым тел коллективы булып формалашып җитүеннән һәм шул ук җәмгыятьнең сыйныфларга, төркемнәргә, профессияләргә аерылулары белән бергә бәйләнеп, бер үк җәмгыять эчендәге телләрнең бер-берсеннән бераз башка булуыннан эзләргә тиеш була. Әдәби тел – сыйнфый бер тел ул.

Һәрбер идеологик тамга кебек, тел тамгасы да, социаль аралашу процессында ясалып, билгеле чорның һәм билгеле социаль төркемнең социаль карашы белән билгеләнә. Һәрбер чорның һәм һәрбер социаль төркемнең үзенә караган көнкүреш (тереклеге) идеологик аралашу формаларының репертуары була, шуңа күрә гомумән тел формалары эшләп чыгаручылык мөнәсәбәтләре һәм социаль-политик төзелеш белән билгеләнә. Тел формаларының классификациясе аралашу формаларының классификациясенә таянырга тиеш. Аралашу формаларының классификациясе үзе исә бөтенләй эшләп чыгару һәм социаль-политик төзелешкә таяна.

Тел тамгасында шәүләләнгән тормыш (бытие) ул анда шәүләләнеп кенә калмый, бәлки ул анда чагыла. Тормышның тел тамгасында бу чагылуы бер тел коллективы эчендә төрле якка юнәлгән социаль интересларның катнашуы белән (скрещение) – сыйнфый көрәш белән билгеләнә. Бер үк тел белән төрле сыйныфлар файдалана. Өстен сыйныф бер үк идеологик аралашу тамгасын кулланучы коллектив белән килешә алмый. Телдә төрле якка юнәлдерелгән акцентлар катнашалар. Тел сыйнфый көрәш мәйданы булып әверелә. Идеологик тамга булуын телнең бу социаль күп акцентлыгы аның үзе өчен гаять әһәмиятле момент. Дөресен әйткәндә, шушы төрле акцентларның катнашуы аркасында гына, тел тамга булып яши, үсә һәм киңәя ала. Өстен сыйныф телгә сыйнфыйсызлык, мәңгелек характерын бирергә, аның эчендә бара торган социаль акцентларның көрәшен сүндерергә, җегәрсезләндерергә, аны бер генә акцентлы итеп калдырырга омтыла. Чынлап та бит, һәрбер җанлы идеологик тамга икейөзле була. Һәрбер җанлы чеп-чи ялган

вакыйга бирәүләр өчен чын һәм мактаулы эш булып күренергә, һәрбер җанлы хакыйкать башка бик күпләр өчен бик зур ялган булып яңгырарга мөмкин. Телнең бу эчке диалектиклыгы бары социаль кризислар һәм революцион кузгалышлар чорында гына ахырына кадәр ачыла. Һәрбер идеологик тамгага салынган бу каршылыклар социаль көнкүрешнең (тормышның) гади шәраитендә генә ахырына кадәр ачылып җитүе мөмкин түгел, чөнки идеологик тамгага өстен сыйныфның идеологиясе ныграк урынлашканлыктан, ул һәрвакытта берникадәр реакцион була, гүя ул социаль урынлашу диалектик ташкынының үткән моментын да һаман искечә калдырырга, ныгытырга, мәңгеләштерергә, кичәге дөреслекне бүгенге дөреслек итеп акцентлаштырырга тырыша, көчәнә. Сыйнфый аң кереп җитмәгән (класс в себе) башка сыйныфның кайбер әгъзалары бу акцентны чынлап ук үзенеке итеп кабул итә, сыйнфый аң кергәннәр (класс для себя) исә көчле сыйныфның басымы аркасында вакытлы буйсынырга мәҗбүр була. Ниһаять, өстен сыйныф үзенең телен үзенең хуҗалыкта өстенлеге, сәүдәсе, дәүләте, администрациясе, канцеляриясе, мәхкәмәсе (суд органнары), гаскәре, матбугаты, цензуры, дәреслекләре, мәктәпләре, университетлары, академияләре аркылы башка сыйныфларга, төркемнәргә, профессияләргә йоттыра, тарата һәм җәя. Шулай итеп, билгеле бер чорда билгеле бер милләтнең көчле һәм өстен сыйныфның теленә яраклашып бөтен тел коллективы өчен уртак бер тел килеп чыга.

Социаль тормышның шәраитенә карап, телнең характеры – стиле дә үзгәрә. Стиль – төрле тойгыларның, кәефләрнең, зур һәм кечкенә идеяләрнең тәгъбире ул. Стиль-җәмгыять тормышы – системның рефлексы, шәүләләнүе. Стиль тышкы форма гына түгел, аның тарихында тормыш системының тарихы яшеренә, анда өстен сыйныфның идеологиясе гәүдәләнә.

XVII–XVIII йөзләрдә Париж һәм Версаль сарае француз аксөякләренең (аристократиясенең) кайнаган үзәкләре булганнар. Боларда француз дворяннары өчен мәҗбүри саналган бөтен нечкә һәм нәфис тормыш хосусиятләре эшләнеп чыгарыла икән. Карл сарае һәм аксөяк бикәләренең салоннары янында үзенең хосусый лексик составы һәм тәгъбирләре белән француз әдәби теленең аерым стиле иҗат ителә. Эзләнүчән иркә аксөяк бикәләр француз әдәби теленең үзенә махсусы спайлыгы-нечкәлеге турында чиксез күп көч салганнар. Бу аксөяк бикәләр йомшак ятакта ятып, сөекле

елмаю белән кунаклар кабул итә торган салон матурлыгына, пөхтәлегенә ярашмаган бөтен «тупас» сүз һәм тәгъбирләр француз әдәби теленнән чыгарылып ташланганнар. Мәсәлән, «jaime le melon» (мин кавын сөям) дип әйтергә ярамаган, чөнки бу «aimer» (сөям) сүзен «кимсетү, хурлау» булыр иде, шуңа күрә «jestime le melon» (кадерлим, тәкъдир итәм) дип әйтү яхшырак саналган. Шушы вакытларда француз югары җәмгыятенең теленә стильне нәфисләндерә торган күп гармонияле һәм образлы тәгъбирләр керәләр. Мәсәлән, «le soleil (кояш)» дип әйтелми, бәлки «le flambeau de jaur (көньяктырткыч)» дип, «les yeux (күзләр)» дип түгел, бәлки «les mires de lame (җан көзгесе)» яки «le paradis de lame (күңел оҗмахы)» дип, «la chemise (күлмәк)» дип түгел, бәлки «la compagne perpetuelle des morts et des vivants» (тере һәм үлекләрнең мәңгелек дусы) дип әйтергә тиеш булган. Телнең сафлыгын-нәфислеген саклау турында 1635 елда ачылган француз академиясе дә кайгыртырга тиеш булган. Шушы «ыспай һәм нәфис» аристократия теленең сүзлек составын законлаштырып, кирәкле булган сүзлек төзү академия әгъзаларының төп бурычы саналган. 1694 елда бу сүзлекнең беренче басмасы чыккан. Бу сүзлеккә академиклар тарафыннан шул заман үрнәк язучыларының әсәрләреннән табылган сүзләр генә кертелгән. Монда, телне простойландырудан куркып, көндәлек тормыш сүзләреннән берсенә дә урын бирелмәгән. Француз аристократиясе үзләренең әдәби телләренә шулай әһәмият биргәннәр.

XVII йөз рус әдәби теле белән XIX йөзнең соңгы рус әдәби телен бер-берсе белән чагыштыру нәтиҗәсендә күренгән аермалары, Петр I нең үз заманындагы язучыларга, «илчелек боерыкларында ничек язалар, шулай язарга тиеш» дип киңәш-тон биреп торуы – менә болар һәммәсе дә әдәби телнең ачык сыйнфый булуын күрсәтәләр.

IV

Татар әдәби теле дә, әлбәттә, сыйнфый. Ул сыйнфый булып туган, сыйнфый булып яши һәм сыйнфый булып үсә. Татар әдәби теленең тамыры ерак тарихка – XII–XIV йөзләр арасында Сырдәрьяның түбәнге агымы хаузасында, Харәземдә һәм XIII йөздән алып Алтын Урдада яшәгән кыпчак-угыз әдәби теленә барып тоташа.

Академик А. Н. Самойлович үзенең «Урта Азия төрек әдәби теле тарихына» дигән мәкаләсендә, хәзергә кадәр сакланган тарихи-әдәби хатирәләргә этник, фонетик, морфологик һәм сүзлек яклардан

карап чагыштырмалы анализ ясаганнан соң, ислам чорындагы Урта Азия төрек әдәби телләре үсүен түбәндәге өч периодка аерырга тиешлек фикеренә килә.

Караханилар-уйгур әдәби теле чоры. Караханилар дәүләте төзелү моментыннан башланып XII йөзгә кадәр яшәгән әдәби тел. Бу әдәби телнең үзәге Кашгар шәһәре була. Хәзергә кадәр мәгълүм булган әдәби хатирәләрдән «Кудатгу Билиг» һәм «Һибәтел-Хакаик» әсәрләре шушы чорга карыйлар.

Кыпчак-угыз әдәби теле чоры. XII йөздә кыпчак һәм угызлар арасында ислам культуры ныгудан башланып, XV йөзгә кадәр яшәгән әдәби тел. Үзәкләре Сырдәрьяның түбәнге агымы хаузасы Харәзәем була. Хәзергә кадәр табылган әдәби хатирәләрдән «Кыссаи-Йосыф» (Гали, XIII йөз), Хәким ата (XIII йөз), «Хөсрәү вә Ширин» (XIII–XIV йөз) «Мәхәббәтнамә» (XIV йөз), «Кыйсасел-әнбия» (Рабгузи, XIV йөз), «Нәһҗел-фәрадис» (XIV йөз), «Хикәят Җөмҗөмәи Солтан» (XIV йөз) һәм Каһирәдә гарәп филологы Абел Хайянел-Гарнатый тарафыннан XIV йөз башларында төзелгән «Китабел-идрак лилисамил Әтрак» дигән әсәрләр шушы II чорга карыйлар.

III. Чыгтай әдәби теле чоры. XV йөздә Тимуриләр дәүләтендә культура тормышы ныгудан башланып, XX йөзгә – хәзерге яшь үзбәк әдәбиятына нигез салганга кадәр яшәгән әдәби тел. Үзәкләре Чагатай өлешенең утырма өлешләрендәге төрле шәһәрләрендә була. Ислам чорында Урта Азия төрек әдәби теле үсүенең бу III чоры үзенең ныгып урнашуы өчен иң уңайлы заманга туры килә. Бу III чорда, башларында Миргалишир Нәваи торган хәлдә, иң көчле әдипләр эшләгәннәр, шуңа күрә бу чор Урта Азия төрек әдәби теле үсүенең иң парлак заманы булып өлгерде һәм классик әдәби тел булып берләшү һәм формалашу дәрәҗәсенә иреште.

Бу өч чорга аерылган әдәби телләр төрек халыкларының эшләп чыгаручылык көчләре, җәмгыять төзелешләре үзгәрү аркасында соңгылары әүвәлгеләренә варис юлы белән үскәннәр һәм һәр өчесе дә үз чорларында бөтен төрек халкы өчен бер һәм уртак әдәби тел хезмәтен үтәгәннәр. Заман үтү, төрек халыклары арасында җәмгыять төзелеше үзгәрү белән бу өч чор әдәби телнең соңгы икесендә, бигрәк тә икенчесендә дифференциация ясалып, хәзерге вакыттагы аерым төрек халыкларының азмы-күпме тарихка ия булган үз әдәби телләре төзелә. II чордан калган тарихи әдәби хатирәләрне җентекләп тикшерү, бер Урта Азия төрек әдәби тел өчен генә түгел,

хәтта Анатолия төрекләре, азәрбайҗан, Кырым, төрекмән һәм шулай ук татар әдәби телләре тарихлары өчен дә бик әһәмиятле, чөнки болар, академик А. Н. Самойлович фикеренчә, һәммәсе дә шушы II чор әдәби телдән мирас булып калган һәм югарыда саналган әдәби хатирәләрнең телләрен татарның XVI йөздән башлап, XIX йөзнең беренче яртысына кадәр килгән әдәби хатирәләр телләре белән чагыштырып карасак, шөбһәсез, академик Самойловичның татар әдәби теленең шушы II чор әдәби телдән дифференциация ясалып оешуы турындагы фикеренә кушылырга тиеш булабыз.

Дөрес, татар әдәби теле, башка әдәби телләр кебек, үзенең үсүендә хәзергә кадәр бик күп үзгәрешләр башыннан кичерде. Әдип Галимҗан Ибраһимов беренче мәртәбә татар әдәбиятына марксистик анализ ясау тәҗрибәсендә, аны өч чорга бүлгәне кебек, татарның әдәби теле үсү процессын да шулай ук татарның эшләп чыгаручылык көчләре, җәмгыять төзелешләре үзгәрү аркасында әдәби телнең бер сыйныф кулыннан икенчесенә күчүенә карап, түбәндәге өч чорга аерырга туры килә:

Феодализм чорындагы әдәби тел. Бу чор Көнбатыш Европа әдәби телләрендә XV–XVI йөзләргә, рус әдәби телендә XVIII йөзгә кадәр тартылган булса, татар әдәби телендә исә үзенең уртак төрек әдәби теленнән дифференциациясе ясалуыннан алып, XIX йөзнең соңгы яртысына кадәр сузыла. Татарның феодализм чорындагы әдәби теле, үзенә бертөрлеләнеп классик бер тел булып оешып, бер эзгә төшеп җитә алмады. Аның җирлеге кыпчак-угыз әдәби теле булган хәлдә, анда бер яктан чагатай әдәби теле, икенче яктан бераз Анатолия төрек әдәби теле йогынтыларын күрәбез. Шулай да кыпчак әдәби теле дә, Чагатай әдәби теле дә, Анатолия төрек әдәби теле дә түгел иде, бәлки үзенә аерым юл алган «татар әдәби теле» иде.

Буржуачылык-милләтчелек чорындагы әдәби тел. Бу чор XIX йөзнең соңгы яртысыннан Каюм Насыйрилар белән башланып, пролетариат революциясенә кадәр сузыла. Бу чорда татар әдәби теле баштарак төрле якка аумакайланып торса да, соңга таба, бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң үзенә аерым бер төрлеләнеп, бер дәрәҗә классик тел булып оешып, бер эзгә төшеп җитә яза. Ул бу чорда һәм теоретик һәм практик ярыйсы гына эшләнә. Дини китаплар, авыл, шәһәр һәм мәдрәсәләр тормышыннан әдәби әсәрләр язарлык кына түгел, хәтта яхшы ук тирән гыйльми-фәнни әсәрләр тудырырлык дәрәҗәгә ирешә яза. Шулай да, бу чорда да әле татар

әдәби теле чын-чынлап формалашып, кискен бер эзгә төшеп җитмәде, чуарлыктан котылып бетә алмады, хәтта бер үк шәһәрдә чыга торган гәзитләр, журналларның телләре бер-берсеннән бик нык аерыла иде. Бер үк темада язучы әдип һәм шагыйрьләрнең телләре төрлесенең төрлечә иде. Татар әдәби телендәге бу чуарлык, бу анархиягә, бер яктан, татар капитализмының үз анархиясе сәбәп булса, икенче яктан, бу чордагы көчле рус империализмының рус берлеген аклау политикасы да аның үз алдына иркенләп үсүенә, чын-чыннап формалашуына ирек бирми иде. Татар теле рус империализмы тарафыннан официаль бер тел – дәүләт теле булып танылу түгел, хәтта моннан соң инде аңа үз халкы – үз тел коллективы түгәрәге эчендә генә җәелергә дә җирлек калмаган иде, шуңа күрә бу чорда татар әдәби теленең, башка вак милләтләрнеке кебек, киләчәге (перспективасы) караңгы иде. Татар әдәби теле пролетариат революциясен менә шулай җитлекмәгән хәлдә каршы ала.

III. Октябрь революциясеннән соңгы әдәби тел. Бу соңгы чор татар әдәби теле үзенең идеологик мөндәриҗәсенә яраклашып, бер эзгә төшеп, формалашып җитмәгән, ул эзләнү периодын башыннан кичерә әле, шуңа күрә аның үзен бербөтен чор итеп алып, аңа тулы анализ ясау хәзергә бераз иртәрәк-иртәрәген, шулай да, аның үзеннән алдагы II чор әдәби телдән алган мирасына, бөек пролетариат революциясеннән соң ук СССРдагы башка милләт телләре белән бертигез дәүләт теле – эшләп чыгаручылык теле булып официаль танылуына һәм, гомумән, революциядән соң ук бөтенләй яңа борылыш алып, гигант адымнар белән туктаусыз алга баруына карагандa, аның хәзерге хәле һәм киләчәге турында анык бер фикергә килергә мөмкин инде: пролетариат революциясеннән соң татар әдәби теленең үсүе юлындагы киртәләр алып ташланды, ул моннан соң туктаусыз үсәргә һәм үз коллективы эчендәге хезмәт ияләрен бөек социализм тормышына алып чыгарлык көчле һәм классик бер әдәби тел булып формалашырга тиеш.

Дәүләт, власть бер сыйныф кулыннан икенчесенә революциясез, тартышсыз, көрәшсез күчә алмаган кебек, җәмгыять тормышында колоссаль роль уйнаучы әдәби тел дә бер сыйныфтан икенчесенә табигый буш кына бирелми. Аның юнәлеше турында сыйныфлар арасында башта яхшы ук кызу көрәш һәм бәхәсләр булып ала. Татар әдәби теле беренче чордан II чорга, хәтта II дән III чорга күчкәндә, дә кызу-кызу көрәшләр, бәхәсләр булды, ләкин татар җәмгыятендә

феодализм илчеләре бик зәгыйфь иде, алар үзләреннән-үзләре эреп үлеп баралар иде. Шуңа күрә әдәби тел I чордан II күчкәндә, феодализм илчеләре артык каршы тора алмыйлар, алар дин исеменнән рәнҗүдән, ләгънәт укудан артык активлык күрсәтә алмадылар. Көрәшнең иң кызуы бигрәк феодализм чорыннан калган мирасны алу өстендә эре буржуа белән вак буржуа арасында барды. Эре буржуа илчеләре көчле рус империализмына пантюркизмны каршы куеп, матбугатта «Без төрекме, татармы?» бәхәсен күтәреп чыктылар, үзләренең гәзитләре аша «Эштә, фикердә, телдә берлек» лозунгысын ташладылар. Ләкин татар җәмгыятенең кирәк тулай төзелешендә, кирәк аның әдәби телендә аңа җирлек юк иде, шуңа күрә эре буржуаның бу романтик фикере дә үзеннән-үзе шиңде, татарчылык җиңде.

Татар әдәби телен өч чорга аеруыбыз, гадәттә, татар җәмгыяте, яки татар әдәбияты шулай өч чорга бүленеп йөртелгәнгә, гүя модага ияреп, стихия рәвешендә генә түгел, әлбәттә, бәлки ул һәр чор әдәби телнең үзенә генә махсус булган координатларына карап үзеннән-үзе аерылып тора. Эшләп чыгаручылык көчләре үсеп, билгеле бер дәрәҗәгә ирешкәч, җәмгыятьтә тигезлек бозылып революция ясала, власть бер сыйныф кулыннан икенчесе кулына күчә. Власть белән бергә әдәби тел дә шул ук сыйныф кулына керә. Һәрбер сыйныф әдәби телдә үзенең идеологиясен торган саен шәүләләндерә, үзенең идеология билгесен торган саен сала бара. Әдәби телнең формалары әлеге сыйныфның социаль оешмалары белән, шулай ук аның үзара аралашу формалары белән шәраитләнә. Шулай итеп, үз тормышының озын процессында телдә әкренләп координатлар (характерлы тамгалар) эшләнәләр. Менә шушы координатларга карап, әдәби телне чорларга аерырга һәм чорның кайсы һәм нинди җәмгыятькә (сыйныфка) караганын күрергә мөмкин була.

Феодализм чорында татар теленә урам теле, «кара халык» теле итеп кенә карала, ул үзе аерым культура теле итеп танылмый, шуңар күрә ул бу чорда һәм теоретик һәм практик эшләнми. Бу чорда татар теле өстендә бөтен көчләре белән гарәп һәм бераз фарсы телләре хөкем сөрәләр. Татар әдәби телендә гарәп һәм фарсы сүзләре, хәтта тәркипләре бик зур урын алалар, шигырьләре гарәп шигырьләре үлчәвендә (квантативный метр) төзелә, хәрефләр гарәп хәрефләре, орфография гарәп орфографиясе калыбында саклана. Татарның саф үз теле нигезендә язу зур кимчелек санала.

II чорда татар теле үзе аерым культура коралы итеп танылa, әдәби тел халык теленә якынлаштырыла, теоретик һәм практик яхшы гына эшләнә башлый, ләкин бу чорда әле әдәби телдә чын-чынлап революция ясалмый, аз-маз реформа белән канәгатьләнелә, гарәп терминнары һәм тәркипләре белән файдалану һаман дәвам итә, халыкара терминнарга капка һаман бикле кала. Орфографиядә татарның үз сүзләре бераз татар орфографиясе калыбына салынса да, гарәп сүзләре мөкаддәс саналып, һаман иске хәлләрендә саклана.

III чорда исә власть пролетариат кулына күчү белән, татар әдәби телендә дә чын мәгънәсе белән революция ясала. Халыкка аңлашылмый һәм татар хезмәт массасының хәзерге культура үсеше өчен һичбер әһәмияте булмаган гарәп һәм фарсы сүзләре татар әдәби теленнән сөрелә, алар урынына мөмкин булганда татарның үз сүзләреннән файдаланылып яңа сүзләр, терминнар иҗат ителәләр, мөмкин булмаганда халыкара сүзләргә, терминнарга киң урын бирелә. Хәзер халыкара сүзләр, терминнар гына түгел, хәтта аларга ияреп халыкара яңа формалардан баралар. Иске сүзләрнең борынгы мәгънәләре пролетариат идеологиясенә ярашып алмашыналар. Орфографиядә дә II чордагы кебек аз-маз реформа белән генә канәгатьләнелми, иске әлиф – гарәп хәрефе бөтенләй ташлана, аның урынына татар хезмәт массасының культура үсеше теләге буенча яңалиф – халыкара латин хәрефе кабул ителә. Шулай итеп, бу III чор әдәби телнең башында ук телдә һәм орфографиядә интернационализмга таба зур борылыш ясала.

## V

Инде гомумән телләрнең килеп чыгулары, үсүләре һәм берләшүгә таба барулары якларыннан карап диалектик анализ ясаганда, татар әдәби теленең бу III чорында алган юнәлеш һәм барышы дөресме, аның бу юнәлешендә һәм барышында читкә тайпылулар юкмы? Тел гыйлемендә марксистик тикшеренү һәм эзләнүләрнең соңгы уңышлары бу сорауларга ничек җавап бирә?

Без югарыда, яфетидологиянең ачуы буенча аваз телләре ралганнан соң, аларның чынлап формалашу һәм сүз үрчү процессы төрле ялгыз-ялгыз кеше төркемнәренең көчлерәк җәмгыять булып берләшүләренә бик нык бәйләнгәнен күреп узган идек. Телдә сүзләр үз ирекләре белән генә тумыйлар. Аларның запасы кешеләрнең ихтыяҗларына карап була. Билгеле аерым индивидуумның гына ихтыяҗы

өчен түгел, бәлки кешеләр белән аңлашырга мохтаҗ булган – берәр коллектив әгъзасы булган кешенең ихтыяҗларына карап була. Бу коллектив ихтыяҗлары үскән саен, сүз составы һаман төрләнә бара, коллектив катлаулана барган саен, телнең төзелеше дә һаман катлаулана.

Телдәге аерым сүзләрне алып, аларга стадиаль (горизонталь) һәм полиантологик (вертикаль) сызыклар буенча анализ ясый торгач, академик Н. Я. Марр хәзерге сүзләрнең составы дүрт төр элементка һәм шуларның тезмәсенә кайтып калганын, бу дүрт элементның бөтен телләрдәге сүзләр өчен уртак булганын раслый. Бу дүрт элемент яфетидологиядә шартлы буларак «сал, бер, йон, чош» исемнәре белән, яки турыдан-туры «A, B, C, D» хәрефләре белән йөртеләләр. Сүз иҗаты үрчүенең баштагы процессында шушы дүрт элементның үзара катнашулары (скрещение) төп фактор санала. Ялгыз яшәүче кеше берүзе генә тел һәм культура тудыра алмый. Культура һәм тел аралашу ихтыяҗлары белән, гомуми интереслары бергә бәйләнгән кешеләрнең төркемләшүләре белән бергә туа. Менә шушы кешеләрнең төркемләшүләре белән бергә, югарыда күрсәтелгән, төбендә бөтен кешелек өчен уртак аваз комплексларыннан гыйбарәт булып та, соңыннан, кешеләр төркемләшә башлагач, һәр төземдә үзләренә тышкы аерымлык алып өлгергән әлеге дүрт төп элемент та үзара катнаша башлыйлар. Бу дүрт төп элемент үзләренең аерым интереслары белән яши торган һәрбер ялгыз-ялгыз төркемнәрдә фонетик яктан һәммәсе дә гел бертөрле генә булып формалашмаган, шулай ук һәр төркемдә һәм һәркайда, бер үк төшенчәне аңлату өчен бер үк элемент беркетелмәгән. Димәк, башта теләсә нинди мәгънәне аңлатуда ирекле булган бу дүрт элемент, хәзер инде аларга билгеле берәр мәгънә беркетелгән, һәм, шулай озак урынлашу-ныгу нәтиҗәсендә, төрле кеше төркемнәре арасында төрле мәгънә алганнар, төрле төшенчәләр белдерергә хезмәт итә башлаганнар. Кеше төркемнәре арасында катнашу башлангач, электә бер төрле булып та, соңыннан форма ягыннан аерылышкан бу дүрт элемент та үзара катнаша башлаганнар. Аларны үзара төрлечә кушу аркасында, сүз запасы һаман арта барган, яңа туган төшенчәләргә яңа сүз кирәк булган саен, алар белән файдаланган. Шушы юл белән, төп элементларны бергә кушып, сүзлек запасы бераз җыйналу нәтиҗәсендә, бер яктан бу катнашкан яңа катлаулы авазлар составына тагы икенче элементларны бергә кушу юлы буенча аваз телнең үсүе һаман дәвам иткән. Шул рәвешчә, башка ике төп элементтан гына, аннан соң берничә

элементтан катнашкан сүзләр ясала башлаганнар. Бергә кушылганга кадәр, бу социаль төркемнәрнең һәркайсына бу сүзләрдән (элементлардан) башта бары берсе генә билгеле була, бергә катнашканнан соң, аларның суммасы һәр ике төркемгә дә (һәр ике якка да) тигез аңлашылмалы бер сүз булып әверелгән. Мәсәлән, безнең татар телендә мәгъбүд мәгънәсендә «тәңре» дигән сүз бар. Бу сүзнең лозунгы күренеше «тангир» булып, ике төп элементтан кушылган: тан + гир (С+А). Бу ике элементтан берсе бер ыруның, икенчесе икенче ыруның терминнары булып, икесе дә һәр ике ыруда бер үк төшенчәне аңлатканнар. Шуннан, бу ике ыру бергә кушылганнан соң, бу ике элемент та бергә катнашып, һәр ике якка да аңлашмалы яңа бер термин килеп чыккан. Бу термин элек «күк» төшенчәсен биргән. «Күк» төшенчәсе үзе исә космик стадиядә өч төрле «күк» төшенчәсен алган: 1) күк (югары күк), 2) җир (түбәнге күк) һәм 3) диңгез. Шуннан бу сүз төрле ыруда төрле мәгънәдә урынлашып калган: төрекләрдә – тагри (күк), шорларда – тангри, теләветләрдә танара (күк), татарларда – таңгри (мәгъбүд) һәм дингез (диңгез).

Академик Н. Я. Маррның фикере буенча, сүзләрнең үзара катнашу процессы телнең башлангыч дәрәҗәсендә генә түгел, хәтта үзенең төзелеше ягыннан байтак ук үскән телләрдә дә дәвам иткән. Шулай ук, һәрбер катнашуның да үз үрчүендә, теләсә нинди мохиттә булсын, тагы үзенә күрә этаплары булган. Катнашу башта бөтенләй аерым ике сүзне куш (пар) куллану белән генә башланып, тора-бара бу сүзләр үзара бөтенләй физик чәбәләнеп бетү белән генә калмаган, хәтта бу ике төр элементтан җыйналган дүрт тартык авазның өчесе, күп вакытта бары берсе генә калу белән тәмамланган. Шуңа күрә үскән телләрдә ике тартыклы төпләрнең төп элементлардан берсенә туры килүе аларның бары тышкы яктан тартыклары саны буенча гына булуы мөмкин, әмма төбендә ул һәр икәвеннән берәр тармаклары төшеп калган элементлардан булып чыга. Гадәттә, тартыкларның төшеп калу процессы (процесс усечения) катнашкан сүзләрдә генә түгел, бер генә элементлы сүзләрдә дә күренә.

Телләрнең эволюциясендә катнашу процессының күп фактор булу идеясен бөтен ачыклыгы белән башлап кәшеф итүче академик Марр булды. Бу катнашу факторы телләрнең килеп чыгу проблемасын чишүдә дә аның тарафыннан нигез итеп танылды.

Сүзләрнең үрчүе процессында икенче фактор итеп ике яки икедән артык сүзләрне бергә кушып яңа сүзләр ясауны исәпләргә

кирәк. Сүзләрне бергә кушып яңа сүзләр ясау процессы төрле тел төркемнәрендә һәр ике якка да аңлашыла торган, бер үк мәгънәдә йөри торган мәгънәдәш сүзләрне бергә кушуда гына түгел, бәлки төрле-төрле мәгънәле булган ике яки икедән артык элементларны бергә кушып та яңа сүзләр ясалганы күзәтелә. Мондый сүзләрне катнашкан сүзләрдән аеру өчен, «кушма сүзләр» исеме белән икенче термин кулланыла. Тартык авазларның төшеп калулары кушма сүзләрдә дә очрый.

Сүз иҗаты инде яхшы ук киңәйгәннән соң, кеше, үзенең фикерен белдерү өчен, шул ук сүз запасыннан файдаланып, фразалар төзи ала башлаган, ләкин ул вакытта әле сүзләр исем белән фигыльгә аерылмаган. Бер үк сүз төшенчәне дә, эшне дә аңлатканлыктан, аның бу яки теге мәгънәсе фразадагы урыны белән билгеләнгән. Эш бары сүзләр комплексы белән генә тәгъбир ителгән, аларның берсе эшнең мәнбәгын (субъект), икенчесе эшнең максатын (объект), өченчесе эшнең рәвешен (хәбәр) белдергән. Озак заман үтү белән, фразадагы көчлерәк сүз ялгыз әйберне генә белдерү өчен, аның символы ролендә урынлашып калган (исемнәр), тора-бара субъект һәм объект символы ролендә, икенче төрле әйткәндә, эшкә актив һәм пассив катнашучылар ролендә шул ук төп элементлардан исемнәрнең урынбасарлары – алмашлыклар килеп чыкканнар. Алмашлыклар яхшы ук таралганнан соң гына, исемнәрдән фигыльләр аерыла башлаган. Ниһаять, телнең соңгы уңышларыннан булып шул ук исем, фигыль һәм алмашлыклардан функциональ сүзләр туганнар. Тора-бара бу функциональ сүзләр функциональ кисәкләргә (формаль морфемнарга) калып, аларны билгеле бер системда материаль морфемнарга кушып, яңа сүзләр ясала башлаган. Озак заманның үтүе белән, алар үзләренең төп мәгънәләрен җыйганнар. Хәзер алар, телдә бер материаль морфемга кушылып, яңа берәр оттенок бирү өчен, яки аннан икенче яңа сүз ясау өчен, яки җөмләдә бер сүзнең икенче бер сүзгә мөнәсәбәтен күрсәтү өчен генә кулланылалар. Хәзерге үскән телләрдә бу функциональ кисәкләрнең әһәмиятләре гаять зур, чөнки шулардан файдаланып, телдә яңа сүзләр һаман ясала торалар.

Югарырак хуҗалык периодларында тел коллективлары арасында бер-берсеннән сүз алышу да (заимствование) һаман көчәя бара. Чит сүзләр, гадәттә, бер коллективның үз социаль төзелеше тудырып өлгермәгән, ләкин икенче бер тел коллективның культура үсеше йогынтысы белән кергән төшенчә һәм әйберләрне аңлату өчен

алыналар, төшенчә һәм культура әйберләре белән бергә аларның сүзләре дә, билгеле, урынлашып калалар. Әйтик, безнең тел коллективыбызның социаль төзелеше телефон, телеграф, радио, трактор, совет һәм башка культура әйберләрен тудырып өлгерә алмаган, бу әйберләр безгә икенче тел коллективларының культура үсеше йогынтысы белән кергәннәр, әйберләре белән үк аларның сүзләре дә кереп урнашканнар.

Тел коллективлары арасында бер-берсеннән сүз алышуга яфетидология гадәттәгегә караганда күбрәк әһәмият бирә, коллективлар арасында сүзләр генә түгел, формаларның күчүен дә таный. Озак һәм гомуми аралашу (общение) вакытында телнең төзелеше, шуның белән бергә уй-фикер дә, шулай булгач, сүзлек кебек үк морфология дә бер тел коллективыннан икенчесенә күчәргә мөмкин. Бу мәсьәлә турында академик Н. Я. Марр әйтә: «Иске лингвистика мәктәбе, сүз алына, әмма форма алынмый, дип өйрәтте. Бу да шулай ук төшеп кала, чөнки форма да алына, шуның белән бергә, озак һәм гомуми (массовой) аралашу вакытында сөйләмнең төзелеше һәм аның белән уй, шулай булгач һәм сүзлек кебек үк морфология дә бер ыру җәмгыятеннән икенчесенә күчергә мөмкин. Телләрнең кардәшлеге дә, төрле ырулар арасында аваз теле белән аралашудан, идеологик-сүзлек өлешендә дә, шулай ук формаль-аваз һәм морфология өлешендә дә уртак сыйфатлар (черты) туу белән билгеләнә. Менә шуннан инде билгеле бер телнең яки билгеле бер тел төркеменең формаль типология яки морфологиясе белән сүзлек составының бер-берсеннән аерылуы – бер халыкның икенче бер халык белән аралашу рәвешенә бәйләнгән булу турында мәсьәлә кузгала да, шушының нәтиҗәсендә бер төрле халыкның үзенә бертөрле аралашуыннан сүзлеге түгел, тышкы ягы – морфологиясе алмашынган, әмма икенчеләрендә бу алмашыну бары сүзлектә генә күренгән, ягни бер үк тел тышкы типологиясе ягыннан бер тел төркеменә, әмма сүзлек ягыннан бөтенләй икенче бер тел төркеменә кардәш булырга мөмкин. Телләргә классификация ясалганда, үзара мөнәсәбәтнең бу ягын да исәпкә алырга кирәк», ди.

Телнең үсүенә йогынты ясый торган фактлар төрле һәм күпсанлы, һәр-хәлдә, югарыда саналганнар белән генә чикләнми. Мәсәлән, югары һәм соңгы хуҗалыкларда тел иҗатында аерым вакыйгаларның, аерым революция җитәкчеләренең, әдип һәм шагыйрьләрнең колоссаль рольләрен дә исәпкә алырга кирәк.

Аваз телләре яралганнан соң, аларның чын-чынлап формалашуларында, үсүләрендә, киңәюләрендә без менә шушы факторларны күрәбез:

а) ахрылары *logiə* морфемына беткән сүзләрдә:

| | | |
|---|---|---|
| *Социалистический* | *социология* | *sotsialogik* |
| *Психологический* | *психология* | *psixalogik* |
| *Идеологический* | *идеология* | *idialogik* |
| *Морфологический* | *морфология* | *marfologik* |

ә) ахрылары *ka* белән беткән сүзләрдән:

| | | |
|---|---|---|
| *Технический* | *техника* | *tixnik* |
| *Практический* | *практик* | *praktik* |
| *Грамматика* | *грамматический* | *gramatika* |
| *Методика* | *методический* | *mitodik* |

б) ахрылары *grafiə* белән беткән сүзләрдән:

| | | |
|---|---|---|
| *Орфография* | *орфографический* | *orfagrafik* |
| *Этнография* | *этнографический* | *itnografik* |
| *Топография* | *топографический* | *topografik* |
| *Биография* | *биографический* | *biografik* |
| *Педагогия* | *педагогический* | *pidagogik* |
| *Экономия* | *экономический* | *ikanomik* |
| *Магия* | *магический* | *magik* |
| *Теория* | *теоретический* | *tioritik* |

в) ахрылары *ист* морфемына беткән *kommunis, sotsialis, impirialis, idialis* кебек терминнардан да рус телендә шул ук *ический*, француз телендә шул ук *ique=ik* морфемнары ялганып сыйфат исемнәре ясалалар. Аналогия буенча мондый терминнардан татар телендә дә *ik* морфемы ялганып,

| | | |
|---|---|---|
| *Коммунист* | *коммунистический* | *kommunistik* |
| *Социалист* | *социалистический* | *sotsialistik* |
| *Империалист* | *империалистический* | *impirialistik* |
| *Идеалист* | *идеалистический* | *idialistik* |

рәвешләрендә сыйфат исемнәре ясалырга тиеш иде, ләкин хәзергә кадәр татар матбугатында бу формадагы сыйфатлар күренгәне юк әле. Мондый терминнардан сыйфатлык мәгънәсен аңлату өчен, гадәттә, аларны иялек килешендә куеп ясалган тезмәләр кулланыла. Мәсәлән,

*Kommunislar partiəse = Коммунистическая партия*

2) Рус телендәге халыкара терминнардан *аль+н+ый=альный* морфемнары ялганып ясалган сыйфат исемнәре урынына татар әдәби телендә шул ук француз теле сыйфатлык формасы булган «*alь*» морфема ялганып ясалган сыйфат исемнәре туры киләләр. Димәк, боларда да ахырлардагы рус сыйфатлык формасы ташланып, татар телендә француз сыйфатлык формасы гына кала:

| | | |
|---|---|---|
| *Индустрия* | *индустриальный* | *industrial'* |
| *Дифференция* | *дифференциальный* | *diffirinsial'* |
| *Форма* | *формальный* | *formal'* |
| *Театр* | *театральный* | *teatral'* |
| *Документ* | *документальный* | *dokumintal'* |
| *Музыка* | *музыкальный* | *muzьjkal'* |

3) Рус телендә халыкара терминнардан «*ивный=ив+н+ый*» морфемнары ялганып ясалган сыйфат исемнәре урынына татар телендә шул ук француз теле сыйфатлык формасы булган «*if*» морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре туры киләләр. Боларда да ахырларындагы рус сыйфатлык формасы ташлана:

| | | |
|---|---|---|
| *Об'ект* | *об'ективный* | *ob'ektif* |
| *Суб'ект* | *суб'ективный* | *sub'ektif* |
| *Прогресс* | *прогрессивный* | *progressif* |

4) Рус телендә халыкара терминнардан ахырларына *ный* морфемнары ялганып ясала торган сыйфат исемнәреннән татар әдәби телендә ахырларындагы рус сыйфатлык формасы ташланып, шул хәлләрендә генә кулланыла:

| | |
|---|---|
| *Конкретный* | *konkret* |
| *Стандартный* | *standart* |

Соңгы вакытларда татар әдәби телендә күренгәли башлаган *rivolytsion, agitatsion, traditsion, artikylətsion* формаларын да шушы категориядән исәпләргә мөмкин. Ләкин бу форманың Европа тел коллективларында сыйфат булып йөрүе юк икән, шуңа күрә мондый формаларны татар телендәге *kormьt eş, jfək jaulьq* кебек сыйфат исемнәре урынына йөри торган зат исемнәре белән дөресләргә туры килә. Шуның белән бергә, бу фонлар урынына *revolytsiəcel, revolytsiəcən, revolytsiəce* рәвешләрендә татар теленең үз сыйфатлык морфемын ялган кулланучылар да юк түгел.

Татар әдәби теленә яңа кереп һәм урынлашып бара торган яңа сыйфатлык формалары белән беррәттән, гарәп теленнән мирас

булып калган һәм хәзерге вакытта да әдәби телдә кулланыла торган түбәндәге ике төрле сыйфатлык формаларын да өстәргә кирәк:

1) ахырлары тартык авазга беткән гарәп сүзләренең ахырларына «i» морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре:

*Sьjnьf – sьjnfi, gilmi, fənni, ədəbi, tabiꞑi, tarixi, dini, xoquqi.*

2) Ахрылары сузык авазга беткән гарән сүзләренең ахрыларына *ьj* морфемы ялганып ясалган сыйфат исемнәре:

*Dөnja – dөnjavi, məꞑnəyi, aꞑzaui, tərbiəyi, ꞑailəyi.*

Чит тел элементлары һәр яктан татар теленең үз морфологик төзелешенә буйсыналар. Алардан *kristallaşu, ratsianallaştьru, standartlaştrlꞑan, konkretlap, ditalləp*... кебек төрле форма фигыльләр, шулай ук *xaraktrle, kvalifikatsiəle, taktikəle, taкtikəsez, partiəle, partiəsez, kul'turlь, kul'tursьz, sovitcel*... кебек сыйфат исемнәре дә ясала алалар.

Хуҗалыклары күтәренке тел коллективлары арасында бер-берсеннән сүз алышу – табигый тел законы ул. Чөнки хәзерге тел коллективлары хуҗалык ягыннан үзара бик нык бәйләнешкәннәр. Иң элек җирле хуҗалык авыл белән шәһәр арасын бәйли, шәһәр авылдан авыл хуҗалыгы продуктларын, авыл шәһәрдән эшләп чыгарылган промышленность товарларын ала, ләкин авыл белән шәһәр арасындагы бу бәйләнеш җирле хуҗалык күләмендә генә түгел, бәлки бөтен дәүләт күләмендә дә бара. Татарстанның авыл хуҗалыгы продуктысы Кубань өлкәсенең бодае, үзәк фабрика һәм завод районы ситсы һәм бумазее. Донбассның таш күмере һәм металлы табылган яки эшләнеп чыгарылган районнарында гына кулланмыйлар. Аерым районнар арасында шулай хезмәтне бүлешү дә бар. Шуның белән бергә, Мәскәү туку фабрикалары үзләренә кирәкле мамыкны бер Төрекстаннан гына түгел, кирәк булса Мисырдан да алалар; Союз уру машиналары көлтәләрне Америка шпагатлары белән бәйлиләр; Кытай тегүчеләре шулай Америка тегү машиналары белән тегәләр; Европа халкы Кытай һәм Һиндстан чәйләрен эчәләр; Европа азык фабрикалары Җир шарының икенче кисәкләреннән китерелгән какао, кофе һәм башка әчкелтем-төчкелтем продуктларны эшкә кертәләр.

Тел коллективлары арасындагы хуҗалык һәм культура ягыннан булган бу бәйләнеш турыдан-туры экономик базиска корылган өскорманың органик продуктыннан гыйбарәт булган аларның телләренә дә, әлбәттә, йогынты ясый, әдәби телләр арасында тел элементлары белән туктаусыз алыш-биреш бара. Аерым сүзләр һәм

терминнар гына түгел, хәтта бөтен-бөтен тәгъбирләр, алымнар да бер тел коллективыннан икенчесенә күчә. Мәсәлән, түбәндәге тәгъбирләрне чагыштырып карагыз:

(французча) *okvires organise et conscient* = (русча) *организованный и сознательный рабочий* = (татарча) *ojşmalь həm aņпь eşce;* (немецча) *im grossen und ganzen* = (русча) *в общем и целом;* (немецча) *ganz und voll* = (русча) *целиком и полностью* = (татарча) *tulьsь həm bөtenese blən;* (русча) *объявить вне закона* = (татарча) *zakonnan tьş dip iqlan qlu;* (русча) *порядок дня* = (татарча) *kөn tərtibe;* (русча) *план работы* = (татарча) *eş planь.*

Хәтта хәзерге хуҗалыклары күтәренке тел коллективлары арасында саф милли әдәби тел табу мөмкин дә түгел. Татар җәмгыяте дә хуҗалык һәм культура ягыннан икенче тел коллективларыннан туктаусыз файдаланып торган кебек, үзенә классик әдәби тел төзүдә дә, әлбәттә, пич эчендә көлдән борчак чүпләп, «милли чикләнүчелек» белән кала алмый. Ул икенче тел коллективларының тел уңышлары белән дә файдаланырга мәҗбүр. Шуның белән бергә, һәр тел төзелешенең үзенә караган аерым грамматик системы бар, ул үзенең шушы системы белән генә үз коллективының әгъзалары арасында социаль тамга булып яши ала. Бер телнең табигый системы никадәр чуатылса, аның социаль объективлыгы да шул кадәр югала, бер телнең төзелеше ни кадәр авырайтылса, ул телне киң массаның үзләштерүе дә шул кадәр читенләшә. Шуңа күрә әдәби телдә чит элементлар белән файдалану да һәр тел коллективында закон урынында йөри торган «норма» бар. Бу норманы һәр тел коллективының махсус гыйльми йортлары һәрвакытта күзәтеп торалар. Ул норманы түбәндәгечә күз алдына китерергә мөмкин:

1) берәр төшенчә яки әйберне тулы аңлату өчен, үз телеңдә сүз бар икән, аның урынына икенче тел коллективларыннан мотлак сүз алмау;

2) яңа төшенчә яки әйберне аңлату өчен, яңа сүз кирәк чакта, аны мөмкин кадәр үз тел байлыгың белән файдалану юлы белән үз телең җирлегендә ясау, шуның белән бергә, халыкара оборотка кергән сүзләр урынына яңа сүз ясау белән артык көчәнмәү (мәсәлән, *Sovit, ajroplan, protsint, marfalogiə* кебек терминнар урынына *kiņəşmə, ocqьc, ysem, tөrlek* кебек сүзләр ясап азаплану кебек);

3) чит тел элементлары белән файдаланганда, телнең грамматик системына, бигрәк тә синтаксис төзелешенә зарар китермәү

(мәсәлән, элек *xariql qadə, mədrəsəi qaliə* яки хәзерге вакытта кайберәүләрнең *narodnьj obrazavaniə blən zavidovajt itə* дип сөйләү һәм язулары кебек).

Чит тел элементлары белән файдаланганда, һәр әдәби телдә менә бу «норма» бик нык сакланырга тиеш: юк исә әдәби телнең социаль объективлыгы югалып, якын киләчәктә аның киң массадан ераклашуы бик табигый. Тел коллективлары арасында мондый факторлар күп. Урта йөзләрдә серб һәм болгар теленә хокукый терминология Византиядән, политик терминология төрекләрдән кереп урнашып калган булган. Поляклар һәм чехлар немецлар власте астында яшәгәндә, аларның телләренә немец сүзләре бик күп кергән булган. Ләкин үзләренә әдәби тел төзи башлау белән, бу халыкларның һәммәсе дә үз телләрен чит элементлардан тазартырга мәҗбүр булдылар. XVIII йөзнең азакларында Карамзин һәм көнбатышчы яшь язучылар рус әдәби телен нормадан тыш чит тел элементлары белән күмә башлагач, Шишков һәм аның фикердәшләре тарафыннан махсус көрәш алып барылган.

Төрек диалектларының күбесенә гарәп һәм фарсы элементлары кереп тулганы һәркайсыбызның күзе алдында. Хәтта Анатолия төрек әдәби телен яхшылап белү өчен, төрекнең үз грамматикасы белән бергә гарәп һәм фарсы грамматикаларын да өйрәнергә кирәк. Һәр диалектта бу элементлардан әдәби телне тазарту хәзергә кадәр дәвам итә.

Чит сүзләрне кирәксез һәм урынсыз куллану мәсьәләсенә Ленин иптәш тә игътибар иткән. Бер җыелышта тыңлап утырганда, үзенең күршесенә карандаш белән түбәндәгечә язып биргән:

«Без рус телен бозабыз. Чит сүзләрне кирәксезгә кулланабыз. Аларны ялгыш кулланабыз. “Недочеты” яки “недостатки” яки “пробелы» дип әйтергә мөмкин булган чакта, “диффект» дип әйтү нәрсәгә кирәк. Билгеле, күптән түгел генә укырга, бигрәк тә гәзитләр укырга өйрәнгән кеше аларны чын дәрт белән укырга тотына да ул ирексез гәзит оборотларын үзләштерә, гәзит теле дә бит бездә шулай ук бозыла башлады. Әгәр күптән түгел генә укырга өйрәнгән кеше, яңа өйрәнчек булганга, чит сүзләр куллануы өчен гафу ителсә дә, әмма әдәбиятчыларны моның өчен гафу итү мөмкин түгел. Безгә чит сүзләрне кирәксез куллануга каршы сугыш игълан кылырга вакыт түгелме?»

Менә бу тәҗрибәләр татарның хәзерге әдәби телен төзү чорында да чит тел элементлары белән файдалануда бик сак булырга һәм югарыдагы норма бик нык сакланырга тиешлекне ачык күрсәтәләр.

Татар әдәби телендә чит тел элементларын алу һәм куллануда хәзергә яхшы ук тотнаксызлык һәм принципсызлык сизелә әле. Бер яктан. гарәп сүзләре урынына халыкара терминнар алына, икенче яктан, алар белән параллель шул ук гарәп сүзләре дә кулланыла. Бер үк гәзиттә, хәтта бер үк кешенең бер үк мәкаләсендә *сәясәт – политика, икътисад – экономика, мәдәният – культура, гамәл – практика, тәнкыйть – критика, мантыйк – логика, матбага – типография, мөхәррир – редактор, гамил – фактор, шәкел – форма, гонсер – элемент, җәдвәл – таблица, маузуг – тема, шигар – лозунг...* кебек параллель кулланыла торган терминнарны һәрвакытта очратырга туры килә. Шулай ук *гамәли – практик, сәяси – политик, икътисади – экономик, мантыйкый – логик* кебек сыйфат исемнәрендә дә бу параллелизм.

Иске мирастан файдалануда да күп кенә җитешсезлек һәм анархия хөкем сөрә. Яңа тормыш шәраитендә туган яңа төшенчә һәм әйберләрне аңлату өчен, тормыш үзгәрү белән үзенең элекке мәгънәсен киметкән яки функциясен югалткан халык сүзләреннән аңлы рәвештә әдәби телдә файдалану бөтенләй юк. Киндер һәм сөлге туку, чыпта һәм кап сугу станнарын һәм аларның өлешләрен, тегермән, яргыч, киле кебек бер катлаулы әйберләрнең төзелешләрен, аерым оста һәм кустарьларның коралларын, кыскасы, иске кустарьчылык терминнарын өйрәнеп, алардан хәзерге индустрия һәм эшләп чыгаручылык өчен кирәкле булган байтак кына терминнар табарга мөмкин булыр иде. Тел эшчеләре арасында, гомумән, халык телен өйрәнү бик түбән тора. *Маныгу – увлекаться, манту – развитие, комачаулык, токкарлык – маныйг – задержка, ялыныч – ихтыяҗ, култамга – подписка, нәгыз – сущность, йомышчы – посыльный, тылмач...* кебек халыкара конкретлашкан төшенчәләр өчен халык тел хәзинәсеннән бик күп сүзләр алырга ярар иде. *Кору, төзү, ясау, эшләү, әмәлләү, әтмәлләү; манту, үсү, киңәю, җәелү, таралу, үрчү...* кебек бер-берсенә якын сүзләрнең мәгънәләре арасында әдәби телдә гыйльми дифференциация ясалырга тиеш.

Аерым язучылар, түгәрәкләр, коллективлар, яки терминология комиссияләре тарафыннан киң массаның үз теле нигезендә бик уңышлы ясалып, оборотка җибәрелгән яңа терминнарны әдәби телдә бертөрле куллану, шушы юл белән аларның социаль объективлыгын киң масса арасында *утырыш – заседание, җыелыш – собрание, кулланма – руководство, җитәкче – вожатый, белешмә – справка,*

*таныклык – удостоверение, ышанычлык – доверенность, йогынты – тәэсир, оешма – организация, үзәк – центр, өлкә – область, төбәк – район, хуҗалык – хозяйство*... кебек параллель йөри торган сүзләр чиксез күп. Чит тел элементлары белән файдаланудагы мондый тотнаксызлык һәм принципсызлыкның болай озакка сузылуы әдәби тел турында яшь көчләр арасында пессимистлык таралуга сәбәп булачак һәм аның бер эзгә төшеп, якын киләчәктә классик бер тел булып ясалуын шөбһәсез кичектерәчәк.

Югарыда күрелгәнчә, пролетариат революциясеннән соң, бер яктан, яңа конкрет культура үсеше шәраитендә татар әдәби теленә әдәби, гыйльми, фәлсәфи, экономик, техник һәм административ халыкара яңа терминнар агыла торса, икенче яктан, аннан феодализм чорыннан мирас булып калган һәм хәзерге культура үсеше өчен кирәге булмаган гарәп һәм фарсы сүзләре ташлана баралар. Әдәби телләрнең тарихларына караганда, бу процесс яңа әдәби тел төзү периодларында һәр тел коллективы башыннан бер кат кичкән. Урта йөздә феодализм төзелеше чорында Европа тел коллективлары өстендә культура теле ул вакытта официаль чиркәү-дин теле булган латин теле санала иде. Һәр тел коллективының үз теле түбән сыйныф теле саналып, аңа үсәргә, кинәергә ирек бирелми иде. Урта йөзнең икенче яртысында, шәһәр экономикасы баш күтәрү белән бергә, Европада яңа сыйныф – буржуазия сыйныфы туды. Шуннан соң буржуа сыйныфының культура йогынтысы астында шәһәр укымышлылары теле нигезендә Европа тел коллективларының үз әдәби телләре эшләнә башлады. Латин теле һәр халыкның үз теленә юл сабарга мәҗбүр булды. XVIII йөзгә кадәр рус теле коллективы өстендә шул ук чиркәү-иске славян теле хөкем сөрә иде. XVIII йөз башларында рус буржуа сыйныфы баш күтәрү белән, аларда да чиркәү теленә каршы көрәш башланды. Татар җәмгыятендә бу процесс XIX йөзнең соңгы яртысыннан башланып хәзергә кадәр сузылды. Революциядән соң әдәби тел дин белән һичбер мөнәсәбәте булмаган пролетариат кулына күчү белән, татар әдәби телендә инде гарәп теленә кискен балта чабылды. Шуның белән бергә, һәр тел коллективының әдәби телендә бу иске мирасның азмы-күпме йогынтысы калды. Көнбатыш Европа әдәби телләрендә латин һәм грек телләренең, рус әдәби телендә исә чиркәү-иске славян теленең элементлары бар. Шулай ук төрек әдәби телләрендә дә гарәп теле элементлары, һәрхәлдә, бераз калмый булмас, чөнки гарәп теле төрек халыклары арасына бер яктан дин,

икенче яктан азмы-күпме культура йогынтысы белән кереп, ничә йөз еллар буенча үзенең тамырын тирән җибәргән инде. Шулай булса да кайбер татар тел эшчеләре арасында әдәби телне гарәп элементларыннан тазарту мәсьәләсендә бераз «балалык авыруы» юк түгел. Гарәп сүзеннән бары гарәпнеке булганлыгы өчен генә качу тенденциясе яхшы ук бар. Әлеге сүзнең киң масса арасында күпме үзләшүе, яки әдәби телдә ни дәрәҗәдә урынлашуы артык тикшерелми. Гарәп сүзе булдымы – аны икенче тел коллективы сүзе белән, бигрәк тә рус сүзе белән алмаштыру артыграк санала. Татарның үз теле нигезендә сүз табылганда, яки халыкара оборотка кергән сүз булганда, гарәп сүзләрен алар белән алмаштыру турында ике төрле караш булмас. Ләкин гарәп элементлары арасында *мәктәп, китап, каләм, дәфтәр, сәгать, сыйфат, гыйлем, фикер, халык, хәбәр, хезмәт, кәеф...* кебек бөтен татар хезмәт массасы өчен үзләшеп беткәннәре, *мәгариф, мәкалә, әсәр, тәрҗемә, мөндәриҗә, җәмгыять, сыйныф, тарих, гаилә* кебек әдәби телдә урнашып калганнары, шулай ук *хокук, максат, мәсьәлә, җавап, тәртип, мөнәсәбәт, хосусият, әһәмият...* кебек, болар урынына халыкара сүз табу, яки татарның үз теле нигезендә яңа сүз ясау хәзергә бераз уңгайсызрак булганнары бар. Ничек булсалар да, бу сүзләр иске әдәбияттан мирас булып калганнар, хәзергә кадәр билгеле төшенчәне аңлату өчен тамгалык хезмәтен үтәп килгәннәр. Димәк, мондый сүзләр татарның үз телендә сүзләре булмаган кайбер төшенчәләрне аңлату өчен, әдәби телдә эшкә ярыйлар. Шулай булгач, аларга гарәп элементлары булганнары өчен генә нәфрәт белән карарга, аларны тагы рус сүзләре белән алмаштырып *мәктәп, мәкалә, кәеф, мәсьәлә* урынына *школа, статья, настроение, вопрос* сүзләрен кулланырга хаҗәт юк иде. Бу бит әдәби телне тазарту киң массага якынайту, интернациональ телгә тарту түгел, бары Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ындагы иске феодализм романындагы даменла Фәриделгасри тибы телен, прокурор Гайфуллин тибы теле белән алмаштыруга гына омтылыш була.

Шуңа күрә, бер яктан, әдәби телне гарәп элементларыннан тазарту, икенче яктан анда рус теле элементлары белән ни дәрәҗәгә кадәр файдалану мәсьәләләренә дә анык принцип билгеләргә кирәк булыр.

## X

Бер сыйныфның әдәби теле баюы, классик бер тел булып, чын-чынлап формалашуы өчен, аңа шул сыйныфның гыйльми

җитәкчеләре, аерым талантлары, бигрәк тә әдип-шагыйрьләре һәм тәрҗемәчеләре үзләренең гадәттән тыш зур көчләрен сала килгәннәр. Италиянең көчле шагыйре булган Данте (1265–1321), италия әдәби теленә башлап нигез салу белән бергә, үзеннән соң кечкенә һәм зур әдәби (поэтик) һәм политик эшчеләрдән тыш Петрарка һәм Бокаччо (1313–1375) кебек гениаль көчләр калдырган. Инглиз буржуа әдәби телен тудыручы Шекспир бөтен дөнья күләмендә үлмәс талантлардан санала. Лютер һәм аның Библияне немецчага тәрҗемә итүе белән немец әдәби теленә нигез ташы салынып, немец телендә гаять тирән әдәби, гыйльми, фәлсәфи әсәрләр туугa туфрак хәзерләгән. Француз буржуазиясенең мәгънәви җитәкчеләре булган Рабле, Маргарита, Мантон кебек талантлар француз әдәби теленә нигез салучылар булганнар. Рус тел коллективының хәзерге көчле әдәби теле мәйданга килүе өчен Карамзин, Жуковский, Грибоедов, Пушкин, Гоголь, Тургенев, Толстой һәм Достоевский... кебек рус әдәбият даһилары азмы көч һәм хезмәт салганнардыр.

Үз чорлары, үз сыйныфының мохите хәзерләгән бу талантлар, бу даһилар үзләренең иконология, ивфония һәм композициягә искиткеч осталыклары белән билгеле бер чорның, билгеле бер сыйныфның чын-чынлап экономик базасына корылган идеологик өскорманы гәүдәләндереп кенә калдырмаганнар, бәлки шул идеологик өскорманы тулы һәм бөтен килеш гәүдәләндерерлек шул сыйныфның көчле әдәби телен дә тудырганнар. Бу көчле тел байлыгы аларга билгеле үзеннән-үзе күктән төшмәгән, бәлки алар мохитләренең этәрүе буенча үз сыйныфларының әдәби теленә хезмәт итүне үзләренә профессия итеп сайлаганнар, тормыш мәктәбендә үз телләренең бөтен законнарын, бөтен нечкәлекләрен энәсеннән җебенә кадәр җентекләп өйрәнгәннәр.

Пушкин рус телен үзен караучы Арина Родионовна дигән марҗадан өйрәнеп кенә рус әдәбиятының классик шагыйре булмаган, әлбәттә. Иң элек аны «Пушкин» итеп үзенең чоры һәм үз сыйныфының мохите хәзерләгән, аңа шагыйрьлек аңы биргән. Ул шул хәзерлек, шул аң белән шагыйрьлек эшен үзенә профессия итеп алган, аннан соң үз сыйныфының теләген, зәүкын, үз тел коллективының телен бөтен нечкәлекләре белән өйрәнергә керешкән. Рус халык әдәбиятын тикшергән, үз заманасында русның җанлы теле сүзлеген төзүче Даль белән һәрвакыт фикер алышкан, рус әдәби теле проблемаларында актив катнашкан, иске рус елъязмаларын

(летопись) җентекләп өйрәнгән, хәтта күмәч сатучы марҗаларның телләренә, сөйләүләренә колак салган. Ул бу эшләрнең һәммәсен дә аңлап һәм кирәксенеп эшләгән. Пушкин, үзенең иҗат көче пешеп өлгергән чорында «Борис Годунов» дигән романы нинди йогынты астында язылуы уңае белән, «елъязмалардан шул вакытлардагы телне һәм уйлар рәвешләрен табарга тырыштым» ди. Пушкин үзенең төрле истәлек язмаларында ялган әдәби тел мәсьәләләренә туктала һәм халык теле элементларына гадәттән тыш зур әһәмият бирә. Ул үзенең бер истәлегендә «гади халыкның сөйләү теле гаять тирән тикшерелергә хаклы, Альфери (Италия драматургы) Италия телен Флоренция базарында өйрәнгән. Кайчагында Мәскәү марҗаларының телләренә колак салу да начар эш түгел: алар искиткеч саф һәм дөрес тел белән сөйлиләр» ди.

Пушкинның гадәттән тыш әдәби иҗат көченә үзен караучы Арина Родионовна, халык әкиятләре, әллә кайчангы елъязмалар, күмәчче марҗалар кирәк түгел иде. Ул алардан үз заманындагы идеологик өскорманы тулы һәм бөтен килеш бирә алу өчен кирәк булган әдәби телгә чимал эзләгән, ул алардан рус халык теленең сүзлек запасын, саф һәм тирән тәгъбирләрен, матур-матур алымнарын тапкан. Шул чималдан гаять матур һәм көчле рус теле эшләнеп чыккан.

Бер сыйныфның әдәби теле эшләнүенә һәм урынлашуына ул сыйныфның иркендә булган югары уку йортлары, урта һәм башлангыч мәктәпләре, шулай ук суд һәм администрация органнары да аз роль уйнамыйлар. Академияләр, университетлар, институтлар гыйлем тел һәм гыйльми терминология эшләнеп чыгуына хезмәт итәләр, әдәби телнең дөрес һәм туры юл белән үсүендә җитәкчелек итәләр, нормадан читкә тайпылу моментларында юл күрсәтәләр; урта һәм башлангыч мәктәпләр әдәби телнең киң масса арасына таралуына; суд һәм администрация органнары әдәби телнең бөтен дәүләт күләмендә җәелүенә сәбәп булалар.

Пролетариат сыйныфының да гыйльми җитәкчеләре, аерым талантлары, бигрәк тә әдип һәм шагыйрьләре, эшхәп һәм авылхәпләре, тәрҗемәчеләре, гомумән укымышлылары татар әдәби теленең үсүенә, үз чорының идеологик өскормасын тулы һәм бөтен килеш гәүдәләндерә алырлык көчле классик бер тел булып, чын-чынлап формалашуына хәзергә кадәр күпме көч һәм хезмәт салулары һәм киләчәктә күпме сала алачаклары турында үзләренә үзләре һәм пролетариат сыйныфы алдында конкрет хисап бирергә тиешләр.

Әдип һәм шагыйрьләр борынгы елъязмалардан, фольклор материалларыннан, төннәр буе тәмләп әкият сөйләүче карт һәм карчыклардан, көннәр буе эштә кайнап арганнан соң ял итү, күңел ачу өчен аулак өйләргә, клубларга җыелган авыл егетләре белән авыл кызларының, үзләренең яшьлекләренә чыдаша алмыйча, берсеннән-берсе уздырып үзара әйтешүләреннән, гомумән, татар хезмәт массасының бетмәс-төкәнмәс җанлы тел хәзинәсеннән хәзерге катлаулы хуҗалык төзелешендә туган катлаулы идеологик өскорманы конкрет гәүдәләндерә алырлык гаять бай чимал таба алачаклар.

Буржуа язучылары бөтендөнья хезмәт массасы җилкәсендә гомерләре буе «гыйш-гыйшрәт»тә яшәгән аксөяк бикәләренең яшерен «гыйшык-мәхәббәт»ләрен үзләренең төче каләмнәре белән әдәби телдә төрле сурәтләрдә гәүдәләндергән булсалар, бөтен гомерләрен фабрика һәм заводларда, авылның киң кыр һәм урманнарында эш һәм хезмәт белән коллектив тормыш эчендә кайнаган эшхәп һәм авылхәпләр «эш һәм хезмәт»нең, «коллектив тормыш»ның бөтен матурлыкларын, био-психологик нечкәлекләрен үз тормышларында каннарына сеңгән сүзлек запаслары, саф һәм тирән тәгъбирләре, матур-матур алымнары белән бирә алачаклар.

Татарстанның югары уку йортларының байтагында ачылган тел-әдәбият кафедралары, тиз көннән ачылачак гыйльми тикшеренү институты татар әдәби телендә гыйльми тел, гыйльми терминология эшләнүгә, әдәби телнең дөрес һәм туры юл белән үсүенә, гомумән татар әдәби теле проблемаларына актив катнашырга тиешләр. Комсомоллар, урта һәм башлану мәктәпләр, татар әдәби теленең киң масса арасына таралуы өчен, суд һәм администрация органнары бөтен дәүләт күләмендә җәелүе өчен үзләренең көчләрен кызганмаска тиешләр.

* * *

Югарыдагы озын анализның йомры йомгагы шул: пролетариат революциясеннән соң тарихта беренче мәртәбә Советлар системы урнашу, коммунистлар партиясе юлы буенча милли политиканы тормышка ашыру нәтиҗәсендә Татарстан җөмһүрияте мәйданга килү, бөтен Союз илендәге җөмһүриятләр белән янәшә Татарстан җөмһүриятендә дә промышленностьның искиткеч алга китүе, елдан-ел җирле пролетариат кадрының үсә баруы, бөтен Татарстан күләмендә авыл хуҗалыгын социализм нигезендә – коллектив хуҗалыклар нигезендә өр-яңадан кору һәм гомумән бөтен хезмәт массасының культура үсеше темпын җитезләтү фактлары белән хәзер татар хезмәт массасы-

ның экономикаларында һәм бөтен тормыш төзелешләрендә гадәттән тыш үзгәреш ясалды. Шушы үзгәреш белән бергә чын-чынлап экономик базиска корылган идеологик өскорманың органик продуктыннан гыйбарәт булган татар әдәби теленең үсүенә төпле һәм ныклы нигез салынды... Моның өстенә аппаратны төп халыклаштыру, шулай ук татар телен тулы хокуклы дәүләт теле итеп тану белән бергә, аны күз алдында тормышка ашыру фактлары белән инде татар әдәби теле үсүе юлындагы киртәләр алынып ташланды. Димәк, хәзер татар әдәби теленең үсүе өчен таза һәм киң җирлек бар.

Әдәби тел – сыйнфый бер тел. Татар әдәби теле алпавыт һәм буржуа кулында чагында бертөрлеләнеп, бер эзгә төшеп, классик бер тел булып формалаша алмады. Пролетариат революциясеннән соң ул татар пролетариаты кулына күчү белән, феодалчылык һәм милләтчелек сазлыгыннан чыгып, интернационализмга таба юнәлеш алып, зур адымнар белән һаман алга бара. Үзенең ун гына еллык гомере эчендә дә аның зур уңышлары бар. Шуның белән бергә, югарыда күрелгәнчә, аның хәзерге барышында кайбер мәсьәләләрдә тотнаксызлык һәм принципсызлык кебек кайбер кимчелекләре дә юк түгел. Бу кимчелекләрнең озакка сузылуы татар әдәби теленең социаль объективлыгын киметә, татар хезмәт массасының аны үзләштерүен читенләштерә, якын киләчәктә бертөрлеләнеп, бер эзгә төшеп, классик бер тел булып формалашуын кичектерә, шуңа күрә татар пролетариатының гыйльми һәм мәгънәви җитәкчеләре әдәби телдәге бу кимчелекләрне оешмалы һәм аңлы рәвештә вакытында бетерү чараларын күрергә тиешләр.

## TÜRKISCH WÖRTER IM DEUTSCHEN[1]

Wie allgemein bekannt, gibt eseine grosse Anzahl von morgenländischen Wörtern im Deutschen. Diese Wörter, die unser Volk in unsere Sprache aufgenommen hat, sind meist durch mancherlei andere Sprachen durchgegangen,ehe sie zu uns kamen. Auf verschiedenen Wegen, zu ganz verschiedenen Zeiten sind sie nach Europa und damit auch nach Deutschland gekommen.

---

[1] *Badigy Kh.* Türkisch Wörter im Deutsche. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 19 нчы фонд, 2 нче тасв., 47 нче бер. Мәкалә автор редакциясендә бирелә.

Türkische Wörter im Deutschen

Wie allgemein bekannt, gibt es eine grosse Anzahl von morg ländischen Wörtern im Deutschen. Diese Wörter, die unser Volk : unsere Sprache aufgenommen hat, sind meist durch mancherlei ar dere Sprachen durchgegangen, ehe sie zu uns kamen. Auf ver - schiedenen Wegen, zu ganz verschiedenen Zeiten sind sie nach Europa und damit auch nach Deutschland gekommen.

Die ältesten dieser Wörter sind solche, die von den Phönizi und Aegyptern oder von den kleinasiatischen Völkerschaften zu den Griechen gebracht und von denen an die Römer weitergegeber wurden, dann wurden sie in die romanischen und germanischen Spr chen aufgenommen. Schon vor der Einführung des Christentums be stand ein Verkehrsweg von dem Orient nach dem germanischen Nor den, der über Südrussland führte. Dieser Weg blieb dann auch we ter bestehen, als das Christentum sich ausbreitete. Im Mittela ter wurden die arabischen Wörter von Spaniern, Italienern und Franzosen aufgenommen und an die Deutschen weitergegeben. Diese Wörter kamen aus Spanien, Nordafrika, Syrien und Palästina. Sie s wohl von den orientalischen Wörtern im Deutschen am zahlreichs aber sie enthalten neben echt arabischen Wörtern auch griechis lateinische, persische, indische und wahrscheinlich einige aus n andern Sprachen, asiatischen und afrikanischen.

In der Neuzeit kamen, seitdem die Türkei eine Grossmacht gewo den war, türkische Wörter nach Deutschland, meist auf dem Wege ül Ungarn oder die slawischen Länder, und unter diesen waren wiede manche nicht echt türkisch, sondern von arabischer, persischer ur indischer Herkunft. Immer mehr wurde auch die morgenländische Li teratur in Übersetzungen bekannt. Deutsche reisten in den Orie und gebrauchten orientalische Wörter für Menschen, Tiere, Pflanze Dinge und Begriffe, die sie dort kennen gelernt hatten; oder Re sebeschreibungen wurden aus andern Sprachen ins Deutsche über

Х. Бәдигыйнең «Türkisch Wörter im Deutschen (Немец телендә төрек сүзләре)» мәкаләсенең беренче бите

Die ältesten dieser Wörter sind solche, die von den Phöniziern und Aegyptern oder von den kleinasiatischen Völkerschaften zu den Griechen gebracht und von denen an die Römer weitergegeben wurden, dann wurden sie in die romanischen und germanischen Sprachen aufgenommen. Schon vor der Einführung des Christentums bestand ein Verkehrsweg von dem Orient nach dem germanischen Norden, der über Südrussland führte. Dieser Weg blieb dann auch weiter bestehen, als das Christentum sich ausbreitete. Im Mittelalter wurden die arabischen Wörter von Spaniern, Italienern und Franzosen aufgenommen und an die Deutschen weitergegeben. Diese Wörter kamen aus Spanien, Nordafrika, Syrien und Palästina. Sie sind wohl von den orientalischen Wörtern im Deutschen am wahlreichsten, aber sie enthalten neben echt arabischen Wörtern auch griechische, lateinische, persische, indische und wahrscheinlich einige aus noch andern Sprachen,asiatischen und afrikanischen.

In der Neuzeit kamen, seitdem die Türkei eine Grossmacht geworden war, türkische Wörter nach Deutschland,meist auf dem Wege über Ungarn oder die slawischen Länder, und unter diesen waren wieder manche nicht echt türkisch, sondern von arabischer, persischer und indischer Herkunft. Immer mehr wurde auch die morgenländische Literatur in Übersetzungen bekannt.Deutsche reisten in den Orient und gebrauchten orientalische Wörter für Menschen,Tiere, Pflanzen, Dinge und Begriffe, die sie dort kennen gelernt hatten; oder Reisebeschreibungen wurden aus andern Sprachen ins Deutsche übersetzt, wobei dann die orientalischen Wörter natürlich beibehalten wurden.Auch die Berichte der Tageszeitungen kommen hier in Betracht.

Dieser Prozess dauert noch heute an und wird immer manigfaltiger und verwickelter.

Es ist schwer jedes einzelne Wort auf seinem Werdegang genau zu verfolgen. Die Forschungsarbeit deutscher Gelehrter hat sich aus ernsteste damit beschäftigt, wann und wo diese Wörter zuerst aufgenomen wurden und hat es darin sehr weit gebracht. Wer würde z.b. denken dass «Rose» im Deutschen und «gül» im Türkischen ursprünglich dasselbe Wort sei. Das deutsche Wort – «Rose» geht auf das latfenische «rosa» zurück, das wiederum auf das griechische Wort rhodon; wann und wo das «d» zu «s» geworden und der Wechsel des Geschlechts stattgefunden hat, darüber sind sich die lehrten freilich noch nicht einig. Die ältere Form von «rhodon» i «wrodon» und dies ist aus einem altpersischen Wort entlehnt, das etwa «wurdo» lautete. Im Neupersischen wurde das

«w» im Anlaut zu «g» und altes «rd» ist dort regelmässig zu «l» geworden. Aus dem Persischen «gül» haben die Türken, die ja das kurze «u» wie «ü» aussprechen, ihr «gül» entlehnt und so ist die Gleichung Rose – gül entsanden.

Andererseits nun gibt es Wörter in verschiedenen Sprachen, die ganz änlich klingen und dasselbe Bedeuten, aber dennoch nichts miteinander zu tun haben (Vergleiche zwei einander ähnlich Menschen, die nicht miteinander verwandt sind). Die sogennante Volks etymologie lebt aber auch heute noch fort und könnte solche Wege gehn. Im Jahre 1900 wollte in hama, in Syrien, ein türkischer Offizier beweisen, dass Deutsch und Arabisch dieselbe Sprache seien. Er hatte gerade das Wort «Ei» gelernt und behauptete, es sei das gleiche wie das arabische Wort âi (das ein Schmerzens – ausruf ist, etwa wie das deutsche «au») den die Henne sagt «âi» wenn sie ein Ei lege, weil es ihr sehr weh tue.

Wenn wir unsere Aufmerksamkeit jetzt auf eine Reihe von deutschen Wörtern lenken, die wir aus den orientalischen Sprachen entlehnt haben, so müssen wir in erster Linie die Wörter türkischer Herkunft, die ja für uns von besonderem Interesse sind aufzuzählen und zu erklären versuchen. Es handelt sich hier nun um rein Türkische aufgenommen wurden.

Da persien seit dem Tode Alexanders des Grossen stets durch andere Völker von Europa getrennt gewesen ist, so sind persische Wörter auch fast immer auf dem Umwege über andere Sprachen nach Europa gekommen, vor allem über das Türkische, da ja die Türkisch lange Zeit unter tiefgreifendem persischen Kultureinfluss gestanden haben. Einzelnen der hier vorkommenden Wörter sind aber gieichfalle ins Arabische aufgenommen, sei es aus dem Persischen oder aus der Türkischen, dabei können wiederum persische Wörter auf dem Umwege über das Türkische in das Arabische gedrungen sein. Die Wege, die manche von ihnen eingeschlagen haben sind noch dunkel.

Ein «Perser» oder «Persianer» wird meist ais persischer Teppich verstanden. Der «Türkisch» (italienisch turchese – türkisch) ein persischer oder indischer Edelstein, der zuerst von der Türkei aus in Italien eingefürt wurde. Wir bezeichen in Deuschland den Mais als «türkischen Weizen», obwohl er aus Amerika zu uns gekommen ist; so nennen die Engländer den amerikaniscgen Truthahn «turkey».

Inbeiden Fällen bedeutet türkisch ursprünglich so viel vie ausländlisch. Persische und türkische Titel und Bezeichnungen sind den Deutscgen mehrfach verraut geworden, seit die Türken nach Europa

Es ist schwer jedes einzelne Wort auf seinem Werdegang genau
zu verfolgen.Die Forschungsarbeit deutscher Gelehrter hat sich
aufs ernsteste damit beschäftigt, wann und wo diese Wörter zuer
aufgenommen wurden und hat es darin sehr weit gebracht.Wer wür
z.B. denken dass » Rose» im Deutschen und » gül» im Türkischen
ursprünglich dasselbe Wort sei. Das deutsche Wort - »Rose» geh
auf das lateinische » rosa» zurück, das wiederum auf das griec
sche Wort rhodon; wann und wo das »d» zu »s» geworden und der
Wechsel des Geschlechts stattgefunden hat,darüber sind sich di
lehrten freilich nochtnicht einig.Die ältere Form von »rhodon»
»wrodon» und dies ist aus einem altpersischen Wort entlehnt,da
etwa » wurdo» lautete.Im Neupersischen wurde das »w» im Anlaut
zu »g» und altes »rd» ist dort regelmässig zu »l» geworden.Aus
dem Persischen » gül» haben die Türken,die ja das kurze »u» wi
»ü» aussprechen,ihr »gül» entlehnt und so ist die Gleichung Ro
-gül entstanden.

Andererseits nun gibt es Wörter in verschiedenen Sprachen, d
ganz ähnlich klingen und dasselbe bedeuten, aber dennoch nicht
miteinander zu tun haben / Vergleiche zwei einander ähnlich Me
schen, die nicht miteinander verwandt sind/.Die sogenannte Vol
etymologie lebt aber auch heute noch fort und könnte solche We
gehn. Im Jahre 1900 wollte in Ifama,in Syrien, ein türkischer
Offizier beweisen, dass Deutsch und Arabisch dieselbe Sprache
seien. Er hatte gerade das Wort » Ei» gelernt und behauptete,
sei das gleiche wie das arabische Wort âi /das ein Schmerzens
ausruf ist, etwa wie das deutsche »au»/ denn die Henne sagt »â
wenn sie ein Ei lege, weil es ihr sehr weh tue.

Wenn wir unsere Aufmerksamkeit jetzt auf eine Reihe von deut
schen Wörtern lenken, die wir aus den orientalischen Sprachen
lehnt haben, so müssen wir in erster Linie die Wörter türkisch
Herkunft, die ja für uns von besonderem Interesse sind aufzuzä
und zu erklären versuchen.Es handelt sich hier nun um rein tür

Х. Бәдигыйнең «Türkisch Wörter im Deutschen (Немец телендә төрек сүзләре)» мәкаләсеннән фрагмент

kamen und sogar bis Wien vordrangen. Zuerst ist hier Padischah zu nennen. Im Persiscgen bedeutet «Padischah» nächtiger König, daraus ist der türkische Titel für den Sultan der Türken geworden. Schah (neupersisch schah) ist die herkömmliche Bezeichnung des Königs von Persien.

Ein ost-oder zentralasiatisches Wort für «Herrscher», das ins Persischr und Türkische überging, ist Chan (chân). In der Türkei führt nur der Sultan diesen Titel; aber in der Form chanum (später Hanym) eigentlich «mein Herr» oder «meine Herrin», da im Türkischen das grammatische Geschlecht nicgt unterschieden wird, ist das Wort von der Sultanin auf die hohen Würdenträger und dann auf jede «Dame» übertragen und entspricht dem französischen «Madame». In Persien ist der Titel Chah in gewissen vornehmen Familien erblich oder wird vom Schah verliehen, er gilt etwas höher als Mirza (mîrzâ = emir zâda wörtlich «Fürstensohn»). Für die türkischen Titel gilt zunâchst die Reihenfolge von oben nach unten:

1) Pasha
2) Bey
3) Militärpersonen – agha
Zivilpersonen – Efendi.

Pascha, Bey und Agha sind echt türkische Wörter.

Die verschiedenen Crade der Paschawürde wurden durch die Zahl der Rossschweife gekennzeichnet.

«Bey» türkisch ursprünglich «beg» dann bei (Bai/, wird aue in der Zusammensetzung «beglerbeg» gebraucht; diesen Titel führ die Statthalter grosser Provinzen, er bedeutet «der Bey der Beys» d.h. der oberste Bey. «Agha» ist in seinem Werte ziemlich gesunken: heute ist es eine Beleidigung einen gebildeten Menschen, es ei den der ältere Bruder, so zu titulieren; zumal ah die Eunuchen den Titel Agha führen. «Pascha» und «Agha» scheine ursprünglich Ehrenbezeichnungen für den älteren Bruder gewesen zu sein. «Efendi» ist ein durchaus höfliches Wort. Es stammt aus dem griechischen authentes, das neugriechisch in der Anrede (im Vokativ) afthendi oder afendi gesprochen wurde, solche Anredeformen in erweiterter Bedeutung sind in sehr vielen Sprachen nachgewiesen. Efendi sind auch die Prinzen des kaiserlichen Hauses gewesen und «efendimiz» ‘unser Efendi’ war in der ältesten Türkei der Sultan selbst. Auch eine Frau konnte mit «efendim» angeredet worden, und «hanym effendi» heisst «gnädige Frau».

Der Derwich (persisch – därwisch – arm, Bettler) ist in Deutsland gut bekannt. Der Dolmetsch oder Dolmetscher ist über das Slawische (russisch Tolmatsch) aus dem Türkischen ins Deutsch gekommen.

Von weiblichen Wesen gehören hierher noch die Peris und die Odalisken. Peri (persisch päri) bezeichnen Engel, Feen und gut Dämonen. Odaliske ist aus dem türkischen «odalyk» entstanden und bedeutet ursprünglich «etwas zum Zimmer oda» (Gehöriges; (vergleiche «femme de chambre» und deutsch «Frauenzimmer»).

Türkisch ist ferner sogar eine ganzo Waffengattung um preußischen Heere, die der Ulanen. Ihr Name stammt aus dem Türkischen, wo, 'oghlan, dialektisch ölan' der junge Mann bedeutet.

Der sächsische Graf Bühl warb für einen Krieg gegen Friedrich den Grossen bosnische Lanzenreiter an, die man Bosniaken oder Ulanennannte. Diese liexen aber im Jahre 1745 größtenteils zu Friedrich über und bildeten den Kern der preussischen Ulanen – truppe. Ihr Waffenrock heißt Ulanka, d.i. das türkische Wort mit polnischer Endung. Im türkischen bedeutet ordu Heerlager, es umfasst sowohl die eigentliche Armee wie den mitziehenden Tross. Daraus ist unser Wort «Horde» entstanden, das zuerst für um herziehende Tatarenstämme gebraucht wurde ( russ. «orda»). Bekannt ist auch das Wort «Baschibosuk» türkisch «baschy bozuk» – d.h. irregulare Truppen, die oft wegen ihrer Plündereier gefürchtet waren.

Von persisch-türkischen Tiernamen ist der «Schakal» zu uns gelangt. Er heisst im Türkischen «tschakal» aber dieses Wort ist über das persische schagâl aus dem Indischen entlehnt. Es ist merkwürdig, dass die europäischen Sprachen für den Schakal das indisch – persisch-türkische Wort verwendet haben, da et doch auch in Vorderasien und Nordafrica xon jeher weit verbreitet is Ein tierisches Produkt ist der «kaviar»; dieses Wort scheint zunächst im Italienischen (Caviarom Cavialo) aus dem gleichbedeutenden türkischen «chalvyâr» (tatarisch: qaviar) entlehnt zu sein.

Gebäude und bauliche Anlagen mit persisch-türkischen Namen sind «Serai», «Bazar» und «Kiosk».

Serai, das im Deutschen oft nach französischer Art Serail geschrieben wird, ist sârâi – Palast, grosses Haus.

«Bazar» (persisch bâzar also mit weichem S, nicht mit deutschem Z) ist der «Markt» oder besser gesagt die Strasse mit Kaufläden.

Kiosk (türkisch «kiöchk») ist eine Art Gartenpavillon. Einige Früchte und Genussmittel weisen auch nach Persien und der Türkei hin.

Die Bergamotte ist die «Birne des Beys» (türkisch «beg armudy») Noch heute gibt es in der Türkei eine Birne, die «Mustafa beg armudy» heisst; beim Ausrufen in den Strassen preisen die verkäufer ihre Früchte als für den Bey oder den Pasha geeigneten.

Der «Pilaw», das türkische Reisgericht, ist allen, die im vorderen Osten gewesen sind, bekannt, man findet ihn jetzt häufig auf der Speisekarte in Deutschland. Das Wort stammt aus dem persischen «pälâv». Das Worte «Droge» (vrgl. russ дрожжи) hat die Gelehrten viel beschäftigt nachdemmen es früher aus dem holländischen Wort dro (o) g – trocken abgeleitet hatte, glaubt man jetzt,dass es aus der arabischen Medizin stamme. Die arabische Medizin ist aber stark von Persien aus beeinflusst und der bekannte Orientalist Enno Littmann weist auf das persische Wort «dârû» oder «dârûi» als Vorbild hin, das sich in seiner Bedeutung ganz und gar alt «Droge» deckt.

Tücke und Stoffe persisch-türkischen Ursprungs sind Fes, Baschlik, Kalpak, Turban, Schal, Kaschmir, Chagrin und Saffian.

Den Fes bezeichnen die Türken nach der Stadt «Fes» in Marokko,weil die ursprünglichen Fesse von dort kamen. In den letzten Jahrzehnten wurden die türkischen Fesse in Osterreich und Deutschland hergestellt.

Der Baschlik, ein Kopftuch, das zugleich Schultern und Nacken bedeckt, war in der 2-ten Hälfte des 19. Jahrhunderts in Deutschland sehr beliebt; gegenwärtig ist er nicht mehr modern.Im Türkischen bedeutet baschlyk zunächst jede Art von Kopfbedeckung

«Kalpak» bezeichnet bei den Turken verschiedene Arten von Mützen. In den deutschen Fremdwörterbüchern finden wir «Kalpak» und «Kalpack». Kalpak ist die ungarische Husarenpelzmütze und die schwarze Kalbfellmütze der nichtmuselmanisehen Türken; «Kalpack» wird aus dem Russischen hergeleitet und heisst Nachtmütze. Anscheinend besteht zwischen diesen Wörtern wohl kaum ein Unterschied, sie stammen wahrscheinlich beide von dem Tükischen Wort Kalpak.

Der Turban (holländisch tulband) heisst türkisch «tülbend» oder «dülbend» persisch «dulbänd».

Schal (deutsch Umschlagetuch, persisch Schâl). Kaschmir und Chagrin (sprich Schagren (g) – шагрень sind aus Indien wohl über Persien und die Türkei nach Europa gewandert, der Kaschmir ist natürlich nach dem Lande oder der Stadt (Kaschmir in Nordwestindien benannt. Chagrin heisst türkisch saghry, persisch sâghâri (vgl, die indische Stadt «Sagar»). Der Saffian wurde gelegentlich aus der Stadt

Saffi in Marokko hergeleitet; Enno Littman glaubt, dass er eher aus dem persischen «sachtijân» stammt; er gelangte aus der Türkei über die slawischen Länder nach Deutschland und die slawischen Formen zeigen die Mittelstufen zwischen der persisch-türkischen und der deutschen Form.

Waffen und Geräte sind Handschar, Kantschu, Tschibuk, Nargilch. «Handschar» ist das persisch-türkische «chandschar», Dolch, «Kantschu» geht auf das türkische «qamtschi» – Peitsche. Dieses Wort ist über das Slawische ins Deutsche gedrungen, wie ja auch Peitsche und Knute slawische Wörter sind (deutsch Geissel).

«Tschibuk» lautet im Türkischen ebenso. Dort bedeutet es zunächst den Pfeifenstiel, dann aber auch die ganze Pfeife aus einem Holzrohr mit Tonkopf. Nargilch geht auf das persische nârgil zurück, das die «Kokosnuss» und dann die «Wasserpfeife» bezeichnet; das Wort ist aber natürlich nicht echt persisch, sondern ist aus Indien gekommen.

Zuletzt ist noch auf die Indisch-Persische Herkunft des «Schachspiels» hinzuweisen. Seine Heimat ist Indien, es wurde durch die Perser den Arabern und durch sie den Europäern übermittelt.

«Schach» ist dasselbe wie «schâh» der Konig. Wenn wir aber schachmatt sagen, so wird hier ein persisches mit einem arabischen Worte verbunden, die Araber riefen «eschachah mât» – der König ist gestorben. Von schachmatt stammt (über das Romanische) unser deutsches Wort matt, das also eigentlich rein arabisch ist und mât, «er ist gestorben» wiedergibt; im Türkischen sagt man mât olmag (besiegt worden). In der Studentensprache ist Schwachmatikus in Anlehnung an «schwach» und an lateinische auf «maticus» endende Wörter gebildet. Weiter ist im Deutschen von matt noch Mattigkeit und Mattheit abgeleitet (vgl. russisch – «матовый» – тусклый, «дело» – швах»).

Wenn sie jetzt noch das uns allen so vertraute Wort Scheck betrachten, so hat dieses Wort innerhalb der europäischen Sprachen noch keine Erklärung gefunden. Es geht wahrscheinlich auf das persische «tschäk» Urkunde, Vertrag, Kaufvertrag zurück; es wurde auch ins Türkische übernommen und ist vielleicht von dort über das Englische oder Französche zu uns gelangt (engl – Check sprich – Tscheck; rus // «чек»).

Ungefähr 1100 aus Asien stammende Wörter zählen die deutscheh Orientalisten in ihrer Muttersprache. In unserem Artikel werden nur 40 (also ein ganz kleiner Teil) besprochen, aber auch sie beweisen, dass die morgenländische Kultur einem tiefgreifenden Einfluss auf das kulturelle

Leben Deutschlands gehabt hat und dass alle Zweige der Kultur davon betroffen sind.

Die Mongolen

Das Stammland aller mongolischen Stämme ist das im Norden gebirgige, im Süden ebenere Wüsten = und Steppen= und Tafelland zwischen Sibirien und Tibet, dem Quellenland des Hoangho und der Mandschurei. Man spricht von äusseren Mongolen, welche den Norden der Wüste Gobi und den Fruchtlandstreifen Länge der siberischen Grenze bewehnen, von inneren Mongolen, die im Süden der Wüste Gobi die Grassteppen und die Dünenienöden mit eingesprengten Qasen durchwandern. Der Natur des Bodens haben sie ein Nomadenleben angepasst: im Winter suchen sie die Ebene, in Sommer so weit wie möglich die Berghänge auf um die Herden ihrer Kamele, Pferde, Schafe, Rinder füttern zu können. Lm Süden trägt der chinesische Einfluss, Ackerbau-Siedelung ins Land, durch sie und die politischen Kämpfe eine Zerstörung der alten Eigenkultur; im Norden besorgt Sowjetrussland und sein Europäertum dasselbe Geschäft.

Sie zichen das Pferd als Reittier und Kapitalsanlage, – selten wird sein Fleisch gegessen – das zweihöckerige Kamel als Reit = und Lasttier, Schafe und Rinder für ihre Nahrung, die aus Fleisch, Fett, Milch, Buttermilch, Butter und Käse besteht. Als Zukest dienen Kräuter, Beeren, Zwiebeln, Brennesseln.

Das bewegliche Gitternetz die Jurte mit Filzbelag ist die Wohnung der Nomaden; des Ackerbauer haben Häuser aus Lehmziegeln, die Reichen chinesische Bauwerke angenommen. Die Innensinrichtung wird durch die Lebensart, wirtschaftsform und Umwelt bestimmt. Holz, Horn, Knochen, Fell und Wollfilz sind die alten gegebenen Stoffe der Hauswirtschaft, überall in den trockenen Steppen dient der Pferde und Kamelmist zur Fenerung. Die altmongolische Kleidung wird durch chinesische Formen verändert; in der Steppe herrscht der Pelz.

Im Kultus herrscht Tibet. Von alten Schamanismus leben nur mehr äussere Symbolhafte Reste die «Obos», das sind die Gedächtnismale, die für die geistigen Wesen an Pässen und sonstigen beconderen Stellen aus Steinen, Holzstangen und Eleiderfetzen errichtet sind, die Weissagungen aus den Springen eines erhitzen Schafsschulterblattes, Krankrtnbeschwörungen magische Medizinen, Sonst hängen die Mongolen dem Buddhismus in seiner Lamaistischen Form an die aus Tibet zu ihnen kam.

Von Tibet kam auch die Literatur, die in Geschichts chroniken, buddhistischen Legenden und Vorgeburtsgeschichten, in Resten alter Heldenlieder, in Scherz = und Neckstrophen besteht. Sie haben eine eigene Schrift, die aus dem sorgischen, von Nestorianen zu den türkischen Uiguren und von diesen zu den Mongolen gebrachtem Alphabet stammt.

Die Doppelung ihres Geisteslebens, aus den alten Schamanentum, das ganz in Kosmos und seinem Einfluss lebte und aus dem Buddhismus, dessen kultusausübende Diener ein Drittel der ganzen Bevölkerung ausmachen, führt zu einer letzten Verachtung des Körperlichen, der irdischen bedeutungslosen Hülle des Geistes: sie warfen ihre Toten Hunden, Fischen oder Geiern vor.

Die Männer der Mongolen sind durchschnittlich klein und mager: die im Prinzip der Frauengewandung gleiche Grundlage ihres Anzuges bilden Stulpstiefel mit Ueberschuhen, Lange Röcke und Pelze, Mützen aus Filz oder Schaffell. Mongolentum und Chinesen – tum berühren sich in diesem Prinzip. Den spitzen Kugelhut, die runde Mütze, die gestrickte Kappe der Sarten, den runden auf geklappten Hut der Chinesen sieht man nebeneinander auf den mongolischen Rundschädeln, die kurz geschoren oder vorn glattrasiert und hinten mit Zopf nach Chinesenart getragen werden.

Die Frauen tragen Zöpfe, die sie mit Korallen, Bündern und Glasperlen verzieren und über die Brust herabhängen lassen.

## 1935 ЕЛГЫ ТЕЛ ЭКСПЕДИЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ҺӘМ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ЯКТАН ҮСЕШ ТЕНДЕНЦИЯСЕ (БАШЛАНГЫЧ ЙОМГАКЛАР)[1]

**Кереш**

1. Тел – практик, реаль аң. Тел – җәмгыятьнең социаль-экономик төзелешен һәм шушы төзелеш шартларында туган идеологиясен чагылдыра торган өскорма. Тел – җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән бергә үзгәреп бара торган аралашу чарасы. Тел – сыйнфый җәмгыятьтә сыйнфый бер күренеш.

[1] *Бәдигый Х.* 1935 елгы тел экспедициясе материаллары йомгаклары буенча хәзерге татар әдәби һәм сөйләм теленең лексик-семантик яктан үсеш тенденциясе (башлангыч йомгаклар). КФУның Н. И. Лобачевский исем. Фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 1779 Т.

2. Телнең менә бу өскормалык маһияте, сыйнфый шартлылыгы һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән бергә бәйләнеп үзгәрүчәнлеге, барыннан да элек, аның сүзлек составында ачыграк чагыла. Сүзлек составындагы үзгәрешләр – кайбер сүзләрнең үлүләре, кайберләренең яңа туулары белән я сүзлек составының үзендә яки аерым мәгънәләрендә, яисә аларны куллану шартларында булырга мөмкин.

3. Телдә сүзлек составының арту һәм баю процессы, гомумән, телләрнең өске диалектик үсеш сызыгы буенча, бер яктан, үзенең иске мирасыннан файдалану, икенче яктан, икенче тел коллективларыннан сүзләр алу юлы белән бара.

4. Хәзерге татар теле дә, кирәк кешелек тел иҗады гомуми үсешендә булсын, гомумән, тел үсешендәге бер этапны башыннан кичерә. Пролетариат диктатурасы һәм җиңешле социалистик төзелеш чоры – хәзерге татар теленең үсеш тарихында яңа этап ул. Хәзерге татар телендә үткәннең мирасы да һәм киләчәкнең үсеш тенденциясе дә билгеләнә. Хәзерге татар теленең үсеш тенденциясе – эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли буларак, татар теленең үз потенцияләре һәм совет-интернациональ байлыклар исәбенә, өр-яңа юнәлештә үсүеннән гыйбарәт. Татар әдәби теленең сүзлек составы да төрек теле сүзләре белән чуарланды. Төрек әдәби теле сүзлек составында гарәп һәм фарсы сүзләре иң күп урынны алганда, татар әдәби теленең сүзлек составы да шул ук гарәп һәм фарсы сүзләре белән чүпләнә. Болар өстенә тагын төрек теле сүзләре дә киң урын алалар: «яшь – көнеш, бала – чуҗык, уң – саг, күп – чук, эссу – сыҗак, яхшы – ийи, иштә – менә» һәм башкалар кебек. Кайбер төрек сүзләре татар сүзләре белән параллель йөрделәр.

## ОКТЯБРЬГӘЧӘ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ

1. Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы ягыннан үсеш динамикасын ачу һәм шуннан чыгып үсеш тенденциясен билгеләү өчен, татар җәмгыятенең феодализм формациясендәге язма әдәби теленә, бигрәк тә капитализм формациясендәге милли әдәби теленә, кыскача гына булса да, экскурс ясап үтмичә мөмкин түгел.

2. Татар җәмгыятендә феодализм төзелеше, нигездә, XIX йөзнең соңгы яртыларына кадәр сузылды. Феодализм формациясендә татар язма әдәби теле, башлыча руханилар кулында булып, шул формациядәге хаким сыйныфының интересларын саклау, дин китапларын

dalcьlьq hem millətcelek cyplerennen tazartьldь hem haman tazar-
tьla ʙara.

Xezerge tatar edeʙi tele yzeneŋ yseş protsesьnda yzeneŋ tep jыeleşen ʙilgelev julьnda, ʙer jaqtan, çirle milletcelek kyrneşe, ikence jaqtan olь derzavacьl şovinizmь tarafьnnan, qajcaqьnda astьrtьn, qajcaqьnda acьqtan acьq reveşte terle qarşьlьqlarƣa ocradь.

Bu kereş, ʙer jaqtan, tatar teleneŋ terʙie hem uqьtu eşlerendege ehemieten tanьmavcь olь derzavacьl elementlarьnьŋ tatar edeʙi telen russizm ʙelen tutьrьrƣa omtьlularьnda, ikence jaqtan, ʙurzuaz - milletce elementlarьnьŋ, soltanƣəliefceler hem Şeqidullincьlarьnьŋ tatar telen qatьp qalƣan iske formalarьnda saqlarƣa omtьlularьnda kyrende. Bu ʙurzuaz - milletce elementlar massaƣa aŋlajьşsьz iske ƣerep hem farsь terminnarьn saqlarƣa, ƣemerlere ʙetken ylek syzlerne tergezerge, qatьp qalƣan iske formalar nigezende "jasalma syzler" tudьrьrƣa tьrьştьlar, tatar edeʙi telen ystery eşende xezerge rus edeʙi teleneŋ ehemieten iske almasqa mataştьlar, e şul uq vaqьtta sovet cьnʙarlьƣь aşa sikerep, "internatsionallaşu"ƣa omtьldьlar. Bilgele, partie hem sovet vlastьnьŋ tel politikasьna qarşь kereş alьp ʙarƣan ʙu aƣьmnar Tatarstan partie ojьşmasь tarafьnnan qatь tipken ala kildeler hem tazartьla ʙardьlar.

Okteʙr revolytsiesennen soŋ çemƣietneŋ tezeleşe yzgery ʙelen ʙerge ʙəjlenep edeʙi teleneŋ tezeleşe de yzgerde. Teldəge ʙu yzgereş, hemmesennen elek, anьŋ syzlek sostaʙьnda acьqraq caqьldь. Yzlerende patşalьq tezeleşen caqьldьrƣan "starşina, yrednik, politsejski, spravnik, stanovoj, pristef, polit-

Х. Бәдигыйнең «1935 елгы тел экспедициясе материаллары йомгаклары буенча хәзерге татар әдәби һәм сөйләм теленең лексик-семантик яктан үсеш тенденциясе (башлангыч йомгаклар)» хезмәтеннән фрагмент

шәрехләү, суфилар, мөритләр тәрбияләү, яңа рухани кадрлар хәзерләү өчен хезмәт итте.

3. Феодализм формациясендә татар язма әдәби теле хаким сыйныфның җитәкче идеясе булган ислам дине йогынтысы астында яшәде һәм, бер яктан, гарәп теле, икенче яктан, фарсы, чыгытай һәм бераз соңрак Анатолия төрек телләре элементлары белән чуарланды, шуңа күрә бу әдәби тел татар хезмәт массасы өчен авыр һәм аңлаешсыз, тик хаким сыйныфының үзенә генә хас булган кискен сыйнфый бер тел иде.

4. Феодализм формациясендә татар язма әдәби теленең менә шушы шартларда оешып, барыннан да элек, аның сүзлек составында бик нык чагылды. Әдәби телнең сүзлек составы, бер яктан, гарәп, икенче яктан, фарсы, чыгытай һәм төрек телләренең сүзләре белән чүпләнеп, әдәби тел татар халык хезмәт массасының үз теле җирлегендә үсә алмады һәм моңа мөмкинлек тә булмады.

Экспедиция материалларына караганда, феодализм формациясендә татарязма әдәби теленең сүзлек составына гарәп, фарсы, чыгытай һәм төрек телләренең сүзләре, аерым әсәрләргә карата алганда 25% тан 80% ка, ә гомумән алганда, 60–70% ларга җиткәне күренә. Шуның белән бергә чыгытай һәм төрек телләре татар теленең сүзлек составыннан бигрәк, аның фонетик һәм грамматик төзелешенә көчлерәк йогынты ясалды.

Әдәби телнең сүзлек составында татар хезмәт ияләренең үз сүзләре 30–40% ка гына калды, фарсы, чыгытай һәм төрек телләре басымы астында формалашуы менә бу хәлләрнең һәммәсе дә әдәби телне хезмәт ияләре теленнән бик нык аерды. Әдәби тел хезмәт ияләре массасы өчен авыр һәм бөтенләй аңлаешсыз бер телгә әйләнде, шуңа күрә бу чордагы әдәби тел хезмәт ияләренең аңнарын томалау һәм эксплуатацияләү коралы гына булып, турыдан-туры хаким сыйныфның үз интересларына гына хезмәт итте.

5. XIX йөзнең соңнарында, эре индустрия промышленностеның көчәюе аркасында, гомумән, Россиядә бераз соңрак татар җәмгыяте эчендә дә буржуа милли хәрәкәте башлана. Татар буржуа милли хәрәкәтенең социаль-политик юлбашчы идеясе пантюркизм җирлегендә оеша. Бу юлбашчы идея капитализм формациясендәге татар әдәби телендә дә, әлбәттә, бик нык чагыла, шуңа күрә бу чордагы татар әдәби теле бер татарның үз хезмәт ияләрен генә түгел, бәлки татарга дин һәм тел ягыннан якын булган башка милләт

хезмәт ияләрен дә эксплуатацияләү нигезенә корылган һәм буржуаз чикләнгән бер тел була. Бу чорда әдәби телдәге татарчылык агымы да шул ук буржуа милли хәрәкәтенең икенче төрле күренешеннән генә гыйбарәт булып, шул ук пантюркизм идеясенә хезмәт итә һәм буржуаз чикләнгән бер адым була.

6. Татар әдәби телендә пантюркизм идеясе, бер яктан, аның фонетик һәм грамматик төзелешендә, икенче яктан, сүзлек составында гәүдәләнә. Әдәби телнең фонетик һәм грамматик төзелеше төрек теле фонетик һәм грамматик төзелеше нигезендә формалашты. Мәсәлән, *килде – кәлде, китерде – кәтүрде, булды – улды, бирде – вирде, килер – кәлүр, йөрер – йөрүр, кирәк – кәрәк, бар – вар, бик – пәк, ул – у, шул – шу, мин – мән, син – сән* һ. б.

Татар әдәби теленең сүзлек составы да төрек теле сүзләре белән чуарланды. Төрек әдәби теле сүзлек составында гарәп һәм фарсы сүзләре иң күп урынны алганда, татар әдәби теленең сүзлек составы да шул ук гарәп һәм фарсы сүзләре белән чүпләнә. Болар өстенә тагын төрек теле сүзләре дә киң урын алалар: *яшь – кәнеж, бала – чүҗык, уң – саг, күп – чук, эссе – сыҗак, яхшы – ийи, иштә – менә...* һәм башкалар кебек, кайбер төрек сүзләре татар сүзләре белән параллель йөрделәр, хәтта мондый параллель сүзләрдә төрек сүзләре артыграк һәм әдәбиерәк саналды. 1908 елның июль аенда чыккан «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарын алып, «Төркиядә идарәи игълан ителде» дигән бер үк темадагы ике мәкаләне сүзлек составы ягыннан анализлау йомгагы менә болай килеп чыга:

Таблица 1

| Сүзләр | «Вакыт» | | | | «Йолдыз» | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | гомуми | % |
| Татарча сүзләр | 179 | 44,8 | 134 | 49,9 | 176 | 44,0 | 121 | 48,4 |
| Интернациональ | 8 | 2,0 | 8 | 2,8 | 10 | 2,5 | 7 | 2,8 |
| Русча сүзләр | 9 | 2,2 | 7 | 2,5 | – | – | – | – |
| Гарәпчә, фарсыча | 122 | 30,5 | 78 | 28,0 | 129 | 32,25 | 78 | 31,2 |
| Бүтән телләрдән | 10 | 2,5 | 6 | 2,1 | 3 | 0,75 | 3 | 1,2 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Төрле телләрдән | 20 | 5,0 | 20 | 7,1 | 32 | 8,0 | 22 | 8,8 |
| Ялгызлык исемнәр | 52 | 13,0 | 27 | 9,6 | 50 | 12,5 | 19 | 7,6 |
| Барлыгы | 400 | 200 | 200 | | 400 | | 200 | |

Таблицадан күренгәнчә, бу ике газетаның бер үк темада язылган мәкаләләрендә сүзлек составында татарның үз сүзләре 50% ка да җитми, икенче төрле әйткәндә, татар әдәби теле сүзлек составының яртысыннан күбрәк өлеше икенче телләр исәбенә төшә. Шулардан 30% ы, ягъни иң күп өлеше гарәп һәм фарсы сүзләре исәбенә туры килә. Халыкара һәм интернациональ сүзләр шулай ук русча сүзләр икешәр, өчәр проценттан артмыйлар. Татар хезмәт массасының сөйләү телендә исә бу чорда инде рус сүзләре һәм рус теле аша кергән халыкара сүзләр, гарәп һәм фарсы сүзләренә караганда, күбрәк кулланылалар иде.

Шуның белән бергә, бер үк елда, бер үк көннәрдә чыккан бу мәкаләләрдә бер үк төшенчә төрле сүз белән, бер үк сүз төрле грамматик формада кулланылуларын түбәндәге чагыштырмадан күрергә мөмкин:

| «ВАКЫТ» | «ЙОЛДЫЗ» |
|---|---|
| *илә* | *илә – белән* |
| *ушбу* | *бу – ушбу* |
| *Аврупа* | *Йавропа* |
| *Иран* | *Персия* |
| *реформа* | *ислахат* |
| *яшь төрек* | *кәнеҗ төрек* |
| *Казанга да* | *нәзаран* |
| *кәгазь* | *кагыйд* |
| *ел* | *сәнә* |
| *фикер тарату* | *агитация* |
| *мәҗлисе мәбгусан* | *милләт мәҗлесе* |

Шуның өстенә, «Вакыт» газетасында бер үк төшенчәне аңлата торган сүз төрлечә кулланыла. Мәсәлән, «таләп итә – таләп кыла, рәхмәт укыганнар – рәхмәт кылганнар» һ. б.

Пантюркизм идеясе татар әдәби теленең терминологиясе өлкәсендә тагы да ачыграк чагыла. Терминнарның зур күпчелеге төрек әдәбияты аша гарәп һәм фарсы телләреннән алындылар. 1917 елда кулланылган грамматика, математика, физика һәм биология терминнарын сүзлек составы ягыннан анализлау йомгагы менә болай күренә:

Таблица 2

| Фәннәр | Сан | Татарча | Халыкара | Русча | Гарәп-фарсы | Катнаш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Грамматика | 140 | 28,5 | – | – | 27,3 | 44,2 |
| Математика | 200 | 0,5 | 0,5 | – | 95,0 | 4,0 |
| Физика | 100 | 5,5 | 5,4 | – | 79,1 | 10,1 |
| Биология | 151 | 66,2 | 1,3 | 0,6 | 20,6 | 11,3 |
| Барлыгы | 601 | 25,2 | 1,8 | 0,1 | 55,5 | 17,4 |

Димәк, капитализм формациясендәге татар әдәби теленең терминологиясен сүзлек составы ягыннан караганда, 601 терминнан татарның үз сүзләре бары 25,2% кына килеп чыга. Икенче төрле әйткәндә, терминологиянең 74,8% ы башка телләрдән алынган була. Шулардан 55,5% ы, ягъни яртысыннан күбрәк өлеше гарәп һәм фарсы сүзләре исәбенә төшә. Халыкара – 1,8%, ә русча – бары 0,1% кына. Биредә 17,4% төрле телләрдән кушылып ясалган терминнар арасында да гарәп һәм фарсы сүзләренең иң зур урын алуларын исәпкә алырга кирәк. Интернациональ терминнарның булган кадәресе дә күбесенчә гарәпчә формалаштырылганнар. Мәсәлән, *мәкнатыйс, гамәле механики, эластикият, гази җисем, лагарифми* һ. б. Гарәпчә терминнарның үзләренә килгәндә – алар *ихтар, истисна, фаиз, завия, ингыйкас* кебек татар массасына бөтенләй ят булган аерым сүзләр генә дә түгел, бәлки гарәп грамматикасы системасы буенча төзелгән 4–5 сүзлек бөтен бер тезем рәвешендә дә алынганнар. Мәсәлән, *галәмәте нида, мохәллия-тәлһева, дәрәҗәи сания мокадәләсе, зу ходуде кәсире, гадәде там мәгалкәсер* һ. б.

Татарчылык агымы шул ук татар буржуа милли хәрәкәтенең икенче төрле күренешеннән генә гыйбарәт, дидек. Әдәби телдә татарчалык агымының чынлап та татар буржуа милли хәрәкәтенең икенче төрле күренешеннән генә гыйбарәт булганын һәм аның пантюркизм идеясенә хәзерлек баскычы гына икәнен «Бөтенроссия мөселманнары 1 нче съезды»ның тел турындагы карарлары да ачык күрсәтә. Бу съезд әдәби тел турында түбәндәге карарларны кабул итте:

1. Ибтидаи мәктәпләрдә уку һәр төрек кабиләсенең үз шивәсендә булыр.

2. Урта мәктәпләрнең баш сыйныфында гомуми төрек теле аерым дәрес булып калыр, ә соңгы сыйныфларда исә уку теле гомумән төрек теленә якынлаштырылыр.

3. Гали мәктәпләрдә уку гомумән төрек телендә генә булыр.

Димәк, бу карар буенча әдәби тел әкренләп төрек теленә күчәргә тиеш була.

Ләкин бу татарчылык агымы татар әдәби теленең бары примитив матур әдәбият өлешендә генә бераз чагылып калды, вакытлы матбугат һәм фәнни-популяр әсәрләрдә, шулай ук терминология өлкәсендә үзенең йогынтысын артык күрсәтә алмады. Бу күренешнең бары примитив матур әдәбият телендә генә чагылуы, бу әдәбиятта фән, техника һәм производство терминнарының булмавы, татарның үз теле җирлегендә яңа сүзләрнең иҗат ителмәве, бәлки яңа төшенчәләрне аңлату өчен шул ук гарәп һәм фарсы сүзләре белән генә чикләнеп калуы – татарчалык агымының да үзенең төп үсеш юнәлешендә шул ук пантюркизм идеясеннән гыйбарәт булуын, буржуаз чикләнгәнлеген безнең алдыбызга ачык факт итеп куя.

Татар буржуазиясенең яшь капиталы үзенең үсеш юлында төрле каршылыкларга очраган кебек, бу чорда аның әдәби теле дә каршылыклардан, әлбәттә, котыла алмады. Көчле рус империализмының рус берлеген саклау политикасы вак милләтләргә карата чыгарылган төрле чикләү законнары нәтиҗәсендә татар теленең алда үсүе өчен артык мөмкинлекләр дә юк иде.

Иптәш Сталин царизмның, помещиклар һәм буржуазиянең вак милләтләргә карата тоткан политикасы турында:

«Бу халыкларга карата царизмның тоткан политикасы, помещиклар һәм буржуазиянең политикасы – алар арасындагы һәртөрле дәүләтчелек чаткысын үтерү, аларның культурасын имгәтү, телләрен кысу, аларны дошманлыкта тоту һәм, ниһаять, мөмкин кадәр руслаштырудан гыйбарәт. Шундый политиканың нәтиҗәлеге – бу халыкларның үсмәве һәм политик артталыгы», – ди.

Царизмның менә шундый политикасы нәтиҗәсендә татарча дәүләт теле, канцелярия һәм эшбашкаручылык теле бөтенләй тумавын, татар фән теле эшләнмәвен, кыскасы, әдәби телнең дини китаплар, авыл, шәһәр һәм мәдрәсәләр тормышы турында примитив эчтәлекле әдәби әсәрләр язарлык дәрәҗәсеннән югары күтәрелмәвен күрәбез.

Шуның белән бергә, бер яктан, царизмның менә шундый политикасы, икенче яктан, гомумән капитализмның үз эчендәге анархиясе, татар буржуазиясенең колониаль-арадашчылык характеры, 1905 ел революциясеннән соң бөтенләй монархиянең ышанычлы терәге булып китүе, икейөзлелеге, куркаклыгы, феодализм калдык-

ларына каршы көрәштә килешүчәнлеге, гомумән, реакцион табигате нәтиҗәсендә бу чордагы әдәби телнең булган дәрәҗәсе дә гарәп, фарсы һәм төрек телләреннән оешкан чуар һәм корама тел булуын, бер үк шәһәрдә чыга торган газеталар һәм журналларның телләре, бер үк темада язучы әдип һәм шагыйрьләрнең телләре төрлесенеке төрлечә булуын, шуңа күрә Октябрь революциясенә кадәр бердәм татар әдәби теле бөтенләй тумавын күрәбез.

Дөрес, 1905 ел революциясе чорларында татар хезмәт ияләре массасының үз әдәби телләре дә туа башлаган иде. Башта, революция елларында социаль-демократлар комитеты тарафыннан җилем басма белән идән астында басылган яшерен прокламацияләр таратылалар, аларның саннары яхшы ук күп була. Аннан соң 1907 елның гыйнварында беренче мәртәбә татар социаль-демократ-большевиклар органы буларак, Оренбургта «Урал» газетасы чыгарыла. «Урал» газетасы, чынлап та, татар хезмәт ияләре массасының революцион идеологиясен беренче мәртәбә татар телендә гәүдәләндерә. «Урал» газетасы аша татар әдәби теле беренче мәртәбә пролетариат идеологиясенә хезмәт итә башлый.

«Урал» газетасының теле яхшы эшләнгән бер тел түгел иде әле. Шулай да бу тел буржуа әдәби теленнән үзенең юнәлеше белән бик нык аерыла иде. Аның сүзлек составында гарәбизм һәм башка көнчыгыш телләр йогынтысыннан котылып, халыкара һәм русча терминнар белән урынлы файдалану, гомумән татар хезмәт ияләре массасына якын һәм аңлаешлы итеп язарга тырышу кебек әдәби телдә яңа юнәлеш эзләнү факты бар иде. Бу фактны «Урал» газетасы сүзлек составын күрсәткән түбәндәге таблицадан да ачык күреп була (табл. 3).

Бу таблицаларны югарыдагы бер үк вакытта чыккан «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарының сүзлек составын күрсәткән таблицалар белән чагыштырып карасак, «Урал» газетасында татар хезмәт массасының үз сүзләре, «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарындагы 48–49% урынына 72,2% ка җиткәнен, гарәп һәм фарсы сүзләренең 28–30% урынына 19,5% ка кадәр төшкәнен, шуның белән бергә халыкара һәм русча сүзләрнең артканын күрәбез.

«Урал» газетасы үз тирәсендә татар эшче язучыларны яхшы гына җыя башлаган иде, ләкин гомере бик кыска булып, бары 30 гына номер чыгып калды, апрельнең 18 ндә, политик юлы монархия өчен зарарлы табылып, патша хөкүмәте тарафыннан туктатылды.

Таблица 3. «Урал» газетасының сүзлек составы

| Алынган өземтәләрнең исемнәре | Газета номеры | Гомуми сан | Абсолют сан | Татарча сүзләр | | | | Халыкара инт. | | | | Русча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гомуми | % | | % | | % | | | | % | | |
| «Идарәдән» газетасының бурычлары турында | 1 | 128 | 97 | 90 | 70,36 | 71 | 73,32 | 5 | 3,9 | 4 | 4,12 | 2 | 1,56 | 1 | 1,03 |
| «Оренбург» хәбәрләре | 3 | 139 | 115 | 79 | 36,80 | 68 | 59,16 | 13 | 9,36 | 8 | 6.9 | 9 | 5,48 | 7 | 6,09 |
| социализм | 6 | 515 | 290 | 364 | 71,31 | 223 | 77,20 | 28 | 5,32 | 9 | 3,0 | 11 | 2,09 | 8 | 2,72 |
| Шәкертләргә ачык хат | 15 | 372 | 243 | 254 | 68,19 | 183 | 75,38 | 13 | 3,51 | 6 | 2,47 | 9 | 2,48 | 7 | 2,88 |
| Идарәгә килгән хатлар | 26 | 143 | 121 | 93 | 60,0 | 80 | 63,1 | 9 | 7,2 | 4 | 3,6 | 1 | 0,8 | 1 | 0,9 |
| Барлыгы | 5 | 1297 | 866 | 880 | 69,4 | 625 | 72,2 | 68 | 6,3 | 31 | 3,8 | 32 | 2,5 | 24 | 2,8 |

Таблицаның дәвамы

| Гарәп-фарсы | | | | Бүтән сүзләр | | | | Төрле телләр | | | | Ялгызлык исемнәр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми | % | Гомуми | % | Гомуми | % | | % | | % | | % | | | | |
| 30 | 23,4 | 20 | 26,6 | – | – | – | – | – | – | – | – | 1 | 0,78 | 1 | 1,03 |
| 27 | 19,44 | 21 | 18,27 | – | – | – | – | 2 | 1,44 | 2 | 1,74 | 9 | 6,48 | 9 | 7,84 |
| 111 | 21,09 | 49 | 16,66 | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | 1 | 0,34 |
| 89 | 24,03 | 44 | 48,04 | – | – | – | – | 1 | 0,27 | 1 | 0,41 | 6 | 1,62 | 2 | 0,82 |
| 39 | 31,2 | 15 | 31,5 | – | – | – | – | – | – | – | – | 1 | 0,8 | 1 | 0,9 |
| 296 | 29,3 | 169 | 29,3 | – | – | – | – | 3 | 0,2 | 3 | 0,4 | 17 | 0,1 | 14 | 0,2 |

Шул ук «Урал» газетасы тарафыннан «Урал көтепханәсе» исеме астында русчадан тәрҗемә ителеп, 5 данә экономик-политик брошюралар да басылып таратылдылар.

Болардан башка татар пролетариат матур әдәбиятының беренче карлыгачы булып 1908 елда Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер» исемле пьесасы басылды. Бу инде татар пролетариат әдәби теленең матур әдәбиятта беренче күренеше иде. Менә татар пролетариат әдәби теленең капитализм шартлары эчендә булган байлыгы шушылардан гыйбарәт иде.

## II. ОКТЯБРЬДӘН СОҢ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ

Татар әдәби теленең үсүе өчен таза җирлек һәм киң шартлар бары Октябрь революциясеннән соң гына туды. Октябрь революциясеннән соң рус империализмы җимерелеп, аның урынына пролетариат диктатурасы, Советлар системасы урнашу факты – бу үзе эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли булган татар әдәби теленең үсүендә иң көчле фактор була. Пролетариатның һәм аның җитәкчесе булган коммунистик партиянең Ленин-Сталинча милли политикасы милли культура һәм милли телгә карашы билгеле һәм ачык. Милли культура һәм милли телләр мәсьәләсе коммунистик партия съездларында, конференцияләрендә һәрвакытта аерым төр мәсьәләләрдән булып килделәр.

Партиянең XVI съездында иптәш Сталин:

«Без киләчәктә милли культураларны, уртак бер тел белән уртак (формасы ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да) бер культурага кушу ягында торабыз, шуның белән бергә, без хәзерге вакытта, пролетариат диктатурасы чорында, милли культураларның чәчәк атуы ягында торабыз. Бу гаҗәп тоелырга мөмкин. Ләкин монда гаҗәпләнерлек бернәрсә дә юк. Барлык культураларны уртак бер тел белән уртак бер культурага кушу шартларын тудыру өчен, милли культураларга, үзләренең барлык потенцияләрен ачарак, яшәргә һәм киңәергә юл бирергә кирәк. Пролетариат бөтен дөньяда җиңгәч, социализм көнкүрешкә кергәч, формасы ягыннан милли, эчтәлеге ягыннан социалистик булган милли культураларны уртак бер тел белән уртак социалистик (формасы ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да) бер культурага кушу өчен, бер илдә пролетариат диктатурасы шартларында аларның чәчәк атуы – милли культура турындагы мәсьәләнең ленинча куелышы диалектикасы менә шуннан тора да» – ди.

Димәк, Коммунистик партиянең һәм Социалистик Советлар Союзы хөкүмәтенең Ленин-Сталинча милли политикасы буенча пролетариат диктатурасы һәм СССРда социализм төзелеше чорында эчтәлеге буенча социалистик булган милли культуралар һәм милли телләрнең үсүләре, чәчәк атулары алдан ук тәэмин ителгән иде.

Коммунистик партиянең һәм Социалистик Советлар Союзы хөкүмәтенең менә шушы Ленин-Сталинча милли политикасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы төзелде. Бөтен Союз илендәге республикалар һәм өлкәләр белән янәшә Татарстан Республикасында да промышленность үскәннән үсә бара. Татарстан Республикасы алдынгы индустриаль республикалар һәм өлкәләр сафына килеп басты. Җирле пролетариат кадры үсә һәм ныгый.

Авыл хуҗалыгы социалистик нигездә яңадан корыла. Хәзерге көндә Татарстанда 47 совхоз һәм 3800 колхоз бар. Элекке ярлы һәм урта хәлле хуҗалыкларның 78,1 проценты колхозда.

Культура өлкәсендә татар хезмәт ияләренең уңышлары тагы да зур. Бу уңышлар тагы да зур. Бу уңышлар формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булган культураның гомуми үсеше белән характерлана.Татар хезмәт ияләре арасында грамоталылык күтәрелде. 7 еллык гомуми-мәҗбүри уку кертелде. Урта һәм югары уку йортларында татар хезмәт ияләренең саны арткannan-арта бара. Татар хезмәт ияләре арасыннан фән эшчеләре, техник инженерлар, агрономнар җитештеләр. Матбугат, матур әдәбият, театр, кино, радио киң күләмдә җәелде. Татар хезмәт ияләре Союз илендәге башка хезмәт ияләре белән бергә туганнарча социалистик җәмгыять, сыйныфсыз җәмгыять төзү эшендә актив катнашалар.

Бөтен Союз илендәге, аның органик бер өлеше булган Татарстан Республикасындагы менә бу социаль-экономик үзгәреш һәм үсеш татар әдәби теленә дә, әлбәттә, йогынты ясады, аның үсүе өчен кискен этәреш бирде. Пролетариат диктатурасы һәм социалистик төзелеш чорында татар әдәби теле үзенең үсешендә революцион сикереш ясады. Бу чор эчендә татар әдәби теле интернациональ юнәлеш алып, татар хезмәт ияләренең үз телләре, совет-интернациональ тел байлыклары җирлегендә сан һәм сыйфат ягыннан бик нык үсте.

«Совет власте, – ди ип. Сталин, – сыйнфый җәмгыять, дәүләт оешмаларының һәммәсеннән дә артыграк интернационалистик

булып тора, чөнки ул һәртөрле милли кысынкылыкны җимерәчәк һәм төрле милләт хезмәт ияләре массаларының бердәмлегенә таяначак, шуның үзе белән үк бу массаларның бер дәүләт союзында берләшүләрен җиңеләйтә».

Совет властеның сыйнфый җәмгыять дәүләт оешмаларының һәммәсеннән дә артыграк интернационалистик булуы, билгеле, телгә дә интернациональ юнәлеш бирде. Татар әдәби теле феодализм һәм капитализм формацияләрендә хезмәт ияләрен эксплуатацияләү коралы булып хезмәт иткән булса, пролетариат диктатурасы чорында ул барлык хезмәт ияләренең үзләре өчен, социализм һәм сыйныфсыз җәмгыять төзү өчен хезмәт итә. Татар әдәби теле хәзер яңа кешелек җәмгыяте өчен, яңа кешеләрнең яңа хокуклары өчен, ирекле һәм аңлы хезмәт өчен көрәш коралы булып үсә һәм ныгый.

Татар әдәби телендәге бу революцион үсеш, үсеш процессындагы бу яңа юнәлеш аның сүзлек составында тагы да ачыграк чагыла. Революциядән соң әдәби телнең сүзлек составы бик нык үзгәрде, сан һәм сыйфат ягыннан бик нык үсте. Бу өлкәдә аеруча зур уңышлар бар.

Билгеле, әдәби телнең һәм аның җирлегеннән гыйбарәт булган сүзлек составының бу үсеш процессы, социалистик төзелешнең барлык тармакларында булган кебек, көчле сыйнфый көрәш шартларында барды һәм бара.

Революциянең беренче елларында әдәби телдә, бигрәк тә аның сүзлек составында, билгеле вакытларгача буржуа әдәби теле калдыклары яшәп килде. Капитализм формациясеннән калган тел мирасына Маркс-Энгельс-Ленин-Сталин тәгълиматы буенча критик күз белән карый алмау яки тиешле бәя бирә белмәү аркасында кайбер язучыларның телләрендә буржуа әдәби телендә генә табыла ала торган мистика образларын, милләтчелек һәм вак милекчелек тәкбирләрен очратырга була иде. Мисал өчен, түбәндәге өземтәләрне күрсәтергә мөмкин:

*Җәһәннәмдән эссе утларында*
*Чуен эреп су булып ага,*
*Каты корыч анда бер минутта*
*Әйләнәдер юка тактага.*
*Тышта зәмһәрирдән салкын икән,*
*Эчтә һавиядән эссерәк,*

*Анда тәгәрәп торган машиналар*
*Дию пәриеннән көчлерәк.*

(М. Гафури. «Эшче» поэмасыннан)

*Төн уртасы. «Гакыйль» уйлап ята:*
*Җир өстендә җәннәт төзергә*
*Көчле кулы белән табигатьнең*
*Барлык богауларын өзәргә.*

(Һ. Такташ. «Эшлиләр» дигән шигыреннән)

*Тәкбир әйтте шунда җир, күк бергә,*
*Тәһлил әйтте, дөнья тетрәде,*
*Изге көчкә мәңге эш сорады,*
*Тәкъбир әйтте, сәма күкрәде.*

(Ф. Бурнаш. «Эш иртәсе» дигән шигыреннән)

*Без – яшь көчләр! Кулыбызда кояш яна,*
*Без – Аллалар! Тормыш бары бәхет безгә!*

(Н. Исәнбәт шигыреннән)

Менә бу мисаллар һәммәсе дә пролетариат диктатурасы шартларында язылып басылган әсәрләрдән алынды. Боларда һәм революциянең беренче елларында чыккан башка байтак әсәрләрдә, *җәһәннәм, зәмһәрир, һавия, дию пәрие, тәкбир, тәһлил, без – Аллалар* һ. б. кебек, пролетариат каршына бөтенләй ят идеология белән сугарылган сүзләрне байтак очратырга була. Биредә мондый сүзләр пролетариат телендә бөтенләй кулланылырга тиеш түгел, дигән фикер аңлашылып калмасын. Телнең сүзлек составы билгеле бер чорның җәмгыятьчелегенә бәйләнгән сүзләр белән генә чикләнеп калмый. Тел капалы бер күренеш түгел, анда икенче төрле җәмгыятьчелеккә җавап бирә торган сүзләр дә үзләренә урын алалар, ләкин мондый сүзләр, бу яки теге дәрәҗәдә саклансалар да, нигездә, үзләренең мәгънәләре, идеологик төсләре яки алардан файдалану характерлары белән үзгәреп кулланылалар һәм шулай гына куланылырга тиешләр дә.

Октябрь революциясеннән соңгы әдәби телдә мондый хәлләр вакытлы күренешләрдән генә гыйбарәт иде. Әдәби тел әкренләп феодалчылык һәм милләтчелек чүпләреннән тазартылды һәм һаман тазартыла бара.

Хәзерге татар әдәби теле үсеш процессында үзенең төп юнәлешен билгеләү юлында, бер яктан, җирле милләтчелек күренеше, икенче яктан, олы державачыл шовинизмы тарафыннан, кайча-

гында астыртын, кайчагында ачыктан-ачык рәвештә төрле каршылыкларга очрады.

Бу көрәш, бер яктан, татар теленең тәрбия һәм укыту эшләрендәге әһәмиятен танымаучы олы державачыл элементларның татар әдәби телен русизм белән тутырырга омтылуларында, икенче яктан, буржуаз-милләтче элементларның, солтангалиевчеләр һәм сәгыйдуллинчыларның татар телен катып калган иске формаларында сакларга омтылуларында күренде. Бу буржуаз-милләтче элементлар массага аңлаешсыз иске гарәп һәм фарсы терминнарын сакларга, гомерләре беткән үлек сүзләрне тергезергә, катып калган иске формалар нигезендә «ясалма сүзләр» тудырырга тырыштылар, татар әдәби телен үстерү эшендә хәзерге рус әдәби теленең әһәмиятен искә алмаска маташтылар, ә шул ук вакытта совет чынбарлыгы аша сикереп, «интернационаллашу»га омтылдылар. Билгеле, партия һәм совет властеның тел политикасына каршы көрәш алып барган бу адымнар Татарстан партия оешмасы тарафыннан каты типкен ала килделәр һәм төзәтелә бардылар.

Октябрь революциясеннән соң җәмгыятьнең төзелеше үзгәрү белән бергә бәйләнеп, әдәби телнең төзелеше дә үзгәрде. Телдәге бу үзгәреш һәммәсеннән элек аның сүзлек составында ачыграк чагылды.

Үзләрендә патшалык төзелешен чагылдырган *старшина, урядник, полицейский, справник, становой, пристав, политсеместр, губернатор, патша җәнап галиләре, әфәндем хәзрәтләре*... кебек бик күп сүзләр һәм терминнар хәзер архивка ташландылар. Хәзер пролетариат диктатурасының дәүләт формасы булган Совет власте төзелешен чагылдыра торган *совет, съезд, председатель, секретарь, Башкарма комитет, үзәк комитет, милиционер, комиссар, Халык комиссарлары советы*... кебек яңа сүзләр, яңа терминнар урнаштылар.

Сүзлек составы социаль мөнәсәбәтләр, производство, көнкүреш, җәмгыятьчелек һәм идеология формалары үзгәрү белән алмашына бара. Феодализм һәм капитализм формациясендә гарәп һәм фарсы телләреннән кергән *тәһарәт, намаз, җомга, гает, корбан, фытыр*... кебек дини терминнар телдә югалалар. Пролетариат карашына капма-каршы булган элекке бик күп сүзләрнең функцияләре һәм куллану шартлары үзгәрә. *Хәзрәт, мулла, остазбикә, мәхдүм, мәхдүмә, хәлфә, ишан, суфый, мирза*... кебек сүзләр элек буржуа

әдәби телендә хөрмәтләү һәм олылау сүзләре булып йөрсәләр, хәзер алар я ирония, яки тарихи сүзләр буларак файдалану өчен генә кулланылалар. Элекке көнкүрешкә бәйләнешле *көндәш, асрау, им-том, җиләп, чапан, чалма, бөти, ячуы*... кебек сүзләр дә хәзер хезмәт массасының тел-аңында акрынлап ят булып баралар.

Әдәби телнең сүзлек составы кайбер сүзләрнең үлүләре, югалулары, кайбер сүзләрнең туулары белән генә үзгәреп калмый, бәлки бу үзгәреш элекке кулланылып килгән кайбер сүзләрнең мәгънәләрендә һәм кулланылу функцияләрендә дә чагылырга мөмкин.

Октябрь революциясеннән соң кайбер сүзләр үзләренең сүзлек мәгънәләренә караганда бөтенләй икенче төрле мәгънәдә кулланыла башладылар. Мәсәлән, *йомгак* (*җеп йомгагы* – сөйләнгән фикернең йомгагы), *кадак* (*дага кадагы* – көн кадагы), *баскыч* (*агач баскыч* – беренче баскыч) һ. б.

Кайбер сүзләрнең мәгънәләре киңәйде. Мәсәлән, *фронт (сугыш фронты, культура фронты), көрәш (батырлар көрәше – социализм өчен көрәш), өзеклек (юл өзеклеге – производстводагы өзеклек*) һ. б.

Кайбер сүзләрнең мәгънәләре конкретлашты. Мәсәлән, *эшче* (элек ялланып эшләгән һәрбер кеше, хәзер производствода эшләүче), *укытучы* (элек бала укыткан һәрбер кешегә әйтелә иде, хәзер укыту эшен үзенә профессия итеп алган кеше) һ. б.

Октябрь революциясеннән соң әдәби тел сүзлек составының үсүе электәге сүзләрнең мәгънәләре үзгәрү, киңәю яки конкретлашу белән генә, әлбәттә, калмады, бәлки социаль-экономик шартлар үзгәрү, культура үсү нәтиҗәсендә туган яңа аң, яңа төшенчәләрне аңлату өчен, аның күләме дә сан һәм сыйфат ягыннан бик нык үзгәрде, бик нык үсте. Хәзерге әдәби телдә сүзлек составы арту һәм баю процессы, гомумән, телләрнең өске диалектик үсеш сызыгы буенча, бер яктан, үзенең мирасыннан файдалану, икенче яктан, башка тел коллективларыннан яңа сүзләр, яңа терминнар алу юлы белән бара.

Әдәби телдә иске мирастан файдалануда, шулай ук икенче тел коллективларыннан яңа сүзләр, яңа терминнар алуда һәр тел коллективының закон урынында йөри торган билгеле бер тел нормасы була. Бу норма гадәттә әдәби телдә билгеле бер юнәлеш бирә, шуңа күрә һәрбер сыйныф бу норманы үзенчә, үзенең социаль-политик программасына, юлбашчы идеясенә карап билгели.

Капитализм формациясендә бу норманың татар буржуа милли хәрәкәтенең юлбашчы идеясе булган пантюркизм нигезендә оешка-

нын һәм гомумән әдәби телнең, аерым алганда, аның сүзлек составының шушы норма буенча үскәнен күрдек.

Октябрь революциясеннән соң социаль-экономик шартлар алмашыну белән, капитализм формациясендәге әдәби тел өчен булган бу нормалар да, әлбәттә, үзгәрде. Хәзерге әдәби тел үсешендәге бу норманың 1933 елда стабиль дәреслекләр төзү эшенә керешелү уңае белән, Татарстан Халык Мәгариф Комиссариаты, үткән этапларның тәҗрибәләрен, хәзерге татар әдәби һәм сөйләү теленең үсеш тенденциясен исәпкә аларак, түбәндәгечә билгеләгән иде:

«Хәзерге татар әдәби теле терминнарын тудыру һәм унификацияләү эшендә шушы чыганакларны нигез итеп алырга:

а) хәзерге татар әдәби һәм сөйләү теле;

б) интернациональ социаль-политик терминнар;

в) хәзерге рус әдәби теле терминнары.

Бу чыганаклардан түбәндәге прициплар буенча файдаланырга:

1. Билгеле төшенчәләрне аңлату өчен барыннан да элек хәзерге татар әдәби һәм сөйләү телендәге байлыкларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әдәби һәм сөйләү телендә теге яки бу төшенчәгә тулысынча һәм төгәленчә уйгын килә торган сүз һәм терминнар булганда, термин итеп шулардан файдаланырга кирәк. Татар әдәби теле терминологиясен үстерү эшендә, татар теленең үз грамматик чараларыннан да файдаланып, яңа терминнар тудыру методын куллану да кирәкле дип санарга, ләкин катлаулы – авыр, читен аңлаешлы сүзләр ясауга һәм гомерләре беткән иске сүзләмең тергезергә бармаска.

2. Социаль-политик фәннәр өлкәсендәге интернациональ терминнар Совет чоры рус әдәби телендә кулланыла торган формаларында алырга кирәк.

3. Фәнни-техник терминология өлкәсендә, һәр фәннең спецификасын исәпкә аларак, совет чынбарлыгында кулланыла торган халыкара фәнни-техник терминнарны файдаланырга. Шуның белән бергә, татарча фәнни-техник терминологиясен русча шундый ук терминология белән бердәм булуына омтылырга кирәк.

4. Югарыда саналган чыганакларда теге яки бу төшенчәгә тулысынча уйгын килердәй терминнар һәм сүзләр булмаганда һәм татар теленең үз чаралары белән ясау да максатка җавап бирерлек булмаганда, русча терминнар куллануны мөмкин һәм кирәкле санарга. Ләкин кирәксезгә русча сүзләр алуга каршы, шулай ук татар әдәби телен рус сүзләре белән авырлаштыруга каршы, шулай ук

урынсызга рус телендәге сүз ясалышы формалары куллануга каршы кискен көрәш алып барырга кирәк.

5. Интернациональ, халыкара һәм русча терминнарны, аларны термин килеш кулланыла торган формаларында шушы составына кергән барлык элементлары белән алырга, шул килеш алынган терминнар нигез буларак унификацияләнәләр, ә болардан ясала торганнар да татар теленең грамматик үзенчәлекләренә ярашлы рәвештә формалаштырылалар.

Димәк, хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы, бер яктан, татар хезмәт ияләренең үз теле җирлегендә үсә һәм бу үсеш ике төрле юл белән бара:

1. Татар хезмәт ияләренең үз телендә булган әзер сүзләрдән файдалану юлы белән. Бу юл белән Октябрь революциясеннән соң татар әдәби теле феодализм һәм капитализм формацияләрендә кергән һәм хезмәт ияләренә аңлаешсыз булган гарәп, фарсы һәм төрек сүзләреннән бик нык тазартылды һәм һаман тазартыла. Октябрьгәчә татар әдәби телендә кулланыла торган *сәнә, һәфтә, лисан, инсан, иҗтимагый, мөҗтәһид, мөбаләга, истигъдад, истикбаль, мөнтәзем, тәхсил, әлхасыйль, фәүкылгадә, мәгаттәссеф, бәни бәшәр, мәдрәсәи галия, суҗык, кәнеҗ...* кебек санап бетергесез гарәп, фарсы һәм төрек сүзләре татар хезмәт ияләренең үз телләре белән алмаштырылдылар. *Йомгак, кыскарту, корткыч, уңыш, ярыш, көрәш...* кебек сүзләр үзләренең элекке сүзлек мәгънәләрендә калу белән бергә, яңа конкрет төзелеш шартларында туган яңа төшенчәләргә билгеләнделәр.

2. Татар теленең үз грамматик чараларыннан файдаланып, гади, ясалма, кушма һәм кыскартма яңа сүзләр ясау юлы белән. Октябрьгәчә бу юл белән татар әдәби теленең сүзлек составын баету бөтенләй юк дәрәҗәсендә иде. Әдәби телдә билгеле бер система белән кыскартып яңа сүзләр ясау факты бөтенләй очрамый, ике тамырны кушу һәм кушымчалар ялгау юлы белән сүз ясауда бик сирәк һәм стихия рәвешендә генә бара иде. Әдәби телдә яңа сүз иҗады процессы бары Октябрьдән соң гына билгеле принциплар буенча активлашып һәм җанланып китте. Хәзерге әдәби телдә бу өлкәдә чиксез зур уңышларыбыз бар.

Халыкара һәм интернациональ сүзләр хәзерге татар әдәби теле сүзлек составы үсешендә аерым әһәмиятле фактор булып тора. Халыкара һәм интернациональ сүзләр феодализм формация-

сендәге татар язма – әдәби телендә бөтенләй очрамыйлар, капитализм формациясендә бераз күренә башласалар да, ләкин алар билгеле бер принцип буенча түгел, бәлки очраклы рәвештә генә кергән сүзләрдән генә гыйбарәт була. Халыкара һәм интернациональ сүзләргә татар әдәби телендә киң урын бары Октябрьдән соң гына бирелде. Алар хәзерге әдәби теленә татар хезмәт ияләренең техника һәм культура үсеше белән бергә бәйләнеп, билгеле бер принцип һәм билгеле систем белән алыналар һәм татар хезмәт массасы тарафыннан җиңел үзләштереләләр. Халыкара һәм интернациональ сүзләрнең татар әдәби теленә керүләре һәм масса тарафыннан җиңел үзләштерелүләре исә хәзерге татар әдәби теленең үсеш тенденциясен интернациональ юнәлеш белән барганын күрсәтә.

Татар әдәби теле сүзлек составының үсешендә рус теленең дә билгеле бер үлчәүдә катнашы бар. Руслар белән татарлар күптәннән бирле бергә яшәүләре нәтиҗәсендә, бу ике телнең дә үзара бер-берсенә йогынтылары көчле булды. Башта татар теле рус теленә бераз йогынты ясаган булса, аннан соң, киресенчә, рус теле татар теленә тагы да көчлерәк йогынты ясады, ләкин бу йогынты Октябрьгәчә сөйләү телендә генә чагыла иде. Әдәби телдә исә феодализм формациясендә бөтенләй күренмиләр дип әйтерлек, капитализм формациясендә дә аларга бик аз урын бирелә иде, хәтта турыдан-туры дәүләт төзелешенә бәйләнешле һәм сөйләү телендә бик нык үзләштерелгән *губерна, губернатор, өяз, завод* кебек сүзләр урынына гарәпчә яки фарсыча *вилаять, вали, нәхия, кархана* сүзләре кулланылдылар.

Хәзер югарыдагы анализны экспедиция материалларыннан алынган цифрлар һәм процентлар белән чагыштырып карыйк. Чагыштыру өчен биредә, бер яктан, матур әдәбият, икенче яктан, вакытлы матбугат, дәреслекләр һәм тәрҗемә теле алынды. Түбәндә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ыннан, К. Нәҗминең «Кояшлы яңгыр»ыннан, Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар»ыннан, М. Крыймовның «Җырларымны бирәм күмәргә»сеннән, К. Тинчурин белән Ишморатның «Тургай»ыннан, шул ук К. Тинчурин белән К. Нәҗминең «Булат бабай» әсәреннән алынган өземтәләрнең сүзлек составын күрсәткән таблица бирелде (табл. 4).

Димәк, 5656 сүздән 87,3% – татарча, 2,0% – халыкара, 2,5% – русча, 5,5% – гарәпчә һәм фарсыча сүзләр килеп чыгалар.

Таблица 4. Октябрьдән соңгы матур әдәбият теленең сүзлек составы

| Әсәрнең исеме | Газета номеры | Гомуми сан | Абсолют сан | Татарча сүзләр | | | | Халыкара инт. | | | | Русча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гомуми | % | | % | | % | | | | % | | |
| «Эшче» | М. Гафури | 360 | 220 | 325 | 89,31 | 197 | 89,57 | – | – | – | – | 3 | 0,81 | 2 | 0,9 |
| «Тирән тамырлар» | Г. Ибраһимов | 2000 | 1480 | 1770 | 88,5 | 1270 | 85,5 | 8 | 0,4 | 8 | 0,5 | 32 | 1,6 | 30 | 2,0 |
| «Кояшлы яңгыр» | К. Нәҗми | 1563 | 1060 | 1312 | 83,94 | 921 | 86,88 | 48 | 3,1 | 18 | 1,7 | 49 | 3,19 | 39 | 3,66 |
| «Киләчәккә хатлар» | Һ. Такташ | 993 | 578 | 820 | 82,6 | 491 | 83,9 | 52 | 5,3 | 23 | 4,0 | 29 | 2,9 | 12 | 2,2 |
| «Җырларымны бирәм күмәргә» | М. Крыймов | 765 | 513 | 664 | 86,07 | 460 | 89,88 | 19 | 2,87 | 16 | 3,04 | 35 | 4,56 | 12 | 2,43 |
| «Тургай» | Тинчурин Ишморат | 1000 | 464 | 712 | 71,2 | 370 | 79,74 | 70 | 7,0 | 23 | 4,95 | 49 | 4,9 | 23 | 4,95 |
| «Булат бабай семьясы» | Тинчурин К. Нәҗми | 2236 | 1341 | 1858 | 83,05 | 1224 | 91,38 | 68 | 3,05 | 21 | 1,45 | 34 | 1,53 | 32 | 2,39 |
| 7 әсәр | барлыгы | 8917 | 5656 | 7361 | 83,7 | 4937 | 87,3 | 265 | 2,97 | 109 | 1,93 | 231 | 2,59 | 150 | 2,5 |

Таблицаның дәвамы

| Гарәп-фарсы | | | | Бүтән сүзләр | | | | Төрле телләр | | | | Ялгызлык исемнәр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | | % | гомуми | % | | % | | | | |
| 31 | 8,91 | 20 | 9,08 | – | – | – | – | 1 | 0,27 | 1 | 0,45 | – | – | – | – |
| 130 | 6,5 | 118 | 0,8 | – | – | – | – | 6 | 0,3 | 6 | 0,8 | 54 | 2,7 | 48 | 3,2 |
| 69 | 4,39 | 50 | 4,7 | 1 | 0,06 | 1 | 0,9 | 1 | 0,06 | 1 | 0,09 | 84 | 5,37 | 32 | 3,01 |
| 68 | 8,8 | 43 | 7,7 | – | – | – | – | – | – | – | – | 4 | 0,4 | 1 | 0,2 |
| 41 | 5,33 | 30 | 5,0 | – | – | – | – | – | – | – | – | 6 | 1,17 | 5 | 0,95 |
| 41 | 4,1 | 26 | 5,6 | – | – | – | – | 1 | 0,1 | 1 | 0,21 | 127 | 12,7 | 21 | 4,52 |
| 58 | 2,61 | 33 | 3,21 | – | – | – | – | – | – | – | – | 218 | 9,76 | 21 | 1,57 |
| 438 | 4,9 | 310 | 5,5 | 1 | 1 | | 1 | 9 | | 9 | | 493 | | 128 | |

Бу цифрлар һәм процентлар матур әдәбият теленең, тулаем алганда, хәзерге татар әдәби теленең үсеш тенденциясе буенча бик нормаль һәм тигез үлчәүдә үсеп барганын күрсәтәләр. Биредә М. Гафуриның «Эшче» поэмасыннан алынган өземтәдә халыкара сүзләрнең бөтенләй очрамавы, русча сүзләрнең проценты да бик аз килеп чыгуы, ә гарәпчә һәм фарсыча сүзләрнең 9% ка кадәр җитүе, бу әсәрнең революция башларында ук язылган булуы белән характерлана.

Хәзер вакытлы матбугат теленең сүзлек составын тикшереп карыйк. Биредә «Кызыл Татарстан» белән «Кызыл яшьләр»дән һәм ОМКУЗ эшчеләре тарафыннан чыгарыла торган күп тиражлы «Мехчы» белән Арча районы «Авангард» колхозчылары массасы тарафыннан чыгарыла торган стенгазетадан алынган өземтәләрнең сүзлек составын күрсәткән янәшә ике таблица бирелә (табл. 5, 6).

Таблица 5

| Газеталарның исеме | Гомуми саннар | Татар сүз. | | Халыкара инт. | | Рус сүз. | | Гарәп-фарсы | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Кызыл Татарстан» I–IV – 35 ел | 797 | 555 | 69,6 | 72 | 9,1 | 88 | 11,0 | 82 | 10,3 |
| «Кызыл яшьләр» II–IV – 35 ел. № 46 | 460 | 270 | 28,7 | 102 | 22,2 | 58 | 12,6 | 30 | 6,5 |
| Шулардан барлыгы | 1257 | 825 | 64,1 | 174 | 15,6 | 146 | 11,8 | 112 | 8,4 |

Бу таблицалар хәзерге вакытлы матбугат телен бер үк юнәлеш, бер үк үсеш тенденциясе буенча үсеп барганын ачык күрсәтеп торалар. Икенче таблицада эшчеләр тарафыннан чыгарыла торган күп тиражлы «Мехчы» газетасының теле үзәк газеталарның теленә, ә «Авангард» колхозлары массасы тарафыннан чыгарыла торган стена газетасының теле сөйләү теленә якынрак торганы күренә.

Бу цифрлар һәм процентлар югарыда күрсәтелгән «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарыннан алынган өземтәләрнең сүзлек составлары белән чагыштырып карасак, болар арасында бик зур аерма барлыгын күрәбез. Хәзерге газеталарның телендә, барысын җыеп алганда, татарча сүзләрнең – 20% ка, халыкара һәм интернациональ сүзләрнең – 11,3% ка, русча сүзләрнең – 9,2 гә артканы, ә гарәпчә һәм фарсыча сүзләрнең, киресенчә, 21,8% ка кимегәне күренә.

Түбәндә фән-техника теле белән тәрҗемә теленең сүзлек составларын күрсәткән тагын ике таблица бирелә (табл. 7, 8).

Таблица 6. Күп сүзлек составын тиражлы һәм стена газеталары күрсәтә

| Газеталарның исеме | Гому-ми сан | Абсо-лют сан | Татарча | | | | Халыкара инт. | | | | Русча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | гому-ми | % | | % | | % | | | | % | | |
| «Мехчы» газетасы №8 (290) | 311 | 205 | 233 | 77,9 | 160 | 78 | 34 | 10,9 | 16 | 7,8 | 14 | 4,5 | 10 | 4,8 |
| «Авангард» колхоз стенгазетасы | 3481 | 1013 | 2478 | 71,0 | 702 | 69,4 | 304 | 9 | 62 | 6,1 | 195 | 5,5 | 86 | 8,4 |
| Барлыгы | 3792 | 1218 | 2711 | 72,9 | 862 | 73,3 | 338 | 9,9 | 78 | 6,9 | 209 | 5,0 | 96 | 6.6 |

Таблицаның дәвамы

| Гарәп-фарсы | | | | Бүтән сүзләр | | | | Төрле телләр | | | | Ялгызлык исемнәр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гому-ми | % | | % | гому-ми | % | | % | | % | | % | | | | |
| 24 | 7,7 | 15 | 7,4 | – | – | – | – | 1 | 0,4 | 1 | 0,5 | 5 | 1,6 | 3 | 1,5 |
| 213 | 9,0 | 73 | 7,1 | – | – | – | – | 132 | 4,0 | 70 | 7,0 | 54 | 1,5 | 20 | 2,0 |
| 342 | 8,3 | 88 | 7,2 | – | – | – | – | 133 | 2,2 | 71 | 3,7 | 59 | 1,5 | 23 | 1,7 |

Таблица 7 (Мехларны буяу – Г. Хөсәен, Кешенең анатомия һәм физиологиясе – Җан Сәгъди, Физика – Шонаси, Физика – Гәлиев, География – Б. Захиров тәрҗемәләре)

| № | Сүзләр | Гомуми | | Абсолют | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сан | % | сан | % |
| 1. | Татарча сүзләр | 1406 | 67,8 | 1149 | 80,4 |
| 2. | Халыкара-интер. | 216 | 10,4 | 72 | 5,2 |
| 3. | Русча сүзләр | 87 | 4,2 | 26 | 1,7 |
| 4. | Гарәп-фарсы | 292 | 14,1 | 128 | 8,9 |
| 5. | Бүтән телләрдән | 2 | 0,1 | 2 | 0,2 |
| 6. | Төрле телләрдән | 60 | 2,9 | 43 | 3,0 |
| 7. | Ялгызлык исемнәр | 12 | 0,5 | 9 | 0,6 |
| 8. | Шулардан барлыгы | 2075 | 100 | 1429 | 100 |

Таблица 8. Тәрҗемә теленең сүзлек составы (ип. Сталинның XVII партия съездында сөйләгән докладыннан өземтә, татарча, II басма)

| Сүзләр | гомуми | % | абсолют | % | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарча сүзләр | 414 | 60,80 | 198 | 70,82 | 21 | 42,88 |
| Халыкара-интернац. | 47 | 7,58 | 20 | 6,71 | 10 | 20,40 |
| русча | 22 | 3,54 | 14 | 4,69 | 11 | 22,44 |
| Гарәп-фарсы | 103 | 16,61 | 42 | 14,09 | 3 | 6,12 |
| Бүтән тел-ләрдән | 2 | 0,32 | 2 | 0,67 | – | – |
| Төрле телләрдә | 12 | 1,93 | 9 | 3,02 | 2 | 4,08 |
| Ялгызлык исемнәре | 20 | 3,32 | 13 | 4,36 | 2 | 4,08 |
| Шулардан бар-лыгы | 620 | 100 | 298 | | 49 | |

Бу таблицаларда да татарча, халыкара һәм русча сүзләрнең процентлары, хәзерге әдәби телнең гомуми үсеш тенденциясе буенча караганда, бик нормаль һәм шактый ук тигез үлчәүдә торалар, тик тәрҗемә телендә генә гарәпчә һәм фарсыча сүзләрнең проценты артыграк күренә. Бу күренеш бер дәрәҗә гаҗәп тоелырга мөмкин, ләкин биредә гаҗәпләнерлек бернәрсә дә юк. Тәрҗемә телендә

гарәпчә һәм фарсыча сүзләрнең процентын тәрҗемә вакытында күбрәк кулланыла торган *һәм, ләкин, бәлки, чөнки, кадәр, ягъни, мәсәлән, гыйбарәт, ниһаять* кебек башлыча ярдәмлек сүзләр күтәрәләр.

Хәзерге татар әдәби теленең терминология өлкәсендә, фәнни тел эшләнү өлкәсендә тагы да зур уңышлар бар. Бу өлкәдә татар әдәби теленең югарыдагы принциплар буенча чынлап та кискен бер эзгә төшкәнен тагы да ачык күрергә мөмкин. Чагыштыру өчен биредә 1934 елгы стабиль дәреслекләр буенча грамматика, математика, физика һәм биология фәннәреннән алынган терминологиянең сүзлек составын күрсәткән таблица бирелде.

Таблица 9. Грамматика, математика, физика һәм биология фәннәреннән алынган терминологиянең сүзлек составы

| Фәннәр | Сан | Татарча | Халыкара | Русча | Гарәп-фарсы | Катнаш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Грамматика | 175 | 40,0 | 9,7 | – | 14,3 | 36,0 |
| Математика | 200 | 52,5 | 32,0 | – | – | 15,5 |
| Физика | 175 | 45,1 | 30,3 | 1,6 | 2,5 | 30,5 |
| Биология | 200 | 74,5 | 18,0 | 1,5 | 4,5 | 2,0 |
| Барлыгы | 750 | 53,0 | 22,0 | 0,7 | 5,3 | 20,0 |

## III. ТАТАР ЭШЧЕ, КОЛХОЗЧЫЛАРЫНЫҢ СӨЙЛӘҮ ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИ ТЕЛЕ АРАСЫНДА ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШ

Октябрь революциясеннән соң Россиядә пролетариат диктатурасы, Советлар системасы урнашу аркасында бөтен татар хезмәт ияләренең башка хезмәт ияләре белән берлектә Советлар илен идарә итү һәм социалистик җәмгыять төзү эшенә актив катнашулары, партиянең Ленин-Сталинча милли политикасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы төзелү белән татар хезмәт ияләренең бер үзәккәрәк тупланулары, Татарстан Республикасында да промышленностьның алга китүе, алдынгы индустриаль республикалар һәм өлкәләр сафына барып басып, татар пролетариат кадрының үсүе һәм ныгуы, авыл хуҗалыгының социалистик нигездә яңадан корылып, татар крестьяннарының колхозларга берләшүләре – менә бу социаль-экономик шартлар һәммәсе дә татар хезмәт ияләренең сөйләү теленә дә, әлбәттә, кискен йогынты яса-

ды. Болар өстенә, татар хезмәт ияләренең культура өлкәсендәге зур уңышлары, матбугат, матур әдәбият, театр, кино, радио, җыелышлар кебек аралашу чараларының киң күләмдә җәелүләре әдәби тел белән сөйләү теле арасындагы аерманың әкренләп бетүенә, аларның үзара якынлыкларына бик нык хезмәт иттеләр.

Татар эшчеләренең сөйләү теленә килгәндә, беренче нәүбәттә анда производство процессында кулланыла торган сүз һәм терминнарның киңрәк күләмдә булганлыгы һәм эшчеләр арасында хәзерге әдәби телнең ныграк үзләштерелгәне күзгә ташлана. Моңа мисал итеп, эшчеләрнең үзләрен сөйләтеп карыйк һәм ОМКУЗ эшчесе Хөснетдинов Ибраһимга сүз бирик: «Квалификациям – сортировщик. Квалификациямне күтәрү өчен үткән кышны администрация мине өч айлык курсларга җибәрде. Анда химикохлар турында, химически төзелеше тиренең, кыска гына әйткәндә, товарны яхшы итеп эшләп чыгару турында әйттеләр. Курсны бетереп кайткач, мине тагын да күтәрделәр», – ди ул.

Вәлиуллин Ярулла иптәштән сөйләтеп карыйк: Монда эшләү өчен белү кирәк, литературалар укырга кирәк, тизлек – скорысть та кирәк. Берничә мәртәбә бүләкләндем. Иптәшләр судының члены. Бригадалар арасында технарук (технорук). Аларга алдан бирелгән заданиеләрне объяснять итәбез.

Әсәдуллина Мәмдүдә сөйли: «Бездә мондый сортлар бар: алчина, струтса, лазули шерстный 1 нче сорт була. 100% чистый, таза, ертылмаган булса әйтәбез.

Тагы шул ОМКУЗ эшчесе, скобачы Җиһанша Зәйнуллин сөйли (дәфтәр № 3).

«Минем бригадам үзебезнең бүлектәге бригадалардан план тотыру ягыннан алда бара. Шуның өчен завод дирекциясе тарафыннан берничә мәртәбә бүләк алдык, аннан соң бригадада өч кеше, “ГТО” значогына норма здавайт итеп, “ГТО” значогы алдылар. Бездә сыйфатны яхшырту өчен, брак ясаучыларны башка яхшы ударниклардан аеру өчен, аларга шунда “бракадил” ордены бирелә иде. Ударникларга, яхшы эшләгән өчен, аларның станокларына кызыл флаклар куялар иде. Аннан соң аларга ударный обедлар бирәләр иде», – ди.

Менә бу өземтәләргә җөмлә төзелешләренең һәм сүзлек составларының әдәби телгә яхшы ук торганын, сүзлек составлары өчен дә производство терминнарының күбрәк кулланылуын күрәбез.

Эшчеләр телендә производство терминнарының күбрәк кулланылуы гына түгел, бәлки аларның аңнары киңәю белән, гомумән тел үсеше фактларының киң адымнар белән алга китүе һәм тизрәк үзләштерелүе бик нык чагыла.

Эшчеләрнең сөйләү теле сүзлек составы нинди юнәлештә үсә соң?

Экспедиция материалларына караганда, эшчеләр сөйләү теленең сүзлек составы да, нәкъ әдәби телдәге кебек үк, хезмәт иярәренең үз теле һәм совет-интернациональ тел байлыклары исәбенә үсә, һәм бу үсеш интернациональ юнәлештә бара. Моны күз алдына китерү өчен, тагын эшчеләрнең үзләрен сөйләтик. ОМКУЗ эшчесе Гайнуллин Яхьядан сөйләтеп карыйк (30 яшь, 1920 елдан бирле эшче):

«33 нче елга хәтле эшләп, май аенда бөтен Союз күләмендә ачылган нормировщиклар курсларына җибәрелдем. Бу курслардан декабрьнең актыкларында кайтып, заводның өчпочмагы тарафыннан чимал сехына хезмәт иярәре буенча начальник ярдәмчесе булып билгеләндем. Төп эшемнән башка, эшчеләр арасында 40 кешелек техника түгәрәге белән дә юлбашчылык итәм», – ди ул.

Тагын Вәлидова Җиһаннан сөйләтеп карыйк (21 яшь, ФЗУ бетереп чыккан, 29 нчы елдан бирле эшли):

«Безне җибәрделәр ОМКУЗга эшләргә. Мин анда ай ярым эшләгәннән соң, мине күтәрәләр югары уку йортына, Ленинградка хронометражислыкка. Мин анда укып бетерәм 32 нче елны 18 нче августта. Ишуннан ОМКУЗга кире кайтып, үз эшемне дәвам иттерәм хәзерге көнгә кадәр. Мин анда нибары 2 ай ярым гына тордым».

Күрәсез, бу иптәшләрнең сүзлек составларында халыкара һәм интернациональ сүзләр белән бергә татар теленең үз байлыгы җирлегендә ясалган бик матур яңа сүзләр дә бар: *чимал, бүләкләнү, күтәрелә, өчпочмак, бөтен Союз күләмендә, хезмәт эшләре буенча, начальник ярдәмчесе, партия оештыручысы, техника түгәрәге, югары уку йорты, билгеләнү, хезмәтне оештыру, төп эш, юлбашчылык итү, югары күтәрү, хронометражислык* һ. б.

Бу сүзләрнең кайберләре үзләренең тышкы яклары белән гүя иске сүзләр, ләкин сөйләүчеләр аларны бик аңлап һәм әдәби тел калыбына салып бөтенләй икенче төрле функцияләрдә кулланалар. Хәтта *изге* сүзен дә элекке дини эчтәлеге белән түгел, бәлки хәзерге тел аңындагы социалистик эчтәлеге белән бик урынлы кулланалар. Болардан башка, эшчеләрнең сүзлек составында *туплау, өзеклек, йомгак,*

*өземте, тайпылыш, йогынты, торак, шугак, көрәш, ярыш, типкен, каршылау планы, алмаш, штат кыскарту, корткычлык, уңыш* һәм башкалар кебек яңа ясалма сүзләрнең һәр төрен очратырга була.

Шулай ук сөйләү теле сүзлек составында икенче тел коллективларыннан кергән сүзләргә татар кушымчалары ялгау юлы белән ясалган һәм массага якынлаштырылган сүзләр дә аз түгел, мәсәлән: *электрлаштыру, машиналаштыру, редакцияләү, формалаштыру, партиялелек, скобачы, хронометражислык* һ. б.

Эшчеләрнең сөйләү теле булган сүзлек составында халыкара һәм интернациональ сүзләр дә яхшы ук киң урын алалар. Бу күренешнең эшчеләрнең һәр төрле катларында очратырга мөмкин. Монда аерым мисаллар китереп тормасак та, югарыдагы өземтәләр ачык күрсәтеп торалар: *квартал, план, производство, цех, радио, норма, профсоюз, фабком, энергия, квалификация, практика, стабиль, хронометрия, социализм, критика, продукт, группа, курс, экскурсия, кооператив, дирекция, пленум, курорт* һ. б. санап бетергесез сүзләр сөйләү теле сүзлек составының активы булып әверелгән. Интернациональ сүзләр эшчеләрнең зур күпчелеге тарафыннан бик урынлы һәм аңлы кулланылалар, алар әдәбиятта гына түгел, бәлки бүгенгә чаклы тормышта эшчеләр авызында да сөйләнеләләр, бу фактлар, һичшиксез, сөйләү теленең әдәби телгә якынлашып баруын күрсәтәләр.

Эшчеләрнең сүзлек составында рус сүзләре, колхозчылар теле белән чагыштырганда, күбрәк очрыйлар. Мисал өчен, берничә иптәшнең сөйләмен карыйк.

ОМКУЗ эшчесе Гайнуллин Гаян, 22 яшь, башлангыч мәктәп, курслар һәм комсомол мәктәбе үткән, сортлаучы булып эшли. Менә аның тексты:

«Минем урында эшләү өчен, каян нинди товар килә, шуны белергә кирәк, тиражын белергә кирәк, тозлымы, тозсызмы? Шуларны кире инде кансивировкага. Аннан соң дефектларны белергә кирәк, нормаларны, бракларны. Аннан соң документын оформләйт итәргә белергә кирәк. Аннан соң товарга павишиние буламы, понижение буламы, белергә кирәк. Үзем – ударница, бригада белән ярышабыз. Товарның качествосыннан, количествосыннан план тутыру турында тырышабыз».

Тагын Вәлиуллин ...Менә мондый сөйләү эшчеләр арасында юк түгел, алар бар. Кайбер эшчеләрнең сөйләмендә русча сүзләр күбрәк тә очрыйлар, хәтта аерым сүзләр генә түгел, бәлки тулы фраза,

җөмләләр дә очраштыргалый. Русча катнаштырып сөйләү эшчеләр телендә, колхозчылар теленә караганда, байтак кына очрыйлар, ләкин алар барлык эшчеләр теле өчен уртак һәм типик күренешләр түгел, бәлки мондый күренешләр булу белән беррәттән, аларның күпчелегендә әдәби телгә якынлаша бару бик нык сизелеп тора.

Эшчеләр телендә гарәп һәм фарсы сүзләре бик сирәк очрый. Очраганнары да әдәби телдә кулланыла торган һәм хезмәт массасы тарафыннан үзләштерелгән сүзләр генә. Үрнәк өчен берничә эшчедән сөйләтеп карыйк.

ОМКУЗ эшчесе Гобәйдуллин Галиулла (32 яшендә, хезмәт стажы – 41 ел, ударник, грамотасыз) сөйли:

«Социализм ярышына катнашам. Ничек булса да планны вакытыннан элек тутырып барам. Көч җиткән тиңешле иптәшләргә дә булышлык итәм. Собраниеләргә дә йөрим.

Грамотам булмау сәбәпле, газета-журнал укып бара алмыйм. Кино-театрларга йөргәлим. Фатирым, искесенә караганда, күп яхшы. Радио кертергә теләк бар, ләкин кертү читен. Дүрт балам бар, берсе эшли, эшләгән җирендә укый. Икенчесе ун яшьлек була, соцгородок мәктәбендә укый», – ди.

Менә бу иптәш 400 сүзлек текстта барлыгы 32 данә, ягъни 5,5% гарәп һәм фарсы сүзләре куллана: *вакыт, һәрбер, сәбәпле, ләкин, мәктәп* һ. б. Ләкин бу сүзләрнең һәммәсе дә, масса тарафыннан үзләштерелгән сүзләр, хәтта бу иптәш гадәттә гарәп яки фарсы сүзләре күп кулланыла торган очракларда да алар урынына татар сүзләре белән файдалана. Мәсәлән, ул: «Көчем җиткән тиңешле иптәшләргә дә булышлык итәм», – ди. Биредә кадәр урынына тиңешле, ярдәм урынына булышлык сүзләрен куллана.

Тагын 25 яшьлек, яхшы гына грамоталы, матур әдәбият һәм вакытлы матбугат укып баручы, урта квалификацияле нормировщик Валиуллин Ярулланы алыйк. Менә аның тексты:

«...Хәлебез начар булгач, мине интернатка бирделәр. Анда ике ай гына булдым. Әти карамагында тора башладым. Авыл белән элемтәм юк, кунакка кайтканым бар. Квалификацияне күтәрү турында көндәлек эшне генә өйрәнеп барам. Производствода булган эшчеләргә норма билгелим, заводның һәрбер продукциясенә бирелгән план буенча күпме нәрсә кирәкне билгелим. Зарплата турында контроль ясыйбыз. Бирелгән нормаларны тикшереп торабыз: артык булмыймы, тутырмаса, ни өчен тутырмый? Сәбәбен беләбез».

Күрәсез. Бу иптәшнең телендә дә гарәп һәм фарсы сүзләренең үзләштерелгәннәре генә кулланыла: «хәл, начар, һәрбер һ. б.».

Югарыда текстлар өстендәге анализыбызны цифрлар һәм процентлар белән чагыштырып карыйк. Биредә Казандагы Зеркомбинат, җитен комбинаты һәм ОМКУЗ эшчеләренең 50 эшченең сөйләү теленнән алынып язылган 50 дәфтәрнең сүзлек составын күрсәткән таблица бирелә.

Таблица 10. Татар эшчеләре сөйләү теленең сүзлек составы

| № | Сүзләр | Гомуми сан | % | Абсолют сан | % |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарча сүзләр | 11614 | 73,4 | 6999 | 68,2 |
| 2 | Халыкара һәм интернац. сүзләр | 920 | 5,6 | 645 | 6,4 |
| 3 | Русча сүзләр | 1706 | 10,5 | 1217 | 12,1 |
| 4 | Гарәп-фарсы | 908 | 5,3 | 555 | 5,8 |
| 5 | Бүтән телләрдән | 91 | 0,5 | 62 | 0,8 |
| 6 | Төрле телләрдән | 416 | 2,6 | 372 | 3,7 |
| 7 | Ялгызлык исемнәр | 366 | 2,1 | 208 | 2,6 |

50 эшченең сөйләү теленең язылып алынган текстларның сүзлек составы 10,124 сүз була. Шуларның 68,2% ы – татарча, 6,4% ы – халыкара, 12,1% ы – русча, 5,8% ы – гарәпчә һәм фарсыча, 0,7% ы бүтән телләрдән алынган, 3,7% ы – төрле телләрдән кушылып ясалган сүзләр һәм 2,6% ы – ялгызлык исемнәр.

Цифрлар һәм процентлар безгә нәрсәне күрсәтәләр.

Беренчедән, татарча сүзләрнең 68,2% ка җитүе һәм алар арасында да яңа ясалма сүзләрнең дә кулланылуы татар эшчеләре сөйләү теленең татар хезмәт ияләренең үз теле җирлегендә үсә барганын; икенчедән, халыкара һәм интернациональ сүзләрнең 6,4% ка кадәр булуы һәм аларның да аңлы һәм урынлы рәвештә сөйләнүе сөйләү теленең дә интернациональ юнәлеш алганын, рус сүзләренең 12,1% ка кадәр җитүен, моның сәбәбе дә, бер яктан, производство кораллары һәм производство процессларының байтагы русча аталганлыктан, икенче яктан, завод-фабрика тормышында татар эшчеләре белән рус эшчеләренең үзара туганнарча мөнәсәбәтләреннән килгәнлеген; гарәп һәм фарсы сүзләренең 5,8% ы гына булуы –

аларның эшчеләр телендә ныклап тамыр җәя алмавын, кергәннәренең дә әкренләп тазартыла баруын ачык күрсәтәләр.

Әгәр татар эшчеләренең сөйләү телен әдәби телнең публицистик һәм фәнни-популяр әсәрләр жанрлары теле белән үзара чагыштырып карасак, безнең алдыбызда тагы бик матур картина ачыла. Әдәби тел белән сөйләү теле арасындагы аерманың татарча сүзләрдә 6,7% ка, халыкара һәм гарәп-фарсы сүзләрендә 1–2% ка гына калуы хәзерге әдәби тел белән сөйләү теленең бер-беренә яхшы ук якын торганын, сөйләү теле белән әдәби тел арасындагы аерманың бетүгә якынлашканын ачык күрсәтә.

Татар эшчеләренең сөйләү теле менә шулай тора. Хәзер татар колхозчыларының сөйләү теленә күчәбез.

Татар колхозчыларының сөйләү теленең үсеше дә, нигездә, эшчеләр сөйләү теленнән аерылмый һәм аерылмаска тиеш тә, чөнки аларның икәве дә бер үк социалистик үсеш нигезендә үсәләр һәм байыйлар.

Коммунистлар партиясенең Ленин-Сталинча дөрес җитәкчелеге астында элекке таркау һәм ярлы авыл хуҗалыгының социалистик нигездә өр-яңа корылуы авылның йөзен социаль-экономик яктан бөтенләй үзгәртте. Аларның күпчелеге булган ярлы һәм урта хәлле крестьяннар хәзер социалистик ил төзүче булып әврелделәр. Авылга социалистик нигездәге яңа техниканың үсүе, яңа социалистик культураның урнаша баруы белән хәзерге колхозчыларның аңнары һәм культура дәрәҗәләре көннән-көн үсә һәм ныгый. Аң һәм культураның күтәрелүе белән бергә, билгеле, колхозчыларның тел культурасы да сан һәм сыйфат ягыннан бик нык үзгәрә һәм үсә бара. Бер яктан, яңа техниканың керүе, авыл хуҗалыгының да машиналаша баруы, икенче яктан, партиянең дөрес политикасы нигезендә колхозчылар арасында үткәрелә торган политик-тәрбия эшләре, социаль аралашу һәм башка культура чаралары – болар һәммәсе дә тел культурасы өчен төп база булып торалар. Киң күләмдә грамоталылыкның җәелүе, газеталар, журналлар, дәреслекләр, матур әдәбият таралу, төрле төрдәге җыелышлар, конференцияләр, съездларда катнашулар, театрлар, кинолар һәм радиолар – болар һәммәсе дә колхозчы крестьяннарның тел культурасы үсүенә стимул булып хезмәт итәләр. Яңа эш кораллары керү белән, *трактор, комбайн, тракторист, комбайнчы, урак машинасы, сугу машинасы, чәчкеч, җилгәргеч* һ. б. кебек бик күп корал исемнәре, социаль-экономик

мөнәсәбәтләр алмашыну белән, *колхоз, колхозчы, совхоз, ферма, МТС, колхоз базары, агротехника, бригада, звено, звеновод, ударник, ярыш, нарәд, норма, хезмәт көне, доклад, отчет, речь, район газетасы, стена газетасы, күп тиражлы газета, прогул, ялкау, брак* һ. б. кебек бик күп сүзләр һәм терминнар колхозчылар тарафыннан үзләренең көндәлек тормышларында үзләштереләләр. Болардан башка, башта күбесенчә әдәбиятта гына очрый торган *капитализм, кризис, торгынлык, социализм, индустрия, техника, культура, дисциплина, товар әйләнеше, агротехника чаралары* кебек санап бетергесез бик күп сүзләр һәм терминнар әдәбият, кинорадио, театр, җыелыш, конференция һәм съездлар аша колхозчылар теленә керәләр.

«Батыр Курса» колхозчысы Ә. Касыймов «Иптәш Сталин докладын өйрәндеңме?» дигән сорауга җавап урынына менә болай сөйләп бирә:

«Капитал илләрендәге хәзерге кризис элекке кризислар кебек йомшак кризис түгел. Кризисның сәбәпләре – капитал илләрендә плансыз эшләү, шулай ук товарны күп эшләү аркасында товар бәясе төшә», – ди ул.

Үзенең эше турында:

«Колхозда көндәлек норманы үтәү өчен һәм бракларны булдырмау өчен, колхозчылар арасында социализм ярышы договоры төзибез. Ул договорларны бригада эчендә булган комиссия тикшереп тора. Яхшы эшләүчеләргә бүләк куела. Колхозчы нарәд ала да аны үтәргә тырыша» ди.

Менә бу өземтәдә Касыймов иптәш «кризис, товар, торгырлык (торгынлык сүзен шулай үзенчә бозып әйтә), плансыз норма, брак, социализм ярышы договоры» һәм башка сүзләрне үзенең сүзлек составы байлыгына керткән.

Бу сүзләрне аңлап сөйлиме соң Касыймов?

Касыймов иптәш һәрбер сүзен бик үлчәүле һәм бик урынлы куллана, бередә аның алып ташларлык урынсыз кулланылган бер сүзе дә юк, хәтта ул бер урында «кризис» дисә, икенче урында «торгырлык» ди. Революциягә кадәр крестьян телендә мондый тел байлыгы булырга мөмкин дә түгел иде. Чөнки ул чордагы крестьянның социаль-экономик шартлары бөтенләй икенче төрле иде. Мондый яңа сүзләр колхозчыларга, бер яктан, үзләренең көндәлек производство процессындагы эшчәнлекләре, икенче яктан, газета-

журнал, матур әдәбият, театр, кино, радио, төрле җыелышлар, кыскасы, политик-тәрбия эшләре аркылы керәләр һәм урнаша баралар. Колхозчыларның сөйләү теле үсешендәге мондый күренешләр аерым фактлардан гына гыйбарәт түгел, бәлки алар – бик гади һәм масса күләмендәге күренешләр. Тел байлыгының бу үсеше барлык колхозчылар массасын чолгап алган. Билгеле, бу әле барлык колхозчыларның да тел байлыгы бер үк дәрәҗәдә тигез үсә дигән сүз түгел, монда аерым колхозларга карата азмы-күпме аерма бар. Мәсәлән, производство эшләре белән бергә политик-тәрбия эшләре дә яхшы гына оештырылган, «Батыр Курса» колхозында колхозчыларның сүзлек составы байлыгы башка колхозчыларга караганда шактый алга бара. Хәтта бер үк колхозда да барлык колхозчының тел байлыгы, һичшиксез, бер үк дәрәҗәдә түгел. Алдынгы һәм актив колхозчыларның тел байлыгы да алдарак тора. Шуның белән бергә, калган колхозчылар да, алдынгы колхозчылардан ерак калмыйча, үсеп баралар. Боларга алдынгы һәм актив колхозчыларның телләре бик нык йогынты ясый.

Тагы бер мисал алыйк. Шул ук «Батыр Курса» колхозчысы Фәесева Мәгълүфәне сөйләтеп карыйк. Фәесева иптәш культура ягыннан башка колхозчылар белән чагыштырганда шактый ук түбән тора. Үзенең эшләре турында менә ничек сөйли ул:

«МТСка кар көрәргә бардык. Күпер башы дамбасына бардык. Субайлар казыдык. Бригадирлар әйткән вакытка, конюхларга салам ташладык.

Кыш көнендә театрга йөрибез, киногa да йөрибез, бичерларга йөрибез. Хәзер үзебез колхозчы, абый – тракторчы. Колхозда эшләп икмәк алабыз. Үткән ел йөз потка якын икмәк алдык. Колхоз сәүдәсенә 32 пот бирдек. Безнең бригадада эшне яхшырту өчен, прогулларны бетерергә кирәк. Район газетына, стена газетына язарга кирәк. Агротехника чаралары булдырырга кирәк. Нинди җирләргә нинди эзбисләр барын өйрәнергә кирәк. Эш көннәрен биш көннең биш көнгә тикшереп барабыз. Кенәгәләрне үзем укый белмәсәм дә, кенәгәләрне укый белә торган кешеләрдән тикшертәбез», – ди.

Бу өземтәдә *МТС, дамба, күннек (конюх), театр, кино, радио, бичер (вечер), тракторист, агротехника чаралары, колхоз сәүдәсе, бригада, прогул, стена газетасы* кебек яңа кергән һәм яңа ясалган сүзләр, терминнар бар. Бу колхозчының культура дәрәҗәсе түбән дидек, чөнки ул әле грамотасыз. Шуңа карамастан аның сүзлек

составында элекке крестьяннарның телендә һич очрамый торган һәм очравы мөмкин дә булмаган яңа сүзләр һәм яңа терминнар бар.

Сүзлек составындагы бу узышлар аңа кайдан килә соң?

Алар, һичшиксез, социалистик төзелеш нигезендә үсеп бара торган производство эшчәнлекләре, производство мөнәсәбәтләре һәм хезмәткә яңача караш нәтиҗәсендә үскән сүз байлыгыннан гыйбарәт.

Татар колхозчыларының яңа социалистик төзелеш нигезендә сан һәм сыйфат ягыннан яңача үсеп бара торган бу сөйләү теле кайсы телләр исәбенә һәм нинди юнәлештә үсә соң?

Йөзләрчә колхозчыларның сөйләү теленнән җыйналган экспедиция материаллары колхозчыларның сөйләү теле дә, әдәби тел һәм эшчеләрнең сөйләү теле кебек ук, татар хезмәт ияләренең үз теле һәм совет-интернациональ тел байлыклары җирлегендә үсүен һәм бу үсешнең интернациональ юнәлештә барганын ачык күрсәтәләр. Әдәби тел белән эшчеләр һәм колхозчылар сөйләү теленең үсеш тенденцияләре бер, алар бер үк социалистик төзелеш нигезендә үсә баралар.

Колхозчыларның сөйләү теле сүзлек составы, бер яктан, татар хезмәт ияләренең үз телләре җирлегендә үсә һәм ныгый бара. Колхозчылар арасында берәр төшенчә аңлату өчен, үз телләрендә булганда, аның урынына икенче тел коллективларының сүзен куллану сирәк очрый. Шулай ук башлап әдәби телдә туа торган *ашлама, өземтә, элемтә, өзеклек, тигезләүчелек, төзелеш, тайпылыш, урынбасар, эшбашкаручы, түгәрәк, йомгак, корткыч, акча туплау, эш көне* кебек яңа ясалма сүзләр дә колхозчыларның сөйләү теленә керәләр һәм урнаша баралар.

Татар колхозчылары сөйләү теленең сүзлек составында халыкара һәм интернациональ сүзләрнең шактый җәелеп барганлыгын аерым әйтеп китәргә кирәк. Чынлап та социалистик мөнәсәбәтләр нигезендә техника-экономика һәм шуның белән бергә, культураның үсеше татар колхозчылары сөйләү теле үсешенә көчле этәреш биргән. Халыкара һәм интернациональ сүзләр колхозчылар сөйләү теленә бик урынлы кереп баралар. Моны күрү өчен, колхозчыларның үзләреннән сөйләтеп карыйк.

«Известие» колхозчысы Халитова Хәсәнә үзләренең тормышы турында менә ничек сөйли (дәфтәр № 98):

«Сыер фермасы бар бездә, дуңгыз бар, куян, йорт куяны фермасы бар, кинолар була, хәзер авыл халкы аз гына булса да культуралаша башлады инде. Гомуми-мәҗбүри укытулар кертелде. Радиолар

кертелде. Менә безнең бу клубларыбыз юк ийе. Кәнселәриябез кеше йортында була торган ийе. Клуб салдык, менә кәнселәрия эшләнде. Кәнүшни бар, ферма эшләнде. Умарталарыбыз бар. Элек безнең өйләребездә сәкеләр була торган ийе, хәзер караватлар, өстәлләр бар».

Менә болар колхозчының үзе сөйләп биргән 60 сүзлек кыска гына өземтәдә 7 данә интернациональ сүз бар: *ферма, кино, театр, культура, радио, клуб, канселәрия*. Шуның белән бергә, ул бу сүзләрне бик урынлы һәм аңлап куллана.

Әгәр бу иптәшнең 234 сүзле барлык текстын цифрлар һәм процентлар белән чагыштырып карасак, без анда түбәндәге картинаны күрәбез:

Таблица 11

| № | Сүзләр | Гомуми | | Абсолют | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сан | % | сан | % |
| 1 | Татарча сүзләр | 196 | 84,04 | 136 | 85,51 |
| 2 | Халыкара һәм интернац. сүзләр | 24 | 10,08 | 13 | 8,19 |
| 3 | Русча сүзләр | 3 | 1,26 | 3 | 1,89 |
| 4 | Гарәп һәм фарсы | 10 | 4,20 | 6 | 3,78 |
| 5 | Төрле телләрдән катнаш | 1 | 0,42 | 1 | 0,62 |
| | Шулардан барлыгы | 234 | 100 | 136 | 100 |

Менә бу цифрлар һәм процентлар татар колхозчыларының сөйләү теленең үсеше кая таба юнәлгәнен ачык күрсәтәләр. Барлык сүзлек составының 85,51% ы татарча булып, башка телләрдән кергән сүзләрнең 8,19% ы, ягъни иң күп өлеше халыкара һәм интернациональ сүзләр исәбенә төшәләр. Бу фактлар очраклы гына күренешләр түгел, бәлки барлык колхозчыларның да сөйләү теле шушы бер үк тенденция буенча үсә бара.

Халыкара һәм интернациональ сүзләр әдәби телдә дә, шулай ук сөйләү телендә дә, гадәттә, рус теле аша һәм рус телендәге әйтелешләре буенча алыналар: *бригада, бригадир, клуб, ферма, трактор, культура, радио, кино, театр, социализм, революция* һ. б. Шулай да, сөйләү телендә бу сүзләр төрлечәрәк кулланылалар әле, алдынгы актив телендә дөресрәк, ә культура дәрәҗәләре түбәнрәк катлау телендә әдәби телдәге формаларыннан бер кадәр үзгәртелеп сөйләнәләр. Мәсәлән, *бригада, бригады, бригад, бригат; кооператив,*

*капиратиф, кәпирәтиф; газета, газита, гәзит, гәҗит* һ. б. Шуның белән бергә, бер үк сүз бер үк кеше тарафыннан бер урында бозылып, ә икенче урыннарда дөресләнеп куллану да бар. Гомумән алганда, дөрес әйтелешкә таба бару тенденциясе күренеп тора.

Революциядән соң әдәби телгә кергән *социалистик, актуаль, объектив, революцион* кебек яңа халыкара сыйфатлык формалары сөйләү теленә кереп үзләшеп җитмәгәннәр әле. Бу формалар бары алдынгы, бигрәк тә культуралы активлар телендә генә сирәк очраштыргалый. Алар урынына күбесенчә русча сыйфатлык формалары кулланылалар: *социалистический, актуальный, революционный* һ. б.

Хәзер рус теленнән кереп бара торган сүзләр һәм алар белән файдалану мәсьәләсенә күчик. Рус сүзләре колхозчыларның сөйләү телендә эшчеләр теленә караганда, азрак очрыйлар. Шулай да бу көнгә социалистик мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә рус теленең колхозчылар сөйләү теленә дә йогынты ясый башлаганы күзгә ачык күренә.

«Орнашбаш» колхозчысы Шакирова Хасимә үзенең тормышы турында менә болай сөйли:

«Колхозга карата наданнарны бетерүдә эшләдем. Акча туплауда эшләдем. Сталин районына падписка җыйнадык. Ячейка тарафыннан бирелгән эшләрне үтәп барам. Спектакльләргә якшы катнашам. Массаара аң-белеме бирү белән, мин лодыр хатын булып уйнадым. Съезд карарларыннан чыккан әйберләр була. Халык кызыксына лодырларны күрсәткәндә», – ди ул.

Бу иптәш үзенең 250 сүзлек составында 10 данә, ягъни 4,0% рус сүзе куллана: *съезд, ячейка, подписка, заем, уборка, завплощадка* һ. б.

Рус телләрен катнаштыруда колхозчыларның күпчелеге менә шушы иптәш тибында дияргә ярый.

Колхозчылар телендә *самавар, поднус, чәйнек, пароход, поезд, паровоз, станция, пристань* кебек күптән кергән һәм үзләшкән рус сүзләре булу белән бергә *съезд, заем подписка, договор, ударник, лодыр, задание, нарәд, жатка, молотилка, звено, заготконтора, кыр ыстаны, смотр, доклад, площадь, производство* кебек хәзерге производство мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә ешрак кулланыла һәм бүгенге көннең таләпләрен үтәп бара торган рус сүзләре дә керә һәм урнаша баралар. Хәтта мондый сүзләр әдәби телдә кулланыла башлаган яки хәзерге көндә дә кулланыла торган кайбер сүзләрне кысрыклап чыгаралар һәм шуның белән әдәби телгә йогынты ясыйлар. Мәсәлән, *бәрмәчә* сүзен *ударник* сүзе кысрыклап чыгарган, *уру*

*машинасы, ургыч* сүзләрен *жатка*, *чәчү машинасы, чәчкеч* сүзләрен *сеялка* сүзе тыгызлап бара. *Уру машинасы, ургыч* һәм *чәчү машинасы, чәчкеч* сүзләре кулланыла һәм аңлашылуга карамастан, алар белән *жатка* һәм *сеялка* терминнары да йөри бирәләр.

Шуның белән бергә, татар колхозчылары арасында рус сүзләрен куллануда икенче төрле типлар да юк түгел. Хәзер аларга сүз биреп карыйк.

Менә «Үрнәк» совхозы кооператив эшчесе Исхаков Әхәт иптәш сөйли:

«Мин бу моментта предправление завкопта хезмәт итәм. Мине куйдылар монда по постановлению триугольника совхоза. Моңарчы мин завхоз булып эшлидер идем, мине куйдылар, иске состав отказать иткәч.

Райисполком постановлениесе буенча, атлар отдыхка куелганнар. Үзебездә бер генә ат, совхоздан да, колхоздан да ат булмый иде. Ни арба, ни чана вакыт иде», – ди ул. Бу иптәшнең 231 сүзле текстындагы 19, ягъни 13,3% рус сүзе бар.

Тагы шул ук «Үрнәк» совхозының слесаре Сәйфуллин Малик иптәштән сөйләтеп карыйк:

«Струмент, можно әйтергә, юк, тискылар юк. Ике тискы бар, только. Саломовозк...ларга ремонт производить итә икенче слесарь. Мин, значит, унике яшьтән механическига ученик булып чыктым», – ди ул.

«Батыр Курса» колхозы бригадиры Хөснеттинов И. менә ничек сөйли:

«Болай минем тормыш, какраз, чиритнәк иде этиләр заманында. Мин кердем колхозга 30 нчы елны. 33 ел мин булып йөрдем рулевод. Мин болай итәм, как бригадир, үзем белгәнчә: пример, уборкы, вакытында колхозчыларны таныштырам».

Күрәсез, бу иптәшләрнең телендә *предправление, зафкопта, по постановлению, триугольника совхоза, отказать иткәч, отдыйх, ни арба, ни чана, можно әйтергә, тольке, ремонт производить итә, значит, ученик, как раз, как бригадир* кебек рус сүзләре һәм алынмалар бар. Менә мондый рус сүзләре һәм алымнары, алар урынына татар хезмәт массасының үз тел байлыгында сүзләр һәм алымнар булуга карамастан, колхозчылар телендә кулланылалар. Ләкин мондый фактлар бөтен колхозчылар өчен уртак һәм типик күренеш түгел, алар колхозчылар арасында бик аз очрыйлар.

Сөйләү телендә рус теленең инфинитив формасына татар теленең үз ярдәмче фигылен кушып фигыль ясап сөйләү яхшы ук таралган. Мәсәлән, *организовайт итү, сдавайт итү, загатовить итү, контрактовайт итү, премировайт итү, разоблачайт итү* һ. б. Билгеле, әдәби телдә бу сүзләр урынына татар теленең үз байлыгыннан файдаланып ясалган яки үз грамматик калыбына салынган сүзләр бар. Ләкин алар сөйләү телендә гражданлык алып өлгермәгәннәр әле. Шулай да, сөйләү телендә татарның үз сүзләре булганда, алар урынына *читайт итү, работайт итү, зит итү* кебек сүзләр кулланылмыйлар.

Без югарыда Октябрьгәчә татар әдәби теленең сүзлек составына гарәп һәм фарсы сүзләре тулганын, ул сүзләрнең 40% ка якын урын алганын, ә татар хезмәт ияләренең үз сүзләре бары 45% ка гына калганын күргән идек. Билгеле, бу тел үзенең үсеш юнәлеше белән татар хезмәт ияләрен эксплуатацияләү һәм аларның аңнарын томалау өчен хезмәт итә торган реакцион бер тел иде. Хәзерге социалистик төзелеш шартларында без бөтенләй яңа юнәлеш белән үскән, хезмәт ияләренең интересларын, бары хезмәт ияләренең интересларын гына үтәргә хезмәт итә торган, эчтәлеге белән социалистик булган яңа сыйфатлы әдәби телнең үсеп барганын, шуңа күрә хезмәт ияләренең конкрет тормышларыннан бөтенләй ерак, аңлашылмый торган гарәп һәм фарсы сүзләреннән әдәби телнең әрчелә, тазартыла барганын күрдек.

Хәзер колхозчыларның сөйләү телендә гарәп һәм фарсы сүзләренең күпме урын алуын тикшереп карыйк. Моны күрү өчен, колхозчыларның үзләрен сөйләтик.

«Батыр Курса» колхозы бригадиры Шәфигуллин иптәш менә ничек сөйли:

«Безнең үзебезнең җаваплылыкка бирелгән атлар бар. Збруйлар бар, аларны саклау, колхозчыларны ач калдырмыйча, аларны эшләтеп икмәк белән тәэмин итү – безнең җаваплылыкта. Үзебезгә бирелгән участкаларны эшләтеп, иген уңышын күтәрү – бригадирның задачасы. Халыкны планлы рәвештә кушып, тиешенчә файдалану, тиешле урыннарга урнаштыру безгә бигрәк тә җаваплы булып төшә. Халыкның эшләгән көннәренә дөрес хисап алып бару, халыкка үзебез белгәнчә социализм тәрбиясе бирү, колхозчыларга правление биргән һәр задачаны үтәп бару», – ди ул.

Бу текстта *җаваплылык, тәэмин, рәвеш, дөрес, хисап, тәрбия, һәм* – гарәп һәм фарсы сүзләре.

Шул ук колхозның бригадир ярдәмчесе Шәфигуллин Юнусның 167 сүзле текстында 8% гарәп һәм фарсы сүзләре бар: *хезмәт, идарә, вакыт, мәктәп, хисап, ярдәмче, хәтле, һәйбәт, гаҗизләнеп*.

Менә тагы шул ук колхозның фермасында хайван караучы Сафиева Разиянең (грамотасыз) 244 сүзле текстында 8,6 % гарәп һәм фарсы сүзләре бар. Алар – шулар: *хайван, идарә, һаман, хисап, сәгать, һәммә*.

Күрәбез, болар арасында *хайван, мәйдан, вакыт, сәгать, хисап, һаман, хәзер* кебек күптән кергән һәм хезмәт массасы тарафыннан бик нык үзләштерелгән, ә *идарә, әһәмият, тәэмин, гади, фән* кебек хәзерге әдәби телдә кулланыла торган һәм әдәбият аша кергән сүзләр бар.

Сөйләү телендә кайбер гарәп һәм фарсы сүзләре халыкара яки рус сүзләре белән параллель кулланылалар һәм үзенә күрә көрәш процессын үткәрәләр. Мәсәлән, *идарә – правление, кабул итте – принимайт итте, мәгълүмат – сведение, карар – резолюция, постановление, решение* һ. б. Болар арасында «*идарә*» сүзенә караганда «*правление*» сүзенең өстенлек алып барганы сизелә, ә *кабул итте* белән *принимайт итте* сүзләре тигезрәк кулланылалар, *гариза* сүзен *заявление* сүзе җиңеп бара, *мөдир* белән *заведующий* көрәш процессында, *рәис* сүзен *президент* сүзе җиңгән инде.

Мондый көрәш процессында сүзләрне регулярлаштыру мәсьәләсендә әдәбиятның зур роль уйнаганы, параллель кулланыла торган сүзләрдән әдәби телдә кайсы урнашса, сөйләү телендә дә шунысы җиңәчәге күренеп тора.

Кайбер картрак колхозчыларның телендә *минем гозерем бар, мәшрикъ, мәгъриб, иҗтиһат кылу, гаҗиз булдым, шөкер әле* кебек дин һәм иске әдәби тел йогынтысы астында кереп калган, шулай ук кайбер яшьрәкләрнең телендә дә *вазыйфа, шәрык, мөгаллим* кебек хәзерге әдәби телнең башлангыч чорларындарак (НЭП чорларында) кулланылып килгән гарәп сүзләре дә очрап куялар, ләкин алар бик аз инде.

Димәк, гарәп сүзләрен куллануда сөйләү теле белән хәзерге әдәби тел арасында артык аерма юк, алар икесе дә бер чамарак баралар.

Хәзер югарыдагы аерым колхозчыларның сөйләү теленнән иллюстрация өчен мисаллар алып ясалган анализыбызны цифр һәм процентлар белән чагыштырып карыйк. Биредә хәзерге Арча районы колхозчыларыннан 50 кешенең сөйләменең (50 дәфтәр) сүзлек составын карыйк.

Таблица 12

| № | Сүзләр | Гомуми | | Абсолют | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сан | % | сан | % |
| 1 | Татарча сүзләр | 9919 | 77,5 | 6220 | 75,2 |
| 2 | Халыкара һәм интернац. сүзләр | 648 | 5,0 | 458 | 5,5 |
| 3 | Русча сүзләр | 741 | 5,7 | 524 | 6,3 |
| 4 | Гарәп һәм фарсы | 857 | 6,6 | 561 | 6,8 |
| 5 | Башка телләрдән | 12 | 0,1 | 12 | 0,1 |
| 6 | Төрле телләрдән | 443 | 3,5 | 347 | 4,1 |
| 7 | Ялгызлык исемнәр | 205 | 1,6 | 171 | 2,0 |
| 8 | Шулардан барлыгы | 12810 | 100 | 8276 | 100 |

Таблицадан күренгәнчә, 8276 сүзлек составының 77,2% ы – татарча, 5,5 % ы – халыкара һәм интернациональ, 6,3 % ы – рус, 6,8 % ы гарәпчә һәм фарсыча сүзләр килеп чыгалар.

Цифрлар һәм процентлар нәрсәне күрсәтәләр?

Алар, беренчедән, колхозчылар сөйләү теленең сүзлек составында татарча сүзләрнең 75 % тан артыграк булуы – колхозчылар сөйләү теленең дә, нәкъ әдәби тел кебек үк, татар хезмәт ияләренең үз телләре җирлегендә үсүен; икенчедән, халыкара һәм интернациональ сүзләрнең 5,5% ка җитүе – колхозчылар сөйләү теленең дә үзенең үсешендә, нәкъ әдәби тел кебек үк, интернациональ юнәлештә калуын; өченчедән, русча сүзләрнең 6,3% урын алып татар хезмәт ияләре белән рус хезмәт ияләренең бергәләшеп, дусларча социалистик җәмгыять төзү нәтиҗәсе булуын; гарәп һәм фарсы сүзләренең 6,8% ка гына калуы – феодализм һәм капитализм чорларындагы татар әдәби теленең колхозчылар сөйләү теленә аз йогынты ясаганын, булган кадәресе дә хәзерге социалистик төзелеш шартларында аларның инде бик нык кысрыкланганын ачык күрсәтәләр.

Әгәр без татар эшчеләре белән татар колхозчылары сөйләү теленең сүзлек составларын күрсәткән таблицаларның икәвен бергә янәшә куеп карасак, нәтиҗәдә болар арасында аерма бик аз булганын, боларның икәве дә бер үк социалистик төзелеш нигезендә бер үк юнәлештә үсеп барганын күрербез.

Таблица 13. Татар эшчеләре һәм колхозчылары сөйләү теленең сүзлек составы

| Кемнәр | Гомуми сан | Абсолют сан | Татарча сүзләр | | | | Интернациональ һәм халыкара сүзләр | | | | Русча сүзләр | | | | Гарәпчә-фарсыча сүзләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | абсолют | % |
| Эшчеләр | 15831 | 10124 | 11614 | 73,4 | 6999 | 68,2 | 920 | 5,6 | 645 | 6,4 | 1706 | 10,5 | 1217 | 12,1 | 908 | 5,3 | 555 | 5,8 |
| Колхозчы | 12810 | 8276 | 9919 | 77,5 | 6220 | 72,2 | 648 | 5,0 | 458 | 5,5 | 741 | 5,7 | 524 | 6,3 | 853 | 6,6 | 561 | 6,8 |
| Барлыгы | 28641 | 18400 | 21533 | 73,8 | 13219 | 71,3 | 1568 | 5,48 | 1103 | 6,0 | 2447 | 8,5 | 1741 | 9,46 | 1761 | 6,16 | 1116 | 6,05 |

Таблицаның дәвамы

| Кемнәр | Бүтән телләр | | | | Төрле телләр | | | | Ялгызлык исемнәр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | абсолют | % | гомуми | % | абсолют | % |
| Эшчеләр | 91 | 0,5 | 62 | 0,8 | 416 | 2,6 | 372 | 3,7 | 366 | 2,1 | 208 | 2,6 |
| Колхозчы | 12 | 0,1 | 12 | 0,1 | 443 | 3,5 | 347 | 4,1 | 205 | 1,6 | 171 | 2,0 |
| Барлыгы | 103 | 0,35 | 74 | 0,4 | 859 | 3,65 | 719 | 3,9 | 571 | 1,98 | 379 | 2,05 |

Таблица 14. Татар эшчеләре һәм колхозчылары сөйләү теленең сүзлек составының максимум һәм минимумнары (абсолют саннар гына күрсәтелә)

| Кемнәр | Татарча сүзләр | | Интер. һәм халыкара сүз. | | Русча сүзләр | | Гарәпчә-фарсыча сүзләр | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | максимум | минимум | максимум | минимум | максимум | минимум | максимум | минимум |
| Эшчеләр (50 кешенең сөйләменнән) | 86,6 (d. № 62 – 127 сүз) | 56,3 (d. № 51 – 81 сүз) | 11,9 (d. № 8 – 218 сүз) | 2,5 (d. № 67 – 159 сүз) | 28.0 (d. № 35 – 231 сүз) | 3,0 (d. № 61 – 165 сүз) | 12,1 (d. № 23 – 264 сүз) | 0,5 (d. № 34 – 201 сүз) |
| Колхозчы (50 кешенең сөйләменнән) | 88,5 (d. № 237 – 167 сүз) | 27,3 (d. № 266 – 117 сүз) | 11.8 (d. № 260 – 195 сүз) | 1,1 (d. № 237 – 176 сүз) | 13,4 (d. № 273 – 120 сүз) | 0,8 (d. № 235 – 122 сүз) | 12,6 (d. № 235 – 136 сүз) | 2,1 (d. № 174 – 93 сүз) |

Бишьеллыкның куелган бурычларыннан берсе авыл белән шәһәр арасында капма-каршылыкны бетерү иде. Хәзерге көндә хуҗалыкның индустрияләшүе, колхозчыларның культура дәрәҗәләренең күтәрелүе – болар һәммәсе дә шушы бурычларның үтәлүен күрсәтәләр. Шулай ук социаль-экономик шартлар нигезендә тел өлкәсендә дә эшчеләр сөйләү теле белән колхозчылар сөйләү теле арасындагы каршылыклар бетә баралар. Болар икесе дә бер үк социалистик төзелеш шартларында үсәләр. Әлбәттә, эшче һәм колхозчылар сөйләү телендә, үзләренең производстволарына һәм аларның үсү күләмнәренә карата, азмы-күпме специфик моментлар юк түгел, ләкин аларның һәр үсеш тенденцияләре бер үк социалистик нигездә корылганнар һәм бер үк юнәлештә, интернациональ юнәлештә үсәләр.

Шулай ук әдәби тел белән сөйләү телен бергә куеп, чагыштырып караганда да, сөйләү теленең әдәби телгә якынаеп барганын, сөйләү телен регулярлаштыру мәсьәләсендә әдәби телнең зур йогынтысын, аның җитәкләүче роль уйнаганын күрәбез.

## IV. БАШЛАНГЫЧ ЙОМГАКЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1. Феодолизм формациясендә татар-язма әдәби теле, бер яктан, гарәп, икенче яктан, фарсы, чыгтай һәм бераз соңрак Анатолия төрек телләренең басымы астында яшәп, аның сүзлек составында хезмәт ияләренең үз сүзләре бары 30–40% ка гына калып, фонетик һәм грамматик төзелеш ягыннан да, башлыча – чыгтай һәм төрек телләре йогынтысы астында формалашуы әдәби телне хезмәт массасы теленнән бик нык аерды, әдәби тел хезмәт массасы өчен ят һәм бөтенләй аңлаешсыз бер тел булып калды, шуңа күрә бу формация әдәби тел хезмәт ияләренең аңнарын томалау һәм аларны эксплуатацияләү коралы булып, турыдан-туры хаким сыйныфның үз интересларына гына хезмәт итте.

2. Капитализм формациясендә татар әдәби теле татар буржуазиясенең юлбашчы идеяләре булган пантюркизм нигезендә оешып, аның сүзлек составы да гарәп, фарсы һәм төрек телләре сүзләре белән бик нык чүпләнде, татар хезмәт ияләренең үз сүзләре, гомумән алганда, 50% ка да җитмәде (табл. 1–2). Фонетик һәм грамматик төзелеш ягыннан да төрек һәм төрки тел басымы астында формалашты, шуңа күрә капитализм формациясендә татар әдәби теле бер татарның үз хезмәт ияләрен генә түгел, бәлки татарга дин

һәм тел ягыннан якын булган башка милләт хезмәт ияләрен дә эксплуатацияләү нигезенә коылган һәм буржуаз чикләнгән бер тел иде.

3. Бу чорда әдәби телдәге татарчылык агымы да шул ук татар буржуа милли хәрәкәтенең икенче төрле күренешеннән генә гыйбарәт булган һәм буржуаз чикләнгән бер агым иде.

Шуның белән бергә, бер яктан, царизмның вак милләтләргә карата тоткан кысу һәм изү политикасы, икенче яктан, гомумән капитализмның үз эчендәге анархиясе, татар буржуазиясенең феодолизм калдыкларына каршы көрәштә килешүчәнлеге, 1905 ел революциясеннән соң монархиянең ышанычлы терәге булып китүе, куркаклыгы, икейөзлелеге, гомумән реакцион табигате нәтиҗәсендә капитализм формациясендә бердәм татар әдәби теле бөтенләй туа алмады.

Татар әдәби теленең үсүе өчен таза җирлек һәм киң шартлар бары Октябрь революциясеннән соң гына туды. Пролетариат диктатурасы һәм җиңешле социлистик төзелеш чоры – гомумән татар әдәби теленең үсеш тарихында өр-яңа этап ул. Бу яңа этапта татар әдәби теле үзенең үсешендә революцион сикереш ясады. Бу чор эчендә гомумән татар әдәби теле, аерым алганда, аның сүзлек составы, эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли буларак, татар хезмәт ияләренең үз теле потенцияләре һәм совет-интернациональ тел байлыклары нигезендә бөтенләй яңа юнәлештә, сан һәм сыйфат ягыннан бик нык үсте һәм ныгыды (табл. 4, 5, 6, 7, 8, 9).

4. Аерым алганда, татар әдәби теленең фәнни тел, терминология өлкәсендәге уңышлары тагы да зур. Бу өлкәдә татар әдәби теленең интернациональ үсеш тенденциясе билгеле принциплар буенча инде кискен эзгә төшкән һәм урнашкан дип әйтергә мөмкин (табл. 9).

5. Октябрь революциясеннән соң социаль-экономик шартларның үзгәрүе, коммунистлар партиясенең ленин-сталинча дөрес җитәкчелеге нәтиҗәсендә хезмәт ияләренең культура өлкәсендәге зур уңышлары татар эшчеләре һәм колхозчыларының сөйләү теленә дә, әлбәттә, тирән йогынты ясады. Сөйләү теле дә, нәкъ әдәби тел кебек үк, җиңешле социалистик төзелешкә ярашлы рәвештә хезмәт ияләренең үз тел потенцияләре һәм совет-интернациональ юнәлештә җитез адымнар белән үзгәрә һәм үсә бара (табл. 10, 11).

6. Гомумән алганда, татар эшчеләре теле белән татар колхозчылары теле арасында әйтерлек аерма юк, боларның икәве дә бер үк социалистик төзелеш нигезендә, бер үк юнәлештә үсә һәм байый баралар. Шулай ук әдәби тел белән сөйләү теле арасындагы аерма

да әкренләп бетә бара, болар үзара бик якын мөнәсәбәттә үсәләр. Шуның белән бергә, сөйләү телен регулярлаштыру, культуралаштыру мәсьәләсендә әдәби тел җитәкчелек ролен тота (табл. 13, 14).

7. Октябрь революциясеннән соң татар телендәге революцион үсеш, үсеш прцоессындагы бу яңа юнәлеш телнең семантика өлкәсенә дә көчле йогынты ясады. Телдәге үзгәреш кайбер сүзләрнең югалулары, бик күп яңа сүзләрнең туулары белән генә чикләнеп калмады, бәлки бу үзгәреш телнең семантика өлкәсендә дә бик нык чагылды. Кайбер сүзләр октябрдән соң үзләренең элекке үзлек мәгънәләренә бөтенләй икенче төрле мәгънә кулланыла башлады *(йомгак – җеп йомгагы һәм сөйләнгән фикернең йомгагы);* кайбер сүзләрнең функцияләре үзгәрде *(изге – элек дини эчтәлек, хәзер социалистик эчтәлек);* кайбер сүзләрнең мәгънәләре киңәйде (*көрәш – батырлар көрәше һәм социализм өчен көрәш* һ. б.); кайбер сүзләрнең мәгънәләре социальлләште *(эшче – ялланып эшләгән һәрбер кеше, хәзер производствода эшләүче кеше).*

8. Бу яңа этапта татар әдәби теленең революцион үсеше, аерым алганда, аның морфологик төзелешендә дә нык чагылды. Яңа сүз иҗады өлкәсендә кайбер формаль морфемаларның функцияләре үзгәрде (*-ма -мә: язма, бүлмә* кебек элек конкрет төшенчәләрнең исемнәре генә ясала иде, хәзер *аңлатма, белешмә, тигезләмә* кебек абстракт төшенчәләрнең исемнәре дә ясала; *-чы -че:* элек *эшче, китәпче* кебек билгеле берәр профессияләрнең исемнәре генә ясала иде, хәзер *ленинчы, советчы, милләтче, солтангалиевчы...* кебек билгеле, берәр караш яклы әйберләрнең исемнәре дә ясала); кайбер үлек морфемалар җанланды *(-мта -мтә: сыгытма, өземтә* һ. б.); кайбер ясагыч морфемалар активлашты (*-ш: казаныш, төзелеш* һ. б.).

Ясагыч морфемалар ярдәме белән татарның үз сүзләреннән генә түгел, бәлки рус, халыкара һәм интернациональ сүзләрдән дә яңа сүзләр ясала (*сортлау, активлашу, редакцияләү, колхозчы, квалификацияле, индустрияләштерү, большевиклык, оппортунистлык* һ. б.). Халыкара сүзләр белән бергә кайбер халыкара сыйфатлык формаларын санарга мөмкин (*актуаль, Коммунистик, прогрессив, революцион* һ. б.); шулай ук русча сыйфатлык формаларының урынлы кулланылуын да әйтеп китәргә кирәк (*фактический, коммерческий, массовый, формальный* һ. б.), ләкин сөйләү телендә җенес бетемнәре сыйфатларда сакланмый (*пролетарский революция. Красный Армия...* һ. б.); кайбер халыкара ясагыч морфемалар татар хезмәт ияләренең

тел аңында арым морфема булып таныла (*коммунизм, коммунист, революция, революционер, стенография* һ. б.), шулай ук (*ударник – ударница, колхозница, комсомолка, бригадирша* һ. б.).

Сүз иҗаты өлкәсендә берничә сүзне бергә кушып кушма сүзләр ясау (*көнчыгыш, чынбарлык, өскорма, Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы* һ. б.); шулай ук кушма сүзләрне билгеле принциплар буенча кыскартып яңа терминнар тудыру (*СССР, АТССР, МТС, ҮБК, педтехникум, пионерхәрәкәт, профхәрәкә*т һ. б.) процесслары да активлашты.

9. Октябрь революциясеннән соң татар әдәби телендә туган менә бу яңа факторларның зур күпчелеге (яңа ясалмалар, халыкара һәм интернациональ сүзләр, терминнар, морфологик яңа формалар һәм семаник үзгәрешләр) эшче һәм колхозчыларның сөйләү телендә дә бик ачык гәүдәләнәләр һәм күбесенчә әдәби телдәге формалары белән урнаша баралар.

## V. КИМЧЕЛЕКЛӘР ҺӘМ ПРАКТИК ТӘКЪДИМНӘР

1. Татар әдәби телендә әдәби телнең күчү чорын чагылдыра торган кайбер кимчелекләр юк түгел. Әдәби телдә шулай ук әдәби тел йогынтысы астында сөйләү телендә дә, бер үк төшенчәне аңлату өчен, параллель кулланыла торган сүз һәм терминнар бар әле *(сәясәт – политика, икътисад – экономика, определение – тәкъриф – тәкърифләү – билгеләмә – таныту, кушымта – кушынты – кушылдык, (приложение мәгънәсендә) (тәгълимат – өйрәтмә, укым – укыма (учение мәгънәсендә), утырыш – заседание, рәис – председатель, гариза – заявление, идарә – правление, делегат – вәкил* һ. б.).

2. Яңа төшенчәләр өчен атамалар һәм терминнар кирәк булганда, гомумән сүз иҗаты мәсьәләләрендә, шулай ук мәгънә оттенокларын чагылдыру эшендә татар теленең барлык потенцияләре файдаланыла дип әйтә алмыйбыз әле. Бездә сүз ясагыч кушымчаларның төрләре һәм аларның мәгънә оттеноклары җентекле рәвештә өйрәнелмәгән *(бүлем – бүлек – бүлемтек, кисемте – кисенте, уремте – уренте, үсемте – үсенте – үсемтек ..., формаландыру – формалаштыру* һ. б.); килеш кушымчаларының да барлык функцияләре һәм мәгънә оттеноклары тиешенчә өйрәнелеп бетмәгән *(китаптан файдалану, китапны файдалану, китап белән файдалану, юкка борчыла, юкны борчыла, юктан борчыла...*); ярдәмлек сүзләр

турында да шуны әйтергә туры килә. Шунлыктан терминология тармакларында да, тәрҗемә практикасында да байтак чатаклыклар очраштыргалый әле (артык ясалмалар биология терминнарында), совет чынбарлыгы аша сикереп «интернациональләшү» (химия терминнарында 64–75%) һәм механистик тәрҗемә элементлары). Бу пункттагы мәсьәләләрнең плюслары, минуслары да экспедиция материалларында яхшы ук гәүдәләнелер. Ләкин алар турында әлегә тик сиздереп кенә үтәбез. Аларны ныклап тикшерәсе, өйрәнәсе бар.

3. Сөйләү телендә диалектизм һәм арготизм калдыклары, шулай ук кирәксезгә һәм урынсызга русча сүзләр белән телне чүпләү фактлары да яхшы ук очрыйлар (*Җаңа җыл, газит, киги, ызма, сүгү, какраз, штобы, только, значит, сдавать итү, хлебозаготовка, прикрепленный комитет, дом отдыха, институт марксизма-ленинизмага бардым, прокурор Республикага жалоба бирдем* һ. б.).

4. Әдәби телдә кулланыла торган *коммунистик, коммуналь, объектив, революцион* кебек халыкара һәм сыйфатлык формалары сөйләү телендә сирәк очрыйлар. Ләкин бу күренеш, мондый формаларны әдәби телдән д чыгарып ташларга кирәк, дигән нәтиҗәне бирмиләр әле, алар әкренләп сөйләү теленә дә кереп баралар. Шуның белән бергә, *массовый, коммерческий, генеральный* кебек русча сыйфатлык формаларын да кирәкле урыннарда куллანудан баш тартырга ярамый.

5. Сүзлек составын морфологик яктан анализлаган вакытта *тиеш, кирәк, бар, юк, гыйбарәт, мә, чү, әйдә* кебек сүзләрне стабиль дәреслекләр буенча сүз төркемнәреннән кайсына кертү, шулай ук *янында, эчендә, арасында, буенча, карата* кебек сүзләрне ярдәмлек сүзләр арасында санау турында аңлатма бирергә кирәклеге күренә, чөнки бу моментлар дәреслектә кирәгенчә ачылып җитмиләр.

6. Ясагыч кушымчаларның сүзлек составын баетү өлкәсендә рольләре бик зур. Ләкин аларның функцияләрен өйрәнү канәгатьләнерлек түгел (*бүлем, бүлмә, бүлек, белем, белек* һ. б.), аларны детальләп тикшерүне дәвам итәргә кирәк.

7. Экспедиция материаллары эшчеләр сөйләү теленең хәзерге әдәби телгә шактый якын торганын һәм гомумән эшче, колхозчы активының сөйләү теле шактый кызу темп белән үсүен һәм боларның масса теленә чиксез зур йогынты ясавын күрсәтә. Шуңа күрә алар массага политик тәрбия бирү белән бергә, тел өлкәсендә дә үзгәрешләрнең җаваплылыкларын бик нык сизәргә һәм иң элек үзләре

әдәби телне үзләштерергә, аны теоретик һәм практик өйрәнергә, культуралы тел өчен көрәштә массага үрнәк булырга тиешләр.

8. Хезмәт массасында, бигрәк тә активлар арасында тел белән кызыксыну бик нык күзгә ташлана, ләкин бу өлкәдә фәнни-популяр кулланмалар юклыктан зарланалар. Рабкор, селкор, стенкорлар һәм, гомумән, газета работниклары өчен популяр кулланмалар; термин комиссияләре, шулай ук авторлар һәм тәрҗемәчеләр өчен кулланма булырлык инструкцияләр; русча-татарча сүзлекләр, социаль-политик сүзләр һәм халыкара сүзләр сүзлекләре төзүне ашыктырырга, татар теленең тулы сүзлекләрен төзү эшенә керешергә кирәк.

9. Татар эшчеләре һәм колхозчылары сөйләү теленең бөтен потенцияләреннән әдәби тел тиешенчә файдаланып киткәне юк әле. Сөйләү теле байлыкларыннан яхшырак файдаланырга һәм аның социализм төзелеше таләпләренә җавап бирерлек юнәлештә үсүен тагын да активлаштырырга кирәк. Моның өчен эшче һәм колхозчыларның сөйләү телен өйрәнүне, шулай ук аерым диалектларны өйрәнүне дәвам иттерергә тиешлебез.

## ТЕРМИНЫ ПО ФОНЕТИКЕ

**А**

| | |
|---|---|
| Акустика | акустика |
| Акустический | акустик |
| Артикуляция | артикуляция |
| Аспиранты (придыхательные) | аспирантлар (өрелүлеләр) |
| Артикуляционная база | артикуляция базасы |
| Артикуляционная зона | артикуляция зонасы |
| Аффриката | аффрикат |
| Анатомия органов речи | сөйләү әгъзаларының анатомиясе |
| Анализ процесса речи | сөйләү процессының анализы |
| Анализ звуковых кривых | аваз кәкреләренең анализы |
| Амплитуда | амплитуда |
| Амбужур | амбужур |
| Ампула | ампула |
| Аттакирование | һәмзә, һәмзәләү |

| | |
|---|---|
| Аттакированное начало | һәмзәле башлау |
| Альвеляционные звуки | альвиола авазлары (урт авазы) |
| Ассимиляция | ассимиляция |
| Ассимиляция прогрессивная | прогрессив ассимиляция (ошашлану, ошашсызландыру) |
| Ассимиляция регрессивная | регрессив ассимиляция (кире ошашлану) |
| Ассимиляция полная | тулы ассимиляция |
| Ассимиляция частичная | өлешле ассимиляция |
| Ассимиляция лабиальная (губная) | лабиаль ассимиляция (ирен ошашлануы) |
| Ассимиляция полятильная (нёбная) | полятиль ошашлану (аңкау ошашлануы) |
| Ассимиляция гортанная | гырылтык ошашлану |

**Б**

| | |
|---|---|
| Барабанчик | барабанчык |
| Барабанная перепонка | барабан (колак) ярысы |
| Билабиальные звуки | билабиаль авазлар (ирен авазы) |
| Боковые звуки | ян авазлары |
| Бимоль | бимоль |

В

| | |
|---|---|
| Вибрация | вирбация,тибрәнмә |
| Вибрирование | тибрәнү |
| Вдыхание | тын алу (сулыш) |
| Выдыхание | сулыш (тын) бирү (чыгару) |
| Высота тона | тон күтәренкелеге |
| Веляризация | виләризация |
| Велярные звуки | виләр авазлар (йомшак аңкау авазлары) |
| Взрывные звуки | шартлаулы авазлар (өрелмәсез авазлар) |

**Г**

| | |
|---|---|
| Гармония | гармония (аһәң) |
| Гармония гласных согласных | сузыклар һәм тартыклар гармониясе (аһәңе) |

| | |
|---|---|
| Гармонические тона | гармонияле (аһәңле) тоннар |
| Гамма | гамма |
| Голос | тавыш |
| Голосовые связки | тавышлыклар (тавыш ярылары) |
| Голосовые связки ложные | ялган тавышлыклар (тавыш ярылары) |
| Голосовая щель | тавыш ярыгы |
| Гласный | сузык |
| Гласные верхнего подъема | кысык сузыклар |
| Гласные среднего подъема | уртача сузыклар |
| Гласные нижнего подъема | ачык сузыклар |
| Гласные переднего ряда | алгы сузыклар (алгы рәт сузыклары) |
| Гласные среднего ряда | уртангы сузыклар (урта рәт сузыклары) |
| Гласные заднего ряда | арткы сузыклар (арткы рәт сузыклары) |
| Гортань | гырылдык |
| Гортанные звуки | гырылдык авазлары |
| Гортанная капсула | гырылдык капсуле |
| Горло | бугаз |
| Глотка | йоткылык |
| Грудной тон (звук) | күкрәк тоны (авазы) |
| Графика | графика |
| Глухие звуки | тавышсыз (саңгырау) авазлар |
| Грудная клетка | күкрәк челтәре |
| Грудной прибор | ирен приборы |
| Гортанный прибор | гырылдык приборы |

**Д**

| | |
|---|---|
| Дифтонг | дифтонг |
| Дифтонгические звуки | дифтонгсыман авазлар |
| Десна | (урт) теш урты |
| Диффузные звуки | диффуз авазлар |
| Диафрагма | диафрагма |
| Дорсальные звуки | дорсаль авазлары (тел аркасы авазлары) |

| | |
|---|---|
| Дыхательное горло | сулыш (тын) юлы (коры үңәч) |
| Длительное согласное | сузылмалы тартыклар |
| Диссимиляция | диссимиляция, охшашсызлану |
| Долгота | озынлык |
| Долгие гласные | озын сузыклар |
| Длительность | сузылыш, сузылмалылык |
| Дикция | дикция (әйтеш) |
| Диэз | диез |
| Дисгармония | дисгармония, гармониясезлек. аһәңсезлек |
| Движение тона | тон хәрәкәте (үзгәреше) |

**З**

| | |
|---|---|
| Звук | аваз |
| Звуковая волна | аваз дулкыны |
| Звуковой закон | аваз кануны |
| Звуковой кривой | аваз кәкресе |
| Звуки звонкие | тавышлы (яңгырау) авазлар |
| Звуки глухие | тавышсыз (саңгырау) авазлар |
| Звуки гласные | сузык авазлар |
| Звуки согласные | тартык авазлар |
| Звуки слоговые | иҗек ясаучы авазлар |
| Звуки неслоговые | иҗек ясамаучы авазлар |
| Звуки придувные фрикативные | өзелмәле авазлар |
| Звуки затворные взрывные | өзелмәсез (шартлаулы) аваз |
| Звуки носовые | борын авазлары |
| Звуки чистые ротовые | саф авазлар (авыз авазлары) |
| Звуки твёрдые | калын авазлар |
| Звуки мягкие | нечкә авазлар |
| Звуки гортанный | гырылдык авазлар |
| Звуки язычковые | кече тел авазлар |
| Звуки мягко-небные | йомшак аңкау авазлары |
| Звуки задне-небные | арткы аңкау авазлары |
| Звуки средне-небное | урта аңкау авазлары |
| Звуки передне-небное | алгы аңкау авазлары |
| Звуки альвеолярное | урт аңкау авазлары |

| | |
|---|---|
| Звуки задне-язычные | тел арты авазлары |
| Звуки средне-язычные | тел уртасы авазлары |
| Звуки передне-язычные | тел алды авазлары |
| Звуки дорсальные | тел аркасы авазлары (дорсаль авазлар) |
| Звуки корональные | тел кырые авазлары (корональ авазлар) |
| Звуки нёбо-язычные | тел-аңкау авазлары |
| Звуки межзубные | тел арасы авазлары |
| Звуки зазубные | тел арты авазлары |
| Звуки зубные | теш авазлары |
| Звуки губно-зубные | ирен-теш авазлары |
| Звуки губно-губные | ирен-ирен авазлар |
| Звуки боковые | ян авазлары |
| Звуки шумные | шавылдаулы авазлар |
| Звуки музыкальные | музыка авазлары |
| Звуки сонорные | сонор яңгыраулы авазлар |
| Звуки шепотные | пышылдаулы авазлар |
| Звуки сильные | көчле авазлар |
| Звуки полушепотные | ярым пышылдаулы авазлар |
| Звук редуцированный | зәгыйфь редукцияле аваз |
| Звук напряженный | этемсез авазлар |
| Звук ненапряженный | этемле авазлар |
| Звук лабиализированный | иренләшкән авазлар |
| Звук нелабиализированный | иренләшмәгән авазлар |
| Звук более передний | алгы авазлар |
| Звук задний | арткырак авазлар |
| Звук открытый | ачыграк авазлар |
| Звук закрытый | ябыграк авазлар |
| Звук изолированный | аерым әйтелештәге (изоляциядәге) аваз |
| Звук комбинированный | бергә әйтелештәге (комбинированный) аваз |
| Звуки корневые | тамыр авазлары |
| Звуки аффиксальные | аффикс (кушымча) авазлар |
| Звуки простые | гади авазлар |
| Звуки слитные | кушма авазлар |

| | |
|---|---|
| Звуки придыхательные | өрелмә авазлар |
| Звуки имплозивные | япма (имплозив) авазлар |
| Звуки экспользивные | ачма аваз (эксплозив) |
| Звуки плавные | йөзмә авазлар |
| Звуки дрожащие | калтыраулы (тетрәүле) авазлар |
| Звуки свистящие | сызгырулы авазлар |
| Звуки шипящие | чыжылдаулы авазлар |
| Звуки переходные | күчү авазлары (ике ара авазлар) |
| Звуки длительные | сузылмалы авазлар |
| Звуки мгновенные | сузылмасыз авазлар |
| Звуки долгие | озын авазлар |
| Звуки короткие | кыска авазлар |
| Звуки иррациональные | иррациональ (анык сизелмешлек) авазлар |
| Звукоподражание | авазга иярү |
| Звучание гортани | гырылдык тавышлануы |
| Звуковая система языка | телнең авазлар системасы |
| Зев | тама (иснәк) |
| Записывающий барабанчик | теркәү барабанчыгы |
| Записывающее пёрышко | теркәү каләмчеге |
| Зубы | тешләр |
| Зубы резцы | көрәк тешләр |
| Зубы клыки | казык тешләр |
| Зубы коренные | алгы азау тешләр |
| Зубы коренные задние | арткы азау тешләр |
| Зубы мудрости | акыл тешләре |
| Зубы верхние | өске тешләр |
| Зубы нижние | аскы тешләр |
| Звуковой язык | аваз теле |
| Звуки конечные | (сүз) туктар авазлар |
| Звуки начальные | (сүз) башлар авазлар |
| Звуки широкие | киң (җәйпәк) авазлар |
| Звуки узкие | тар (кысык) авазлар |
| Звуки язычковые | кече тел авазлары |
| Звуки беглые | чабык авазлар |
| Записывающее ухо | теркәүче колак |

**И**

| | |
|---|---|
| Интонация | интонация |
| Интонация вопросительная | сорау интонациясе |
| Интонация восклицательная | эндәшү интонацияс |
| Интонация повелительная | боеру интонациясе |
| Интонация утвердительная | беркетү (хәбәр) интонациясе |
| Индифферентный уклад | индифферент куелыш |
| Индивидуальное произношение | индивидуаль әйтеш |
| Искусственное нёбо | ясалма аңкау |
| Интерференция звуков | авазлар интерференциясе |

**К**

| | |
|---|---|
| Колебание струны | кыл тибрәнүе |
| Колебание одностороннее | бер яклы тибрәнү |
| Колебание двухстороннее | ике яклы тибрәнү |
| Колебание полное | тулы тибрәнү |
| Классификация звуков | авазларны төркемләү (авазлар классификациясе) |
| Краткое произношение | китапча әйтеш |
| Кончик языка | тел очы |
| Корень | тел тамыры |
| Кимограф | кимограф |
| Кортиев орган | кортиф органы (әгъзасы) |
| Контоминация звуков | авазлар контоминациясе |

**Л**

| | |
|---|---|
| Лабиализация | иреннәү (лабиализация) |
| Лабиализированный | иренләшкән |
| Лингвограммы | лингвограм |
| Лабиограммы | лабиограм |
| Лёгкие | үпкә, үпкәләр |
| Лёгкие правые | уң үпкә |
| Лёгкие левые | сул үпкә |
| Ларингоскоп | ларингоскоп |
| Лабиринт уха | колак лабиринты |
| Ламбдаизм | ламбидаизм |

**М**

| | |
|---|---|
| Мягкое небо | йомшак аңкау |
| Монофтонг | монофтонг |
| Методокрашивание | буяу методы |
| Мышечное ощущение | мускул сизенүе |
| Место образования звука | аваз чыганагы |
| Микрофон | микрофон |
| Мышца, поднимающая угол рта | авыз почмагын күтәрүче мускуллар |
| Мышца, опускающая угол рта | авыз почмагын төшерүче мускуллар |
| Мышца двубрюшная нижней челюсти | аскы казна чәңек ике кормаклы мускул |
| Мышца подбородочно-язычная | ияк-тел мускулы |
| Мышца подбородочно подъязычная | ияк-тел асты мускулы |
| Мышца челюстно-подъязычная | казна тел асты мускулы |
| Мышца подъязычная | тел асты мускулы |
| Мышца шило-язычная | без тел мускулы |
| Мышца шило-глоточная | без йоткылык мускулы |
| Мышца подъязычно-язычная | тел асты-тел мускулы |
| Мышца языка-продольные | тел буй мускуллары |
| Мышца поперечные | тел аркылы мускулы |
| Мышца щито-подъязычные | калкан тел асты мускулы |
| Мышца грудино-щитовидная | күкрәк калкан кимерчәк мускулы |
| Мышца подъязычная | күкрәк тел асты мускулы |
| Мышца лопаточно-подъязычная | калак-тел асты мускулы |
| Мышцы межрёберные | кабырга ара мускулы |
| Мышцы диафрагмы | диафрагма мускулы |
| Мышцы «антогонисты» | антагонист мускулы |
| Момент экскурсии | экскурсия моменты (чыганакка бару) |
| Момент рекурсии | рекурсия моменты (чыганактан китү) |
| Момент средний | урта момент (чыганак моменты) |

**Н**

| | |
|---|---|
| Надгортанник | гырылдык каплаучы |
| Надставная труба | өске көпшә (труба) |
| Назализация | назализация (борынлау) |

| | |
|---|---|
| Назалированный звук | борынлашкан аваз |
| Напряженное произношение | этемне әйтеш |
| Напряженность звука | авазның этеме |
| Научная транскрипция | фәнни транскрипция |
| Нельота | телсезлек |
| Нервная система | сөйләү аппаратының нервлар системы |
| Нерв нижне-челюстной | аскы казна (җәек) нервы |
| Нервы основно-небные | төп аңкау нерваларын |
| Нерв напрягающий мягкое небо | йомшак аңкау киерүе нервы |
| Нерв челюстно-поъдязычный | казна (җәек) тел асты нервы |
| Нерв лицевой | бит нервасы |
| Нерв языко-глотный | тел-йоткылык нервасы |
| Нерв блуждающий | гизүче нерва |
| Нерв гортанный | гырылдык нервасы |
| Нерв подъязычный | тел асты нервасы |
| Нёбо | анкау |
| Нёбо твёрдое | каты аңкау |
| Нёбо мягкое | йомшак аңкау |
| Нёбная занавеска | аңкау пәрдәсе |
| Носовая олива | борын оливы (зәйтүне) |
| Носовая полость | борын куышы |
| Нота | нота |
| Нотная транскрипция | нота транскрипциясе |

**О**

| | |
|---|---|
| Обертона | обертоннар |
| Обмолвка | әйтү ялгышы |
| Объединение звуков | авазлар берләшүе |
| Описки | язу ялгышы |
| Органы речи | сөйләү (органнары) әгъзалары |
| Органы произношения | әйтү (органнары) әгъзалары |
| Органы произношения активные | әйтү актив (органнары) әгъзалары |
| Органы произношения пассивные | әйтү пассив (органнары) әгъзалары |

| | |
|---|---|
| Округление губ | иреннәрне түгәрәкләү |
| Октава | октава |
| Ослышка | ишетү ялгышы |
| Ослабление звука | авазның көчсезләнүе |
| Открытость звука | авазның ачыклыгы (җәйпәклеге) |

**П**

| | |
|---|---|
| Полятальный звук | полеталь аваз |
| Полятализация | полетализация |
| Полятограмма | полетограмма |
| Полутон | ярым тон |
| Пауза | пауза (тыныш) |
| Пневмограф | пневмограф |
| Период колебания | тибрәнү дәвере |
| Придыхание | өрелү |
| Придыхательное | өрелүле авазлар |
| Повышение тона | тонның күтәрелүе (тонны күтәрү) |
| Понижение тона | тонның төшүе, тонны төшерү |
| Подъязычная кость | тел асты сөяге |
| Полость рта | авыз куышы |
| Полость носа | борын куышы |
| Полость глотки | йоткылык куышы |
| Полость гортани | гырылдык куышы |
| Произношение | әйтеш |
| Потология языка | тел потологиясе |
| Процесс речи | сөйләү процессы |
| Прекращение звуков | авазлар өстәлү |
| Перестановки | аваз урыннарын алмаштыру |
| Психо-физиология речи | сөйләү психо-физиологиясе |
| Подъём верхн. средн. нижн. | |
| Парные звуки | игез (парлы) авазлар |

**Р**

| | |
|---|---|
| Расподобление | ошашсызлану, ошашсызландыру |
| Речь | сөйләү |
| Ритм речи | сөйләү ритмы |

| | |
|---|---|
| Ритмичность | ритмлылык |
| Ритмичный | ритмлы |
| Резонанс | резонанс, яңгырау |
| Резонатор | резонатор, яңгыравык |
| Ревонансные тона | резонатор (яңгыравык) тон |
| Речевой аппарат | сөйләү аппараты |
| Редукция звука | авазның зәгыйфьләнүе (редукциясе) |
| Ртораскрыватели | авыз ачтыручылар |
| Ртосмыкатели | авыз йомдыручылар (яптыручы) |
| Регистрация | теркәү (регистрация) |
| Регистрирующий барабанчик | теркәү барабанчыгы |

**С**

| | |
|---|---|
| Слог | иҗек |
| Слог открытый | ачык иҗек |
| Слог закрытый | ябык иҗек |
| Слог ударный | басымлы иҗек |
| Слог неударный | басымсыз иҗек |
| Слог преударный | басым алды иҗеге |
| Слог заударный | басым арты иҗек |
| Слогообразование | иҗек ясау |
| Слогообразующий | иҗек ясаучы |
| Слогораздел | иҗекләр чиге (мизасы) |
| Сингармонизм | сингармонизм (аһәңдәшлек) |
| Скопление согласных | тартыклар тупланмасы |
| Сила звука | аваз көче |
| Смягчение звука | авазның нечкәрүе |
| Спиранты | спирантлар |
| Сибилянты | сибиләтләр |
| Сонорные звуки | сонор (яңгыраулы) авазлар |
| Сужение | кысылу, кысыклык |
| Смычные согласные | йомма тартыклар |
| Синтез звуков речи | сөйләү авазларының синтезы |
| Способ образования звука | авазның ясалу ысулы |
| Спирометр | спирометр |

**Т**

| | |
|---|---|
| Тон | тон |
| Тон высокий | күтәренке тон |
| Тон низкий | төшенке тон |
| Тон восходящий | үрләүче тон, күтәрелүче тон |
| Тон нисходящий | иңүче тон, төшүче тон |
| Тон простой | гади тон |
| Тон сложный | катлаулы тон |
| Тон основной | төп тон |
| Тон побочный | кырый (өстәмә) тон |
| Тона гармоничные | гармонияле тоннар |
| Тона негармоничные | гармониясез тоннар |
| Тембр | тембр |
| Такты речи | сөйләү тактлары |
| Темп речи | сөйләү темпы тизлеге |
| Трение | ышкылу |
| Терция | терция |
| Треугольник гласных | сузыклар өчпочмагы |

**У**

| | |
|---|---|
| Ударение | басым |
| Ударение основное | төп басым |
| Ударение второстепенное | икенче дәрәҗәдәге басым |
| Ударение начальное | баштагы басым |
| Ударение конечное | азактагы басым |
| Ударение логическое | логик, мантыги басым |
| Ударение музыкальное | музыкаль басым |
| Ударение тоническое | тоник (тонлы) басым |
| Ударение экёспираторное | икспиратор басым |
| Ударение выдыхательное | тын бирү басымы |
| Ударение смешанное | катнаш басым |
| Ударение побочное | кырый (өстәмә) басым |
| Увулярные звуки | увуляр авазлар (кече тел авазлары) |
| Уподобление звуков | авазларның ошашлануы (авазларны ошашландыру) |

| | |
|---|---|
| Удвоение согласных | тартыкларның игезәкләнүе (тәҗдитләнүе) |
| Уклад | куелыш |
| Уздечка языка | тел кереше |
| Уздечка губ | ирен кереше |
| Утрата звука | авазның югалуы |

**Ф**

| | |
|---|---|
| Фонетика | фонетика, аваз |
| Фонетика общая | гомуми фонетика |
| Фонетика сравнительная | чагыштырмалы фонетика |
| Фонетика описательная | тасвири фонетика |
| Фонетика историческая | тарихи фонетика |
| Фонетика экспериментальная | эксперименталь (сынаулы) фонетика |
| Фонетический | фонетик |
| Фонограф | фонограф |
| Фонограмма | фонограмма |
| Фрикативный | фрикатив |
| Фонетическое письмо | фонетик язу |
| Фонетическая транскрипция | фонетик транскрипция |
| Фонация | тонация |
| Фонационный ток | тонация агымы |
| Фальцот | фольсит |
| Фаукальные согласные | фаукаль тартыклар |
| Физиология звуков речи | сөйләү авазларының физиологиясе |
| Факторы звуковых изменений | авазлар үзгәреше факторлары |
| Физико-акустическая сторона звуков речи | сөйләү авазларының физик-акустик ягы |
| Фонендоскоп | фонендоскоп |

**Х**

| | |
|---|---|
| Хрящи гортани | гырылдык кимерчәкләре |
| Хрящ щитовидный | калкан кимерчәк |
| Хрящ перстневидный | йөзек кимерчәк |
| Хрящ чарполовидный (пирамидальный) | соскыч (пирамид) кимерчәк |

| | |
|---|---|
| Характерный тон | характерлы тон |
| Хоренческие слова | хорый сүзләр |

**Ч**

| | |
|---|---|
| Челюсть | теш казнасы (җәек) |
| Челюсть верхняя | өске казна (җәек) |
| Челюсть нижняя | аскы казна (җәек) |
| Чередование звуков | авазлар нәүбәтләшүе |

**Ш**

| | |
|---|---|
| Шум | шавылдау |
| Шумные звуки | шавылдаулы авазлар |
| Шопот | пышылдау |
| Шопотные звуки | пышылдаулы авазлар |
| Щель | ярык |
| Щельные звуки | ярыклы авазлар |

**Я**

| | |
|---|---|
| Язычок | кече тел |
| Ямбические слова | ямб сүзләр |

## Х. БӘДИГЫЙНЕҢ БАСЫЛГАН ХЕЗМӘТЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ

1. Габделбәдигъ Х. Халык әдәбияты. Мәкальләр, табышмаклар. 1 төп. 1 бүлек. Казан: Мәгариф, 1912. 82 б.

2. Бадигов Х. Татарский букварь. Казан, 1913.

3. Габделбәдигъ Х. Халык әдәбияты. Бәетләр. 1 төп, 3 бүлек. Казан: Гасыр, 1913. 75 б.

4. Габделбәдигъ Х. Халык әдәбияты. 1 төп., 1 бүлек. Табышмаклар, такмаклар, такмазалар. 2 басма. Казан: Гасыр, 1919. 66 б.

5. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Ана теле дәресләре. 1 кит. Казан, 1919. 32 б.

6. Корбангалиев М., Бәдигов Х. Ана теле сарыфы. Икенче баскыч мәкт. 1 елында укыту өчен. 2 басма. Казан: Корылтай, 1919. 90 б.

7. Корбангалиев М., Бәдигов Х. Ана теле нәхүе. 2 уку елы өчен. 1 бас. Казан: Корылтай, 1919. 91 б.

8. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Дөнья. 3 кис. 1 сыйн. өчен. 2 басма. Казан, 1919.

9. Корбангалиев М., Габделбәдигъ Х. Тыныш билгеләре языла торган урыннар // Ана теле нәхүе. Казан: Милләт, 1919. Б. 84–92.

10. Бәдигъ Х. К. Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлында хезмәтләре // Насыйри Каюм (Вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте белән чыга). Казан: ТССҖ дәүләт нәшр., 1922. 160 б.

11. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Крестьян әлифбасы. Зурлар өчен. Казан, 1923. 59 б.

12. Корбангалиев М., Шәрәф. Г., Бәдигъ Х. Татар теле дәреслеге. Рус мәкт. өчен. Казан: Татар. матбугат-нәшр. комбинаты, 1923.

13. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Укый-яза белмәүчелекне бетерү мәктәпләрендә укытучылар өчен кулланма. М., 1924.

14. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Татар теле дәреслеге. Рус мәкт. өчен. 1 кит. 2 басма. Казан: Татар. матбугат-нәшр. комбинаты, 1925. 162 б.

15. Бәдигъ Х. Халык әдәбияты. Мәкальләр, табышмаклар. 1 төп. 1 бүлек. Казан: Татиздат, 1926. 76 б.

16. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Татар теле дәреслеге. Рус мәкт. өчен. 1 кит. 3 басма. Казан, Татар. матбугат-нәшр. комбинаты, 1926. 162 б.

17. Бәдигый Х. Бер табак кәгазь. А. Бәхтияровтан. Казан: Татиздат, 1926. 32 б.

18. Бәдигъ Х. Морфология элементлары, сүз төркемнәре турында // Беренче тел-әдәбият конференциясе материаллары (15-22-VI. 1927, Казан). Казань: Изд-во Дома Тат. культуры, 1927. С. 142–146.

19. Бәдигъ Х. Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан: Мәгариф, 1928. № 1. Б. 75-84; № 3. Б. 60–65; № 4. С. 63–68.

20. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Шәкли нигездә гамәли тел сабаклары. 3 кит. 4 бас. Казан, Татар. дәүләт нәшр., 1928.

21. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Шәкли нигездә гамәли тел сабаклары. 2 кит. 4 бас. Казан, 1929.

22. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Гамәли тел сабаклары. Беренче баскыч мәктәпләрнең беренче уку елы өчен. Казан, 1929.

23. Табигатьтән эш китабы. 3 уку елы өчен төп эш китабы / төз.: Кәримов Х., Нигъмәтуллин Ш., Бәдигъ Х. 1930. 260 б.

24. Бәдигый Х. Татар әдәби теленең барышы // Безнең юл, 1930. №2. С. 34–40.

25. Бәдигый Х. Татар әдәби теленең барышы // Безнең юл, 1930. № 3–4. С. 38–41.

26. Фазлулла М., Бәдигъ Х., Корбангалиев М. Колхоз яшьләре мәктәпләренең 1 (V) уку елы өчен грамматикадан эш китабы. Казан: Татиздат, 1931. 88 б.

27. Тел күнегүләреннән эш китабы. Төзәт. 2 басма. 1931. 141 б.

28. Бәдигъ Х. Татар теле грамматикасы дәреслеге. Казан: Татиздат, 1931. 37 б.

29. Бәдигъ Х., Нигъмәтуллин Ш. Телдән эш китабы. 4 уку елы өчен. Казан: Татиздат, 1932. 110 б.

30. Бәдигъ Х. 15 ел эчендә татар әдәби теле // Яңалиф, 1932. № 9–10. С. 84–94.

31. Бәдигов Х. Грамматика. 1 кис. Морфология. Урта мәктәп өчен дәреслек. 5 уку елы. Казан: Татгосиздат, 1933. 144 б.

32. Корбангалиев М., Бәдигов Х. Әлифба. Казан, Татгосиздат, 1933. 64 б.

33. Корбангалиев М., Бәдигов Х. Әлифба. Казан, Татгосиздат, 1934. 64 б.

34. Бәдигов Х., Нигъмәтуллин Ш. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен: Грамматика һәм дөрес язу. 2 кис. 3–4 нче класслар өчен. 1 нче басма. Казан: Татгосиздат, 1934. 100 б.

35. Бәдигов Х. Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. Яңа басма. Казан, 1934. 98 б.

36. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Башлангыч мәктәпләр әлифбасына карата методик күрсәтмәләр. Казан, Татгосиздат, 1934. 22 б.

37. Бәдигов Х. Әлифба. Шәһәр һәм авыллардагы грамота мәктәпләре өчен. 2 басма. Казан: Татгосиздат, 1934. 70 б.

38. Бәдигов Х. Әлифба. Шәһәр һәм авыллардагы грамота мәктәпләре өчен. 3 басма. Казан: Татгосиздат, 1935. 72 б.

39. Бәдигов Х., Атнагулов С., Нигъмәтуллин Ш. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен: Грамматика һәм дөрес язу. 2 кис. 3–4 нче класслар өчен. 3 нче басма. Казан: Татгосиздат, 1935. 99 б.

40. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Башлангыч мәктәпләр әлифбасына карата методик күрсәтмәләр. 3 бас. Казан: Татгосиздат, 1935. 154 б.

41. Бәдигов Х. Грамматика. 1 кисәк. Морфология. Тулы булмаган урта мәктәп өчен дәреслек. 5 класс. Төзәт. 3 басма. Казан: Татгосиздат, 1935. 154 б.

42. Корбангалиев М., Бәдигов Х. Әлифба. Казан: Татгосиздат, 1935. 64 б.

43. Бәдигов Х. Әлифба. Грамота мәктәпләре өчен. 4 бас. Казан: Татгосиздат, 1936. 72 б.

44. Корбангалиев М., Бәдигов Х. Әлифба. Казан, Татгосиздат, 1936. 66 б.

45. Бәдигов Х. Грамматика. 1 кис. Морфология. 5 кл. өчен. 3 бас. Казан: Татиздат, 1936. 152 б.

46. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Башлангыч мәктәпләр әлифбасына карата методик күрсәтмәләр. Казан: Татгосиздат, 1936. 152 б.

47. Бәдигов Х. Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. Төзәт. 3 басма. Казан: Татгосиздат, 1936. 110 б.

48. Бәдигов Х., Нигъмәтуллин Ш. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен: Грамматика һәм дөрес язу. 2 кис. 3–4 нче класслар өчен. 4 нче басма. Казан: Татгосиздат, 1936. 99 б.

49. Бәдигов Х., Нигъмәтуллин Ш. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен: Грамматика һәм дөрес язу. 2 кис. 3–4 нче класслар өчен. 4 нче басма. Казан: Татгосиздат, 1936. 99 б.

50. Бәдигов Х. Әлифба. Укый-яза белмәүчеләр мәктәпләре өчен. 5 басма. Казан: Татгосиздат. 1936. 71 б.

51. Бәдигов Х. Әлифба. Шәһәр һәм авыллардагы грамота мәктәпләре өчен. 4 басма. Казан: Татгосиздат, 1936. 72 б.

52. Бәдигый Х. Кайбер тел проблемалары турында // Мәгариф. 1936. № 5, 6, 7.

53. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Әлифба. Казан, Татгосиздат, 1937. 88 б.

54. Бәдигов Х. Әлифба. Укый-яза белмәүчеләр мәктәпләре өчен. Яңа басмасы. Казан: Татгосиздат. 1937. 86 б.

55. Бәдигов Х. Дөрес язу күнегүләре. Башлангыч мәктәпләрнең 3 классы өчен. 2 кис. Казан: Татгосиздат, 1937. 62 б.

56. Бәдигов Х., Нигъмәтуллин Ш. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен: Грамматика һәм дөрес язу. 2 кис. 3–4 нче класслар өчен. Казан: Татгосиздат, 1937. 104 б.

57. Бәдигов Х. Грамматика. 1 кис. Морфология. 5–6 кл. өчен. Яңа басма. Казан: Татиздат, 1938. 120 б.

58. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Башлангыч мәктәпләр әлифбасына карата методик күрсәтмәләр. Казан: Татгосиздат, 1938. 119 б.

59. Бәдигов Х. Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. Яңа басма. Казан, 1938. 119 б.

60. Бәдигов Х. Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. Яңа басма. Казан: Татгосиздат, 1939. 119 б.

ЭЧТӘЛЕК

*Миңнуллин К. М.* Күпкырлы талант иясе *(Кереш)* . . . . . . . . 3

*Зәкиев М. З.* Татар тел гыйлеме үсешендә Хуҗа Бәдигый . . . . 7

*Кадирова Д. М., Кадирова Э. Х.* Ученый-филолог и педагог Худжа Бадигый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19

**Хуҗа Бәдигыйнең хезмәтләре**

*Бадигов Х.* Вопросы алфавита и орфографии (по поводу доклада т. Алпарова) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25

*Бәдигый Х.* Әлифба һәм орфография мәсьәләләре (иптәш Алпаров доклады уңае белән) . . . . . . . . . . . . . . 31

*Бәдигый Х., Яфаров Б.* Татарларда гарәп әлифбасы . . . . . . . 38

*Бәдигый Х.* Татар теленең шәкли грамматикасы нигезләре . . . 66

*Бәдигый Х.* Шәкли нигездә татар грамматикасы (Г. Алпаров китабының төзәтелгән 2 нче басмасы чыгу уңае белән). . . . 76

*Бадигов Х.* Склонение в турецких диалектах. . . . . . . . . . . 101

*Бадигов Х.* Основы синтаксиса татарского языка (Опыт изучения синтаксиса татарского языка с формальной точки зрения) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

*Бәдигый Х.* 15 ел эчендә татар әдәби теле . . . . . . . . . . . 127

*Бәдигый Х.* Татар әдәби теленең барышы. . . . . . . . . . . . 148

*Badigi Kh.*Türkisch Wörter im Deutschen. . . . . . . . . . . . . 179

*Бәдигый Х.* 1935 елгы тел экспедициясе материаллары йомгаклары буенча хәзерге татар әдәби һәм сөйләм теленең лексик-семантик яктан үсеш тенденциясе (башлангыч йомгаклар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189

*Бадигов Х.* Термины по фонетике . . . . . . . . . . . . . . . . . 234

Х. Бәдигыйнең басылган хезмәтләре исемлеге. . . . . . . . . 247

Научное издание

**ХУДЖА БАДИГЫЙ – ЯЗЫКОВЕД**

Редактор *А. А. Давлетова*
Компьютерная верстка *Н. Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А. В. Булатова*

Подписано в печать 26.11.2021.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 14,6. Уч-изд. л. 13. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20